Казан утлары

5
МАЙ - 1971

М. Х. СӘЛИМҖАНОВ

КПССның Татарстан өлкә комитетында һәм ТАССР Министрлар Советында

1971 ЕЛ ӨЧЕН ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы, Габдулла Тукай исемендәге Республика премияләре комитетының тәкъдимен карап, 1971 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен бирү турында карар чыгардылар.

Габдулла Тукай исемендәге Республика премияләре

театр сәнгате өлкәсендә — Кәрим Тинчуринның «Американ» һәм «Сүнгән йолдызлар», Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрләрен сәхнәләштергән өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Хәким улы **Сәлимҗановка;**

сынлы сәнгать өлкәсендә — бүгенге көн индустриаль пейзажлар циклы өчен РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, художник Николай Дмитриевич **Кузнецовка** бирелде.

Н. Д. КУЗНЕЦОВ



Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИЖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

5

МАЙ
1971

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Бу санда:

РОМАН, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Н. АРСЛАНОВ. Сагышларым. Каурый калам белән. Күзләр. Әгәр шагыйрь... Далаларым. Тәгәри гомерем арбасы... Пилигрим. Агыйделдә, айлы төндә. Утенеч. Шигырьләр 3

И. ГАЗИ. Табылдык китап. Сарбай — сары эт. Хикәяләр 11

М. ЗАРИПОВ. Җәйге командировкада. Хикәя. . 23

Ә. ХӘКИМОВ. Гомер. Хикәя. 35

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Бүген тормыш танымады мине... Сугыштан кайталмаган егет сүзләре. Ак җептән... Мин күренмәм... Шигырьләр . . . 46

С. РАФИКОВ. Тын елга буенда. Роман 48

ДУСЛАР ҖЫРЫ

В. ЩЕКАЧЕВ. Мостафа авылында. Шагыйрьнең сөеклесе. Шигырьләр 85

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

С. ШАКИР. Даладагы совхозда... 86

ЯЗУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Ш. МАННУР. һаман да истә 91

Г. АФЗАЛГА 50 ЯШЬ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Халыкчан шагыйрь 114

Г. АФЗАЛ. Җирем. Болыннарда билдән үлән... Иртә генә таңнан... Туган илем... Кеше күңеле... Бөгелмә аэропортында. Мин яшь әле... Юллар сүтәбез... Өченче кызым тугач. Челлә. Тун астында кыюлык. Ияләнгән бөркет. Портрет. Заман белән бәхәс. Шигырьләр 122

ХАЛЫК ИЖАТЫ

Н. ИСӘНБӘТ. Аулак өй 128

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Г. ХАЛИТ. Бездә нәкъле шигырь бармы! . . . 146

ҒАФУР КОЛӘХМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Ә. КӘРИМУЛЛИН. «Яшь гомер» драмасы һәм патша цензурасы 158

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МОСТАФИН. Кеше һәм сугыш 163

Бәләкәй рецензияләр 167

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ. «Сәләтсез» студент . . . 171

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Р. БАТУЛЛИН. Курай уйный бер малай. Әкият . 176

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

З. НУРИ. Коры куык. Китмә, Кыш бабай. Характеристика. Ялгыш юл. Үземне күрдем төштә. Җепсез йомгак. Аяктан екты. Шигырьләр . . 184
К. МОСТАФИН. Эпиграммалар. Пародияләр . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары 189

Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, жаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.* Корректорлары *Р. Сулейманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/II-1971 ел. Басарга кул куелды 6/IV-1971 ел. ПФ 09031. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 17,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81946 экз. Заказ И-63. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

Нури Арсланов

Сагышларым

Күзләремдә нурлар бетеп бара,
Бөтенләйгә сүнәр микән бер?..
Замандашлар шунда һич булмаса
Якын итеп сөйләр микән бер?

Горур булдым мин милләтем белән,
Рухым белән — бәйнәлмиләлче.
Тырыштылар ятлар моны миннән
Читләтергә, кулдан килгәнче.

Тыгыз иде еллар, озын — юллар,
Арылмады түгел, арылды.
Арыганнарга походта юк привал —
Абынсаң да алга барылды...

Халкым: «Хезмәт!» диде,— бастым сафка,
Халкым: «Көрәш!» диде,— мин солдат.
Ил язмышы хәл ителгән чакта
Булалмадым сабыр вә салмак.

Зарлану да түгел, ялвару да —
Ни күрмәде безнең бу башлар!..
Төер булды бугазларда ташлар,
Өстебезгә яуды кургашлар...

Узганнардан, киләчәктән туган
Сагышларым өелә тау сыман,
Шул сагышлар ташса күкрәгемнән
Кин дөньяны кайчак тарсынам...

Бәхет назы мине туган көннән
Тибрәтмәде алтын бишектә:
Үзең риза булсаң язмышыннан
Миңа, халкым, ярый ничек тә.

Язмышлары, ялгышлары белән
Әрни-әрни сөйдем илемне.
Әгәр дә ваз кичсәм илдән-телдән
Син мине үз итәр идеңме?!

Арысланның авызын каерганда
Салсал батыр ничек хис итсә,
Мин дә шулай, нәфрәт кайный канда,
Әгәр сине берәү кимсетсә.

Сугыш аты кебек мин мөлдерәп
Күзләреңә карап яшәдем:
Авыр чакта бергә була Ир, Ат,
Бергә түгә әрнү яшьләрен.

И түгимче яшьләремне мин бер,—
Эчләр бушап кала еласаң.
Тар булса да күкрәк, сулыш киңдер —
Халкың белән бергә суласаң!

Болар васыять түгел, болай гына,
Мирасым юк васыять әйтерлек:
Сагышларны тик сүз унаенда
Булсын димен бер җиңеләйтерлек.

Батырлыгың, яхшы атың белән
Горур улың, мәңге сөенәчәк!
Мин ышанам, шул сыйфатың белән
Каршы алыр сине киләчәк.

Күзләремдә нурлар сүнеп бара,—
Аерылышыр көннәр җитәме?..
Бар иде, дип, бер ваемлы бала,
Халкым мине бер яд итәрме?

Каурый каләм белән

Кешегә хас бөтен ялгышны бәндә
Борынгыдан килә җирдә кабатлап:

Гүя мәңге бирелгәндәй тазалык,
Тараттым җилгә, бер дә булмадым сак.

Кешедәй тәрбия күргәнмени без,
Буталды уйда гел кара белән ак.

Үзем ялган сөйләмәгәч, ни чара,—
Һәр әйткәнгә ышандым, уйладым — хак.

Хәким дә булмадым, түгел юләр дә,
Ләкин кайчакта исереп булдым ахмак...

Хәят юлы — сират кичкән чагымда
Исән калдым авып төшмичә чак-чак.

Шигырь дип алданып язганнарымны
Йомарлап ташладым — чыкканга такмак...

Мәхәббәткә әсир, кол булды күнелем,
Юк, ул читләтмәде, тик... китте таптап.

Бик аз гына бәхет кунса да җанга
Мин алгандай идем тауны кочаклап!

Кеше күңелен күрергә күп кирәкми,
Хәтерне калдыру аннан да ансат...

Җәберләнсәм дә бер хаксызга бик еш,
Яшәдем, белгәнемчә, хакны яклап.

Ир ирлеге түгел салсаллыгында,
Егет — дәрте белән көчле вә парлак.

Иминлектә дә тынгы белмәде җан!
Хыялыйга тыныч көн бармы? Һәйһат!

Шагыйрь мин: «Ай да ай!» дип җирдә калдым,
Ә космонавт менеп шартлатты бармак.

Күчә чынга хыяллар бер-бер артлы,
Уяу инде акыл да — булмый арбап.

Акыл белән күнел — Сак-Сок, кавышмый,
Качалар бер-берен, таң җитсә, ташлап...

Басармы яхшы як, дип шикләнә жан,
Әгәр кылганнарым бизмәнгә салсак.

Утырмыйммы икән абелхәятка
Суалчансыз салып, мин тиле, кармак?

Берәүләр бик ризалар үз-үзеннән,
Ходаем, шул бәладән калчы саклап!

Вәзенгә иске булса да уй изге,
Язам каурый каләмне юри сайлап..

Күзләр

Зур күзләре аның әллә кайдан,
Караңгыдан, төптән, тирәннән,
Кара кайгы белән томанланып,
Синнән түгел, синең тирәңнән
Нидер эзли.
Тотылган ай төсле
Нуры сүнгән шомлы карашын
Еракларга төбәп
аерган ул
Дөнья белән ике арасын...

Күзләрендә сагыш, газапларның
Мең төрлесе бергә җыелган,
Язмыш аңа кашын җыерган күк,
Ул дөньяга кашын җыерган...

Кайчагында озын керфекләре
Кара хәнҗәр булып жаныңа
Чәнчә кебек.
Тетрәп китә рухың,
Йөрәгеңә сагыш сарыла...
Ниндидер көч аның тынычлыгын
Тартып алган, биргән борчулар...

Кинәт болар бары да үтәр төсле,—
Бу халәтне яшен бер сугар —
Ачылып китәр төсле акылы аның.
Элеккедәй матур, ягымлы
Бер елмаер төсле тирә-якка.

Күрсәм, сенелем, шундый чагыңны
Шатлыгымнан мин тез чүгәр идем
Серле көчнең бөек гаршенә!

Үзгәреш юк ләкин...
Һәйкәл сыман
Сының гына тора каршыда...

Бер карасаң шундый ансаттыр күк —
Тик бер генә әфсүн өрәсе!..
Кояш булып болыт асларыннан
Чыгуыңны килә күрәсе.

●

Әгәр шагыйрь телгә бай булса —
Фикерләүгә юмарт, сүзгә саран.
Фикереңә тирән, сүзең «сай»
булса...
Исеңдә тот, алай да бит яман.

Күп сөйләүчән була аз белгән,—
Акылы кыскаларның теле озын,
Күпне белгән — тыйнак ул телгә,
Хөрмәт итә сүзен, сине, үзен.

Далаларым

Иркен жәйләү. Кузы, лакълар[1] тавышы,
Төтен, кымыз исе авылда...
Каркаралның биек тауларыннан
Мин атылдым тормыш давына

Жиң сызганган яшь бәхәскәр булып.
Шуннан бирле һаман иярдә.
Алып очты мине язмыш аты
Һәм өйрәтте ирек сөяргә.

Шуннан бирле менә бәйгеләргә,
Көрәшләргә мин бил багладым.

[1] Лакъ — кәҗә бәтие.

Батыр егетләрнең арасында
Һич булмады сафтан калганым.

«Кыз-Жефәк»не, «...Баян-Сылу»[1]ларны
Тыңлап үстем киез өйләрдә.
Гажәп гади казакъ акыннары
Шундый оста иде сөйләргә:

Төннәр буе, учак яннарында,
Менәр юллык поэмаларны
Йокыларым онытып тыңлый идем.
Мин хәтерлим әле дә аларны.

Әкиятләргә юмарт булганга дыр
Яраттым шул казакъ телен мин,
Чичән жырчыларга сокланганга
Ул бай телнең оттым серен мин.

Шигырь өчен генә яшәр тел ул —
Жәмлә саен мәкаль, әйтемнәр...
Акын белән гади дала кешесен
Аера алыр икән, я, кемнәр?!

Әткәм-әнкәм теле әкият сөйләп
Күзләремне ачса бишектән,
Мин идем ул соңра гажәп ипле,
Тапкыр дала телен ишеткән.

«Кара тургай», «Ике жирән»нәрне,
«Сырымбәт»не жырлап үстем мин...
Казакъ иле, шифа кымызың белән
Шигъриятнең серен эчтем мин.

Далаларда конаннарга[2] менеп,
Жилгә каршы жилеп-чапканда
Мин белмидер идем киләчәктә
Менәчәкне иминди атларга.

Безнең атлар чыдам булсалар да,
Авыр булды узар үзәннәр,—
Озатканнан бирле далалардан
Өкеләрен[3] таккан гүзәлләр...

Әй, кайда сез, жилләр белән ярышып,
Камгак куып йөргән «батырлар»,
Айлы төндә «Алты — Бакан»[4] атынып,
Гыйшык тотып йөргән матурлар?!

---

[1] «Кыз-Жефәк», «Кузы-Күрпәш белән Баян-Сылу» — казакъ фольклорының үлмәс поэмалары.

[2] Конан — өч яшьлек ат.

[3] Өке — кама бүреккә тагылган ябалак каурыйлары — кызлар баш киеме — гыйффәт билгесе.

[4] «Алты — Бакан» — таган — казакъ халык уены — яшьләрнең мәхәббәт бишеге.

Тылсымнарын җырның өйрәнгәндә
Тукай да бар иде, Абай да.
Үтте гомер җырга юлдаш булып,
Инде калдым Нури бабайга...

Ләкин миңа илһам аты биргән
Далаларым искә төшкәндә
Мин әйләнәм кабат бузбалага[1] —
Җан яшәрә, күңел нечкәрә...

Татарстан — туган анам, күрче,
Балаң күңеле һаман далада,
Далаларын онытылмаган өчен
Үпкәләмә дәрвиш баланга.

●

Тәгәри гомерем арбасы
Түбәнгә — үзәннәргә,
Илтифат итми заманча
Яшәргән, үзгәргәнгә.

Кычкырып карыйм: «Тукта!» дип,
Ә вакыт каулый бирә,—
Тәгәри арба упкынга,—
Һәлакәт җитеп килә...

И кыска гомер — дөньяга
Бер карап алу гына...
Алышыр идем җәннәтен
Дөньяның тәмугына.

Пилигрим

Кайберәүләр минем яшькә җитсә
Икеләнми сайлый «мич башын».
Тели икән, әйдә, сайлый бирсен,
Минем — яшьлек, амур юлдашым.

Азмы җирдә тумый картайганнар?!
Син картайгач бер ту яңадан!
Мин олыгайган саен хәят телим,
Мин яшәгән саен яңарам.

Табигатьнең иркен кочагында
Рәхәтләнгән җанвар сыман мин.
Хыял һәм дәрт дигән йөкләр артып
Һәр көн саен юлга чыгам мин.

Читлектәге арысландай күңелем
Арлы-бирле килә — талпына:
Мин һаман да юлда, гүя бәхет
Һаман көтә таулар артында.

[1] Бузбала — яшь, буйдак егет.

Сугыш бетүен, Идел дингезләрен,
Айга кеше менүен теләдем...
Кабул булды бары да.
Күрелмәгән
Кинлекләргә инде төбәлдем.

Туар көнне шуңа көтеп алам,
Яналыклар алып килер, дим.
Һәр таң саен шуңа юлга чыгам —
Мин тумыштан бирле пилигрим.

Без бишектән кабергәчә юлда —
Күпме сират күпере үтәсе...
Юл газабы гүр газабы түгел,
Һаман килә гомер итәсе.

Агыйделдә, айлы төндә

Палуба тын. Ярда агачларга
Кача-поса тулган ай чаба,
Кайчак балкый чыгып тар аланга —
Толымнары суда чайкала.

Сердәш итә аны һәрбер гашыйк,
Моңдаш итә һәрбер сагышлы.
«Сагынганда айга кара...» диеп,
Аерылганнар күпме кавышты...

Ай — тылсымлы гажәп бер алиһә!
Тик кемнәр соң әфсүн өрделәр? —
Аның серен ачып, космонавтлар
Туфрагына басып йөрделәр.

Илаһи дип тапкан һәр нәрсәне
Фән чыгара бара гадигә.
Булдырала икән — аның эше!
Бу хакыйкать миңа соң нигә?!

Ай шаян да миңа, сагышлы да,
Бер назлый, бер өзә бәгырьне...
Бушлыктагы жисем булып түгел,
Ай миңа ай булып кадерле!

Фирдәүсидән, Низамидан алып
Мәхтүмколыйларга, Тукайга
Кадәр булган заманнардан бирле
Табынмаган шагыйрь юк айга!

Үтенеч

Үзең коткар бәла һәм афәттән,
Ярдәмчем бул, ниләр күрсәм дә,
Тик коткара күрмә мәхәббәттән,
Учагында көлгә дүнсәм дә.

Озак яшим инде, күп булгандыр
Гөнаһлар да, үзең ярлыка.
Тик мәхәббәт гөнаһларын калдыр:
Мин бәхетле алар барлыкка.

Яман телдән, яман күздән сакла!
Сөю хисең сайрат, телен ач!
Һич рәнжемәм гыйш вә гашрәт хакына
Калсам да ач һәм... шыр ялангач.

Шигең булса, Венерадан сораш,
Синнән-миннән күбрәк белә ул:
Мәхәббәткә әсир һәр газиз баш!
Шуңа бездән көлә генә ул:

Җибрил вәхи — илһам китерә диеп
Көтсәм синнән зарыгып кич-иртә,—
Амурлары аның килә биеп:
Уйный-көлә, сөйдерә, исертә...

Син үзең дә тәхетең — биек күктән
Алиһәне күрсәң, мөгаен
Гашыйк булыр идең һәм мөкиббән
Китәр идең бугай, ходаем!..

Бу дөньяда тынгы белмәгән жан
Тегесендә, белмим, тынармы!
Кисәтеп куй әле үзең алдан
Кабер ташы язучыларны,—

Ташка жамлы амур ясасыннар,
Жамда шәраб — шатлык яшьләре...
«Тыныч йокла...» түгел, ә язсыннар:
— Ул,— дип,— туды, сөйде — яшәде.

1970

Ибраһим Гази

ТАБЫЛДЫК КИТАП

ХИКӘЯ

Кояшта янып-янып та, янып бетә алмаган уникә яшәр Илдус пионер лагерена килеп күп тә тормады, ат чыгарды. Юк, әлбәттә, юк! Ул ат чыгарам дигән уй белән килмәгән иде. Чыгасы ат, күрәсе газап кебек, синең теләү-теләмәвенә карамый икән. Берәүләр бик тырышып багалар да чыгара алмыйлар, ә икенчеләр, мәсәлән, шул ук Илдус, бака кабырчыгы төсле ак колак яфраклары гына кояшта пешмичә калган кап-кара маңгайлы, сап-сары чәчле малай, бер дә теләмәсә дә, чыгарды.

Сабыр, сабыр! Чыгарды дигәч тә, сез аны хезмәт куймыйча бик ансат чыгарган икән дип ялгышмагыз. Баштарак Илдусыбыз, бүтән малайлар кебек үк, атсыз гына йөреп торды, ләкин менә бер көн килде... Юк, көн килмәде, кич килде, төн килде, аннары кояшлы җәйге иртә килде, шуннан соң гына...

...Иртәнге чәйдән соң Илдус лагерь ишек алдына йөгереп чыкты. Аның күңелендә нинди дә булса ачык бер ният юк иде. Йөгереп чыкты, чөнки тамак тук, күңел көр, җәйге кояш агач башыннан бик ягымлы карый, аякларның йөгерәсе һәм сикерәсе килеп кенә тора, шундый чакта ник йөгермәскә, ник сикермәскә...

Ялт алай карады, ялт болай карады. Спорт мәйданында бер кызчык таган атынып маташа икән, Илдусны аяклары шул якка таба чаптырып алып китте.

Үзегез уйлап карагыз, кызлар атынсын, имеш тә, Илдус атынмасын, имеш. Кызчыкларны ул пыранлатып куып төшерде дә таганга үзе менеп утырды, аякларын сузып-сузып атына да башлады. Кызлар, кашларын жимереп, маңгай астыннан бу пырдымсыз малайга яратмыйча карап тордылар.

Атына торгач, аяклары белән «күкне тишәр» чак житкәндә генә, ни күрсен, вожатыйлары Сара апа йөгерә-йөгерә бу якка килә. Кызлар басып карап торганда, малай кешегә атыну бөтенләй дә килешми бит

инде.— Илдус сикереп таганнан төште: «Ник авызларыгызны турсайттыгыз, утырышыгыз!» дип, сыңар кулын матур гына җәеп җибәреп, кызларны таганга чакырды.

Көтмәгәндә кызлар үзара эләгешеп киттеләр: берсе әйтә — минем чират! Икенчесе — минем чират! Эш чәч йолкышуга уҳ барып җитмәде, шулай да чеметешеп, тырнашып алырга өлгерделәр. Илдус тегеләрне оялтырга тотынды: пионерларга, бигрәк тә кызларга, бигрәк тә шундый матур кояшлы көнне сугышу... Ай-яй-яй! Утырышыгыз, чәрелдекләр, саесканнар! Утырышыгыз, дим, абыегыз атындырам дип торганда...

Кызлар боргалансалар боргаландылар, тик икесе берьюлы таганга менеп утырдылар. Илдус аларны чөеп-чөеп, кычкырта-кычкырта атындыра башлады.

Сара апалары килеп җитте.

— Син ни атлы? Илдус? Илдус, син молодец,— диде ул кызарынган малайга.— Ә сез, кызлар! — Сара апалары имән бармагын күтәрде.— Белеп торыгыз: чеметешү не оригинально! — Шулай диде дә баш өстенә печән чүмәләседәй өеп куйган, кызыл буяуга буялган матур чәчен тирбәлдереп, балалар яныннан җәһәт узып китте.

Шулай итеп, Илдусыбыз уйламаганда-нитмәгәндә «молодец» булды да куйды.

Юк әле, юк! Бер тапкыр әйтелгән «молодец» белән генә, гәрчә бу сүз ике саескан, ике сүз бистәсе алдында әйтелсә дә, Илдус кеше теленә кермәде, тик шулай да ат чыгару шушы «молодец»тан башланып китте.

Сара апалары кемне мактый — Илдусны мактый, Илдус, янәсе, кызларга әнә нинди ягымлы, үзе яши торган брезент палатканы әнә нинди чиста тота. Сара апалары кемне тирги — Илдусны тирги, шундый яхшы малай лагерь ашханәсе каршындагы карт өянкенең очына ук менгән дә, язгы кара карга кебек тирбәлеп: «Әһә, менә алмыйсызмы? Әһә! Әтә-тә-тә!» дип, агач астындагы малайларны үчекләгән. Аның үчегеннән котырып китеп, таяк кебек нечкә, чандыр, ябык бер малай,— исеме Дамир, кушаматы белән әйтсәк, До-ре-ми: — «Менә алмыймммы? Менә алмыймммы?» дип аста сикеренгәләп торган да маймыл җитезлеге белән менгән дә киткән. Аңардан күрә бүтән малайлар менгәннәр.

Әлбәттә инде, Сара апалары боларны орышты: — «Беренчедән, агачка менү не оригинально, икенчедән, егылып төшеп имгәнсәгез, әти-әниләрегезгә ни дип җавап бирермен?..» — дип үгетләде. Бу үгет-нәсихәтнең күңелле нәтиҗәсе шул булды, малайлар Сара апаларына «не оригинальный апа» дигән кушамат тактылар. Сара апалары бу хакта белми әле, белсә, «кушамат бирү не оригинально» дип, үзләрен шелтәләр иде.

Юк, ат чыгару өчен бу вакыйга да әле җитеп бетмәде. Дөрес, Илдусны белмәгән бала, белмәгән тәрбияче инде калмады. Берни булса: «Ә, теге өянке башына менгән сары чәчле малаймы? Бишенче палаткада тора, беләбез», диләр.

Су чокырга җыелган кебек, Бишенчегә шундыйраклар җыелды. Доре-ми дә, таяк малай, ул да бит хәзер Бишенчедә Илдус белән янәшә караватта йоклый. Бүтән малайлар да Бишенчегә бик кызыгалар, тик анда эләгү өчен хәзер инде сугышкан кызларны аеру яки өянке башына менеп, Сара ападан әр ишетү генә җитми. Ниндидер тагын да хәтәррәк эшләр эшләргә кирәк, ә каян табарга ул хәтәр эшләрне? Хәтәр эш бит аяк астында аунап ятмый.

Ә менә Илдус тапты. Тапты бит Илдус, ташбаш! Бәхетленең юлына чыгарып куярмын дип әйткән ди шул.

Түгәрәк күлдә су коенган чакта булды бу хәл. Сез инде уйлый башладыгыз. Әһә, дисез. Күлдә бер малай актыгымы, кыз актыгымы күбекләр очыра-очыра су төбенә китә башлаган икән дә, мактаулы Илдус, бөтен каушап калган халыкның күз алдында, шул бәхетсезне тартып чыгарган, дисез.

Сезнең зирәклеккә минем исем китә. Белдегез. Валлаһи әгәр белдегез! Теге ике саесканның, ике бәйләнчекнең берсе (кайсы икәнен үзем дә белмим, икенең берсе инде) Түгәрәк күлдә бата язды бит.

Бу күлдә батучылар элек тә булды, коткаручылар да булды. Заманында мин үзем дә күзләре акайган бер малайны судан тартып чыгарган идем. Тик бүген сүз минем хакта түгел, ташбаш Илдус хакында...

Түгәрәк күлнең мондагы бүтән күлләрдән аермасы шул: аның өстендә утрау бар. Ялгышмагыз, ул теге үрдәкләр, казлар симерә торган гади бер утрау гына түгел, серле утрау. Катырак җил иссә, урныннан куба да үзенең нәзек ак каеннары белән, мүк җиләкләре, кош оялары, саз чәчәкләре, туз башлы еланнары белән бергә күл өстендә йөзеп йөри башлый. Ә җил юкта... җил юкта ярга барып сыена да әлеге шул матур ак каеннары, кошлары, җиләкләре, чәчәкләре, иксез-чиксез озынборыннары белән ял итеп тик тора.

Бу йөзмә утрауны камышлар, үрелеп беткән агач тамырлары шундый нык кысып, җыеп тоталар, бер малай түгел, йөз малай тупырдап барып керсә дә, сыгылса шул бераз сыгылыр, инсә бераз иңәр, каеннары чайкалса чайкалыр, кошлары очып китсә китәр, тик малайлар авырлыгыннан, бигрәк тә инде күбәләктәй жиңел кызлар авырлыгыннан утрау ярдан кузгалып китмәс.

Утрауның тагын бер хикмәтле ягы, юк, хикмәтле генә түгел, бу юлы инде куркыныч, хәтәр ягы шул: аның яшеренеп кенә карап тора торган күзләре бар. Түгәрәк, салкын, куркыныч күзләре... Бу күзләрне мин, сез рөхсәт итсәгез, бәкеләр дип атар идем. Гәрчә беләм, бәке бозда гына була, шулай да, сезнең рөхсәтегез белән бәке дип, яисә хәтта упкын дип атар идем. Абайламыйчарак килеп, шул упкынга китереп бассаңмы? Беттем диген! Ә алданып басып куюың бик ихтимал, чөнки, беләсең килсә, аның өстендә сабаклары бишәр метр су астына киткән төнбоек чәчәкләре, әллә нинди, яшел дисәң, яшел түгел, сары-зәңгәр төстәге саз үләннәре үсәләр. Чәчәк өзәм дип китереп бастыңмы, күл төбе синеке!

Илдус,— ташбаш түгел диген син аны,— шушы упкынга чума да, утрау астыннан йөзеп барып, күлгә килә дә чыга. Бик күп малайлар, аныңча кыланмакчы булып, утрауның шомлы салкын күзләренә карап-карап торалар да чумарга берсенең дә йөрәге житми...

Вожатый Сара апалары, шул теге апа инде, чүмәлә чәчле матур апа, хода белсен — ничек курыкмагандыр, шушы еланлы, озынборынлы, бакалы утрауга кереп: «Хәзер үк чыгып китегез! Юкса мин ташлап кайтып китәм!» дип куркытып, суга батуның оригинальный булмавын әйтеп (чөнки моңа хәтле дә кешеләр батканнар, моннан соң да, аллаһ боерса, батарлар): «Сез башсызлар өчен мин башым белән (чәчем белән дисәң!) жавап бирәсем килеп тормый әле!» дия-дия ялынып, даем-даем утраудан куып, әрләп торган бер заманда, ничек итеп шул акай күз упкынга чумарга кирәк!

Ә бит Илдус чума, ә бит До-ре-ми дә чумды! Янәсе, беткән баш беткән, кай төшем белән Илдустан ким! Әллә ни кадәр кызлар, әллә ни кадәр малайлар, хәтта Сара апа үзе дә, тын алырга да куркып, Дамирның башы күлдән чупылт итеп килеп чыкканны көтеп тордылар. Чыкты бит Дамирның тәвәккәл башы. Чыгуы булды — малайның авызы ерылып китүе булды, ерык авызга күл суы барып керүе булды. Сара апа булып Сара апа, үзенең вожатыйлыгын онытып, кулларын чәбәкләп: «Молодец малай икәнсең!» дип кычкырды.

Син шуны әйт, кызлар арасында да башсыз башлар бар икән. Теге ике саесканның берсе, иң тилесе, иң тинтәге, чәченә кызыл чүпрәк такканы, төнбоеклы упкын каршына килеп басты да: «Әллә мин чума алмас дип беләсезме?» дип, күз карашлары белән ике «молодец» малайны чәнечте дә,— юләр түгел диген син, кыйнап ыргытырга янында әнкәсе юк,— кулларын баш очында очландырып, упкынга тотты да ташланды.

Илдус аны шаяра дип тора, кулларыннан тотып калырга да өлгермәде, Сара апалары да абайламыйчарак калды бугай, югыйсә ул чумарга ирек бирер идеме соң! Чумды кызый, аяк табаннары гына ялтырап күренеп калды.

Күпме малай, күпме кыз — барсы да дүрт күз белән күл өстенә карап торалар: менә-менә теге тиленең кызыл чүпрәк таккан башы су астыннан килеп чыгар, шатлыгыннан кызның авызы ерылыр, ерык авызына су кереп тулар...

Ә кыз юк! Юк бит кыз! Илдус ике күзен тутырып суга карап көтеп тора. Сара апагыз чәчләренә үк ябышты. Күлнең аргы ягында кояшта кызынып ятучы кешеләр утрауга таба йөгерешә башладылар. Юк кына бит кыз!

Илдус тәвәккәлләде дә баш кадала упкынга чумды. Аның артыннан ук, ярдан ташланган бака шикелле, Дамир да чумды. Ап-пак төнбоек чәчәкләре беравык чайкалып тордылар да яңадан үз урыннарына бастылар. Сара апа, йодрыгын тешләп, нидер пышылдый иде.

Бөтен утрау, барлык каеннар, барлык дерелдәвек усаклар көтә... Кошлар көтә... Сары сәрмә тарткан тузбаш еланга хәтле, мүк үләне арасыннан башын сузып, бу өч тиленең чыкканын көтеп тора...

Су астыннан кинәт бер баш күренде. Юк, бу кызлар башы түгел, бу Дамир башы. Кешеләрнең сораулы, зарыгулы күз карашларына җавап итеп, ул бары: «Юк», дип кенә әйтә алды.

— Тиле кыз анда юк...

Ничек инде юк? Кая китсен ул? Олылар да суга сикерешә башладылар. Тизрәк, тизрәк! Яшь кенә башы белән билдән сакал җиткергән бер егет, борынын кысып, күл төбенә чумды. Аңа иярә бүтәннәр, һава йотып, суга чумдылар. Ә кыз табылмый. Ә кыз юк, кызны эзли чумган Илдус та юк.

...Башта су өстенә йодрык-йодрык күбекләр калыкты, аннары... Аннары бөтен күл буе, бөтен утрау, бөтен җан иясе кычкырып җибәрде. Саз үләннәренә чорналган Илдус, кызны чәчләреннән эләктереп, утрау астыннан килеп чыкты бит! Сакаллы һәм сакалсыз абыйлар, аларның икесен дә су өстендә тотып алып, утрауга өстерәп чыгарып салдылар.

Илдус тәмам хәлдән тайган: аягына баса алмыйча, яшел үлән өстенә егылды. Сара апалары кабаланып телефонга чапты. Кызның иреннәре күгәргән, чәчләре битенә сыланган... Тиз генә ясалма сулыш алдыра башладылар.

Ул көнне ишеткәннәр, ул көнне курыкканнар берәүнең дә исеннән чыкмас. Кызыл тәреле машина килеп, кызны шифаханәгә чаптырып алып китте.

Илдусны җитәкләп кайттылар, сөйләттеләр: кыз су астындагы агач тамырларына эләккән булган, Илдус аны көчкә ычкындырган. И туздырды да соң инде Сара апалары! «Моннан ары мин сезне күлгә жибәрсәмме, коенырга рөхсәт итсәмме, моннан ары мин сезне...»

Үзе елый да, көлә дә (елаган да бер авыз, көлгән дә бер авыз!) Илдусны бер мактый, бер тирги... Илдуска әллә көләргә, әллә еларга... Көлә генә башлый, тагын Сара апасы элеп алып селкеп сала... Еламакчы гына була, янә Сара апасы мактарга керешә... Ярты авызы белән көлеп, ярты сы белән елап, атна буе шатлык белән кайгы арасында йөрде Илдусыбыз...

Ул арада балалар теге саескан яткан шифаханәгә берәм-берәм дә, икәүләп-икәүләп тә, конфет тотып та, чәчәк тотып та, бер нәрсә тотмыйча да гел йөреп кенә тордылар. Тиле кыз, әйбәтләп суктырыр кешесе юк кыз, бер көнне, чәчендәге кызыл чүпрәген жилфердәтеп, лагерьга кире кайтты да керде. Ә тагын бер-ике көннән инде яңадан таган атына башлады.

Менә кайчан Илдусның аты чыкты! Менә кайчан ул данга кинәнде! Сабан туенда аягын сагызлап багана башына менүче малай кебек, дан агачының иң очына, иң югары ноктасына, чыпчык килеп кунса, чыпчыкка да чыдамаслык нечкә ботагына менеп житте. Хәзер аның исемен лагерьда гына түгел, бөтен Казан каласында беләләр. Костер бәйрәмендә: «Без ничек коткардык», дигән истәлек сөйләттеләр. Малайны күрше пионер лагереннан чакыра килделәр. Анда сөйләгәндә Илдус инде: «Мин ничек коткардым» дип, шактый үзгәртеп сөйләде. Малай үзе дә күзгә күренеп үзгәрә башлады. Хәзер ул (ходаем, үзгәрсә дә үзгәрә икән кеше дигәнең!) сөйләгәндә тавышын тамак төбеннән чыгарып сөйләшә. Кичәге иптәшләре хәзер ана «Илдус абый» дип эндәшәләр.

— Илдус абый, сине вожатый апа чакыра.

Илдус саңгырау, Илдус чукрак... «Зәңгәр алан» лагерена истәлек белән барасы бар: хәзерләнеп утыра, вакыты юк...

Тик бер Дамир гына Илдус алдында баш имәде. Күзе бар, күрәдер. Дамир аның даныннан көнләшә. «Бәхете шул таш маңгайның», дип уйлый. Түгәрәк күлдә коенырга яңадан рөхсәт бирелгәч («Карагыз аны, батсагыз кайтып керәсе булмагыз!»), Дамир күпме генә күл буен саклап утырмады, һич югында бер йолкыш малай гына батса да ярап торган булыр иде. Дамир аны шундук өстерәп чыгарган булыр иде. Илдус даны хәтле үк зур булмасын, кирәкми, кечкенә генә булсын, тик дан булсын!

Булмады инде, ахры. Калган бер атна эчендә генә булмас та... Бәхете юкның юк инде аның: ни хәтле малай, ни хәтле кыз Түгәрәк күлне аркылыга-буйга гизеп коенып йөри, ник шунда берсе күңел хакы өчен генә батсын... Упкынга чумып та, Дамирны чумдыга санамадылар, чөнки кызны теге ташбаш алып чыкты.

Ләкин хәлиткеч вакыйгалар алда булган икән. Алда булган икән дан казану, дан югалтулар.

Бер дә бер көнне Сара апалары кызлар белән чыштын-пыштын нидер сөйләште дә үз юлы белән матур гына китеп барды. Апалары киткәннән соң кызлар малайлар янына килделәр. Батып-батып та, батып бетә алмаган теге кызчык елмаеп кына, оялып кына Илдуска әйтте:

— Малайларны ярышка чакырабыз.

— Ярышка? Сез безне ярышка?!

— Нинди ярышка? — дип кызыксынды До-ре-ми, ул әле дан казанудан өметен өзеп житкермәгән иде.

— Чәчәк ярышына.

— Курчак ярышына? Илдус, син аңлыйсыңмы, мин, үтер, берни аңламыйм.

— Бичаракайларым,— дип бүлдерде Илдус,— чәчәк ярышы уйнарга бөз бит, шөкер, кызлар түгел.— Илдус ярты авызы белән генә көлде. Бу көлүе белән ул әйтмәкче була: соң мин андый гына эшләр эшләгәнме? Бик ярышасың килсә, син әнә тагы су төбенә кит, мин сине яңадан тартып чыгарырмын, ә чәчәк уены...

— Малайлар курчак ярышы уйнамый, Сара апагызга шулай дип әйтегез,— диде До-ре-ми.

— Чәчәк ярышы,— дип кызчык төзәтеп куйды.

— Әх, чәчәк ярышымыни? — дигән булды Дамир.— Уйлашырбыз, вакыт бирегез.

Кызлар унайсызланып китеп бардылар. Малайларда башланды уйлашу, тартышу, бәхәсләшү. Илдус аяк терәп каршы торды: пустяк! Кызлар уйнасыннар. Дамир катнашу ягын карады (өметсез — бер шайтан!).

...Дан дигән хәерсез нәрсәне мин ярга яккан учакка тиңләр идем: чыбык-чабык салгалап тормасаң, учак сүрелә, сүнә... Аннары дан кагылса, кайберәүләр шашынып китүчән була: аларны инде болай да үтереп мактыйлар, артык мактар җир дә юк кебек, ә тегеләрнең тагын-тагын макталасы килә...

Юк, Илдус, малай кеше, андый зурлар чире белән чирли дип әйтәсем килми, ләкин кем белә бит, кеше күңеле — кара урман, бәлки, аның да ярдагы учакка бер-ике чыбык өстисе килгәндер. Аннары Дамир да бик кыстады.

Ахырда Илдусыбыз сынды, риза булды. Тик үзенең шартын китереп куйды: кая гына алып барсам да, «кая барабыз?» дип сорамаска, кая гына алып керсәм дә, гаҗәпләнмәскә! Малайлар башларын кашып тордылар да күнделәр.

«Кем дә кем үз палаткасын матур итеп чәчәк белән бизәр, шул кешегә бүләк» — ярышның шарты шундый иде.

Кызлар көтүләре белән урманга чәчәк җыярга киттеләр. Малайларның бер төрлесе ылыс сындыра, каен ботакларын туный (гәрчә мәктәптә агачны сындырырга ярамый дип колакларына күп тукылса да, ул бит инде кышлый тукылган, хәзер җәй уртасы — кышкы туку җәйгә ярамый).

Илдус эчтән генә көлеп йөри: өтек фантазияле мескеннәр! Ылыс не оригинально, беләсегез килсә! Урман чәчәге — анысы кызларга, ә без бит, шөкер, ир заты лабаса.

...Көн дә була торган кич бүген дә булды. Көн дә уйный торган бырсы бүген дә уйналды — ятарга, йокларга, матур төшләр күрергә! Илдус үзенең караватына күп итеп нарат күркәсе ташлап, шул күркәләр өстенә йокларга ятты: аларга бик иртә уянырга кирәк иде. До-ре-ми, Илдусны кабатламыйм дип, баш астына мендәр урынына агач яркасы салды.

Әле кояш та күзләрен ертып уянып җитмәгән булгандыр, болар инде сикерешеп тордылар. Утлы күмергә баскан кебек, иртәнге чыкка бармак очлары белән генә баса-баса, караклар кебек, як-якларына карана-карана, лагерьдан чыгып киттеләр дә комлы урман юлыннан йөгерешергә тотындылар. Беркавым йөгергәннән соң, малайларның юлы тау астына таба төшә башлады.

Юл анысы төшәр дә, менәр дә. Малайлар да төшәрләр дә менәрләр — аяклар шәп, сөяк җиңел, башта жил.

Иртә таңнан кая киттеләр соң болар? Кәҗәләр кебек, зыянга йөрмиләрдер ич? Бер чыдамсызы түзмәде:

— Кая юл тоттык? — дип сорап куйды.

— Баргач күрерсең! — булды Илдусның җавабы.

Дамирның баядан бирле эче тырный. Башка малайлар кебек, кая барасын алдан сорамаска, кая гына барып керсә дә гаҗәпләнмәскә сүз биргән булса да, Илдус койрыгы булып йөрүдән хурлана. Ул бит үзе упкынга чумган малай. Дамирның күңелендә забастовка! «Әйтмәсә, артык бер адым атламыйм!»

— Чүпрәли башладыңмыни? Курыксаң, барма! Сине берәү дә кыстамый!

Шундый сүзләрдән соң ничек инде Дамир бармасын. Усаклар арасыннан күл елтырап күренеп калды. Комлы юлдан мышный-мышный атлыйлар.

— Минем эзгә генә басып барыгыз! — дигән приказ булды.

Ул да түгел, икенче бойрык:

— Пластуннарча!

Түгәрәк күлдәге бакалар шикелле, аякларын бер жыерып, бер язып, юеш ком, чыклы үлән өстеннән түшләре белән шуышып киттеләр.

Алда койма, койма эчендә такта йортлар.

— Күрәсезме?

— Нәрсәне?

Илдусны танырлык түгел: сары кашлары жыерылып килгән, күзләре усал, авызында каты сүз.

— Күзләрегезгә кигән чабаталарыгызны салыгыз да койма ярыгыннан карагыз!

Карадылар. Бакчада бихисап чәчәк! Чык тамчылары авырлыгыннан башлары жиргә иелгән ал һәм ак пион чәчәкләреме дисең, ялкын төсле, бөтен бакчага үзенә бер ямь биреп, кызыл нур сибеп тора торган күпьеллык мәк чәчәкләреме, сабакларын көянтә шикелле сузып, шул матур көянтәгә берәм-берәм ал-кызыл чәчәкләр тезеп куйган «жәрәхәтле йөрәк» исемле чәчәкме, жирән күзләре белән дөньяга акаеп, әрсез итеп карап торучы сары лалә чәчәкләреме, исемнәре Илдус белән Дамирга билгесез булган әллә нинди зәңгәр башаклы, ал кыңгыраулы, ак чуклы, кызгылт чулпылы чәчәкләрме дисең... Бихисап!

— Бу бит караклык була! — диде Дамир, тавышы калтырап китте.

— Булмый! — дип кисте Илдус, ул ни арададыр шулай кисеп сөйләшергә өйрәнеп алды.— Булмый караклык! Болар, бик беләсең килсә, частник! Ә без халык өчен тырышып йөрибез. Лагерь өчен! Ягез, кем кыю, кем куркак? До-ре-ми чүпрәләде, ул керми.

— Минме чүпрә? — дип, Дамир чәчрәп куйды.

— Ә ник агардың? Кулларың калтырый.

Дамир үрмәләп килә-килә юеш комга буялып беткән кулларына карап алды.

— Кул калтырамый, ә менә монда... (ул комга буялган түшенә төртеп күрсәтте). Намус...

— Аңлашылды, чүпрә,— Илдуснын тавышы боз, чырае кырыс,— бүтән малайларга борылды — частниклар уянганчы әйдәгез!

Койма тактасын этеп бакчага керделәр. Дөньясына кул селтәп, Дамир да койма ярыгына чумды.

Их, пәкеләре палаткада онытылып калган. Чәчәкләрне сындырырга, йолкырга, ботарларга туры килде.

Кайтканда: «Минем эзгә басып!» командасы онытылды (укучы ялгышмасын, аларны эзләреннән килеп тапмыйлар). Чыктылар да тауга түбән йөгерештеләр. Лагерь кузгала башлаганчы ук кайтып житәргә кирәк иде.

Һәм кузгалганчы кайтып та життеләр. Чәчәкләрне карават асларына томырдылар да ялт та йолт кайсы кая юрган астына кереп бетте. «Уянмыгыз! Торыгыз!» дип бырлы жырлатканнан соң гына, тәмле йокыдан арына алмаган кешеләр сыман кинерелеп-сузылып, палатка ишегеннән килеп чыктылар. Илдус хәтта йодрыгы белән күзләрен дә уып торган булды.

Шундук боерык:

— Сакка бас! Берәүне дә кертмә!

Кеше серен белмәсәләр тамакларыннан кала торган кызлар килеп-килеп сакчыга ялынып-ялынып бактылар. Сакчы таш, сакчы тимер. Таягын ишеккә аркылы куйды. Суда күбек очыру остасы, чәч толымына кызыл таккан су төбе саесканы (инде бит гади кыз түгел, ярты герой!) ул да килеп борынын төртеп карады, ана да жавап кыска булды:

— Сабыр ит. Вакыты житкәч белерсең.— Һәм ишеккә аркылы таяк куелды.

Тегеләр эчтә ни кыландыралардыр, нәрсә белән лагерь әһелен шаккаттырмакчы булалардыр, анысын сез түгел, мин дә белмим. Минем дә алдымда аркылы таяк.

Боларның яшерен эшләре көн буена сузылды. Көн буе ишектә сакчы басып торды (ашын да аягүрә генә ашады). Ниһаять... Дөньяның исен китәрергә тиешле эшләрен кулларына тотып, болар ишектән килеп чыктылар.

Ике күземне күзлекләрем белән дүрт итеп карап торам. Юк, юк, моны сүз белән тасвир итеп бирү минем кулымнан килми: сүз һәм буяу табудан мин гаҗиз. Китерә алсагыз күз алдына китерегез: аллы-гөлле чәчәкләрдән гаҗәп тә матур итеп үрелгән (юк, үрелгән сүзе бу урында бик тупас, бик дорфа, ижат ителгән дип китапчарак итеп әйтсәк, хакыйкатькә якынрак булыр), гаҗәп матур итеп ижат ителгән зур кәрзин, чәчәк кәрзин, ә кәрзин эче тагы аллы-гөлле чәчәк... Кәрзин түгел, әкият! Хуш исләр бөркп торган әкият! Һәм шушы матур әкиятне ташбаш Илдус белән аның иптәшләре ясаганнар бит!

Кызлар күрүгә егылдылар да киттеләр. Ах белән вахның чиге булмады. Илдус компаниясенә сыймаган малайларның кәнләшүләре йөзләренә чыкты.

— Каян алдыгыз мондый чәчәкләрне? — дигән мәкерле сорау бирмәсеннәрме.

— Таптык инде,— дигән булдылар тегеләр, серле елмаеп.

— Бакчадан өзгәннәр ич! — дип кычкырды бер кәһәр төшкәне.

— Өзсәләр, сезнең бакчадан өзмәгән,— дип кисте Илдус салкын гына.

Әкиятне Сара апаларына илтеп тоттырдылар. Сара апаның да исе акылы китте.

— Кайсыгыз моны шулай?

— Бишенче палатка шулай,— диделәр тегеләр.

— Молодецлар! Бик оригинально. Ә мондый чәчәкләрне каян алдыгыз?

Илдус бу сорауны көткән иде.

— Дамирлар бакчасыннан. Ышанмасагыз, әнә Дамирның үзеннән сорагыз. Шулай бит, До-ре-ми?

Дамирның авызы ачылды да ябылмыйча калды: ни «юк» дими, ни «әйе» дими. Бу ташбаш Илдустан ул мондый әшәкелекне һич көтмәгән иде.

— Дамир, ник дәшмисең? — диде йомшак кына вожатый апалары.

До-ре-ми маңгай астыннан бер Илдусны сөзә, бер — Сара апасын.

— Безнең бакчадан. Әтиләр белми.

— Ә менә бусы не оригинально. Сорарга кирәк иде. Ну ярый. Барыбер молодецлар!

Беренче бүләк Бишенче малайларына эләкте: һәр малайның сузылган (яки сузылмаган) кулына бик матур китап тоттырдылар.

Кичке аш вакытында алар аерым өстәлгә утырыштылар. Бүләкләнүчеләрдән битәр Сара апа үзе шат, үзе куанган. Бер урында басып тора алмый: әле йөгереп чыгып китә, әле тагын йөгереп керә. Пирожныйларны үз кулы белән тәлинкәләргә салып-салып чыкты.

Гади малайларның «тегермәннәре тарта» да башлады, ә бүләкләнүчеләргә әле Сара апалары рәхәт итми. Илдус белән Дамир кереп житмәгән. Кая олакканнардыр вакытсыз. Әйтелде бит аларга, китеп югалмагыз, диелде. Сара апа утка баскандай йөри. Палаткага бер малайны йөгертте, теге: «Анда да юк», дигән хәбәрне китерде. Кая киткәннәр? Мәжлеснең ямен бозып, бу инде бөтенләй дә не оригинально! Радио аша чакыртып караргамы әллә үзләрен?

Менә бер вакыт кичке урманны яңгыратып, радио кычкырды:

— Ил — дус! Да — мир! Сезне көтәбез! Ил — дус! Да — мир!

Радио авазы, агачтан агачка бәрелеп, Ил — ил, да — да, дус — мир булып, урман эченә чәчелде.

Илдус белән Дамир әллә ишетте, әллә юк, бик кызган чаклары иде. Лагерьдан ерак та түгел, куш нарат артына килеп керүгә, Дамир, кизәнеп торып, чукмарлы таяктай кулы белән Илдуснын яңак төбенә берне ямады да, минем эш бетте дигән кыяфәт белән, борылды да китеп барды. Көтмәгәндә яңагына китереп утыртсыннар әле, син дә югалып калырсын. Илдус аңына килеп өлгергәндә, Дамир, салмак-салмак атлап, шактый юл алган иде. Ярсыган Илдус куып килеп житте дә тегенең өстенә ерткыч жанварлай ташланды. Әлбәттә инде, ике малай сугышкан чакта канаган жир дә, күгәргән жир дә булмый калмый.

Алар кайтып күренгәндә, бөтен лагерь аякка баскан иде. Сара апалары тегеләрнең өстенә карчыга булып кунды:

— Кайда йөрисез бәйрәм бозып? Кем рөхсәте белән?

Кысып-кысып караса да, икесеннән ярты сүз дә ала алмады. Бәйрәм чәенә дәшеп бакты («Пирожныйларыгыз холодильникта!»), тегеләр баш кына чайкадылар.

Икенче көнне иртә белән, көн яктысында, күгәргән күз төбен, ярылган иренне күргәч, вожатый апалары:

— Кем кыйнады сезне? — дип бәйләнде.— Әллә сугыштыгыз? Нәрсә житмәде?

Алырсың бу ике ташбаштан сүз. Берсе күз төбен сыпырды, икенчесе китек иреиенә кагылды, бер сүз дәшмәделәр.

«Мин ничек коткардым» истәлеген сөйләтергә дип, Илдусны күрше «Көмеш күл» лагереннан чакыра килгәннәр иде. Малаең палаткадан да чыкмады. Чирлим, бара алмыйм дип, кеше аркылы гына әйттерде.

Дамир хәзер бүтән палаткада — бер малай белән урын алышты. Сара апалары әле Дамир яныиа, әле Илдус яныиа йөгереп кера, тел яздырмакчы, сөйләтмәкче була. Алармы соң инде тел язучылар! Юк, яздыра алмады. «Булды инде, малайлар арасында ни булмас» — бөтен жаваплары шул.

Илдус лагерьдан кайтып китәргә үк йөри ди бугай. Дамир шулай дип ишетте. Һәм чынлап та, беркөнне (Дамир урманда иде), лагерь житәкчеләрен аптырашта калдырып, өч көн алдан кайтып китте.

Ул китсә китте, әле бит кояш калды. Түгәрәк күл калды, аланлы, бакалы утрау калды. Балалар тагын өч көн су коендылар, кояшта кызындылар, Илдус китте дип, гәрчә шундый данлыклы кеше китсә дә, тормыш туктамады.

...Менә сәгать сукты, аерылышыр минутлар житте. Автобуслар урман авызында көтеп тора. Ата-аналар лагерь капкасы төбенә килеп өелде — койма аркылы кычкырып сөйләшәләр, елмаешалар, балаларның жыенып бетүен көтәләр...

Кем борыны ул автобус тәрәзәсендә — пыялага төртелеп ямьшәйгән? Теге кызыл чүпрәкле баш борыны түгелме соң? Дамир узышлый тәрәзәдәге кызчыкка елмаеп, ни өчендер (аларныкын кем белгән!) йодрык күрсәтеп узды. Автобуслар кузгала да башладылар.

Сара апалары кул болгый:

— Хушыгыз, алдагы жәйдә тагын рәхим итегез!

Кырык авыз кырыгысы да елмая, тәрәзә саен ямьшәйгән борын, елтыраган күзләр...

Уф, болары китте. Ике-өч көн үтмәс, яңалары килеп житәр. Палаткаларны жыештыру, өрү-сөрү башланды. Онытылган билбау, тапочка, баш яулыгы, дәфтәр, карандашларны жыеп алдылар. Бер палаткадан бик матур тышлы китап табылды.

— Менә ашыкканда онытып калдырганнар,— дип, жыючы хатын барысын да вожатыйга илтеп бирде.

— Бер юньсезе бүләк китабын онытып киткән.

Сара апа, шулай дип, китапның титул битен ачып бакса: «...Шундый-шундый ярышта җиңеп чыккан өчен Дамир Фәсхетдиновка... Июнь, 1970 ел», дип язылган сүзләрне күрде.

— И, хәтерсез... Ә бусы ни тагы?

Астарак карандаш белән тырнаштырган тагын бер язу бар иде: «Мин җиңүче түгел, мин...» дип яза башлаган да, аннары «мин» сүзен «без»гә төзәтеп куйган: «Без җиңүчеләр түгел, без...»

Сара апалары укып бетергәнче үк ике куллап матур чәчләренә ябышты.

«...шул сәбәпле китабыгызны үзегезгә калдырам.

Дамир».

САРБАЙ— САРЫ ЭТ

ХИКӘЯ

Бер малайның эте бар. Йонга бай, гәүдәгә бай. Бозау хәтле! Юк, арттырдым. Бозау хәтле үк булмас, шулай да зур, бик зур. Тавышы... Нәрсә белән чагыштырыйм икән тавышын? Бүрәнә калынлыгы. Ул өргәндә тәрәзә пыяласы дерелди, моржадан чыккан төтеннәр сынып-сынып китә, үләннәр җиргә яталар.

Ә йоны... Сап-сары йоны җирдән өстерәлеп бара. Безнең бакчадагы бер алмагачка Сарбай куштылар, аның да нечкә ботаклары җиргә тиклә салынып төшә, алма уңган елны бигрәк тә...

Малайның исеме Илдус. Хәер, Илдус булса ни дә, Илгизәр булса ни, Илсөяр булса ни дә, Илнур булса ни. Исемгә карап малайның асылы үзгәрми, малай булып кала бирә...

Хәтерләп калдыгызмы? Кечкенә малай бар, кечкенә малайның зур эте бар. Исеме Сарбай.

Бер малай бар җирдә икенче малайның булуы гажәп түгел. Икенчесе янында өченчесе, бишенчесе чабып йөрсә, шулай үк бик табигый. Безнең урамда малайдан күп нәрсә юк. Ни арада туып өлгерәләр дә ни арада үсәләр... Бер карыйсың — әнисенең имиенә борынын төртеп, мышмыш чүпрәк чылатып ятканын күрәсең, икенче карыйсың— өч тәгәрмәчле велосипедта чабып йөргәнен күрәсең. Әллә инде ашлама сибеп үстерәләр ул малайларны?

Әйе, безнең урамда малайлар бер көтү. «Автоматтан» ата-ата, ура кычкыра-кычкыра, алар урамнан чабышып узганда чыдап кына тор— кай төшләреннән чыгадыр шул хәтле әче тавыш... Ә Сарбайны әйт, күсәктәй башы белән оялмыйча, шул бала-чаганың уенына тыгылып, шул әч әрвахлар белән уйнап йөрергә ярата. Нишлисең бит — ярата. Яратуга каршы әмәл юк. Малайлар да Сарбайны яраталар. Сарбайга кайвакыт бик авырга килә шул хәтле малайның яратуы: чөнки бит

Илдус та ярата, Илгизәр дә ярата, Илсөяр дә ярата, Илнур да ярата — барысы да ярата. Ә Сарбай бер ялгызы. Бер көтү малай берьюлы ярата башлагач, Сарбаегыз арып тәмам эт була.

Малайларның нинди ярату белән яратканын беләсез: алар Сарбайга атланып йөриләр: чиратлашып та атланалар, чиратсыз да атланалар, алга карап та атланалар, артка карап та атланалар. Илдус та атлана, Илгизәр дә атлана, барысы да атланалар. Бичара Сарбайга ходай сабырлык бирсен! Шабыр тиргә батып, яшел үләнгә егылганчы мәхлукның сыртыннан төшмиләр.

Малайларның шундый рәхимсез булуы мине әллә ни гажәпләндермәди. Малай халкы гомер-гомергә эт белән мәче азаплап үсә (азаплыйм дип уйламый да). Мин үзем дә күршеләрнең Дүрткүзенә атланып үскән малай, бер дә үкенмим, мине гажәпләндергәне бүтән: шундый көчле, шундый акыллы Сарбай ни өчен шул үзен азаплаучы малайларны ташлап качмый, ни өчен ул аларга ябышып ята? Ничә күргәнем бар: аңа таяк белән кизәнәләр, аңа аяк тибеп кычкыралар, бичара этнең көйрыгыннан тарталар, ә ул һич кенә дә үпкәли белми. Кая үпкәләү, жиргә сузылып ята да,— юк, чалкан төшеп, ботларын күтәреп, ялагайланып ятмый,— алгы аякларына башын куеп ята, үзен азаплаучыларга акыллы, сөйкемле күзләре белән ягымлы гына карап тик ята.

Шундый сәер жан инде, күрәсең, бу Сарбай дигәннәре: ачулана да белми, үч тә саклый белми. Инде бит шундый озын, шундый шәп аяклары була торып, һич югында, качып та котыла алыр иде.

Илдуснын әтисе, Закир абый, малае кебек үк, эт дигәндә үлеп китә торган кеше. Тик аның яратуы гадәттә озакка бармый, этләрне ул гел алмаш-тилмәш китереп тора. Әле шушы арада гына Закир абый яңа эт алып кайтты — исеме Рекс. Бүре дә бүре, Рекс та бүре. Бик усал эт булып чыкты бу Рекс. Шушы усаллыгы аркасында үзенә еш кына чылбырда утырырга туры килә. Нишлисең бит, характерың начар булгач, утырмый хәлең юк.

Яңа эт алып кайтты, Сарбайны да куып чыгармады. Куган да булыр иде, бәлки. Илдус бик ялынып-ялынып сорагач, бераз балавыз да сыгып алгач, Сарбайга тимәскә булды.

Сарбай калды, тик барыбер Закир абыйның жан яраткан эте хәзер инде Сарбай түгел, Рекс. Сарбай йокыга бай, гәүдәгә бай, акылга да ярлы түгел, тик нишләмәк кирәк, хужа икенче этне ярата, көчләп яраттырып булмый. Сарбай күздән төште. Сөякнең майлысы — Рекска, Сарбайга — калдык-постык. Ягымлы сүз — Рекска, Сарбайга — пошел отсюдова!»

Шулай итеп, Сарбай — сары эт малайлар кулына калды: алар бирсә — ашый, бирергә онытсалар — ашамый йөргән чагы да була. Хәер, бала-чага Сарбайны бик ташлап бетермн, өйдәгеләрдән кая сорап, кая урлап дигәндәй, сөяген дә, ашын да алып киләләр. Рекс, комсыз, ач күз, әле шунда да Сарбайныкына сузыла, аның барлы-юклы сөяген таламакчы була, малайлар Сарбайны аерым ашаталар, ә Рекска бу бер дә ошамый, малайларга ырылдый, тешләрен ыржайта...

Малайлар кулыннан ашап бер ай яшәде, ике ай яшәде. Бер дә бер көнне, кичкырын, яңарак яуган кар өслән бер чаңгычы узды: аучы булдымы ул, әллә болай гына мылтык асып йөрүче булдымы, андыйлар да хәзер дөнья тулган, шәһәр ягына таба кайтып бара иде. Гөнаһ шомлыгына каршы дип әйтикме, шушы ни аучы, ни яучы булмаган адәм затының каршысына үзенең бозаудай гәүдәсе, бүрәнәдәй тавышы белән Сарбай чабып чыкмасынмы...

...Менә бервакыт кинәт мылтыктан аткан тавыш ишетелде. Илдус йөгереп чыккан чыкта Сарбай инде ап-пак кар өстендә сузылып ята иде.

Кар өстендә сары эт Сарбай ята, Сарбай янында — ике-өч тамчы кызыл кан ята... Ә теге мылтык, узышлый эткә атып киткән адәм затын әйтәм, артына да әйләнеп карамыйча, чаңгысы белән шәһәр ягына җилдертеп-ме җилдертә...

Тавышка җыелып өлгергән малайлар, Сарбайның кечкенә дуслары, күзләрен тутырып, таңга калып, карап торалар: Илдус та карап тора, Илгизәр дә карап тора, Илсөяр дә, Илнур да, барысы да аптырашып карап торалар: шундый зур, шундый көчле Сарбай кар өстендә сары чүпрәк шикелле аунап ята. Моржалардан чыккан төтеннәр инде сынып-сынып китмиләр, тәрәзә пыялалары да дерелдәми. Кемгә атланып уйнарлар инде бу балалар? Җәй җиткәч, кем үзенең бозаудай гәүдәсе белән балалар арасында уйнап йөрер? Ята Сарбай кичке зәңгәр кар өстендә, ә Сарбай янында ике-өч тамчы кара кан ята...

Малайлар әллә ни гомер шулай телсез калып тордылар. Аннары Закир абыйлары Сарбайны урманга илтеп ташларга кушты.

Малайлар Сарбайны, сары этне, үзләренең сөекле дусларын, кышкы урманга илтеп, карга күмделәр. Ул бит инде хәзер берәүгә дә кирәкми. Берәүгә дә. Хәзер инде барлык татлы сөяк Рекныкы, бай хәзер Рекс сөяккә.

Үттеме икән бер көн, Сарбай урманнан кире кайтты. Рекс аны кар астыннан эзләп тапкан да өстерәп алып кайткан. Алып кайткан да оясындагы йомшак печән өстенә кертеп салган, ә үзе... үзе сакка баскан: берәүне дә Сарбай янына якын җибәрми: килә башласаң, ачулана, тешләрен ыржайта, килмәгез, тимәгез Сарбайга дип әйтүе... Барлык булган сөякләрен Сарбай алдына китереп өйгән.

Закир абый Рексны чылбырлады да, Сарбайны оядан тартып чыгарып, малайларга атты: илтегез күмегез. Тегеләр бу юлы тагын да ераграк илтеп, тагын да тирәнрәк күмеп кайттылар.

Ә ап-ак кар өстендә, балалар күңеленә шом салып, ике-өч тамчы кара кан әле һаман да ята иде.

Марсель Зарипов

ҖӘЙГЕ КОМАНДИРОВКАДА

ХИКӘЯ

Әгъзәмов менә тагын «Кызыл шәрык» совхозына бара. Бу хуҗалык республиканың иң чигенә урнашкан. Барыр юл ерак, сикәлтәле. Шулай да Әгъзәмовның күңелендә әйтеп бетергесез күтәренкелек. Нинаять, ул теге кире беткән Доргуновага кемнең хаклы булганын, кемнең ялгышканын исбат итәчәк. Әнә шул уйлар юл уңайсызлыкларын киметкәндәй була, Әгъзәмов түземсезләнеп таныш совхозның кырларына барып житкәнне көтә иде.

— Кызулата төш, Петрович. Ташбакада сөйрәләбез бит...— дип, ул шоферына хәтта үпкә дә белдереп алды.

Менә «Кызыл шәрык» совхозының басулары башланды. Житез «Волга», тыгыз булып үскән иген стенасына борылыш саен орына-орына, тар гына басу юлыннан тузан туздырып алга чаба. Авыр башаклар машина тәрәзәсенә бәрелеп-бәрелеп калалар. Иген чыннан да котырып уңган иде. Әгъзәмов, шатлыгын яшерә алмыйча, шоферга таба борылды да:

— Күрәсеңме, Петрович? Мондый бәрәкәтнең күптән булганы юк иде инде,— дип куйды.— Хәтерем ялгышмаса, мондый муллык утыз жиденче елны булган иде. Тәжрибәсез бер белгеч кенә идем әле — агроном булып эшли генә башлаган чагым иде.

Шофер, борылмалы юлдан бер генә минутка карашын алып, күзен кыса төште.

— Әйе, ел уң килде быел. Көзе дисеңме, кышы-жәе дисеңме — гариза язып сорасаң да болай булмас. Нәкъ утыз жиденче ел инде...

«Нәкъ утыз жиденче» дигәне Әгъзәмовка ошап ук житмәсә дә, ул моны артык сиздермичә генә шоферга каршы төште:

— Алай ук түгел инде анысы, быелгы ел климат ягыннан уртача гына булды... Яле, туктат бер мәлгә. Кеше үстергән ашлыкка юл буе машина эченнән генә сокланып киләбез, ә менә төшеп, башак исен иснәп карау уйга керми. Онытканбыз, Петрович, түрә булып кыланабыз. Яле, чамалап кара — күпме алырлар дисең бу арыштан?

Машина туктады. Әгъзәмов калын ашлык стенасын инбашы белән этеп жибәргәндәй итте дә инде саргая башлаган арыш арасына кереп

китте. Шаян җил арыш башакларын тузгыткалап бер урында уйнаклап тора да кинәт, дәррәү кузгалып, үзе алдыннан саргылт дулкыннар куып китә. Әгъзәмов булачак оҥрашуны түземсезләнеп көтү тойгысына бирелгән хәлдә салмак кына шул дулкыннар артыннан атлый. Тагын утыз минут, күп дигәндә, бер сәгать үттеңме, менә синә совхоз, институт бетергән елны агроном булып эшли башлаган жирең. Тиз дә уза соң вакыт дигәнең! Бәлки менә шушы иген кырларыннан, усал холыклы Доргуновадан башка монда Әгъзәмовны хәтерләүче дә калмагандыр инде. Моны ул күңеленнән икърар итәргә теләмәсә дә, командировкага шул Доргунова аркасында гына баруын һәм аны хәзер биләп алган шатлыкның да котырып уңган ашлыкны күрүдән бигрәк әнә шул Доргунова белән булачак оҥрашуны көтүдән икәнен аңлый иде.

— Егермедән ким булмас,— диде Петрович, Әгъзәмовка якынрак килеп.— Бәлки егерме икене дә тартыр. Башагы шәп бит, кара, ничек авырайган!

— Тартыр,— диде Әгъзәмов, аның сүзен жөпләп, һәм, үзе Петровичка таба борылмыйча гына, өстәп куйды: — Хәтерлисеңме, без былтыр бирегә менә шушы басу аркасында килгән идек?

Әгъзәмовны ун ел буе машинада утыртып йөрткән һәм аның белән дөнья хәлләре турында гына түгел, агрономиягә кагылышлы мәсьәләләр турында да сүз куертырга күнеккән Петрович:

— Алайса, Настасья Петровна ялгышкан булып чыга инде,— диде.— Болай акыллы гына хатын күренә үзе, ә менә бу эшне чамалый алмаган...

— Доргунованы әйтәсеңме? — дип кайтарып сорады Әгъзәмов.— Акыллы агроном ул. Менә барып житкәч без аңа бер сабак бирәбез әле. Хәзер зуррак итеп көлтә ясыйбыз да шундагы бөртекләрне санарга кушабыз үзенә, шуннан безгә уңышның күпме булачагын исәпләп чыгарсын.— Һәм ул озын буйлы арыш сабакларын учлап йолкырга тотынды.

Тагын алга киттеләр. Әгъзәмов, авыр арыш көлтәсен тезенә салган хәлдә, совхозга ничек килеп житәчәген күз алдына китерде: ул Доргунованы эзләп тапкач, исәнләшәсе урында, башта кашларын жыерып: «Начальствоның канын бозганың өчен хәзер үк гафу үтен»,— диячәк һәм шуннан соң гына елмаеп: «Я, ярый, килешик әйдә»,— дип кул суза чак.

Алар чыннан да бер-берсенең канын шактый күп боздылар. Гаеп атта да, тәртәдә дә булды.

Узган ел җәй көне Әгъзәмов өлкән агроном булып эшли торган Авыл хуҗалыгы министрлыгына идарә начальнигы итеп яңа кешене билгеләделәр. Эшли башлавына бер атна үтәр-үтмәс яңа начальник Әгъзәмовка ашлык житештерү буенча исәп-хисап ясап китерергә кушты. Әгъзәмов ясап китерде. Начальник аның алдында бу кәгазьләрне карап, кесә дәфтәренә кайбер саннарны күчереп тә алды. Аннары ул аңа эзләнүчән акыллы агрономы булган нык хуҗалыкны сайлап алып, анда эксперимент ясап карарга, чиста пар һәм үләннәр бөтенләй калдырылмаган чәчү әйләнешен сынарга кушты.

Эшлибез аны, тәжрибә хуҗалыгына команда бирәбез,— диде Әгъзәмов.

— Юк, алай ярамас. Дүрт ел көткәнебез бушка китәр, крестьянны ышандыра алмабыз. Тәжрибә хуҗалыгы — оҗмах бит ул, анда машинасы-техникасы дисеңме, кешесе-кадрлары дисеңме — барысы бар, андагы жир үзеннән-үзе уңдыра,— диярләр. Тәжрибәне гади бер хуҗалыкта янә кабатларга туры килер. Ә бу тагын дүрт ел әрәм китә дигән сүз.

Әгъзәмов моңа каршы төшмәкче булды. Эш уңышсыз барып чыкса, мондый хуҗалыкның хәле бик мөшкел булачак, көтелгән табыш урыны-

ла зыян өстенә зыян киләчәк, ә бу хәл игенченең, белгечләрнең кесәсенә китереп сугачак,— аларның хезмәт хакы, бүтән төрле акчалата керемнәре хужалыкның экономик хәленә бәйле бит. Ләкин бу уйлар аның күңелендә генә калды, ул әйтергә теләгәнен әйтә алмады, әйтергә базмады.

Заманасы нинди бит аның хәзер! Бүген син бернәрсәне ерактагы кыялга санап йөрисең, ә иртәгә, карыйсың, ул инде гап-гади бер хәлгә әверелгән. Хәзер бит атом бозваткычлары төзиләр, айны рәсемгә төшереп кайттылар, жир тирәсендә спутниклар очып йөри... Менә яңа начальник кушкан эшнең дә ни белән бетәчәген алдан әйтеп кара әле син... Бүген аңа каршы сүз әйтерсең, иртәгә үк үзеңнең төпсез көймәгә утырганыңны сизми дә калырсың...

Һәм Әгъзәмов, «эзләнүчән, акыллы агроном» урынында Доргуновадан да әйбәтрәк кеше булмас дип, экспериментны «Кызыл шәрык» совхозында үткәрергә тәкъдим итте. Ул совхозның яңа чәчүлекләр структурасын үзе төзеп, аны үзе раслады һәм, «үтәлергә тиеш» дигән резолюция салып, урынга жибәрде. Ә бер-ике атнадан «Кызыл шәрык»тан алынган кәгазьләрне күреп шаккатты: совхозда чәчү әйләнешен үзгәрешсез калдырганнар — шул үк ужым культуралары, шул үк клевер, ә сөрү жиренең алтыдан бер өлеше элеккечә «ял итәргә» тиеш булып чыккан.

Әгъзәмов бик ашыгыч рәвештә командировка кәгазьләренә кул куйдырды да шул үк көнне «Кызыл шәрык»ка китеп барды. Менә шул баруында инде алар Доргунова белән, кем әйтмешли, пычакка-пычак килештеләр.

— Министрлыкның күрсәтмәсен алдыгызмы? — диде Әгъзәмов.
— Алдык,— диде Доргунова.
— Ашламага дигән нарядны?
— Анысын да алдык.
— Черемә чыгарасызмы?
— Чыгарабыз.
— Нигә башбаштакланасыз?

Бу сөйләшү вакытында бүлмәдә аның белән Доргуновадан тыш совхоз директоры да бар иде. Әгъзәмов, инде чал керә башлаган, нәхтәләп таралган чәчләрен сыпыра-сыпыра, нишекле-түрле йөренә һәм шуклык эшләп тотылган сабыйны шелтәләгәндәй, Доргуноваңы жиңелчә тирги, тик аның тавышында сабыйны гафу итәргә теләү дә сизелеп тора иде.

Совхоз директоры, төз гәүдәле, яшь кенә чырайлы, өстенә хәрбиләр френче кигән Никитов, телефон яныңа утырып алган да, кулындагы карандашын йөртә-йөртә, аларның бәхәсен тыңлый. Гади генә ситсы күлмәкле, ак брезент тапочкалы Доргунова әллә ни исе китмәгән кыяфәт белән диван читендә утырып тора.

— Барысын да алдык, Нигъмәтжан Хәкимжанович, рәхмәт инде сезгә! — дип, Әгъзәмовка карап алды да директор, моннан соң әйтәсе сүзе өчен аңардан алдан ук гафу үтенгәндәй, гаепле кеше төсле елмаеп куйды: — Бездә жир мәсьәләсендә беренче сүзне агроном әйтә, бөтен власть аның кулында...

«Кем артына яшеренергә икәнен белә, шайтан,— дип уйлап алды Әгъзәмов директор турында.— Ә Доргунова — ул беркатлы нәрсә, барысын да үз өстенә алачак. Шулай булгач, ниемә дип соң әле мин бу сүзне директор бүлмәсендә, аның янында башладым? Әгәр без Доргунова белән икәүдән-икәү генә сөйләшсәк, сүз бөтенләй икенче юнәлеш алган булыр иде. Шулай да, каян килгән диген син аңа бу тикле үҗәтлек?»

Әлбәттә, Әгъзәмовка бу бәхәс өчен вакыт әрәм итеп тормаса да ярый иде. Беткәнмени республикада совхозлар! Әлеге боерыкны бүтән адрес белән жибәрергә дә көз житүен тыныч күңел белән көтәргә иде... Акылы аңа хәзер дә шулай эшләргә куша, ләкин берничә сәбәп арка-

сында ул моның киресен эшләргә, «Кызыл шәрык»ка килеп вакытын әрәм итәргә мәҗбүр. Беренчедән, ул Доргуновага ышана, аның нинди генә эшкә тотынса да уңышлы башкарып чыгачагын белә. Икенчедән, ни генә әйтсәң дә, ул бит инде үз совхозына битараф кала алмый. Ник дисәң, ул нәкъ менә Доргунованы «якты дөньяга» чыгарырга тели. Әгәр сынау уңышлы тәмамланса, дан-шөһрәте яңа идеяне тормышка ашыручыларга булачак. Өченчедән — монысы, мөгаен, иң мөһиме булгандыр,— командировкадан ни күзең белән буш кайтмак кирәк?! Яңа начальник аның турында ни уйлар? «Әгъзәмов кешеләрне белми... Кешеләр Әгъзәмовны санга сукмыйлар, димәсме?..»

— Мин беләм, сез җир өчен борчыласыз,— диде ул, бүлмә буйлап арлы-бирле йөрүен дәвам итеп.— Янәсе, бер ел «ял итмәсә», җирнең көче-җегәрлеге калмый, ярлылана...

— Барыбызны да шул туендыра бит,— диде Доргунова.— Халык шуннан туена...

— Сез нәрсә, ә мин күктәге фәрештәләрне кайгырта, дип уйлыйсызмы? — диде Әгъзәмов.— Әллә сез арифметиканы онытып бетердегезме? Ягез әле, кулга карандаш алып тапкырлау таблицасын кабатлый башлыйбыз. Сезнең ничә мең гектар җирегез кысыр ята, ничә меңендә бер файдасызга үлән үсә? Исәпләп кара: шуларның барысын бетереп, пар урынына, үлән урынына борчак чәчәсең, аны урып алуга шунда ук арыш чәчеп җибәрсән,— күпме файда була?! Эш өстәмә җыеп алынган бөртектә генә дә түгел, борчак бит гектар саен центнер ярым азот калдыра. Ә хәзер инде шуны аммоний сульфатына күчереп кара — бу мең гектарга унбиш мең центнер дигән сүз. Синең сөрү җиреңдә мең центнер минераль ашлама. Күктән төшкән хәзинә бит. Әйтче зинһар, «Кызыл шәрык»ның мондый мөлкәтне кайчан күргәне бар?

— Оһо, менә бит ул никадәр килеп чыга! — дип, директор ниндидер саннар язылган кәгазь битен Әгъзәмовка таба этеп куйды: — Чәчеп, урып ал да сводкага язып куй: фәлән кадәр ашлама чыгардык без, дигән! Рәхмәт, акыллы фикерегез өчен!

Директорның болай тиз генә килешүе Әгъзәмовның ачуын чыгарды.

«Менә аумакай,— дип уйлап алды ул эченнән.— Ике якка да ярамакчы. Әле генә Доргунованың сүзен жөпләп утырган иде, ә хәзер минем белән килешергә тора».

Әгъзәмов моның өчен директордан үч алырга — «баш беләнрәк уйларга кирәк» кебек чәнечкеле сүз әйтергә җыенган гына иде, аңардан элек Доргунова сүз башлап:

— Менә сиңа саннар! Чын Ньютон биномы бит бу! — дип төрттереп куйды.

Әгъзәмов бите кып-кызу булып кызарганын, ачуы чыга башлавын сизде, ләкин үзен үзе тыеп калды, кинәт кабынып киткән тойгыларын басарга тырышып:

— Әллә ул саннар дөрес түгелме? Игенчелек институты китереп чыгарган мәгълүмат ул. Галим халкы ул сиңа... Җиде кат кына түгел, мең кат үлчәп карый...

— Дөрес түгел дип әйтмим.— Доргунова аның белән килеште, ләкин шунда ук үзен үзе төзәтеп тә куйды: — Шулай да алар белән төпсез көймәгә утырып калуың да мөмкин. Ә безнең, күктән йолдыз чүпләмәсәк тә, ашлыксыз калган елыбыз юк. Шулай булгач нигә кирәк ди безгә һавадагы торнаны тотарга маташу? Юк, мин экспериментка каршы түгел. Ансыз алга китеп булмый. Мин биш йөз гектар җирне бирергә риза, әмма бөтен сөрү җирен бирмим. Унсигез мең гектар дигән сүз бит ул!

— Әйтсәм әйтим инде, харап та зур демагог булып киткәнсең син, Анастасия Николаевна! — дип, Әгъзәмов аның сүзен бүлдерде.— Син шуны аңларга тиеш: боерык бирелгән икән, аны үтәргә кирәк!

Әгъзәмов биш йөз гектар жирнең үтә дә аз булуын, андый мәйданда, уза китсә, лаборатория күләмендәге тәжрибәне генә үткәрергә мөмкин икәнен һәм андый тәжрибә нәтиҗәләре белән һичкемне ышандырып булмаячагын яхшылап кына аңлатырга тырышты, эш уңышлы чыга калса, совхозның бөтен Союзга шөһрәт казаначагына шаярган-көлгән булып киная ясап карады... Әмма боларның берсе дә файда бирмәде. Ул алдан исәп тоткан, ул көткән дусларча әңгәмә барып чыкмады. Киресенчә, сөйләшү ызгыш белән тәмамланды. Доргунова дөрләп кабынып китте дә кызып-кызып:

— Сез безне югарыдан төшерелгән боерыкларны уйламый-нитми үтәп утыручыларга әверелдермәкче буласыз. Ә без сезнең ул боерыкларыгызга уйлап карамый-нитми генә ышанмыйбыз. Аңламыйбыз без аларны...— дип тезеп алып китте.

— Димәк, сез миңа ышанмыйсыз? Министрлыкның өлкән агрономы сезнең өчен авторитет түгел? — диде Әгъзәмов.

Доргунова, ни дип җавап бирергә аптыраган сыман, бер мәл күзләрен кыскалап торды да, кинәт кашларын өскә чөеп, һич икеләнмичә, сүзләрен өзек-өзек әйтеп салды:

— Хәзер сездән зуррак авторитетларның сүзен дә тота-каба гына үтәмиләр.

Әгъзәмов, агроном хатынның сүзләренең әрем әчелегенә ачуы килеп, аның каршына килеп басты да кычкырып ук куйды:

— Син мина ребуслар биреп маташма, Анастасия Николаевна, мин барыбер аларны чишеп утырачак түгел.

— Ә сез шулай да чишеп карагыз әле, Нигъмәтҗан Хәкимҗанович,— дип, күзен дә йоммыйча жавап кайтарды тегесе.— Безгә андый ребусларны азмы чишәргә туры килде. Торф чүлмәкләр белән теңкәгә тидегезме? Тидегез! Тәмам көлкегә калып беткәч кенә туктадык. Моннан ике ел элек совхозның ул чактагы директоры Фатих Кәримовичка бәйләнә башладылар: янәсе, сез сөрү жиренең һәр йөз гектарына бишәр ана дуңгыз тотарга тиеш. Нәкъ әлеге төсле, исәпләүләр, саннар белән. Фатих Кәримович, йомшак күңелле кеше, арифметика белән бәхәсләшергә базмады. Ана дуңгызларны булдыруын булдырдык, ә аларның балаларын тотарга урын юк, азык житешми... Үләт вакытындагыдай кырылдылар мескенкәйләрем. Ә директорга өч ел бирделәр. Әле дә ярый, Верховный судка барып житәргә башыбызга килде. Юкса, тәки харап булыде кеше...

Әгъзәмов дәшмәде. Кабинет буйлап ишекле-түрле йөренә бирде: өч адым ары атлый, өч адым бире. Ә Доргунова, берсеннән-берсе жилле мисаллар китереп, кызып сөйләвен белә.

— Шулай бер вакыт райбашкарма председателе хатын-кызларга карата үзенчә кайгыртучанлык күрсәтә башлады: янәсе, алар сыер асрап иза чикмәсеннәр, сыер савып кулларын калжайтмасыннар. Ул да булмый, телефон аша боерык килеп төшә: «Сыерларны совхозга тапшырырга!»

— Сүзегезне үлчәп сөйләгез, Анастасия Николаевна,— диде Әгъзәмов.— Йорт башына өчәр дуңгыз, икешәр сыер, бер көтү сарык, йөзләрчә баш кош-корт асрарга кушасызмыни? Андый милек өчен кулакларны себер жибәргәннәр!

Ләкин Доргунова бирешмәде:

— Кулаклар заманы түгел хәзер. Ул чактагы хәлләр артына яшеренмәгез, Нигъмәтҗан Хәкимҗанович! Менә без болай итик: сөт ташучы машина һәр көн иртүк йорт саен йөреп чыга торган булсын, һәркем сөтне теләгәнчә ала алсын, бәяләр дә эшче кеше кесәсенә ярашлы булсын. Әллә сез хатын-кызны юләр дип беләсезме? Аның бер дә сыер кой-

рытына ябышып ятасы килми. Ә бит әле хәзер совхоз директоры, сөтне ашханә өчен сорап килсәләр дә, йөзен чыта...

Бәхәс торган саен кызурак, кискенрәк була барды, һәр ике як эксперимент турында, Әгъзәмовның совхозга ни өчен килгән булуы турында бөтенләй онытты, сүз бүтән гомуми мәсьәләләргә күчте. Үзе аяк терәп сорап, бүтәннәрдән таләп итәр өчен килгән Әгъзәмов, ничектер, үзе дә сизмәстән жавап бирергә, акланырга тиешле кешегә әверелде, әйтерсең, «Кызыл шәрык» совхозында, алай гына да түгел, бөтен дөньяда булган барлык житешсезлекләр өчен Әгъзәмов гаепле иде. Болай булгач, аның командировкасы чәлпәрәмә килә бит әле. Казанга кире борылып кайтырга, «Кызыл шәрык»та эш уңмады, агрономнары бер тиенгә яраксыз кеше булып чыкты, дип әйтергә генә кала. Бәхәсне дәвам иттерүнең файдасы юк.

— Бик белдекле булып киттегез әле сез, Анастасия Николаевна. Бар кешедән күбрәк беләсез, күбрәк күрәсез. Ләкин онытмагыз, иптәш Доргунова, киләчәктә дә үзегезне шулай тотсагыз, без сезне жиргә якын да жибәрмәбез,— дип Әгъзәмов сүзне кырт кына өзде. Аның бөтен карашы-кыяфәте гүя: «Дуслык дуслык булып кала, әмма хезмәт бурычын үтәү — беренче чиратта!» — дия төсле иде.

Доргунова әле һаман сүзеннән чигенергә уйламый иде булса кирәк, аның бите бурлаттай кызарган, ул ярсып нидер әйтергә талпына, ләкин Әгъзәмов, сүзне тәмамланганга санап, директорга таба борылып өлгергән иде инде:

— Бүгенгә житәр, мөгаен. Артыкка китмәгәе дим. Кунак өе ерақмы сезнең?..

Әгъзәмов командировкадан кәефе кырылып кайтты, кайту белән бик тә ачулы итеп, тозлы-борычлы приказ чыгартты, анда, «Кызыл шәрык» совхозының баш агрономы Доргуновага соңгы кисәтү белән каты шелтә бирергә, диелгән иде. Бер атнадан ул «Кызыл шәрык» совхозының чәчү мәйданнары структурасы белән яңадан кызыксынып карады һәм, ул тәкъдим иткән структураның расланган булуын күргәч кенә, эченә жылы керде.

Менә шуңа бер ел үтеп тә китте. Һәм хәзер Әгъзәмов былтыргы командировкасының нәтижәсен күрергә дип бара. Сап-сары арыш көлтәсен тезенә салып утырган килеш, Доргунова белән ике арада булган бәхәсне сүзмә-сүз хәтеренә төшерде, ә күңелендә аның торган саен ныграк били барган шатлык, тантана хисе туып ташыды: менә бит, ул хаклы булып чыкты!

Арыш басуы артта калды. Хәзер инде машина барган юлның һәр ике ягында кайчы белән өстән кыркып чыккан төсле тип-тигез булып борчак чәчүлекләре жәелеп ята. Алда, кара-кучкыл бүрекле топольләр арасында, совхоз поселогының шакмак-шакмак ак өйләре күренә башлады. Петрович кинәт машинасын туктатты:

— Яшел борчак, Нигъмәтжан Хәкимжанович! Үлеп яратам шуны! Бераз гына жыйыйк әле?

— Әйдә, жый,— диде Әгъзәмов, риза булып.— Ләкин тизрәк бул.

Петрович кепкасына яшел кузак жыя-жыя борчак арасында йөргән арада, Әгъзәмов, аякларын бераз язып алырга дип, машинадан чыкты да тузанлы юлдан жәяү атлады. Көн инде сүрелә төшкән, кырлар өстендә йомшак кына рәшә челтәре жәйри, зәңгәрсу офык киңлеге, совхоз поселогының йортлары юка болытлар белән өртелгән иде. Әгъзәмов, боларның кайсысы Доргуноваларныкы икән дигәндәй, бер мәл шул өйләргә карап торды. Һәм шунда ук, конторага кереп тормаска, туп-туры Доргунованың өенә барырга, кочагына көлтә тоткан килеш, аны-моны карамыйча, эчкә үтәргә һәм әлеге колтәне шалт иттереп идән уртасына кертеп утыртырга, дип карар итте. Ә Доргунова аны күрүгә, мөгаен,

гаепле кеше сыман тартынып кына елмаер, шатлыктан йөзе яктырып китәр, ә үзе, көтелмәгән кунакка ни хөрмәт күрсәтергә белмичә, кабалана башлар. Һәм алар арасында әүвәлге дуслык-татулык урнашыр... Юкса бигрәк күңелсез килеп чыкты бит.

Киная ул нигәдер моннан күп еллар элек булган, вакыт үтү белән инде тоныклана башлаган вакыйгаларны исенә төшерде.

Ул, авыл хуҗалыгы институты дипломын алып, әле яңа гына совхозның баш агрономы итеп билгеләнгән, мөстәкыйль тормыш башлавына шатланып бетә алмый, моның белән чиксез горурланып йөри торган яшь егет, килүенең беренче көнендә үк кич белән клубка китте. Шактый ук зур һәм гади бер авыл өенә урнашкан клуб ишеге төбендә малай-шалай чыр-чу килә. Стена буена тезеп куелган озын-озын урындыкларга егетләр һәм кызлар утырышкан. Бер егет, авыр итекләре белән идән тактасын сөзә-сөзә, гармунында бию көе уйный, ә залдагы яшьжилкенчәк парлап-парлап идән уртасына чыга да тыпырдап бии-бии, бер-берсенә төрттереп, такмак әйтә.

Әгъзәмов җырга да, биюгә дә катнашмыйча шактый вакыт эре генә кыяфәт белән сүзсез утырды. Киная чандыр гәүдәле чая бер кыз аның каршына килеп чыкты да, идәнгә дөбердәтеп баса-баса, тәкәллефсез генә җырлап җибәрде:

Дорогой, ты дорогой,
Сиреневая веточка,
Ты зачем меня завлек,
Такую малолеточку?!

Әгъзәмов каушап ук калды: аңа, баш агроном кешегә, олы башын кече итеп дигәндәй, идән уртасында бөтерелеп гармунга кушылып такмак әйтеп йөрисе генә калган иде!.. Шулай да ул, минем бит әле бу егетләр һәм кызлар белән бергәләп эшлисем дә бар, үпкәләп-нитеп куймагайлары, дип уйлап алырга да өлгерде. Бүлмә уртасына чыгып, әлеге чая кыз тирәсендә бераз таптанган булды һәм киная, әллә каян килеп чыккан шуклык дулкынына бирелеп, инде күптән үк ишеткән бер такмакны исенә төшерде һәм, гармунчының яңадан уйный башлаганын көтеп тә тормастан, кызга ошатырга тырышып сузып та җибәрде:

Я отчаянный, отпетый,
Ни на что не погляжу,
Если голову отрежут,
Я корчагу привяжу.

Аннары ул кызны озата барды. Алар тынлыкка чумган караңгы өйләр яныннан сүзсез генә атладылар. Әгъзәмов кыз белән нәрсә турында сүз башларга белми интекте. Гадәттә мондый очраклы танышлык вакытында сөйләнә торган юк-барны кабатлыйсы килмәде. Мондыйга аның осталыгы да юк иде. Үзе турында сөйләргә яисә кызның тормышы турында сораштырырга унайсызланды. Өйтүр бакчалы кечкенә генә бер йорт янына җиткәч, алар тукталдылар. Икесенә дә ничектер унайсыз булып китте. Кыз кыюсыз гына аңа күтәрелеп карады, тик шунда гына Әгъзәмов аның керфекләре матур-озын булуына игътибар итте.

«Күзле бүкән» — дип үз-үзен тиргәп алды Әгъзәмов.— Кич буе биегән булдың, озатырга дип алып киттең, ә үзеңнең әле аңардан исемен дә сораганың юк...»

— Ә сез андый түгел,— диде кыз, шыпырт кына һәм көрсенеп куйды.

— Ничек андый түгел?

— Шулай... андый түгел инде...— дип, кыз оялудан башын иде һәм балаларча эчкерсез беркатлылык белән пышылдады:

— Бездә очрашып-танышмас борын үк кочакларга тотыналар, үбешмәкче булалар. Өченче көн Санька Демин бәйләнде генә бит: үбешик тә үбешик! Кулыннан ычкынам ди-ди өстемдәге жакетымны ертып җибәргәнмен...

— Настя,— диде кыз һәм тавышсыз гына көлеп куйды.

— Настя? — Ни өчен икәнен үзе дә белмичә, әйтергә сүз булсын өчен генә кайтарып сорады Әгъзәмов һәм, кызга таба иелә төшеп, аны кочагына алды һәм, аның тыгыз тәненнән, ислемай исеннән башын югалтыр дәрәҗәгә житеп, колак артыннан чупылдатып үбеп куйды.

— Я, менә мин дә... бүтәннәр төсле! — диде ул, кайнар сулышын кызның жакет якасы астына бөркеп.

Настя, аның кулыннан ычкынып, ян капкадан кереп китте һәм болдырга җәһәт кенә йөгереп менде дә шуннан торып:

— Барыбер андый түгел! Андый түгел!..— дип кычкырды.

— Настя! — дип, Әгъзәмов аның артыннан болдырга йөгереп менде, ләкин кыз өйалдына кереп китәргә һәм аның борын төбендә генә ишекне шапылдатып ябып куярга өлгерде. Әгъзәмов чабып менгән жиреннән ишеккә килеп төртелде, ишек шыгырдап куйды, бераз гына ачыла төште, ләкин шунда ук эчке якта келәнең шалтырап бикләнгәне ишетелде.

— Настя, ач әле! Ач инде! — дип пышылдады ул. Ләкин һич көтмәгәндә эчке яктан карлыккан ирләр тавышы ишетелде:

— Ачармын мин сиңа! Дилбегә белән берне тамызсам. Халык йоклый, ә ул тапкан кычкырып йөрер вакыт: ач, имеш!

Әгъзәмов болдырдан ничек төшеп киткәнен, ничек койма аша сикереп чыкканын да сизмәде. Тынычлана төшкәч, үзен үзе ин соңгы сүзләр белән битәрләргә тотынды. Ахмакларча булды. Шунда алыптай бер бәндә килеп чыгып, күз төбенә тамызган булса!.. Кем аркасында дигән әле! Шул кычыткан чыпчыгы аркасында бит! Төкереп бирәсе үзенә...

Үзсүзле егет иде Әгъзәмов. Бәлки хәзер, еллар үтү белән, бераз йомшый төшкән, күндәмрәк, килешүчәнрәк булып киткән булса гына, әмма ул чакларда ул сүзеннән кайта торган егет түгел иде. Теге вакыйгадан соң ул ай буена, көнне төнгә ялгап, бер бригададан икенчесенә чапты, зур хуҗалыкның бөтен нечкәлекләрен өйрәнергә тырышты һәм, шулай итеп, теге хәйләкәр чая кызны да, үзенең аны озата барып, көлкегә калуын да онытты. Ә тагын бераздан очраклы бер сөйләшү вакытында: «Настя Доргунова шәһәргә агрономлыкка укырга киткән икән...» дигән хәбәр ишетте.

Әгъзәмовны «Кызыл шәрык»та озак тотмадылар. Юк, начарлык белән китмәде ул аннан. Эшен ярата иде, белә иде, кирәк вакытта үзеннән олыларга түбәнчелек белән юл куярга да, кирәксә үз фикерен аяк терәп якларга да сәләте житә иде. Эшли башлавына өч-дүрт ел үтә-үтмәс, игенчелек культурасы, чәчү әйләнешләре турында сүз чыкканда аның эшен бүтәннәргә мисал итеп китерә башладылар. Ә күп тә үтми — бәлки бу юлы институт дипломының да файдасы тими калмагандыр, ни генә әйтсәң дә, ул елларда әле югары уку йорты бетергән белгечләр колхоз-совхозларда бармак белән генә санарлык иде,— аны совхоздан өлкәгә эшкә алдылар.

Әгәр Әгъзәмов бер вакыт «Кызыл шәрык»ка командировкага килеп чыкмаган булса, әле без сөйләп үткән кечкенә генә вакыйга, бәлки, еллар үтү белән хәтер түрендә бөтенләй югалып та калган булыр иде. Килгән чакта ул ни өчендер агроном урынында өлкән яшьтәге олысымак кына бер ир кешене очратырмын дип көткән иде. Ләкин аның чакыруы буенча конторага... Настя килеп керде.

Әгъзәмов гажәпләнүеннән:

— Анастасия! — дип кенә әйтә алды, уңайсызланды, әмма үзенең бу халәтен яшерә алмады, кызарынды, телдән язды. Ә Настя, киресенчә, һич ни сиздермәде, оялмады-каушамады, Әгъзәмовны беренче тапкыр күргән кеше кебек, үзен ирләрчә эре тотып, тегенең «Анастасия» дигән сүзенә «Николаевна» дип өстәп куйды.

Әгъзәмов аны күрү белән күңеленнән генә чамалап куйды: Настя,

гә чыгып берничә ел торган яшь хатын кебек, бераз калыная төшкән, е вакыттагы сөякчел кычыткан чыпчыгыннан сөйкемле күзләр һәм ан сыман булып жилкәсеннән асылынып төшеп торган калын чәч то- мнары гына сакланып калган иде. Хәер, күзләре дә үзгәргән бугай — чектер йомшаграк, ягымлырак карый башлаганнар...

Алар, тарантаска утырып, совхоз кырларын әйләнеп чыктылар. Дор- нова атны үзе тотып йөрде, кыска-кыска гына, ләкин төпле, аңлаешлы латмалар биреп барды. Әгъзәмов исә үзе аны тыңлады, кырларны кү- тте, үзе янында утырып барган хатынга карап-карап алды, һәм шул кларда күнел түрендә ниндидер үзе дә аңлатып бирә алмаслык көнче- к хисе кузгалып-кузгалып китүен сизде: әнә бит, ул моннан китсә дә, ләр артка тәгәрәмәгән, бер нәрсә дә ул эшләгән чактагыдан ким түг л. Артыграк, әйбәтрәк булмаса әле... Ул күнеленнән, бу безнең беренче рашуны онытмады микән, минем озата баруымны хәтерли микән, дип рәәлек итмәкче булды, шул ук вакытта күкрәгендә ниндидер бер рсә татлы да, сагышлы да итеп йөрәген тырный, һәм шул ук нәрсә ңа: менә бит син тормыш юлында очраган бик тә мөһим бер нәрсәне тләтеп уздың, ялгыштың, дип әйтергә тели сыман иде. Ул: «Минем онда агроном булып йөргән чакларны хәтерлисезме?» — дип аңардан рыдан-туры сорамакчы, ә аннары сүзне сиздермәстән генә әлеге теге лубта булган кичәгә, үзенең кызны озата китүләренә борып жибәр- әкче булды, әмма алай итә алмады, малайларча уңайсызланып кына: Алай икән... Шуннан... Бик әйбәт...» — дип аның сүзен жөпләп барудан үтәнгә кыюлыгы житмәде.

Ул совхоздан үзе дә ахыргача аңлап житкермн торган каршылыклы йлар белән китте. Шуннан соң да ара-тирә «Кызыл шәрык»ка барып өрде. Рәсми документлар буенча килүенең максаты командировка бу- ып саналса да, чынлыкта аны бирегә кадерле дә, сагышлы да булып иткән күптәнге хатирәләр тарта иде. Доргунованың ире совхозның ве- еринария технигы, кинә күнелле, ачык чырайлы кунакчыл бер кеше булып чыкты. Әгъзәмовның һәр килеп чыгуы алар өчен зур бер вакыйга була иде. Алар аны кунакка чакыралар, авыл мунчасы ягып кертәләр, кыярга бал ягып сыйлыйлар, самоварны ишек алдына алып чыгып авылча иркенләп, озаклап чәй эчәләр һәм таң әтәчләре кычкыра башла- ганчы әңгәмә корып утыралар иде.

Әгъзәмов соңга калыбрак булса да Доргунованы һаман тирәнрәк аңлый барды, күргән саен аның яңадан-яңа әйбәт сыйфатларын ачты, ңар сокланды һәм үзенең жирне ташлап шәһәргә күчеп китүенә үкенә торган булды. Кайчак хәтта ышанасы да килми: теге вакытларда клубта аның каршында аякларын тыпырдатып көлке такмаклар әйткән, бездә егетләр беренче очрашуда ук үбешмәкче булалар, дип зарланган чая кызчык шушы идемени соң, шуны озата бардымыни соң Әгъзәмов? «Настя, ач инде!» — дип ишек ярыгыннан шуңа пышылдадымыни?! Мондый командировкалардан соң Әгъзәмовның күнелен озак вакыт ниндидер аңлаешсыз пошынулар биләп йөри, һәм бу пошынулар, торып- торып, тормышның ничектер чатаграк килеп чыгуына, ул теләгәнчә бул- мавына тәмам ышану булып әверелә иде.

Доргунова үзе дә Әгъзәмовның күнелендә ниләр булуын сизенә иде кебек, әмма алар икесе дә, алдан сүз куешкандай, бу турыда ләм-мим бер сүз әйтмиләр иде. Хәер, әйтеп хәзер нишлисең инде? Доргунованың үз гаиләсе бар, Әгъзәмовның — улы, кызы...

Ә менә үткән ел боларның барысы да челпәрәмә килде. Әй, юләр кеше дә соң ул Әгъзәмов! Нигә дип инде сүзне директор барында баш- ларга иде? Доргунова белән икәүдән-икәү генә калып утырырга иде дә бар нәрсәне дусларча тату гына хәл итәргә иде. Юк бит, ул начальник- ларча кыланган булды, ә Доргунова — туры сүзле, үжәт холыклы ха- тын, үзен үз жирендә хуҗаларча хис итәргә күнеккән, кеше кубызына

бии торганнардан түгел,— менә шуннан китте инде бәхәс-тартыш... Ул көнне Әгъзәмов озак еллар таныш булып йөрүләре дәверендә беренче тапкыр кунарга алар өенә бармады, совхозның кунак йортында төн үткәрде һәм, үзенең бик зур хата эшләвен аңласа да, совхоздан киткәндә аларга саубуллашырга да кермәде.

...Әгъзәмов, ашыкмый гына совхоз поселогына таба атлый-атлый, эченнән былтыргы ызгышка бүген, ниһаять, чик куелачагына һәм эшнең нәкъ ул теләгәнчә барып чыкканлыгына чиксез шатлана иде. Менә хәзер ул совхозга барып җитәр дә Доргунованы өеннән алып чыгып машинасына утыртыр һәм менә шушы басуга алып килер. Алар киң ашлык диңгезе эченә кереп китәрләр, һәм алар өчен бу дөньяда үзләреннән башка беркем дә калмас. Тик алар икәү, менә бу чиксез киң башак диңгезе һәм күз ачкысыз якты кояш.

— О-о!.. Бик нык хыялга чумдыгыз бугай, ахрысы!

Әгъзәмов сискәнеп китте, артына әйләнеп карады. Арттан артык гүләмичә генә машина килә, ә Петрович кабинасыннан башын чыгарган да көлә-көлә борчак кузагы ашый.

— Менә мин килеп тә җиттем. Утырасызмы, Нигъмәтҗан Хәкимҗанович?!

Әгъзәмов машинаның арткы урындыгына утырды һәм шоферга тупатуры Доргуноваларга барырга кушты, хатирәләр белән күңеле тәмам чуарланган булганга, бүтән бернәрсә дә әйтмәде.

Көн узып бара. Кояш кызуы сүрелә төшкән. Ул үзенең бөтен эссесен такта коймаларның, йорт-каралтыларның җиләс күләгәләрендә сүндереп бетергән дә хәзер үзе дә аргы басулар артына тавыш-тынсыз гына кереп качарга җыена кебек иде. Машина поселок урамыннан, озын муенлы кое сиртмәләре һәм водопровод колонкалары ягыннан чабып үтте. Менә яңа гына салынып беткән клуб та артта калды. Клуб сүз әйткесез әйбәт: үзе биек, үзе янып торган кызыл кирпечтән салынган. Ләкин Әгъзәмовка, нигәдер, яшьлегендә ул такмак әйтеп биегән элекке авыл өендәге клуб әйбәтрәк иде төсле тоелды.

«Искене аударалар, яңаны үстерәләр,— дип уйлап алды ул.— Элекке клуб та калмаган, һәм менә Настя да! — уйласаң исең китәр! Оялчан, чая кызчык акыллы, җитди агроном булган. Әгъзәмов үзе зур урындагы кеше булып китте, ә узган гомер инде узган, буласы эш булган, дигәндәй, аларны кире кайтарып булмый»...

Петрович машинаны таныш йорт янына китереп туктатты. Рәшәткәле җиңел ян капка җилдән сизелер-сизелмәс кенә селкенеп тора, зәңгәргә буялган өй тәрәзәләре өстенә саргая башлаган антоновка алмалары иелешкән. Менә хәзер болдырга йортның хуҗасы Настя үзе йөгереп чыгачак... Әгъзәмов машинадан яшьләрчә житез генә чыкты һәм ян капканы этеп ачты да... тукталып калды. Болдырга ана һич таныш булмаган тәбәнәк буйлы, какча гәүдәле бер карчык басып тора, ә аның киң күлмәк итәгенә чатан аяклы, таза гына бер ыштансыз малай ябышкан иде.

— Хуҗалар өйдәме? — дип сорады Әгъзәмов.— Анастасия Николаевна кайда?

— Юк ул,— диде карчык төссезләнгән сирәк керфекле күзләрен йомгалап.— Монда хәзер Сибгатуллин дигән кеше яши, совхоздагы иң зур агроном. Мин аларда бала караучы булып торам...

— Тукта әле, әбекәй,— дип аптыраган кыяфәт белән Әгъзәмов аның сүзен бүлдерде.

— Нәрсәсен туктыйсың инде аның? — Карчык һаман шул тыныч тавыш белән сөйләшә иде.— Настасья Николаевна юк монда, эшеннән алдылар аны. Фатирын да бушатырга куштылар.

— Ничек инде эшеннән алдылар? Ни өчен? — диде Әгъзәмов һаман ерни аңламыйча.

Карчык, моңа исе китмәгәндәй, кытыршы куллары белән авызын өртеп куйды.

— Икенче фатирга күчеп китте ул. Әнә теге очта фатиры, тегермән ртында, беләсеңдер бит тегермәнне? — дип, ул поселокның аргы ба-ына таба күрсәтте.— Үзеннән өстен булган бер зур начальник белән әхәскә кергән имеш тә, тегесе «аны җиргә якын жибәрмәскә!» дип әмер ыгарган икән, диделәр. Шуннан соң ул тотты да кооперативка күчте. Мин кызганам аны, бахырны, бик тә акыллы хатын иде, югыйсә...

«Доргунова хәзер агроном түгел?!. Фатирны бушатырга куштылар?!. Кооперативка урнашты?!. Нәрсә булган соң аңа?..» Һәм ул конторага директор янына китте.

Директор, нормалар һәм алар өчен түләүләр белән килешергә телә-әгән төксе чырайлы бер агай белән кызу-кызу бәхәсләшеп, телефон янында утыра иде. Агай мәгънәсез бер үҗәтлек белән директор өстәле каршында таптана, өстәлгә җәелгән яшел постауга кепкасы белән суга-суга, нормалар адәмгә әйтеп адәм ышанмаслык югары куелган дип шау килә: янәсе, тырышсаң да, тырышмасаң да аларны барыбер үтәп булмаячак. Директор исә, счет төймәләрен шалт-шолт суга-суга, монын нәкъ киресен расларга тырыша: совхоздагы эш нормаларын синең ише типсә тимер өзәрлек таза ир кеше генә түгел, теләсәң кайсы хатын-кыз да үтәрлек,— ди. Әгъзәмовның килеп керүен күргәч, ул, елмаеп, озаклап аның кулын кысты. Директорның Әгъзәмовка ягымлы караган күзләре: «Рәхмәт инде, килә белгәнсез!» — дия иде.

— Ә син бүтән вакытта кер, шунда хәл итәрбез,— диде директор әлеге гаугалы агайга һәм тегене бүлмәдән чыгарып жибәрергә ашыкты.

Әгъзәмов башта сөйләшүне булачак уңыш турында башлап, аннан гомуми мәсьәләләр хакында берничә сүз әйтергә һәм сүз уңаенда, сездермәстән генә, былтыр булган хәлләргә күчәргә теләгән иде, әмма үзе дә абайламастан кырт кына әйтеп ташлады:

— Доргунованы ни өчен эшеннән алдыгыз?

— Анастасия Николаевнанымы? — диде дә директор авыр көрсенеп куйды. — Бүтәнчә нишләргә иде соң? Аның бит үз сиксәне сиксән. «Сез миңа, янәсе, ышандырып бирегез, шунда гына риза булам». Төрлечә маташып карадым инде мин, үгетләдем дә, кисәттем дә,— ә ул һаман үз ягын каерды...

— Нигә, кешенең үз фикере булырга тиеш түгелмени? — дип, түземсезләнеп сорады Әгъзәмов.

— Кемгә хаҗәт аның үз фикере? Һәркем үзе теләгән якка тарта башласа — беләсезме, нәрсә, килеп чыгар иде? — Директор инде көрсенми, аның тавышында кырыслык сизелә башлаган иде.— Менә үзегез дә күрдегез бит әле, күз алдыгызда берәү бәхәсләшеп маташты. Аның да, әйтергә кирәк, үз фикере бар. Ярый, мин ул таләп иткәнчә эшләдем ди? Нинди директор инде мин шундый хәлдән соң? Мине эштән куарга гына кала!.. Менә Доргунова да шундый. Үгетләү керми андыйларга, аларны каты кул белән генә жиңеп була. Эшкә комачау булмасын өчен урыныннан алырга туры килде үзен.

Әгъзәмовның, кешене үз фикере булганы яисә булмаганы өчен генә бөтенләй чыгарып ташлау, яраткан эшеннән мәхрүм итү, квартирасыннан куу — бу бит ахмаклык, бу гаделсезлек,— дип кычкырасы, бу турыда миңа телеграмма бирергә, һич югында, тотарга да телефоннан шалтыратырга кирәк иде, шулай иткәндә без ул үзсүзле Доргуновага күл селтәгән, эксперимент өчен бүтән бер хуҗалык тапкан булыр идек,— диясе килде. Әмма директор аның бу теләген анламады, күрмәде, аның күзенә түбәнчелек белән караган килеш, авыл хуҗалыгы министрлыгыннан килгән кәгазьдән чыгып эш итәргәме, әллә Доргунованы саклап

калыргамы икәнен белмичә күпме вакыт баш ватуын, Әгъзәмовның үзенең күрсәтмәләрен дә, әлеге кәгазьдәге шелтәне дә игътибарга алуын һәм, шуларның барысыннан да чыгып, нихаять, агрономны эшеннән азат итү турындагы приказга кул куюын бәйнә-бәйнә сөйләп китте.

Әгъзәмов хәзер инде кычкыруның да, өстәл сугуның да файдасыз икәнен, берни бирмәячәген аңлады. Ярый, Доргунованы эшенә кире кайтарып та булсын ди, ләкин булган хәлне кеше хәтереннән сызып ташларга мөмкинме соң? Ул, директор белән саубуллашып та тормастан, Доргунова янына ашыкты. Ни өчен дип китте? Бу сорауга ул үзе дә тәгаен генә җавап бирә алмый иде: киттеме — китте... Машинаның арткы урындыгына утырган килеш, ул Петровичка мыгырдап әйтеп барды: «Менә хәзер тыкрык. Кое. Тегермән». Тагын эченнән генә чамаларга тотынды: килү белән башта кире холыклы кеше булганы өчен Доргунованы ныклап торып тиргәячәк, аннары аны әлеге-теге кооперативыннан чыгартачак. Анда, тавык йомыркасы хәзерли торган җиргә, ниемә дип барып кергәндер? Ахмаклык лабаса бу! Ул хатынны теләсә кая алган булырлар иде... Нинди әйбәт белгеч бит!..

— Юл уңа болай булгач,— диде Петрович, башы белән алга таба ымлап.— Әнә бер хатын коедан чиләк тутырып су алып маташа...

Чыннан да, алар барган урамның аргы башындарак урнашкан кое янында яшьрәк кенә бер хатын тулы чиләкләрне көянтәсе белән элә-төреп алды һәм өгәүдәсен турайтты да якынлашып килүче машинага таба борылды. Әгъзәмов аны шундук танып алды — Доргунова! Һәм кинәт аны курку биләп алды. Нәрсә дип әйтер соң ул аңа? Хәл-әхвәл сорашырмы? Гафу үтенерме? Яңа эше белән кызыксынырмы? Шул гына калган иде!..

Менә алар сөян бүрәнәләрдән өелгән бура яныннан үттеләр, менә тигез рәт булып үсеп утырган топольләр дә, яфракларын шыбырдатып серләшә-серләшә, артта калдылар, менә өч йорттан соң тагын тыкрык, ә тыкрыктан соң кое... Әгъзәмов күзләрен йомды һәм бер кулы белән тыкрыкка таба күрсәтте.

— Шунда борыл, Петрович!

Поселоктан чыккач, Әгъзәмов машинада яткан көлтәне яңадан тезләренә куйды, битен башаклар эченә яшермәкче булды. ләкин кинәт ишекне ачты да көлтәне тузанлы юл өстенә ыргытты. Петрович, газны киметә төшеп, артка борылды һәм Әгъзәмовка сораулы караш ташлады.

— Әйдә, район үзәгенә тот,— диде Әгъзәмов кыюсыз гына.— Һәм битенә кызулык йөгергәнен сизгән хәлдә, ялган оештырырга мәҗбүр булды: — Онытып җибәрә язганмын, безгә райкомга керергә кирәк бит.

Петрович газны арттыра төште, машина кинәт тартылып алга ыргылды, тәрәзәләргә авыр башаклар бәрелә башлады. Әгъзәмов, арткы урындыкта тирбәлеп утырган хәлендә, әле моннан ике сәгать элек кенә үзе карап узган арыш басуларыннан күзен ала алмыйча барды. Ләкин теге вакытта аның күңелен биләгән тантаналы шатлыкның хәзер әсәре дә калмаган иде. Кем өстеннән тантана итәргә тиеш соң ул? Доргунова өстеннәнме? Ә нигә ул, ягъни Әгъзәмов, тантана итәргә тиеш? Эш урыны югарырак булган өчен генәме? Минем әйтүем булды — аларның минемчә эшләүләре булды,— дипме? Ләкин тантана итәрлек сәбәп бар микән соң әле монда? Менә бу авыр башаклар, басуда игеннәрнең күкрәп утыруы, бәлки, елның уңай килүеннән генәдер, яңгырлы булуыннандыр? Ә аның, Әгъзәмовның, моңа, бәлки, бернинди дә катнашы юктыр? Җирдә, иген басуында бер ел әле бернәрсә дә хәл итми, киләсе көздә, аның сонгысында ни буласын белгән юк бит әле... Ә Доргунова акыллы хатын, кооперативта эшләп булса да үз совхозында калган, киләсе елны көтәсе, экспериментның ни белән бетәсен үз күзе белән күрәсе килгән аның. Ә киләсе көзнең ниндирәк булачагын кем әйтә алыр икән? Әгъзәмовмы?

Әхияр Хәкимов

ГОМЕР

ХИКӘЯ

Язгы кояшка изрәп, тимгел-тимгел булып карала башлаган кар яланына караган да Мансур, күзе камашудан уң кулы белән маңгаен күләгәләп, аклан читендәге калкулыкны күзәтә. Яшь чаган, төлҗимеш, имән үсентеләре әле бер, әле икенче урында капыл хәрәкәткә килә, өермә бөтереп алган төсле чайкалып, кайнап китә дә, кар өстенә ут йомгакларыдай ике төлке атылып чыга. Менә ике йомгак бергә кушылып, тәгәрәп китә, алар ауналган төштә кар тузаны куба. Бераздан төлкеләр җан-фәрман куышып, вак куакларны кыштырдата-кыштырдата, тагын урманга китеп югалалар.

Мансур күзен кысып елмая. Менә ул, әллә язгы кояш җылысының кичәле-бүгенле бермә-бер артуына кинәнеп, әллә төлке уенына мавыгып эшен онытканга: «Эх!» — дип куя. Борылып, кояшка аркасын куеп утыра да тагын үз эшенә тотына.

Кулындагы озынча агач кискәсе түгәрәкләп юнылган, нәзегрәк башына калын резин беркетелгән. Хәзер ул шушы кискәне — яңа агач аягын — пыяла белән кырып шомартып утыра. «Мәшәкате күп әле моның»,— дип уйлый Мансур. Өйгә кергәч, үрелеп, киштәдән алюминий саплы озын безне ничек аласын, аны учакта кыздырасын, кып-кызыл булып кызган без белән агачны әче төтен исе бөркетеп тишәсен күз алдына китерә. Бу эшләрне карангы төшкәнче тәмамларга кирәк. Гөлниса кайтуга өйдә чүп-чар да, төтен исе дә калмасын. Учакны да, бер көйрәткәч, сүндермәскә иде. Чуен чүлмәк белән бәрәңге пешерергә куйсам, тап-таман булыр, дип уен дәвам итә Мансур. Гөлниса авылга барган көндә буш кул белән кайтмый торган иде, кибеткә сугылыр, мөгаен. Базга төшеп тозлы кыяр алып чыгарга, төшке аштан калган итне турап куярга... Гөлниса итне вак тураганны, суык көе табынга куйганны ярата. Хатынының, бит алмаларын уелдырып: «Вәт үземнең картым, ичмасам! Уңган киленнәрең бер якта торсын!» — дип көлүенә хәтле күз алдына китерә Мансур.

Бүре хәтле Сарбай, аш-су турындагы уйларын сизгән төсле, кояшка кызынып яткан җиреннән торып, киерелә-сузыла Мансур янына килде,

күзен мөлдерәтеп, аңа карап торды да, игътибар итмәгәнне күргәч, нидер эзләп лапаска таба китеп барды.

Мансур һаман хәтер йомгагын сүтүендә булды. Агач кискәсен җиренә җиткереп шомартып бетерсә дә, һаман җай гына кыра-кыра, ул эле уйлары белән ераклarда йөри, кузгалырга ашыкмый иде. Гөлнисасының соңгы вакытта сәеррәк кылануын исенә төшереп, кашын җыерып, зиһенен барлый башлады.

Сәер дип, күзгә күренгән әллә ни үзгәреш юк. Гөлниса ирләр кебек эшләп йөри, бәйрәм булса, аяк тибеп күңел ача, кыскасы — барына канәгать булып тормыш итүче, урыны белән алчак, урыны белән мыжгый торган авыл хатыннарыннан бер ягы белән дә аерылмый. Тик Мансур бу араларда күңеленда нинди бер борчылу барлыгын тоя. Әйтергә, уртага салып сүз башларга сәбәбе юк. Әйтмәсә дә тәкате корыган. «Юктан гына рәнҗетермен, күңелен биздереп куярмын», дип уйлый Мансур, сабырлыгын җыеп көтә...

...Уйласаң, егерме ике ел бергә гомер ителгән. Кырык җиденче елның җәендә, Мансур култык таягына таянып кайтып төшкән чакны, Гөлниса әлерәк кенә егерме өч яше тулган, йөрәген сугыш ялкынына көйдереп өлгергән тол хатын иде инде. Сөеп-яратып, үсмер көе диярлек барган Фәтхелисламы Сталинград янында үлеп калды. Фәтхелисламның атасы хезмәт армиясеннән кайтмады, әнисе кайгы йөген күтәрә алмый дөнья куйды. Болын кебек зур өйгә хуҗа булып, килен япа-ялгызы торды да калды.

Сылу, уңган, яшь хатынга күз салучы булмыймы? Булды. Булды күз салучылар, соратучылар да булды. Тик Гөлниса Фәтхелисламын оныта алмады, уенлы-чынлы әйтелгән иркә сүздән, оят кинаяләрдән тәне, рухы рәнҗеде, ир-атның бәйләнүеннән котылу әмәле итеп төртмә теллегә әйләнде. Бернигә дә исе китмичә, башын иеп кенә эшләп йөргән тол киленчәкнең төннәр буе йоклый алмый елап чыгуын, рухын тетрәтеп чакырган табигать авазына каршы торырдай көч тапмый газаплануын берәү дә белми иде шул. Түзмәде Гөлниса, эченә сыеша алмаган сагышны ахирәте Әкълимәгә бушатты. Әкълимә аны үзе белгәнчә юатты. «Яудан кайткан егетләрнең берәрсе белән танышып, йортка керт, гомер буе ялгыз тормассың бит инде»,— дип киңәш итте. Гөлниса аның киңәшен тотмады, әмма сер чишүенә үкенергә туры килде!

Кул ярасы төзәлә, күңел ярасы төзәлми, диләр. Моның шулай икәнлеген Гөлниса гомергә онытмаслык итеп татыды. Хәер, нәкъ менә шул вакыйга аны Мансур белән очраштырды да...

...Сугышта Мансур ике мәртәбә яраланды. Икенчесе Берлинга җитәрәк булды һәм ул аны сыңар аяклы итеп калдырды.

Госпитальдән ул озак кына хат язмады. Күршесе — олы яшьләрдәге авыр җәрәхәтле солдат — Мансурның хәлен аңлагандай: «Яхшы түгел, Мансурка, ни үзең хат язмыйсың, ни сиңа бер кемнән дә хәбәр юк. Ярамый алай, син әле яшьсең, сыңар аягың юк икән — ике кулың бар, башың сау»,— дигәч, ул Әкълимәгә — дүрт ел буе кайнар хисле мәхәббәт хатлары язып торган кызга — чын дәресен язып җибәрми булдыра алмады.

Җавап Мансур көткәннән тизрәк килде. Ул калтыранган куллары белән конвертның читен ертты, хатны бер тын күкрәгенә кысып ятты да дүрткә бөкләнгән кәгазь битен сак кына ача башлады. Әкълимәнең тәүге сүзеннән үк Мансур эсселе-суыклы булып китте: хатта «Җаным Мансур!» дигән гадәттәге ике сүз юк иде, «Мансур!» дип кенә куелган иде.

Калганын укып тормаса да аңлашыла иде инде. Мансур, хатны йомарлап, башын мендәргә кысты. Күпмедер яткач, торып утырып,

хатны бөтенләй укып чыкты, тик сүз белән әйтеп булмастай гарьләнү, үпкәләү, рәнҗү тойгысы аның аның томалаган иде. Юк, Әкълимә аннан йөз чөермәгән, кайтырга кушкан. «Язмышым шулдыр, туемда синең белән парлап биергә язмагандыр. Авылда сыңар аяклы син генә түгел, без дә бер әмәлен табып яшәрбез...» — дигән. Бахыр кыз, ни уйласа, шуны яшермн, иң якын кешесе итеп үкенеч-эрнүен язган да салган, тик горур табигатьле егет күтәрә алмады аның бу үкенүсн.

Суына төшкәч: «Әкълимәгә имгәк булырмын, әйләнгән саен агач аягыма карар да йөрәге сыкрар, жәлләр...» — дип уйлады. Атна буе кара көеп яткач: «Ирек үзеңдә, Әкълимә, вәгъдәңне кире кайтарам, көтмә мине»,— дип хат язып салды. Озакламый, госпитальдән чыгып, Оренбург ягына китеп барды. Авылга кайтмаса да, Башкортстанына якынрак буласы килде.

Ике елга якын заводта эшләде, үзе кебек яшь фронтовиклар белән эшчеләр торагында торды. Кыйгач кара кашлы, томрап торган кара бөдрә чәчле чибәр егеткә игътибар иткән кызлар булмады түгел. Ләкин Мансур жаны-тәне белән туган авылында иде. Уеннан Әкълимә китмәде, ятса төшендә, торса күңелендә булды. Башка якын кешесе юк иде аның авылда, хат-хәбәр алышмады, шулай да йөрәге тойды: Әкълимәне мәңгегә югалтуы иде бу...

Жир йөзендәге иң куәтле көч, мөгаен, туган туфрактыр. Мансур күңеленнән күпме генә карышмасын, авылын күпме онытырга тырышмасын — булдыра алмады, жинелде. Жай гына эшләп яткан жиреннән кинәт завод белән исәп-хисабын өзде дә, дус-ишен, үзенә гашыйк булып йөргән кызларны аптырауга салып, авылга кайтты да китте. Сагынуының чиге юк иде. Күңеленең иң ерак тирән бер почмагында тагын бер хис көйри иде. Ихтимал, Әкълимә көтәдер аны, ярдәмемә мохтаждыр, сугыш аякка бастырган, кешеләрне юлаучы ясаган чиксез Рәсәй буйлап аны Әкълимәнең хатлары эзлидер, дип уйлый иде Мансур. Шулай уйлый да, һәр багана янында диярлек туктап торган поезддан сикереп төшеп, жәяүләп кайтып китәрдәй була иде...

Район үзәгеннән ул юл уңае туры килгән, шылтырап таралыр хәлгә житеп тузган машинага утырып кайтты. Төш авышып барган чакта туган авылы турысында төшеп калды.

Күз бәйләнергә байтак вакыт бар — Мансур ирексездән авылга түгел — урманга таба атлады. Урман ярыйсы ук сирәгәйгән, жирдән бер аршын калдырып киселгән агач төпләре әле тегендә, әле монда сереешеп утыра. «Нигә болай кырыктылар икән?» — дип уйлады Мансур. Бу агачларны билдән көрт ярып, карын көрәп-нитеп тормастан, ашык-пошык, кача-поса аударган хатын-кызны, бала-чаганы күз алдына китерә алмый иде әле ул. Боларын соңыннан белде, сугыш вакытында имгәтелгән урманны терелтү үз өстенә төшкәч аңлады.

Урман юлыннан сак кына кырга тайпылып, Мансур бәләкәй генә бер акланга барып утырды. Бик нык йончылса да, тамагына ризык бармады, аннан-моннан капкалады да чемоданын биклөде. Кичәле-бүгенле генә чабып ташланган печәнне өештереп, сузылып ятты. Бөтен рухын ниндидер хозурлык биләп алган иде. Борынын печәннең хуш исе кытыклый, колагында кыл аваздай нечкә тавыш чыңлый, ә өстә чиксез киңлек, уй житмәс иркенлек! Шушымы икән әллә Ватан тойгысы? Ни жаның белән ят жиргә китә алдың, солдат? Рухыңны рәнжеткән әрнүеңне туган туфрагыңнан башка нәрсә баса алсын? Иненнән авыр йөк төшкән, морадына ирешкән кеше сымак Мансур тирән итеп тын алды, бите буйлап аккан күз яшьләрен сөртте дә тынычланып оеп китте.

Күпме вакыт үткәндер — ул арба шыгырдаган тавышка уянды. Менә арба туктады, ат пошкырганы, хатын-кызның дәррәү көлешкәне, нидер сөйләшкәне ишетелде. Солдат кузгалырга ашыкмады, күзен ачып, тавыш килгән якка карап ята башлады. Ун-унбиш адымда гына бнек

итеп яшел печән төялгән йөк тора. Аның тирәсендә биш-алты кыз тук-таган. Мансур капыл торып утырды. Өнемме бу, төшемме дигәндәй, күзләрен угалады. Йөк башында утырган олаучы — Әкълимә иде. Менә ул нидер дәште (Мансур ишетми калды, тик Әкълимәнең яман сүз әйтү-ен генә абайлап өлгерде), җиргә сикереп төште дә, бөреләнә таянып, кызлар алдына барып басты.

Әкълимә! Шул ук бердән үргән калын, озын толым, шул ук килешле, базык сын. Тик нигә соң әле ул шулай кычкырына, нигә куркышып бер-берсенә сыенган кызларны тукмардай булып чәпчи? «Әкълимә, мин кайттым, мин монда!» — дип аваз бирәсе килә Мансурның, ә Әкълимә-нең ямьсез сүзләре аны җиргә сеңдерә.

Ул арада булмады, Әкълимә биш-алты кыз арасыннан берсен бела-геннән эләктереп үзенә тартты, аның чәч толымын кулына урап:

— Менә сиңа, кәнтәй, менә! Минем иремнән башка ир-ат беткәндер шул сиңа! «Әхмәтҗан агай да Әхмәтҗан агай!» дип күзеңне уйнатмасаң аның алдында!..— дип кызны тукмый башлады.

Башка кызлар, чәрелдәшеп, кайсы кая йөгерде, ә тегесе, башын иеп, учы белән битен каплады да җиргә чүгәләде. Мансур, һични аңламаса да, бу кыргый күренешкә түзеп кала алмады, урынныннан сикереп торып, аксаклый-аксаклый, биш-алты сикерүдә Әкълимә янына барып басты.

— Әкълимә!..— дип эндәште ул, тамагы карлыгып.— Их, Әкълимә...

— Абау, Мансур дисәм... Абау...— дип, тегесе, «корбанын» кулыннан ычкындырып, сыгылып төште.

Котлары очып читтәрәк торган кызлар, хәвефнең үтүен тоеп, берәм-берәм болар тирәсенә җыела башлады. Берничәсе Әкълимә тукмаган олырак кыз янына чүгәләде. Мансур үзенә кызыксынып карап торган уналты-унҗиде яшьлек кызларны, танырга тырышкандай, күздән кичер-де. Юк, танырлык түгел, ул киткәндә сабый бала гына булган бит әле алар, ә хәзер әнә ничек үсеп, яшь агач үсентеләре сымак, буйчан булып киткәннәр. Тик өс-башын рәтләп, тузгыган чәчен үреп утырганы гына таныш төсле. Әйе, әйе, ул бит сугыш башланган елны гына үрге оч Фәтхелисламга качып чыккан Гөлниса лабаса! Фәтхелисламның язмышын моңарчы белмәсә дә, Мансур шундук аңлады: бу бахыр да яшьләй тол калган, бәхетсез хатыннарның берсе...

Берничә минутлык авыр тынлыкны Әкълимәнең сулкылдап елавы гына бозды. Менә ул җай гына урынныннан торды, аты янына атлады. Йөк өстенә менеп утыргач, капыл ниндидер чая бер ашкыну белән:

— Ә-әй! — дип кычкырды да ирләрчә киерелеп атына сукты.

Сикәлтәле урман юлында йөкне дөбер-шатыр китереп, ат авылга ка-рап чапты...

...Әнә шулай очрашкан иде Мансур беренче мәхәббәте белән һәм шу-лай хушлашкан иде.

Кызлар, яшь булсалар да, олыларча фәһемле булып чыктылар. Мансурны таныгач, уратып-суратып, хәтерен аяп, аның авылда борын төртер кешесе калмавын, бердәнбер җиңгәсенең дә бәхет эзләп калага күчеп китүен, йорт-җиренең сатылган булуын аңлаттылар. Һәркайсы: «Безгә төш, агай!» — дип үз өенә чакырды.

Авылга кояш баеганда гына кайтып керделәр. Кызларның ай-ваена куймыйча, Мансур үзләренә ут күрше булып яшәгән Сабит картның ишеген шакыды.

Авылын никадәр сагынмасын, атна-ун көн вакытта Мансур күнегә алмый интекте. Һәркем аны җәлләде, Әкълимә белән аралары бозыл-ганга кызганадыр кебек тоела аңа. Алдагы көндә тормышын ни рәвеш-лерәк җайлап җибәрү, ниндирәк эшкә тотыну хакында баш ватмый мөмкин түгел иде.

Шулай уйланып йөргән чагында аны авыл Советына чакырттылар. Совет председателе — сыңар жине бил каешына кыстырылган, тап-такыр итеп кырылган ялтыр башлы кеше — Мансурның сәламен ияк кагып кына алды да күптәнге әңгәмәне дәвам иткән төсле:

— Тәк, тәк... Моратов Мансур, егерме икенче елгы, белеме — тугыз класс,— дип сөйләнә-сөйләнә, ниндидер кәгазьләрен актара башлады.— Әһә, менә,— дип куйды. Эзләгәнен тапты шикелле.— Хәрби исәптән төшерелгән... Әйе... Ну бит, малай, икмәк исәбеннән төшереп булмый кешене. Кыскасы, иртәгәдән эшкә!

Председатель, урыныннан торып, үз өстәленә каршы сул як почмакта торган икенче өстәл янына барып басты.

— Менә, синең урын шул булыр! — дип, стенага беркетеп куелган «Секретарь» дигән пыялалы язуга шапылдатып сугып алды.

Күңеле ятмады Мансурның бу эшкә. Җае чыккан саен председательгә белдерә торды һәм, азак килеп, Гөлниса белән очрашып вәгъдәләшкән көннәрне урман эшенә күчеп китте.

Ә очрашулары болай булды.

Мансур авыл Советы эшләре белән районга барган иде. Кайтышлый жәяүләп каладан кайтып килгән Гөлнисага тап булды.

— Утыр, Гөлниса! — дип атын туктаткан иде, тегесе:

— Куй, куй, Мансур агай! Болай да муеныма теләсә кемне асарга торалар. Парлап авылга кайтып төшсәк, сиңа да сүз тияр...— дип якын да килмәде.

Чак күндерде аны Мансур. Биш-алты чакрым эндәшми бардылар. Шуннан капыл Гөлниса борылыбрак утырды да:

— Әйт әле, Мансур агай, теге вакыт Әкълимәнең сүзенә ышандыңмы? — дип сорады.

Тагы Әкълимә! Күпме онытырга тырышмасын, арына алмый Мансур аңардан. Я көтмәгәндә Әкълимә үзе очрап куя да, башын иеп, адымын тизләтә, я башкалар, теләпме-теләмичәме, аны исенә төшереп торалар. Ә егетнең сулкылдаган йөрәк ярасы тагын ачыла. Әле дә, шушы хискә бирелеп, ул хәтта жавап бирергә дә оныткан икән.

— Шулай булмый тагы — ирсез хатынга кем ышансын инде,— дип куйды Гөлниса.

Мансур, кабаланып, акланырга, Гөлнисаны һич кенә дә гаепләмәве, киресенчә, хәтта берәр гаебе булган тәкъдирдә дә аңа тел-теш тидерергә хакы юклыгы турында сөйләргә кереште.

— Юкка тырышасың, Мансур,— диде Гөлниса, егетнең сүзен бүлеп.— Бүренең бит ашаса-ашамаса да авызы кан. Эш гаептә генәмени? Намус-вөжданым нихәтле пакь булмасын — барыбер ышанмыйлар, алдан искәртү рәвешендә юк гөнаһны бар итеп беркетеп куялар. Ә минем күңелем, теләк-өметләрем кайда? Кайсы чакта, Әкълимә ише бәхетенә исергәннәргә үч итеп, бер көнлек кысыр куаныч артыннан жәһәннәмгә китәр идем, дип уйлыйм. Юк, йөрәкне алдап булмый... Безнең язмышларга шулай ук гомерлек кара печать сугылганмыни?

Икесе дә уйга калды. Гөлнисаның соңгы сүзләре егетнең хәтерендә ерак истәлекләрне яңарткан иде. Гөлниса кебек үк япь-яшь көе якты хыялларын сугыш таптап узган икенче берәү — белорус кызы Данута да: «Гитлер кара печать сукты безнең язмышка. Сынганны ялгап, яңа бәхет корырга батырчылык итүе, ай-һай, авыр!» дигән иде аңа. Исәнме икән, иле-йорты өстеннән үткән канлы гарасаттан котылып калдымы икән Данута? Ни кылсын адәм баласы — исән булса, сыныкъ язмышын ялгау әмәлен тапкандыр. Ә бәлки, сөлектәй сылу, сап-сау көе тереләй утта янган менә Гөлниса сымак, ул да жәфа чигадер.

Данута, Данута... Аны исенә төшерү белән Белоруссия урманнары, гитлерчылар белән беренче канлы бәрелешләр күз алдына килде. Ул үзен, шушылай тарантаска утырып, тыныч юлдан, көндәлек эшләр, гади

һәм табигый мәшәкатьләр артыннан йөреп торучы секретарь итеп түгел, аягы җәрәхәтләнгән солдат итеп күз алдына китерде.

...Кырык беренче елның җәе иде. Мансурны лейтенант Свиридов белән иң авыр заданиегә җибәрделәр. Хәлдән тайган, снаряд һәм патроннар бетәр чиккә җиткән ротага элемтә кирәк иде. Әгәр бер-ике сәгать эчендә ярдәм килеп җитмәсә, ротаның һәлакәткә дучар булуы көн кебек ачык иде.

Элемтәчеләр, бер олау снаряд һәм патрон төяп, рота торган урынга әйләнеп килгәндә, анда җан иясе калмаган иде. Рота тар-мар ителгән, кая карама, гайре табигый кәяфәттә, соңгы сулышын алып солдатлар ята. Атыш тавышы, ераклашканнан-ераклаша барып, Свиридов белән Мансур бер сәгать элек кенә булган полк штабы ягыннан ишетелә башлады.

— Кирәге тияр,— дип, Свиридов арбадагы ящикларны аулак бер җиргә бушатырга кушты да үзе иң биек имән башына үрмәләп менеп китте.

— Эш хөрт,— диде ул, агач башыннан төшеп. Шуннан атны тугарып алды, җиргә утырып, автомат дискыларына патрон тутыра башлады.— Давай, Мансур, кимендә бишәр диск, икешәр автомат алыйк. Шунсыз ерып үтә алмабыз...

Мансур командирының уен аңлаган иде инде. Эндәшми генә коралларын әзерләргә тотынды. Эше беткәч, запас дискыларны ике бәйләм итеп, атының ыңгырчагына беркетте. Шулай башланды аларның хәвефле сәфәре.

Олы юллардан читтәрәк урман һәм тугай сукмакларын сайлап, күбесенчә төннәрен бардылар. Бер уй, бер теләк иде икесендә дә: тизрәк фронт сызыгын үтәргә, тизрәк үзебезнекеләрне эзләп табарга.

Ун көн дигәндә юлдан читтәрәк торган ниндидер ташландык сарай янына килеп туктадылар. Бу тирәдә немецларның булуына ишарә ясардай берни юк иде. Атларын тышаулап җибәрделәр дә, сарай чормасына менеп, былтырдан калган печәнгә яттылар. Тирә-як тып-тын. Әйтерсең, җир йөзендә сугыш та юк, хәвеф тә. Арыган-талчыккан ике солдат шундук йокыга чумды.

Кинәт дөньяның астын-өскә китереп, кемдер сарай капкаларын ача башлады, тирә-якны дорфа итеп кычкырган, сүгенгән, эт өргән тавышлар күмеп китте.

Күз бәйләнгән чак. Егетләр чорма ярыгыннан аска карадылар да шаккаттылар. Немецлар әсир төшкән солдатлар төркемен, һайһулап куып, этләреннән талатып, сарай эченә тутыра башладылар.

— Эш хөрт,— диде лейтенант гадәтенчә. Ә үзе, ярыкка сылашып:— Бер, ике, өч... унике,— дип конвойны санады.

— Әйе, унике кеше. Күп түгел-түгелен, әмма овчаркалары күп— бишәү,— дип аның сүзенә ачыклык кертте Мансур.

Аста, сарай эчендә, ыңгырашкан, буылып йөткергән тавышлар ишетелә, шалтыр-шолтыр итеп капкалар бикләнә. Берәр карарга килү, эш кыйрату авыр иде бу мәлдә, чөнки Свиридов белән Мансур үзләре дә бик астында калганнар иде. Таң атканын көтәргә булдылар.

Иртәгесен әсирләрне ора-суга сафка тезделәр. Немец солдатларының берсе, шик калмасын диптерме, сарай эченә автоматтан атты да конвоирлар янына йөгерде.

— Давай!— диде Свиридов һәм аска сикерде.

Калганы, әллә төштә, әллә өндә дигәндәй, биш минут эчендә булды. Алдан сөйләшү буенча, Свиридов — конвойга төбәп, Мансур овчаркаларга чамалап, икесе ике яктан ут ачтылар. Эшнең ниндилеген аңлап өлгергән фашистлар котырынып әсирләргә ата башладылар.

— Ятыгыз!— дип кычкырды Свиридов һәм кайсы кая йөгерешкән әсирләрнең берсенә запас автоматын сузды. Яраланып, я үлеп егылган

конвойның коралы безнең егетләргә күчә барды; алай да үлем, болай да үлем дип, куркуның ни икәнен күптән онытқан солдатлар, шашынып-котырынып, җәлладлар өстенә ябырылдылар.

Күп тә үтми, урман эчен тынлык басты.

Мансурның сул балтырына пуля тигән иде. Җәрәхәте артык хәвефле түгел, сөяге исән, тик үз аягың белән сәфәрне дәвам итү турында уйларга да ярамый иде.

— Эшең хөрт, Мансур, көнең носилкага калды,— диде Свиридов.

— Юк, иптәш лейтенант, бара алам әле мин!

Свиридов аны бер төркем кызылармеецларга тапшырды да үзе теләп өстенә алган командирлык вазифасын үтәргә китте. Хәзер аның кул астында бер Мансур гына түгел, ике йөзләп кеше. Ачлыктан йончыган коралсыз-нисез отрядны бәрелеш урынынан ераграк урман эченәрәк алып китәргә ашыга иде командир. Алар партизаннар лагерена барып чыктылар, Мансур шунда Данутаны очратты.

Ярасы жиңел булса да, өч-дүрт көн бүтән тиешле тәрбия һәм дәва күрмәгәнлектән, Мансурның аягы шешеп чыкты. Партизан отрядының врачы:

— Җәрәхәтең бозыла башлаган. Самолет төшү белән үзебезнең якка китәргә туры килер,— диде.

Ул хәтәр заманда кешеләр артык төче теллеләнүне хуп күрми, күнелдәге жылы хисләрен тирәнрәк яшерә торган иде. Врач та, күрәсең, ничәмә кешенең үлеменә шаһит булган, дошманның ерткычлыгыннан, халык язмышына төшкән коточкыч сынаулардан бәгыре каткан солдатка әйләнгәндер. Мансурның, нидер әйтергә жыенып: «Карагыз әле...» — дип авыз ачуына: «Теләсәң нишлә, минем күлдан килгәне шул...— кул сырты белән үзенең аягын күрсәтте.— Безгә сынар аяклы солдатлар кирәкми».

Шул минуттан Мансур сестра Данута карамагына тапшырылды.

Партизаннар белән үткәргән бер атна гомере яшь солдатның хәтерендә мәңге онытылмаслык булып калды. Яше-карты, хатыны-кызы, үсмереннәре — корал тотып илен-жирен дошманнан сакларга күтәрелгән белорус халкының вәкилләре иде болар. Аз сүзле, салмак табигатьле бу кешеләр авызыннан ул аһ-зар, зарлану-сыкрану ишетмәде. Егермесе дә тулмаган менә чандыр гына Данутага тикле көнозын яралылар тирәсендә бөтерелә, аларның авыру-сырхавын үз иненә алырдай булып жан ата, ә кичләрен саңсыз калып егыла иде.

Мансур үзе дә беркайчан мыжык булмады, ата-анадан яшьләй ятим калып, эшчән, чыдамлы һәм күндәм егет булып үсте. Партизаннар лагерена килгәч тә, гөбедәй шешеп киткән аягы никадәр сызламасын, тешен кысып түзде, ыңгырашмаска, игътибарны үзенә алмаска тырышты. Шуңардырмы — Данута Мансур янында озаграк туктала, эндәшми генә аның чәчен сыйпый, мендәрен төзәтә, күзләрен зур ачып, елмайгандай итә дә:

— Күп калмады инде, озакламый самолет килеп житәр,— дип юату сүзләрен әйтә.

Бер көнне ул Мансурга гадәтенчә күзләрен тутырып карады да ягымлы йомшак тавыш белән:

— Чибәр егетсең син. Холкың да әйбәт, мөгаен, сөйгәнең бардыр, көтәдер сине,— диде.

Аның басынкы юаш тавышы шул тикле сагышлы иде, Мансур теленә килгән шаян сүзен әйтми калды. Әйтмәве дә хәерлегә булган, чөнки Данутаның соңыннан ачылып китеп, ышанып сөйләгән сүзе Мансурның йөрәген көйдереп алгандай булды.

— Минем Василем дә, нәкъ синең шикелле, кара бөдрә чәчле, кара кашлы, типсә тимер өзәрдәй егет иде. Башын алдыма куеп ятар иде дә төпсез тирән күк дәрьясына карап: «Менә сугыш бетәр, Дануся, яңа өй

салып жибәрербез. Балаларыбыз булыр. Еллар үтәр, балаларыбызның үз балалары, аларның тагы балалары туар. Безнең токым мәңге-мәңге яшәр...» дип хыялланыр иде...— Данута салмак кына сөйләгән унайга бите буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен сөртеп алды.— Төннәрен, Василь кебек, күккә карап ятам да, юктыр, үлмәгәндер ул, менә урман арасыннан килеп чыгар да: «Данусь! Бу — мин. Озаграк көттердем бу юлы»,— дип әкрен генә сөйли башлар төсле...

Мансур Данутаны беләгеннән сыйпады, башка сүз таба алмыйча:

— Бәлки, чынлап та шулай булыр, эзләп килер сине,— диде.

Данута башын чайкады, карашын каядыр ераккa, ашыгып агылган болытлар төркеменә төбәп, үзенең боек һәм фаҗигале тарихын дәвам итте:

— Үз күзем белән күрмәсәм, ышаныр идем синең изге сүзеңә. Юк, түзмәдем шул. Васильне асканнар дигән хәбәрне ишеткәч, төн уртасында авылга киттем... Әнә, күрәсеңме өстенә йолдыз куелган каберне? Василь шунда... Кул арбасына салып, үзем алып кайттым лагерьга...

Данутаның галәмгә сыймас олы кайгысы янында Мансурның хәсрәте кечерәеп, әһәмиятсез булып калды, ул иректән торып утырырга, нидер эшләргә уйлады, тешен кысып, «ыһ!» дип куйды.

— Син... ни... Данута, ул тиклем үзеңне бетермә әле... яшьсең, бәлки бәхетеңне табарсың, һәркемнең тормышта үз йолдызы — язмышы була...

Данута тагын башын чайкады.

— Ю-ук, Мансур. Безнең язмышка Гитлер тамга сукты, фашистлар минем йолдызымны сүндерде. Йөрәгем кара күмергә әйләнгән, ул хәзер сөюгә түгел, бары тик нәфрәткә, үч алуга гына сәләтле...

Шушы сөйләшүдән соң Данута кинәт үзгәрде. Мансур ул чакта бик яшь иде шул, тормышның катлаулы борылмаларын, кеше язмышының кырыслыгын аңлау аңар соңрак килде, Данута исә, Мансур сүз куша калса, «хәзер-хәзер»,— ди дә башка авырулар янына ашыга, аның янында элекке кебек озак тукталмый торган булды.

Мәскәүгә озатылачак яралы солдатны һәм партизаннарны самолетка утыртып бетергәч, Мансур янына отряд врачы килде. Егетнең борчылуын, ачык ишектән күз алмавын күрде, ахрысы:

— Я, хуш, солдат,— диде ул, Мансурны аркасыннан кагып.— Сугышның иге-чиге күренми, ул-бу була калса, гаепләштән булмасын... Ә теге... ни... Данутаны онытма, солдат. Ул, ире һәлак булгач, япа-ялгызы калды, сина аз булса да кияләнде бит ул.

Мансур дәшмәде. Шулай да аның сораулы-ялварулы күз карашын врач аңлаган иде инде.

— Данутаны төнлә калага озаттык. Заданиегә,— дип кенә җавап бирде.

Самолет, гүләп, һавага күтәрелде, төн карасын ерткалап кабынган зенитка утларын ерып үтеп, көнчыгышка таба юл тотты.

Язмыш аяды Мансурны ул чакта, аягы исән калды. Өч ай чамасы госпитальдә яткач, тәмам савыгып, яңа частька билгеләнде. Булсa була бит шундый могҗиза: уң беләген мина ярчыгы сыздырып үтте, снаряд шартлаудан башы шаулап йөрүен искә алмаганда, Мансурны чынлап та ниндидер тылсым саклый иде сымак. Билгеле, андый гына шаукым белән кабат госпитальгә керергә туры да килмәде. Меңләгән чакрымга сузылган сугыш юлын ул тәпиләп, җәяүле разведчик булып Орел каласыннан Берлингача диярлек үтте һәм кырык бишенче елның апрель урталарында гына, тагы шул сул аягы яраланып, егылып калды.

Төрле хәлләр булды сугышта — көтелмәгән очрашулар да, аяусыз югалтулар да. Бервакыт Мансур Польша жирендә, ниндидер бер елганы кичкән чакта, йөзләгән машина килеп тыгылган кечкенә күпер өстендә үзен дәвалаган партизаннар врачын очратты. Ике минутлык кына ашы-

гыч сөйләшүдән егет үзенең дусы Свиридовның хәзер махсус батальон командиры булуын белде.

— Ә Данута югалды,— диде врач, көрсенеп.— Гитлерчылар лагерьны килеп баскач, өч көн буе атыша-атыша чигенергә туры килде. Яралы командирны алып, Данута икенче базага юнәлгән иде. Шуннан юк булды... Бәлки, исәндер, тик хәзер каян белешеп торасың...

...Мансур, Гөлнисаның кара печатьле язмыш турындагы сүзләрен уйлап, менә шуларны күңеленнән кичерде. Уйлары еракта иде егетнең. Гөлниса да, үз уен уйлап, байтак вакыт дәшми барды. Соңыннан, ниндидер чая бер уйга килде шикелле — Мансурга борылып карап утырды да:

— Я, нигә бозау сымак кыланасың? Гөлниса — даны чыккан ирсез хатын, «һайт» дигәнгә «тайт» дип, кем чакырса, шуның артыннан иярергә, муенына сарылырга тора! Ишеттеңме Әкълимәннең матур сүзләрен? — дип ярсып сөйләргә тотынды.— Әле менә синең белән икәүдән-икәү тарантаска утырып кайтканны болай гына үткәрер дисеңме Әкълимә? Үткәрмәгән кая!

Мансур ирексездән Гөлнисаның беләген сыйпап куйды. Шуннан капыл гына атының дилбегәсен какты да сызгырып жибәрде. Иренеп, жай гына юртып барган ат жан-фәрман чаба башлады...

Ат, юлдан читкә чыгып, тынычрак жиргә, яшь каенлык буена барып туктады. Әнә авам, менә түңкәям дип чаптырып килгән тарантастан чак кына төшеп калмаган Гөлниса, күзен йомып, Мансурның биленнән кочаклап алган иде. Ат туктагач, үкеңү катыш шаянлык белән:

— Нигә туктадык инде, күптән шулай адәм рәтле итеп юл йөргәнем юк иде. Йөрәгең басылдымыни? — дип жиргә сикереп төште.

Мансур, атын тугарып, чаукалыкка тышаулап жибәрде, үлән өстенә газета жәеп, юлга дип алган ризыкларын чыгарды. Күңеленда ниндидер кискен бер уй бөреләнә иде.

Кашын төеп, чуалган фикерен барлый, үз йөрәгенең тавышына-чакыруына колак салгандай, башын иеп, нидер тыңлый. Ә Гөлниса, хәйләсез жан, озын керфекләрен жилпеп, Мансурга аптыраулы караш ташлый да кинәнеп ашый. Житмәсә, «уф, ачыктырган, нинди тәмле кала икмәге!» — дип куя.

Хатын-кыз күңеле — язгы жил. Яңа гына бөтен дөньяга, язмышына, үз-үзенә ачулы сүзләр әйтеп килгән Гөлниса кинәт алчак, мәрхәмәтле кешегә әйләнде.

— Кара әле, кара әле, Мансур! — дип сикереп торды ул, сак кына атлап чаука читенә юнәлде. Иелеп, ике учы белән нәрсәнедер каплаган иде, кул астыннан пырылдап кечкенә генә кош очып чыкты, җәелеп, арырак барып төште. Гөлниса аны, байтак вакыт куалап йөртсә дә, тота алмады. Боегып, урынына килеп утырды.— Тап минем бәхетем сымак,— дип күңелсез генә елмайды.— Тоттым, морадыма життем дигәндә кулдан ычкына да куя...

Мансур баягы уен уйлап бетерде шикелле — Гөлнисаның янына ук күчеп утырды, аптырабрак калган юлдашын иңбашыннан кочаклап, тотлыга-тотлыга сөйли башлады:

— Әгәр рәнжетсәм... күнмәсәң, сүзем шушында калсын... Әлбәттә, сынар аяклы ир берәүгә дә артык зур табыш түгел. Синең кебек сылу, уңган хатынга бигрәк тә... Беренче күрүдә үк күңелем яткан иде — менә, юк димәсәң... кыскасы, кайтышлый ук авыл Советына кереп язылышыйк...

Гөлниса, иңбашын жыерып, егетнең кочагыннан арынды, башындагы чуар парчалы ефәк яулыгын төзәткәләде. Чыраенда житдилек, курку, икеләнү бар иде. Байтак вакыт дәшми утыргач, Гөлниса Мансурга кыюсыз гына карап:

— Соң бит, Мансур, син егет кешесең. Авыл тулы кыз-кыркын. Берсеннән-берсе сылу... Кеше сүзеннән курыкмыйсынмы? — диде.

— Куркудан үткәнмен.— диде Мансур.

— Уйлыйм, вакыт бир... син дә уйла, Мансур. Үкенерлек булмасын. Тагы, әченеп-яратып китеп, сине дә югалта калсам, яшәү юк миңа...

Шушы сөйләшүдән соң атна-ун көн үтүгә, авылның яшь-җилкенчәген аптырауга салып, Мансур Гөлниса өенә күчеп чыкты. Ул бу хәбәр таралып өлгермәде — Мансур авыл Советы белән исәбен өзде дә урман эшенә тотынып китте, яшь гаилә урманга күчте.

...Егерме ике ел гомер иттеләр кордонда. Гөлнисаның күнеле, язгы чәчкә сымак ачылып, сарыфланмаган бөтен назын, янә кабынган кырсез хисләрен Мансурга бирде. Менә әле ул, урманда йөрергә кулайрак булыр дип, агач аяк әмәлләп утырган килеш бөтен тормышын күз алдыннан үткәрә, аның текә борылмаларын барлый. Барлый да үкенер нәрсәләрнең байтаклыгына көенеп куя, тик фикере Гөлнисага җитүгә үзе дә сизмәстән елмая, карашы яктыра, сыны тураю. Юк, җүләр үз хатынын мактар, дисәләр дә, Мансур бөтен ил алдында икеләнмичә: «Уңдым, арабыздан җил дә үтмәде»,— дияргә әзер.

Гаиләләре артык ишле булмады булуын. Бер уллары, бер кызлары бар. «Заманына күрә тап-таман,— дип көлә Гөлниса.— Мин әле кире киткән карчык түгел, гомеремне бала карап өйдә үткәрәсем юк, кулымнан эш килә. Бу заманда икесен үстереп, аякка бастырулары да, ай-һай, жанны әз кыймады». Дөрес сүзгә җавап юк. Жиңел булмады балаларны үстерү. Төпчекләре Айсылу быел унны бетерә. Уллары Тимербай көзгә солдаттан кайтырга тора. Ни язмыш, нинди юллар көтә аларны? Әллә нинди авырлыкларга да күнәргә әзер Мансур, тик балаларының күз яшенә, авыру-сыктавына, күнелләре кыелуга бервакытта да тыныч кына кала алмады.

Капка ягыннан Сарбайның куанып чыйнаганы, һау-һаулап өргәне ишетелде. Мансур борылып карады да, бер аптырап, бер шатланып, җәһәт кенә урыныннан торды. «Үләт, сантый,— дип әрләде үзен,— кояшка изрәп утырып, кич житкергәнмен!»

— Кунакларны каршыла! — дип кычкырды Гөлниса. Ә Айсылу, күбәләктәй очып-калкып, атасы янына йөгереп килде, аны кочаклап үбеп алды.

— Әти, син танымыйсыңдыр да әле. Бу — минем ахирәтем Сания. Әхмәтҗан бабайның кызы.

«Әкълимә кызы»,— дип уйлап алды Мансур һәм капыл күзен йомып, чайкалып китте. Ярый әле, берсе дә сизмәде шикелле. Аның каршысында оялыбрак елмаеп торган кызыкай — коеп та куйган Әкълимә иде!..

Кызлар, юынып, тиз генә аш-су әзерләп алдылар да аннан-моннан капкалагач та: «Таң белән авылга китәбез, мәктәптә өмә була,— дип йокларга яттылар.

Гөлниса белән Мансур, сүз күешкандай, болдырга чыгып утырдылар. Кояш баеп барган чак. Тирә-як алсу нурга чумган, ихата янына ук житеп, өй кыегына тармаклы ботакларын җәйгән урманны кызгылт яктылык ярып үтә. Моңсурак бер тынлык. Рәхәтлек.

Гөлниса иренә сыенып утырды да:

— Күптән күргәнем юк иде Санияне... Китче, китче, охшаса да охшар икән бала әнисенә! — дип пышылдады.

Мансур эндәшмәде. Бая, берсе дә сизмәде, дип ялгышкан икән. Сизми каламы соң Гөлниса! Мансур сүзне икенчегә борырга тырышып, көндез күнелен тырнаган борчулы фикерен үзе дә сизмәстән әйтте дә куйды:

— Син, ни... әнкәсе... нишләптер балтаң суга төшкән кешедәй йөрисең соңгы вакытта... Ул-бу юктыр бит?

— Әйтте дә телен тешләде. «Кеше акылына-зиһененә баш була алмый, көнозын юкны уйлап утырдым — көт тә тор, авызында ахмак сүздән башка берни булмас»,— дип эченеп чикәсен ышкып куйды. Ләкин Гөлниса, сизгер, акыллы Гөлниса, иренең бу уен да сизгәндәй, уратыбрак үзе сүз башлады.

— Балтаң суга төшкән, дип... син ни, авылда сирәк булгач, дөнья менә урман белән чикләнә, дисеңдер әле. Авыл тулы хәбәр.

— Безгә кагылмыйдыр бит ул хәбәрләр?

— Кагылганы бар, кагылмаганы... Тимербаең бит Сания белән хат алышып ята, имеш. Айсылу күптән белә. Кайда ул: «Абыем да Сания ахирәткәем!» — дип өтәләнеп тора очтакай! Өчесе бер төптән булып чыга...

Мансурның йөрәген кинәт коточкыч чәнчү алды. Хатынына белдермәскә тырышып, болдыр рәшәткәсенә чытырдатып ябышты да күзен йомды.

— Абау! — дип Гөлниса ирен кочаклап алды.— Тынычлан, жаным... Куй, нигә алай авырга аласың? Аны ни... гомер буе яшереп, синнән сер саклый торган эш түгел. Болай да ай артык әйтми түздем, жаным чыга язды...

Мансурның йөрәге, ничек капыл чәнчеп алса, шулай ук тиз генә жибәрде дә. Ләкин ул күзен ачарга ашыкмады. Тамагына килеп тыгылган күз яшьләрен тыеп кала алмам дип курка иде ул. Ә күнеләндә яңа бер уй — әллә кайчан белорус урманнары төпкеләндә ишеткән, шушы озак вакыт эчендә үзенекенә әйләнгән изге хыял дулкынлана иде: «Балаларыбызның үз балалары, аларның тагы уллары-кызлары туар. Без күмәк булырбыз. Токымыбыз, хыял-әметләребез, мәхәббәтебез мәңгемәңге яшәр...»

Күк читен алсуга манып, кояш урман артына яшеренде. Тирә-якта шылт иткән тавыш юк. Табигать мәһабәт тынлыкка бирелеп, менә-менә гүләп агасы язгы ташкыны белән хыяллана. Дөнья хәрәкәттән туктаган сыман. Тик узган ел куерып үсеп киткән имән, гөлжимеш, чаган куаклары тирәсендә генә кар бураны туздырып ике төлке уйный иде...

ХОООООООО

Рәшит Әхмәтҗанов

Бүген тормыш танымады мине...

Бүген тормыш танымады мине,
Мин үзгәрдем кебек кинәттән.
Азат булып барлык хөкемнәрдән,
Кайгыларны ташлап йөрәктән —
Бер нарасый кебек, кырлар буйлап,
Көлеп йөрим ап-ак күлмәктән.

Бүген тормыш танымады мине,
Бөтен дөньям әллә нишләгән.
Югыйсә бит иренем көйгән иде,
Сулар ятып эчтем чишмәдән.
Хыялымда күккә менгән идем —
Җаным һаман җиргә төшмәгән.

Бүген тормыш танымады мине,
Сәбәпләре аның бар, димәк.
Ах, яңадан җиргә төшәргә дә,
Үз урнына басарга кирәк...
Иске бу дөньяга күп хәлләрне
Сөйләмәгән әле яшь йөрәк.

1970

Сугыштан кайталмаган егет сүзләре

Иелеп-иелеп ак каеннар сорый,
Ак розалар сорый шул хакта —
Нигә соң мин яшь шаһзадә булып
Киләлмадым сиңа ак атта?

Бар иде бит шундый вәгъдәләрем,
Мин барыр да идем шикелле.
Ләкин атым балачакларымда
Томырылып утка сикерде.

Мин дә яндым көрәш кырларында
Шул ук атта, шул ук ялкында.
Кешнәүләре атның һаман әле
Ишетелә таулар артында.

Кайтавазлар белән кайтып булмый,
Сез калдыгыз, ярым, без киттек.
Сугышларда янган ак атларның
Җайдаклары ул чак без идек.

Ак бәхетең булып күренәдер
Төшләреңә кереп ак атым.
Бәхетлеме соң син, бәхетсезме —
Мин тик сине генә яраттым.

Сөюләрең белән терелт мине,
Уналты яшь миңа... таң ата...
Кайтасы бар сиңа таң алдыннан,
Яшь шаһзадә булып, ак атта.

1969

●

К. Б. га

Ак жептән йомгак урап син
Төшемә кергән идең.
Ак шәлләрем юк инемдә,
Шәл бәйлим дигән идең.

Йомгагың төшеп кулыңнан
Тәгәрәп китмәдеме?
Озын юллар йомгагыңны
Бөтенләй сүтмәдеме?

Әй, дөньяның ялгыз Яры,
Моңнарың, кайгың барга —
Йөгермә йомгак
артыннан,
Син сарыл каеннарга.
Танырлар, сенел диярләр —
Киенсәң дә карадан.
Алар аклык каян ала,
Сора әле алардан.

1959

Мин күренмәм...

Уктай атылдым мин ераклларга,
Исән кайтуларым икеле...
Юлда янып аргамагым үлде —
Гомерен миңа биргән шикелле.

...Кайтып киләм,
Дөнья миңа ялгыш
Хыянәтең аша күренгән.
Мин күренмәм...
шул аргамак кебек
Саклармын тик сине үлемнән.

1965

Сөббух Рафиков

ТЫН ЕЛГА БУЕНДА

РОМАН[1]

Солтан әкрен генә атлый бирде. Нихәтле танышлар, Мәдинә Диләрә, Людалар белән, Гөлзадәләр белән исәнләшеп үтте. Рафис, Алып батыр — Виктор да аны сәламләп калдылар. «Ярый, күпме «оештырып» йөрергә була»,— дип уйлады ул. Аның өстенә, житмәсә, һава болай тын, көн аяз, кояшлы торса да, кышның сиздермәс салкыны аның тәнен кытыклый, аяк очларына салкын тараканнар үрмәли башлады. Янә борылып Зиннурлар янына килде. Секретарь үзләре белән бергә эшли башлагач, Зиннур һәм Хәмидә бөтенләй ачылып киттеләр, чырайлары яктырды.

Алардан шактый читтә калын-калын төпләрне бульдозер жирдән каерып чыгара һәм, бик куәтле үгез коймаларны сөзеп аударган кебек, бер читкә этәрә иде.

Агачлары киселгәннән соң, кин тигезлек булып, меңләгән эзләр белән ала-кола төстә тапталып калган урыннарда, кин мәйданда дистәләп учаклар яна. Бу учакларга һаман саен чыбык-чабык өстәлеп тора, ялкын телләре, күксел төтен баганалары югарыга сузылалар.

Рафис үзләреннән ерак эшләмәгән Солтан абзыйсы белән теге бу турыда ничәмә-ничә сүз алышты. Егетнең эчке хисләрен аңлаган шикелле, Солтан да, Зиннурлар да алардан арырак китә баралар иде. Ә менә Виктор гел аның яныннан китми. Алай гына да түгел, үзенең Людасы була торып, Мәдинәгә әледән-әле сүз кушып тора. Әллә ниндирәк кеше бу Рафис. Сүз кушса соң, аңа карап, Мәдинәнең бер жире дә кителмәс лә. Бәлки кителер дә... Рафисның башына ниләр генә килми. Әйдә, карый бирсеннәр лә, ул барында Мәдинәне берсе дә күтәреп алып китә алмас әле...

---

[1] Дәвамы. Башы 1, 2, 3, 4 саннарда.

Рафис шундый бер-берсенә йогып бетмәгән җүләр тойгыларны башында кайнатып, өемгә чыбыклар ташый. Ул инде хәтсез вакытлардан, ягъни Фиргали абыйлары пар казаннарын монтажлауга күчкәннән бирле, комплекслы бригаданың бригадиры. Башта яхшы ук курыккан, яхшы ук шүрләгән иде. Хәзер күнегеп барган көне. Бригаданы аңа тапшырганда Фиргали абыйлары бик мәгънәле, бик серле итеп бер генә сүз әйтте: «Мине тормыш үзе өйрәтте. Өскә жаваплылык алгач, төрле җүләрлекләр үзләре үк кешедән курка, читләшә башлыйлар...» — диде. Чыннан да, дөрескә туры килә бугай тәжрибәле «карт бүренең» бу сүзләре. Эшләп йөри бит әле. Ярышка чыктылар, яуга кушылдылар дигәндәй, коммунистик хезмәт бригадасы исемен дә алып куюлары бар. Барысын да кеше эшли, кеше ерып чыга ич, аның кебек үк ике аяклы, ике куллы кешеләр... Алар кемнән ким!

Шулай әрәмә кисү, агачлар чистарту белән ыгы-зыгы килеп йөргәндә, үзеннән беркадәр читтәрәк эшләгән Виктор кычкырды аңа:

— Сине чакыралар.

— Кем чакыра?

— Әнә, чокырда. Баргач күрерсең.— Виктор шул сүзләрне әйтте дә куаклар арасына кереп югалды.

Рафис исә каушабрак калды. Якындагы чокырлыктан берничә мәртәбә аның исемен әйтеп аваз салдылар. Кайсылар икән бу? Әрәмәдә һәр тарафка сукмак салынган кебек, монда да кар өстеннән тар гына сукмак кереп китә иде. Бара торгач, Рафис үзәнлектә, кешеләр күзеннән читтә, учак янып ятуын күрде. Арырак баргач, кешеләр дә күренде. Рафис ни күзләре белән күрсен: ияген һәм яңакларын куе сакал баскан Карчыга, Кылый егет, Фарук Фарукшин учак янына тезелешеп утырганнар да жанланып сөйләшәләр. Карга җәелгән газета өстенә ашамлыклар тезеп куйганнар. Күрсең, болар бераз төшереп тә алганнар булса кирәк: кәефләре шәп шикелле. Рафисны күргәч, шаулашып сөйләшүдән туктадылар. Фарук абыйлары куен кесәсеннән бер ярты тартып чыгарды. Җитез куллар аның алдына стаканнарын китереп тоттылар. Аракы голт-голт итеп стаканнарга акты. Бүтәннәр авызларын ерып Рафиска күзләрен текәүгә, Карчыга сүз ачты:

— Әйдә әле, бригадир, бездә кунак бул, берне күтәреп җибәр. Аннан эшлекле сөйләшү булыр, әһем...

Рафис үзенә тәкъдим ителгән стаканны Карчыгага таба этәрде. Ул башта, ничегрәк җавап кайтарырга белмичә, югалыбрак торды. Тегесе артык кыстамаса да, яртылаш салынган стаканны җиргә куймады, кулына тоткан килеш башлаган гәбен алга сузды:

— Кайсыбызны ныграк дус итәсең?

— Миңа барыгыз да бер,— диде Рафис иңбашларын сикертеп.— Берегез дә дошман түгел.

Карчыга тагы да кыюлана төште:

— Дус күрсәң, алайса син, Рафис, безне үз бригадаңа ал. Бергә-бергә ишәчет итеп йөрербез.

— Шаяртма, куй бу сүзләреңне,— диде Рафис.

— Ул шаяртмый, чынын әйтә,— дип сүз кыстырды Фарук Фарукшин.

— Кара син, нинди бөркетләр! Моңа кара, тегеңәр кара. Дядя Фарукны әйтеп торасы да юк: мең эшнең мастеры! Чумарит итми хәзер, сулагайлыгын ташлады. Без дә аның дөрес житәкчелегендә такыр юлга чыктык... Сиңа помбригадирлыкка аннан да кулай тагы кем бар?

Рафис, борылып китәргә ниятләсә дә, ничектер моны бу кешеләр алдында күрку кебек бер хәл булыр дип, урыныннан кузгалмады. Алар аны ничләтә алалар? Тотып ашый алмаслар әле. Үзенең тегеләргә сүз катасы килмәде, тегеләре дә беркавым тын тордылар. Аннары Карчыга янә телгә килде:

— Я, сатулашып тормыйк, ал мине үз бригадаңа. Аннан Мишаны.— Ул кылый егеткә күрсәтте.— Ияләшербез. Алда тагы күз күрер. Безгә артык процент кирәкми. Таякның уң ягында «ике күз» булса, шул житкән...

— Нигә үз бригадагызда эшләргә теләмисез?

— Теләмибез, и бетте-китте. Сезнең прораб белән блат, ә безнең?

— Гафу итегез, егетләр, мин сезне ала алмыйм.

— Теләмисең? Борыныңны югары чөя башладың?

— Куркытма, Карчыга. Мин дә балчыктан әвәләнмәгән! Просто мин мондый эшне булдыра алмыйм.

— Нигә? — дип ярсый барды Карчыга.

— Минемчә, бердән, сезгә үз урыныгызда эшләргә кирәк. Икенчедән, бригадага бер мин генә хужа түгел.

— Хужа булмасаң, Насретдин инде син алайса,— дип көлде Фарук Фарукшин.

— Ә кем хужа синең бригадага? — дип янә сорау куйды Карчыга.

— Бригадага аның барлык членнары хужа. Әйтик, берәүне эшкә алабыз икән, без бригада җыелышында хәл кылабыз мәсьәләне. Чыгарганда да шулай ук. Бу сезгә дә билгеледер дип уйлыйм...— Рафис бераз тукталып торгач, янә дәвам итте: — Белмим, сезне бригадага алырга теләүче табылырмы икән бездә? Мин моңа ышанмыйм.

«Салам торханнар» арасыннан кайтарып сүз эстәүче булмады. Рафис китеп барды. Ул кем тарафыннандыр үзенә карата үчекләү сүзләре ишетте. «Бушлат Терентьевичка ялынасы гына калган икән, төкер барсына, әйдә күтәрик үзебезнең исәнлеккә-саулыкка», янәсе.

Рафис иптәшләре янына ашыкты.

Көн төшке якка авышуга, өмәчеләр бер-бер артлы учаклар янына җыела башладылар. Кешеләр эреле-ваклы төенчекләр белән кайсылары кесәләренә тыгып ашамлык ризык алганнар иде. Учак каршында, йөзгә рәхәт җылы биреп торган урында тамак ялгап алдылар. Кайберәүләр таяк башына кадап колбаса кыздырырга да өлгерделәр.

Рафисның исә бар теләге Мәдинә белән янәшә булуда иде. Ул иртәдән бирле шундый форсатны туры китерә алмавына бик тә, бик тә гажиз иде. Рафисның Мәдинә белән ялгыз икәүдән-икәү генә каласы, икәүдән-икәү генә күзгә-күз карап сөйләшәсе килә. Ул үзе тукталган учакның икенче ягына, иптәш кызлары белән бергә баскан Мәдинәгә күзләрен тутырып-тутырып караудан һич кенә дә тыела алмады. Бер арада ничектер, Рафис кем беләндер гәпкә кергәндә, Мәдинә кызлар арасында күренми башлады. Рафисның йөрәге жу итеп китте. Нык-лабрак караса, ни күзе белән күрсен: Мәдинә таллыклар арасында тар юлдан әкрен генә атлап Тын елга буена төшеп бара. Ераклаша. Аның эзләре гүя Рафисны чакыра кебек. Кузгалды. Китте. Кыз артына борылып карады. Алар кешеләрдән хәтсез еракта, шунлыктан бу урынга шау-шулар да тоныграк ишетелә. Тиздән Рафис Мәдинәне куып та житте. Янәшә бара башладылар. Нинди күңелле Рафиска, көне дә җылынып китте бугай. Кайнарланып сорады:

— Син кая барасың?

— Белмим... Ә син? — дип сорады Мәдинә.

— Мин дә белмим...

Мәдинә яңгыравыклы тавышы белән кычкырып көлеп жибәргәнен дә сизми калды. Күрәсең, икесенең дә уйлары бер тирәдәрәк чуалгандыр. Күрәсең, очрашу турында икесенең йөрәк хисләрен күзгә күренмәс жепләр тоташтыргандыр. Бу араларда Рафислар бригадасы төнге сменада эшләгәнлектән очрашу насыйп булмады. Бер-берсенең эшләре, укулары ничек баруы турында сораштылар.

— Язны хәтерлисеңме? — дип сорады Мәдинә.

— Кәк хәтерләмәскә!

— Ул чагында урманнан кайтканда ни дигән иден әле син миңа?
— Оныттым... Онытылган...— Рафис бурлат кебек кызарды, бер ка-ым күзләрен яшереп торды.
— Син бит хәзер миңа сөям димисең?
— Әйе шул...
— Ә нигә?
— Үзең беләсең...

Алар бер-берсенә якты елмаеп, чырайларын һәм күзләрен нурланды-ып карадылар. Рафиска калса, Мәдинәнең яңаклары гадәттәгедән ал-урак, күз карашлары да чагыштырмаслык матур төсле тоелды. Мәди-әгә калса, Рафис башка чаклардагыдан терерәк һәм җитдирәк, кыю-ак сыман күренә. Аның ягымлылыгы да арткан шикелле иде. Кыз белән алгыз калганчы Рафиснын әйтер сүзләре, теләкләре күп, бик күп иде. Икәүдән-икәү генә булгач, әллә каушаудан, әллә дөньяда үзен иң бәхет-е кеше санап дулкынланудан һәммәсе дә каядыр сибелде дә бетте. Нигәдер Мәдинә дә сүз башларга ашыкмады.

Алда үзәнлек. Һәр якта, һәр тарафта куе әрәмәлек. Икесе генә... аларны беркем күрми, нинди рәхәт! Бу таллыклардан кыш көне дә үзенә генә хас, сулышларга рәхәтлек бирә торган сафлык, тәмле ис аңкый иде.

Туктадылар.

Менә шунда кинәт бер хәл булып алды. Алар сүзсез генә бер-берсенә якынлаштылар. Күзләр күзгә төкәлде... Ләкин... Мәдинә кинәт кире чигенде. Рафис чак-чак егылмый калды.

— Ашыкма,— дип бармак янады кыз.

Рафис азрак үпкәләгәндәй итте:

— Мин сине аңлап җиткермим... Нигә инде? Бүтәннәр...

Мәдинә кычкырып көлеп җибәрде:

— И җүләрем, и акыллым...

Әмма кыз шундук үзе Рафис янына килеп басты. Башны башка куеп янәшә барганда, аларга каршы кемнәрнеңдер килгәне күренде. Сагая калдылар. Рафис кинәт җитди төскә кереп әйтте:

— Эш тә уку, уку да эш... Ул күпмегә барыр, чиге бармы аның?
— Нишләп булмасын, булыр.
— Ә аннан соң?
— Кем белә? Син үзеңне ничегрәк тотарсың бит...
— Во тотармын мин үземне! — диде Рафис.
— Белмим шул. Күрербез...
— Әйтик, көннәр әкренләп уза-уза, кешеләр көн дә эшли-эшли элек-тростанция дә төзелер. Поселок та шәһәргә әйләнер. Син дә техникум бетереп чыгарсың. Техник яки мастер булырсың, я булмаса лаборато-рияда эшләрсең. Мин дә инженер исемен алырмын. Шул чагында без менә хәзерге кебек янәшә булырбызмы? Юкмы? Минем сине гел үз янымда гына күрәсем килә...

Мәдинә уйга калыбрак барды. Егетнең алдагы тормыш турында фи-кер йөртүе аңа ошый да, бигүк ошап та бетми иде.

— Киләчәктә безнең янәшә бару-бармавыбыз безнең үз кулыбызда. Суынмасак, һәр ялтыраганны алтын санамасак... Минем ни әйтергә те-дәгәнемне син аңлыйсың, билгеле?

— Аңлыйм! — диде Рафис.

Алар янә кешеләр шау-шуы эченә кереп югалдылар.

Васил, Солтаннан аерылгач, Фарук Фарукшин белән очрашты.

Фарук нигәдер күзләрен читкәрәк алырга тырыша, үзенең алмадай зур бугаз төере гел йөреп тора иде.

— Безнең начальниклар да эш киеменнән. Бүген барыбыз да тигез,— дип ул тиз-тиз генә үз юлы белән китеп барды. Василның аның белән

алай бик сөйләшәсе килмәсә дә, бер-ике сүз әйтергә исәбе юк түгел иде. Әмма тегенең каушаганрак бер хәлдә ашыгуын сизеп, ул башкача эндәшмәде. Инде Фарукшин байтак киткәч, аның хәтерендә Яңа Наратлыдан хатынын озаткан чаклар калкып чыкты. Нурзилә белән Фарук бер вагонга утырганнар иде бит. Эштә, клубта, тегендә-монда аңа еш очрый торган бу бәндә, ихтимал, аның хатынына ни булса да такылдагандыр. Бәлки ул, Василны күргәч, шуңарга тизрәк таю ягын карыйдыр. Хәер, алай булмавы да мөмкин. Бәлки ул аларның шабашниклык эшләренә балта чабуы өчен Василга ачу саклыйдыр, үпкә тотадыр. Тик ничек кенә булмасын, Василга очраганда бу кешенең үз-үзен тотуы сәер һәм мәзәк иде. Хәер, аннан аерылу белән бу турыда онытты да ул.

Васил Игнатны очратуына куанып бетә алмады. Игнат та аның кебек үк җылы һәм җиңел киенгән иде. Икесенең дә өсләрендә сырма-пиджак, аякларында киез итек. Алар башкалар кебек үк гомуми агымга кушылып, бик озак онытылып эшләделәр: агач кистеләр, чыбык-чабыклар ташыдылар.

Озакламый өмәчеләр тарала башладылар. Васил эшләнгән эшнең күләмен чамалап алды. Бик күп, бик күп куак чистартылган, алда гаять зур мәйдан ачылган иде. Кешеләр автобусларга, йөк машиналарына төялеп, мотоцикллары белән һәм җәяүләп кайтырга чыктылар. Васил да юлга таба атлады. Ләкин шул чагында әче чәрелдәгән хатын-кыз тавышы ишетеп, сагая калды. Юл буеннан бераз читтә кешеләр төркеме җыелып өлгергән иде инде. Ул да шунда таба ашыкты. Барып житүгә аның тәннәре эсселе-суыклы булып китте. Башына җылы шәл ураган, башкалар шикелле үк кыска киемле, җылы чалбарлы таныш төс, таныш кыз кар өстендә чалкан ята иде. Васил чак-чак кына: «Гөлзадә»,— дип кычкырып җибәрмәде. Ул шунда торган берәүдән:

— Ни булды? — дип сорады.

— Белмим. Ниндидер Карчыга...

Мондый хәл алдында сәбәбен сорашып торуның кирәге дә юк иде. Васил үзен көтеп торган шоферны чакырды. Игнат белән икесе Гөлзадәне култыклап машинага утырттылар. Җиңел машина кузгалып та китте.

12

Ял көнен ничек уздыру турында алдан сөйләшеп куйганнар иде инде. Юлдашев мондый чакларда шоферны мәшәкатьләп маташмый. Аның үз машинасы бар. Ул үз машинасында поселок читендәге юлдан гына үтте.

Иске Наратлыга тиз килеп житте. Авыл читендәге кечкенә өйләрнең берсенә тукталды. Озак көттермичә, мөгаен, капка төбенә машина килеп туктаганны күреп, иңенә шәл салган бер карчык чыкты:

— Рәхим итегез, Зариф Салихович, кунак булырсыз.

— Кереп үк торыйммы икәнни? — Юлдашев шул җыйнак кына өйгә керде. Карчык ишектән керә-керүгә кече якка чыкты. Тулы гәүдәле, өсбашы пөхтә, коңгырт чәчләре кабартып бөдрәләнгән, төсе-бите ярыйсы ук чибәр яшь кенә хатын каршы алды аны.

Дина жанланып китеп әйтте:

— Бик вакытлы килдегез. Менә белсәң иде нәрсә минем йөрәктә...

— Ә нәрсә? Утмы-сумы? — дип көлде Зариф Салихович.

— Үзең чамаларга тиеш ул тиклесен.

Бу минутларда Юлдашевның чырае яшәреп китте:

— Ут кына булса — көйдерә. Су гына булса — сүндерә. Икесе дә булсын. Бик кабынып та китәрлек булмасын, гел сүнеп тә житмәсен. Шундый мәхәббәтне мактый китап...

Гөлләр!

Тәрәзә төбендә чәчәктә утырган гөлләрдән хуш ис тарала, өй эчендә

гөл исе белән кыйммәтле хушбуй исе борынга ярып керә иде. Озак юанмадылар, Дина киенде дә җинел машинага чыгып утырдылар. Ул ашамлык-эчемлекләр салынган шактый авыр сумканы артқы утыргычка куйды. Әле кар ятарга да өлгермәгән тигез юлдан, судан барган шикелле бер рәхәтлек белән, кузгалып киттеләр. Ләкин мондый юлдан озак барырга туры килмәде. Юлдашев машинаны уңга борды. Монысы да аларга таныш, моннан элек тә узганнары бар иде.

— Ә тегеләр кая? — дип сорады Дина.

Зариф Салихович, башын ана таба борып, гадәти тыныч-лык белән әйтте:

— Үзәк лабораториянең үз машинасы бар бит, Диночка. Алар шуның белән.

— Аерым барулары яхшырак та,— дип Зариф Салиховичның сүзләренә печать басты Дина. Аннары: — Иптәш Гусев та барасы иде түгелме? — дип сорады.

— Аның вакыты юк,— диде Юлдашев.

Сөрелгән җирләр вак дулкыннар уйнаган елганы хәтерләтә. Ак дулкыннар. Зур-зур салам эскертләре өстенә каргалар кунаклаган. Дина барысына да күз салып бара. Бу кырлар, бу тирәләр яшьтән үк таныш аңа. Ул үзе Иске Наратлы кызы. Ата-анасы, төп тумасы, үскән нигезе шушында. Басулар хисләрне нечкәртәләр. Аның моннан байтак еллар элек урта мәктәп бетерүе, шуннан соң китапханәче булып эшләве исенә төшә. Яшьтән үк чая кыз иде ул. Иргә яраткан кешесенә чыкмады. Дина белән ике елдан артык йөргән Мишасы армиягә киткәч, каядыр эшкә кереп, бөтенләй ят шәһәрдә калды. Менә бер ара аннан хат килми торды. Хикмәте булган икән, озакламый егетнең шул эшләгән жирендә өйләнүе турында хәбәр килеп төште. Миша акыллы да, матур да, куәтле дә, тормыш алып бару өчен тәвәккәл кеше иде. Әмма ул үзенең башка берәүгә өйләнүе белән Динаның барлык хыялларын, өметләрен берьюлы сүндерде дә куйды. Шуннан соң, әллә ни озак гомер узмастан, беренче мәгъшукының хыянәтенә ачу итеп, ул яшьлек юлында очраган икенче берәүгә кияүгә чыкты да куйды. Бу адәм бара-тора бозылды, эчүчелеккә сабышты. Бер балалары булды. Берничә ел этле-мәчеле тормыш кичергәч, Дина иреннән тәмам өметен өзде. Аерылыштылар. Аның элекке ире каядыр ераккә, Себер якларына китеп барды. Сигез ел узды, иреннән хат-хәбәр булмады. Тик аңарга охшаган улы гына калды. Тын елга буйларында зур төзелешләр башланып киткәч, Иске Наратлыдагы байтаклар кебек. Дина да үзенең тормышын шушы яңа төзелешкә китереп бәйләде. Дүртенче ел диспетчер булып эшләү дәверендә ул хәтсез тәҗрибә туплады. Төзелеш эшләренең хосусиятенә төшенде. Аның бу ягын Яңа Наратлыга килгәч озак та тормый төшенеп алган Зариф Салихович тиздән томыраеп торган бу яшь хатын белән яхшы ук танышып та китте. Кешеләр аны еш кына диспетчерлык пунктында күрә башладылар. Әмма бу икенең эчке бәйләнешләре турында берсе дә башына китермәде.

Хәтсездән Юлдашевның башында йөри торган бер ният бар: Динаны хезмәт баскычы буенча күтәрү. Аны өлкән диспетчер итеп куйганда да ул аның эшне сөйри алачагына ышана, үзен аклый алачагына ышана иде. Тик менә жае чыкмый торды. Аны, үзе белән яхшы мөгамәләдә, интим бәйләнештә булганга күрә, югарырак күтәрү өчен, үз вазифаларын әйбәт кенә башкарып килгән икенче берәүне урыныннан алып булмый бит инде. Мәгәр әмәле килеп чыкмый калмады. Өлкән диспетчер икенче эшкә күчәргә сорап баш инженерга гариза китерде. Дина белән очрашканнан бирле Зариф Салиховичның телен кытыклап торган шул күңелле хәбәрне тизрәк мәгъшукасына ирештерәсе килә иде. Бу әллә ничегрәк уңайсыз да, жайсыз да, үкенечле дә тоелды аңа. Сүзне башларга теләп тә әллә ничә мәртәбә тукталып калды. Ләкин ник үке-

нергә? Аның Зәйтүнәсе инде хәзер үк үзен олыгайган саный, мәхәббәт сүзләрен ишетергә дә теләми. Өлкән буын кешесе булып барабыз, янәсе... Зариф Салихович хатынының бу турыдагы үгет-нәсихәтләрен тынлый да эче үртәлә, дөньясы актарылып кайный, күтәрелеп бәреләсе килә. Ләкин ярамый. Гаиләдә, кешеләр арасында итагать сакламый булмый. Ул күбесенчә хатынын тыңлый, аның белән артык бәхәскә керми. Ә Диночка белән дуслык жепләре үрә икән, бераз «куерта» икән, әйтик, ул шул сылу, шул карлыгач белән әллә нигә бер очраша икән, моңа карап айның бер чите кителеп төшәчәк түгел ләбаса...

Урманга килеп керделәр. Юлдашев машинаның барышын бик ныкәкренәйтте. Динага таба башын борды:

— Беләсеңме, Диночка, өлкән диспетчер икенче эшкә күчә бит.

— Белмим, Зариф Салихович. Ул бик яшерен, бик тә йомык кеше. Ул исәбен кешеләр белән уртаклаша торганнардан түгел.

— Минем исемгә язган гаризасы бар.

— Кем килер икән тагы безгә аның урынына?

— Әгәр читтән берәү дә килмәсә, әгәр син калсаң?

— Авыр булыр бит. Болай, ичмаса, үз эшенне генә беләсең.

— Авыр булмас. Син, мактап әйтүдән түгел, бик тә төгәл. Хәтта Никитинның үзенең дә мактап телгә алганы бар.

— Белмим шул... Уйлап карармын. Әлегә өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмыйм, Зариф Салихович.

— Бер атнадан жавап сүзеңне әйтерсең дип ышанам, Диночка.

— Тырышырмын.

Тиздән урман да, калкулык һәм тигезлекләр дә артта калды. Алар Кама буендагы әрәмә, таллар, печән кибәннәре белән бизәлгән бер урынга килеп життеләр. Алда түбәсенә мамыктай кар яткан уртача зурлыктагы ялгыз өй тора. Алар машинадан төшүгә, өйнең икенче ягында кузовы буш йөк машинасы күрделәр.

— Тегеләр дә килгәннәр, күрәсең, безне көтәләрдер,— диде Юлдашев.

Касаткин белән Кукушкин килүчеләрне алдан ук күргәннәр булса кирәк, ишек катында каршы алдылар. Алар бер-берсен әле күптән түгел генә күргән булсалар да, тагы бер кат жанланып кул бирепкүрештеләр.

— Без инде сезне күптән килгәннәрдер, дип уйлаган идек,— диде Кукушкин.

— Өмә. Эш. Ярамый. Оештыру кем жилкәсендә? — дип сораулы жавап кайтарды Юлдашев.

— Ә хәзер...— дип каршы төшкәндәй әйтте Кукушкин.

Юлдашев гажәпләнгән сыман иңбашларын сикертеп куйды:

— Буаны бер ерсаң, аның суы үзеннән-үзе юл ала. Хәзер инде анда эш үзеннән-үзе тәгәри... Эш — башлап жибәрүдә, аннары тукталмый ул.

— Билгеле, шулай,— дип аның сүзен жөпләде Касаткин.

— Я, нәрсә карашып торабыз. Әйдәгез, утырышыйк,— диде Юлдашев.

Өйдә бер урындык, ике озынча эскәмиядән башка утырырлык урын юк иде. Утырыштылар. Юлдашев кемнедер көткән сыман ишек ягына карашын салды.

— Ә хужалар кая?

— Кем белсен, без килгәндә дә өйдә кеше юк иде, Зариф Салихович,— диде Касаткин.

Теге-бу турыда сүз алышкалый-алышкалый, беркадәр гәпләшеп утырдылар. Ул арада, озак көттермәстән, ишек бусагасында сакал-мыегын борынгы картларча мул йөрткән өлкән яшьләрдәге бер кеше күренде. Моны беренче тапкыр гына күрүләре түгел иде инде. Бернича тавыш берьюлы аңа мөрәжәгать итте:

— Петрович, саумы, саумы!

Чакырылмаган кунакларга баштарак беркадәр сәерсенеп караган Петрович ык-мык килә башлап та үзен тиз кулга алды. Өстен салмыйча гына өйнең нәкъ урталыгындагы тимер мичкә күмер өстәде, ишек кашындагы эскәмиягә барып утырды. Аның белән беренче булып Юлдашев үзе сүз ачты:

— Кәефләр ничегрәк, Петрович?

— Ярыйсы, Зариф Салихович.

— Эләгәме?

— Зарланырлык түгел.

— Бригада ял итә, ахры?

— Балыкчылар бүген авылда инде алар.

— Без соң нишләрбез икән?

— Сезгә житәрлек кенә табылыр анысы...

Алар бер-берсен тиз аңлаштылар. Динаны өйдә калдырып, барлык ир-ат берьюлы чыгып киттеләр. Дина өстен салды. Гадәте буенча стена кәзгесенә карарга теләде. Андый көзге булмагач, ридикюлендәге кечкенә көзгегә карый-карый чәчен-башын тәртипкә китерде. Аннары, бу өйдә күптән яшәгән шикелле, алъяпкыч бәйләп, җин сызганып эшкә тотынды: сумкадан бәрәңгесен-суганын һәм башка кирәкле әйберләрне алды. Өйдә аларга гына житәрлек савыт-саба, тегесе-бусы да бар икән.

Бер илле былчырак утырган чүпле идән башта ук Динаның күзенә бәрелгән иде. Ул, әрчи башлаган бәрәңгесен куеп торып, ин башлап бик әйбәтләп идәнне юып алды. Тимер мич гөрләп яна. Шундый сихри тынлыкта, шундый гади генә балыкчылар өендә ул үзен бик рәхәт хис кылды. Моңда килгәненә һич тә үкенерлек түгел. Петрович чиләк белән балык алып кергәндә ул ихлас күнелдән татлы уйларга бирелеп бәрәңге әрчи иде. Карт тулы гәүдәсеннән дәрт ташып торган бу күнелле затка, яшьлекне искә төшерә торган бу карлыгачка ирексездән кызыгып карап торды. Аның шул кызыгу һәм соклану карашын сизенгән сыман, Дина шатлыклы аваз салды:

— Булдымы, Петрович?

— Булды, касаточка!

Дина карт кулыннан бераз кыяр исе килеп торган бер чиләк балык алды. Карт тагы бер мизгел сүз катмыйча гына аңа күз төшереп алды. Аның бу сылуны өчме-дүртме тапкыр гына күрүе. Нигәдер һәр күргән саен сөйкемлерәк һәм чибәррәк тоела ул картка. Ул кайсының бәхете икән? Динаның үзен бик иркен һәм ачык тотуы гажәпләндерә иде аны.

Тулысынча үз шөгыленә бирелгән Дина картның чыгып китүен дә сизми калды. Кин болын куенындагы бу ялгыз өйдә, жылы тимер мич янында кайнашу, беләк хәтле зур-зур чабак, алабуга балыкларының тәңкәләрен кыру аның өчен аеруча күнелле иде. Дина авыз эченнән генә көйли башлады. Бу минутларда ничектер үз тавышы үзенә ошады. Бер арада тәрәзәгә дә күз салды. Анда шактый ерактагы печән кибәннәре һәм әрәмә куакларыннан тыш берни күренми иде. Ул башлаган жырын өзмичә генә үз шөгылендә булды.

Петрович, кунакларны бер-берсеннән ерак булмаган бәкеләр янына утыртқач, кечкенә генә будкага кереп китте. Юлдашев ихлас күнеле белән балык чиертүен көтсә, Кукушкинга барыбер, балык капса ни дә, капмаса ни. Касаткинның да алай бик зур теләге булмаса да, табигать кочагында аңа да рәхәт һәм ул да үзен бик иркен хис кыла иде. Күп булса ярты сәгать вакыт үтмәгәндер, Юлдашев белән Касаткин берничә балык эләктереп тә алдылар. Тик менә Кукушкинга гына эләкмәде. Балык чиерткән сыман итә дә, кармакны тартып чыгаруга берни юк. «Бәхетсез мин. Балыклары да алдарга күнеккән беткәннәр. Хитри бәкегә туры килдем»,— дип үз-үзенә зарланудан бушамады. Шулай утыра торгач, ул әзрәк йокымсырап та китте. Аннары инде балык турында

бөтенләй онытып, кармак сабын да кулыннан ычкындырып жибәрде. Тик Касаткин эндәшкәч кенә ул күзләрен ачып жибәрде һәм кармак сабын яңадан тотты.

Юлдашев бер ара кызыгып карап торды. Кайчандыр пароходлар, баржа, көймәләр кайнашып торган Кама елгасы тирән йокыга талган. Елга өстендә тигез урыннар булган кебек, ак дулкыннарны хәтерләткән эреле-ваклы калкулыклар, ак түмгәкләр дә шактый күренә. Әйтерсең лә елга өстендә дулкыннар уйнаганда көннәр суыткан да алар шул үз рәвешләрен саклаган хәлдә катып калганнар һәм хәрәкәтсез тора бирәләр. Ярның һәр ике ягындагы урманнар, болыннар берсен икенчесе алмаштырып, әллә кайларгача китәләр. Аларда нинди генә төсләр, нинди генә буяулар, нинди генә сихри матурлыклар юк! Бу минутларда дөньясын да онытты ул. Тик кулындагы кармак сабы тартылып киткәч кенә айныган кебек булды. Кармакка тагы бер алабуга элэккән иде. Бара-тора Юлдашевның тәне туңып китте. Болай жылы сыман булса да, кышкы салкынның әкренләп аяк-кулларга үрмәләвен чамалап алды һәм урыныннан кузгалды. Гүя шуны гына көтеп торган Кукушкин да жәһәт кенә тып итеп аякка басты. Касаткин да алар янына килде. Кукушкинның чыраена яңадан кызыллык чыга башлады. Табан астында салкын тараканнар йөгерүен тоеп, ул биеп тә алды, сүзен сүзеннән өзмичә әйтеп ташлады:

— Без Динаны бөтенләй оныттык. Анда аның бер үзенә генә күңелсездер бит...

— Инде уха да өлгергәндер, шактый вакыт булды,— диде Юлдашев.

— Әйтәсе дә юк, Зариф Салихович, уха! — Кукушкин тагы да нидер әйтмәкче иде, якында гына агачлар арасыннан килеп чыккан Петровичны күргәч, туктalып калды. Кешеләр ялгыз өйгә таба атладылар.

Килгән саен үзләрен тәмле уха пешереп сыйлау белән бергә, үзе дә кунаклар алып килгән күчтәнәчләрдән, бигрәк тә эчемлекләрдән авыз итәргә ярата торган Петровичка Кукушкин сүз кушты:

— Сезнең монда бик күңелле икән!

— Төрле чак була инде,— диде Петрович.

Юлдашев, Кукушкинга карап:

— Тамак төбе кычытамы? — дип көлде.

— Анысы да бардыр инде, Зариф Салихович, хи-хи-хи...

Касаткин болай да күп сөйләшергә ярата торган кеше түгел, эндәшмәде. Берничә адым атлауга Кукушкин тагы тел тибрәтте:

— Дөньяда туганнарча гөрләшеп яшәүгә ни житә, Зариф Салихович! Бер-береңә ихтирам белән...

«Менә шундый кешеләр күбрәк булса иде. Ни әйтмә — сүзеннән чыкмас. Нәкъ солдат инде,— дип уйлады Юлдашев.— Бер-береңә ихтирам...» Юлдашев үзе дә үзеннән югарыларга шулай ихтирам белән карый лабаса. Ул һәркайда шулай булырга тиеш тә. Тик менә дөньяда бар кеше дә алай түгел шул. Әзрәк кулында власть булса, тәкәбберләнә кайберәүләр. Андыйларга менә шундый иң кирәкле сыйфатлар житми дә. Үзләренчә мөгез чыгарырга маташалар. Андый мөгезнең сынып кую ихтималын онытalар. ахры. Төзү-монтаж идарәсе башында Касаткин кебек үз чамасын үзе белеп яши торган кеше булса, һәркайсы өчен әйбәтрәк булмас идеме? Кукушкин, гәрчә әллә ни киң колачлы булмаса да, үзенең жанлы, күндәм гадәте белән ошый иде аңа.

— Әйдәгез, бер кәефләнеп алыйк әле, Петрович.

Юлдашевның өйгә житәр алдыннан әйтелгән бу сүзенә каршы Петрович:

— Әйе шул, дөньяда яхшы кәефкә ни житә! — диде.

Картның бу сүзе Юлдашевның күңеленә сары май кебек йомшак ятты:

— Дөрес, Петрович, йөз мәртәбә дөрес!

Ишекне ачып жибәрүгә, әнис, борыч салынган тәмле уха исе кешеләрнең борын юлларын кытыклап сулышларга керде. Һәркайсы Дина тарафыннан өстәлгә әзерләнеп куелган ризыкларны күреп, өске киемнәрен салырга ашыктылар.

13

Юлдашев кабинетны бер-ике тапкыр әйләнеп килде дә янә терсәкле, уңайлы урындыгына утырды. Көньякка караган тәрәзә пәрдәләре кайтарып тартып куелган. Тәрәзәдәге боз бизәкләрен яктыртып кояш нурлары сузылган. Бер караганда язгы боз кисәкләренә, бер караганда тауларга яки дулкыннарга охшыйлар иде ул бизәкләр. Хәтта шундый салкын көндә дә бу кылыч нурлар кышкы бизәкләрне көмешләндереп эретәләр. Нигәдер шул бизәкләр, шул кылыч нурлар Зариф Салиховичның хәтеренә сөйкемле Динаны төшерделәр.

Дина белән бергә аның уйлары әллә кайларга, Кырым, Кавказ курортларына үрмәли башлаган иде инде, өстәлендә яткан сызмалар күзенә ташланып, тукталып калды. «Нишләргә соң моның белән? Дөрес, бик кирәк булганда, кайчагында артык кыю адым ясаудан да чигенергә ярамыйдыр. Аның көтелмәгән файда, уңыш, яңалык биреп куюы да мөмкин... Киресенчә, көймәне комга китереп терәве дә ихтимал. Монысына күбрәк ышанырга була. Сафин ни өчен соң гел үзенчә генә мөгез чыгара? Аның кылган эшләреннең инде әллә ни кин колачлы булмаганнарын баш инженер ул хәтле күреп тә бетерми. Юк. Ул яшь көчләрнең инициативасын буып йөрүчеләрдән түгел. Тик... Ә бу юлы нишләргә соң? Бөтенләй юл куймый торса, моннан элекке берничә очрактагы кебек, тагы да уйлаганын гамәлгә ашырмасмы Сафин? Аны кем белә?»

Юлдашевның өстәлендә яңа рационализаторлык тәкъдиме ята. «Һы,— дип кашларын жыерды ул.— Ниндидер Фиргали Гатиннар, Зиннур Гафиятуллиннар тәкъдиме... Металл-конструкция детальләрен тимер-бетон балкалар белән алыштырырга тәкъдим итәләр. Сафин хуплый?! Имеш... Кислород цехы бинасының түбәсен алар «уйлап тапкан» материаллар белән ябарга кирәк...— Юлдашев, нишләгәнен белмәгәндәй, бер-ике йотым су эчте.— Акылыгыз алтын икән... Ишелеп төшсә, кем жавап бирер? Иң беренче булып кемнең якасыннан урап алырлар?»

Ул моннан күп еллар элек, Себердә эшләгән чакларда булган зур бер күнелсезлекне исенә төшерде. Ниндидер рационализаторлык тәкъдимнәренә ышанып, нигезен тирән казымыйча гына зур пулат салырга керештеләр. Янәсе, мәнгелек түң жир. Чыдар. Күтәрер. Бу булачак зур завод стенасы иде. Өч кат йорт биеклеге салгач, шул стена утырды... Ярыклар хасил булды... Нинаять, ишелде. Соңыннан китте тикшерүләр, китте чокчынулар: түзеп кенә тор! Комиссияләр... Ул вакыттагы яшь белгеч инженер Юлдашевка корткыч маркасы тага яздылар. Хәкем эскәмиясенә чак-чак утырмый калды. Нихәтле тирән кичерешләр, жанны газаплаган кайгылар аның йөрәген телде ул чакта...

Юлдашев, зур һәм кыен мәсьәләне чишүгә якынлашып килгән кебек, имән бармагын маңгаена төртте дә урыныннан торды. Янә уйларын дәвам иттереп, йомшак келәмгә басып йөренә бирде. Әйтик, Сафинны тиздән башланачак яңа төзелешкә күчерсәләр? Ә аның урынына... Касаткин бер дигән кандидат булачак. Касаткин урынына... (Юлдашев татлы елмаеп алды.) Кукушкин менә дигән кандидат түгелме соң! Әйе, якын көннәрдә ул Никитин алдына бу мәсьәләне куярга, үзенең исәпләрен әзер тотарга тиеш. Барыннан элек аның, баш инженер буларак, әйткәннәрен каршылыксыз үти, аңа буйсына, проекттан читкә чыкмыйча эш итә торган кадрлар кирәк. Теге-бу объектта нидер житми, төзү материаллары, тегесе-бусы белән эш хәрти икән, арттан жир янып

килми ләбаса. Үзәргә, көтәргә, югары оешмалардан таләп итәргә һәм максатка шулай ирешергә кирәк. Юлдашев стенада эленеп торган СССР политик картасына күз төшереп алды. «Нинди зур безнең ил. Нихәтле өлкә, шәһәрләр. Һәркайсында дистәләгән төзелеш бара. Шулай булгач, төзү материаллары ничек житеп бетсен? Берсе житсә, берсе бетә, икенчесе кими. Тормыш гел шулай бара инде ул. Ә шундый житмәүчелек кебек мөшкел хәл туганда үзеңнән артык мөгез чыгару... Алла сакласын, әллә нинди башың чыга алмаслык бәлаләргә дучар булып куюың бар. Кул астында беренче ярдәмчең Сафин кебекләр булганда, мондый хәл котылгысыз. Бүген син пан, иртәгә пропал..»

Юлдашев үз уйларына үзе батып төрлечә кичерешләр томанында йөзгәндә, ишек бусагасында секретарь-машинистка күренде. Ул ни әйтергә белмичә кыяр-кыймас торганда, Юлдашев аңа ризасыз төстә карады:

— Кем дә булса керергә сорыймы? Әйттем, кисәттем бит инде: минем вакытым юк. Мин кабинетта түгел...

Секретарь кыз бик дулкынланып һәм каушап кына сүзен башлады:

— Андрей Акимович шалтыратты, үзендә булсын, тиздән киләм,— диде.

Юлдашевның кашлары җимерелде:

— Ул кайдан шалтыратты?

— Төзелештән булса кирәк.

Юлдашев әле һаман хәл кылынмаган сызымнарга күз төшерде. Мәгәр аның башында аларның файдасы, ышанычлы булу-булмаулары турында бернинди дә уй юк иде. Никитин килеп кергәндә ул ниндидер кәгазьләр актарып, үз урынында утыра иде. Андрей Акимович өстен салмыйча гына Юлдашев каршына йомшак урындыкка килеп утырды. Йонлач бүреген салып өстәлгә куйды да, әйтерсең, кем беләндер сөйләшә башлап та ярты юлда өзелеп калган сүзен яңадан дәвам иткән шикелле сөйләнә бирде:

— Әйе, бу беренче дәрәҗәдәге эш... Бу араларда кислород цехында булганыгыз бармы, Зариф Салихович?

— Юк, Андрей Акимович, житешеп булмый. Объектлар күп, сезгә билгеле булганча, һәр көнне телефон аша гына хәбәрләшеп-сөйләшеп чыгарга да нихәтле вакыт кирәк?

— Шулай да ешрак булырга иде объектларда. Нәрсә тоткарлый, нәрсә житми — урында ачыграк күренә. Аннары шуңарга карап компасны борасың.

— Һәр участокның жаваплы кешеләре бар, начальниклар, прорабблар, мастерлар...

— Ә контроль? — дип каршы төште Никитин.

Төсе һаман саен күңелсезләнә барган Юлдашев теләр-теләмәс кенә жавап кайтарды:

— Барсына да житешеп булмый. Алай да йөрибез бит инде көчтән килгәнчә. Колачлыйбыз. Ләкин төп техник житәкчелекнең бит аның үзенә генә хас спецификасы бар.— Ул, аз гына тын торып, өстәде:— Кыскасы, һәркем үзенә тапшырылган эш өчен жаваплы бездә...

Никитин артык бәхәскә кереп торырга теләмәде. Ул кислород цехының жанлануына куана һәм моны баш инженер белән килешенгән дип уйлый иде. Сафин белән Юлдашев арасында барган тартыш аңа мәгълүм түгел иде. Бары ул Юлдашевны авыр табигатьле, басынкы һәм инициативасы шактый аксый, какшый башлаган житәкче итеп кенә таный. Никитин, барлык участокларны да бергәләп карау ниятe белән, аны үзе белән бергә жилтерәтеп төзелешкә алып китмәкче иде. Ләкин Юлдашевның кәефсезлеген күргәч, бу уеннан кире кайтты. Юлдашев порошок капканда, аны бөтенләй авыруга санап, торып китмәкче дә булган иде. Әйтәсе сүзләре бетмәгәнлектән тыелып калды.

Министрлык һәм главка төзелә торган химиклар шәһәрендә жылык электр станциясе салуны да аларга йөкләгән һәм бу эш алдагы эдан да калмый башланырга тиеш иде. Шуны күздә тотып, Никитин йтә куйды:

— Станция җитәкчелегенә бик энергияле кеше табарга кирәк.

— Главкадан жибәрерләр бәлки,— диде Юлдашев.

— Мин инде Мәскәү белән сөйләшеп карадым. Юк. Җитәкче кадр-ар табуны безнең үзебезгә йөклиләр. Сезгә ин жаваплы постларга ниндирәк иптәшләрне кую турында уйларга туры килер. Кыскасы, тиз рада без үзебезнең тәкъдимнәрне главкага хәбәр итәргә тиеш бу-ырбыз.

— Алай икән. Ничегрәк хәл кылырбыз икән соң? — дип, аскы ире-ен тешләп уйга калды Юлдашев. Әллә ничек кенә шунда, ул бер ызарды, бер агарды да, чырае тагы әүвәлге көлсу төскә керде.

— Исемлек төзегәндә бик уйлап, бик үлчәп эш итәргә кирәк булыр. Алай да төп житәкче итеп кемне тәкъдим итәрбез икән? — дигән сорау куйды Никитин.

Юлдашев иягенә таянды. Кинәт куелган бу сорау аны каушатып жибәрде. Никитин соравын кабатлап әйткәч, ул айный башлаган исерек кебегрәк бер хәлдә калды, башын калкытты.

— Белмим шул, Андрей Акимович, төп буын безнең монда. Аны йомшарту ярамый.

— Әлбәттә, шулай, ләкин кемне дә булса билгеләргә туры килә. Бу төзелеш өчен дә, тегесе өчен дә бездән, иң башлап сезнең белән миннән сораячаклар,— диде Никитин.

Аның бу сүзе Юлдашевны беркадәр рухландырып жибәргән кебек булды.

Никитин чыгып киткәч, Юлдашев урыныннан авыр гына торды, тәрәзәгә карап алды. Инде хәзер кояш утлы сөңгеләрен сузмый, боз бизәкләр эреми, күк йөзе дә соры, күңелсез иде. Ул машина чакыртты.

14

Дөнья бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә, диләр. Мөгаен, дөрестер. Юлдашевка шул рәвешчәрәк уйларга нигезләр бар иде шул.

Ачык партия жыелышы — трибунада Андрей Акимович Никитин. Аның чырае, яшьләрне хәтерләткәндәй, бөтенләй ачылып китте. Ул, күзләрендә ниндидер ышанычлы очкыннар уйнатып, көр тавыш белән сөйли-сөйли докладының соңгы өлешенә житте:

— Безнең яшь, әмма тамыры нык, көчле коллектив, нинди кыенлыклар алдында калмасын, аларны ерып чыгарга сәләтле икәнен күрсәтте. Моны без төзү материалларына аеруча ачыккан, аеруча йөдәгән көннәрдә күрдек. Безнең кешеләр кыенлыктан чыгу әмәлен таптылар. Мин бу урында диапазоннары киңәя барган, мөмкинлекләре үсә барган рационализаторларыбыз турында жылы сүзләр әйтергә телим. Безнең Тын елга буендагы төзелештә барлыкка килгән, безнең шушы жирләрдә туган термопоритны гына алып карыйк...

Никитин, үзәк лаборатория хезмәткәрләренең тырышлыгын, аеруча Касаткин һәм Кукушкиннарның бу эшне барлыкка китерү өчен салган хезмәтләрен әйтеп, төзелешкә бик зур файда килгәнлеген аеруча куанычлы төстә сөйләде. Үзен аклаган бу яңа төр төзү материалын алар белән ярышучы күрше өлкәдә төзелә торган электр станциясе объектларында киң кулланалар икән.

Никитин, башта бер кыза, бер сулпәнләнә төшеп сөйләсә, тора-бара бөтенләй кызып китте. Залда чебен очкан тавыш та юк, һәркем бик бирелеп тыңлый иде аны.

— Алдагы яз, җәй һәм көзге вакытлар — хәл иткеч көннәр булырга тиеш. Эшнең күләме гаять зур. Беренче һәм икенче пар казаннарын

төзеп бетерү һәм файдалануга тапшыру — бу безнең беренче чираттагы бурычыбыз, иптәшләр! Турбогенератор комплексы монтажлауны күрсәтелгән срокта төгәлләү — беренче чираттагы бурычыбыз! Химчистка корылмалары, идарә итү щиты, ягулык-мазут хуҗалыгы — болар беренче дәрәҗәдәге эшебез! Механика-ремонт цехлары да — беренче номерлы бурычыбыз!

Ул тагы да әллә ничә төрле «беренче чираттагы бурычлар»ны санап чыгуга, кайсыдыр, әкрен генә:

— Барысы да беренче чираттагы бурыч... Икенче, өченче чираттагы бурычыбыз бер дә юкмы икәнни? — дип куюга, зал буйлап көлү дулкыны үтте. Әмма үз хисләре, үз уйлары белән йөрәге кайнаган Андрей Акимович Никитин бу хәлне сизмәде.

Тагы берничә оратордан соң, сүзне Юлдашев сөйләде. Аны да ярыйсы гына тыңладылар. Юлдашев үз-үзеннән канәгатьләнү хисе белән президиум өстәле артына барып утыруга, залдагы урта рәтләрнең берсендә Васил Сафин белән янәшә утырган Игнат Данилов урыныннан кузгалып куйды.

— Әллә сөйлисеңме?

Сафинның бу соравына каршы Игнат бер генә сүз белән җавап бирде:

— Сөйлим.

Председательлек итүче әллә аны күрмәде инде, сүзне икенче кешегә бирде. Монарчы тыныч кына утырган Игнат Данилов, керпегә ялан аяк баскан сыман, кыбырсый башлады, як-якка каранды, аның күзләре председательлек итүчедә иде. Ниһаять, аңа да чират житте. Ул трибунага күтәрелгәч, үзенә караган йөзләгән күз алдында ни әйтергә белми беркадәр аптырабрак торгач, салмак кына башлап китте:

— Җыелышның вакытын күп алмас өчен мин кереш сүзсез генә башлап китәр идем.— Аның бу сүзе шундук моңарчы илтифатсыз утырганнарны да үзенә каратты.— Алдан ук әйтеп куям. Кайберәүләргә бәлки катырак та бәрелермен, иптәшләр, моның өчен мине гафу итәрләр. Мин менә әйтер идем. Безнең кайбер җитәкчеләребез...— Шулай диюгә ничектер Игнат Даниловның теле көрмәкләнеп калды һәм ул як-ягына каранып алды.— Әйе, кайбер җитәкчеләребез, әллә ялгышып, әллә шул ялгышуларын дөрес санап, кайбер очракларда дөрес булмаган юлга басалар. Ни өчен гамәлгә ашырылган тәкъдимнәрнең авторлары бутала. Хәзер бездә генә түгел, башка урыннарда да кин кулланышка кереп бара торган термопоритны булдыруда Касаткин белән Кукушкин никадәр баш ватканнардыр һәм аны производствога яраклы хәлгә китергәнче үзләреннән никадәр көч яки яңалык керткәннәрдер, мина ул тиклесе билгеле түгел. Баш инженерның бу турыдагы приказы безнең төзелештә күпләргә мәгълүмдер дип беләм. Тик бу тәкъдимнең төп авторы бөтенләй читләтеп үтелгән...

Зал җиңелчә генә шаулап алды да тынды. Халык түземсезләнеп көтә иде. Кинәт ниндидер бер калын тавыш сорап куйды:

— Ә кем ул?

— Мин, иптәшләр, термопорит турында беренче тапкыр Васил Закирович Сафиннан ишеттем һәм сынау өчен дә измә узелында беренче башлап ул материал әзерләде. Үзәк лаборатория белән измә узелы арасында сукмак салып бетерде. Ни өчен баш инженер приказында төп башлап йөрүченең фамилиясе төшеп калган. Ялгышлыкмы бу яки тиса тиенгә, тимәсә ботакка дип чынлыкны читләтеп узарга маташумы? Минем шуны беләсем килә...

Юлдашев үзен инә өстендә утырган шикелле тойса да, түзде, чөнки шунсыз мөмкин түгел иде. Аның инде мондый тәнкыйть сүзләрен гомерендә беренче генә мәртәбә ишетүе түгел. Ләкин кем тәнкыйтьли бит! Үзеннән югарырак торган кеше булса, бер хәл иде. Менә хәзер нишләргә аңа? Бунтарь бу кешегә җавап бирергәме, юкмы? Юлдашев

гул турыда уйлап утырганда, Игнат Данилов, сүзен бетереп, трибунаан китеп тә барды. Игнат кузгаткан шаукым кешеләрнең күнеленә арып кергән инде. Залның төрле ягыннан тавышлар ишетелде:

— Бу ничек болай була инде? Юлдашев аңлатма бирсен.

— Сафин ник тыныч кына утыра? Безгә дәреслек кирәк!

Җыелыш председателе, мәсьәләгә ачыклык кертү өчен иң элек Сафинга сүз бирергә булды. Ләкин, аның фамилиясен әйтеп мөрәҗәгать иткәч, Сафинның залда юклыгы мәгълүм булды. Юлдашев белешмә бирү өчен трибунага чыгып басты. Ул Игнатның чыгышын демагоглык дип бәяләгәннән соң, тавышы калтыраганны да тоймастан, сөйләп китте:

— Мин документларга таянып эш итәм. Дөрес, кайсыдыр бер җыелышта иптәш Сафин да ул турыда сүз кузгаткан иде. Бу минем дә хәтердә. Башка иптәшләр дә хәтерлиләрдер бәлки... Ләкин мәсьәлә турында башлап сүз әйтү генә уйлап табучы исемен бирү өчен нигез булып җитә алмый бит әле.— Юлдашев, нидер әйтергә оныткан шикелле, бераз сүзсез торгач, башлаганын шулай очлады: — мин бу мәсьәлә белән тагы бер кат кызыксынып карармын. Әгәр дә хата-фәлән киткән икән, аны төзәтү әллә ни кыен эш түгел, разберусь, иптәшләр...

Игнат, Василны урынында күрмәгәч: «Нигә китте икән ул?» — дип аптырый калды.

Юлдашев тиз генә тынычлана алмады. Урынына утыргач, авыз эченнән әллә ничә мәртәбә шулай тиргәнде: «Мальчуган, исәр баш...»

Игнат Данилов соңгы сүзләрен әйткән чакта Васил Сафинны телефонга чакыртканнар иде. Ул янадан залга кергәндә икенче берәү сөйли иде инде. Әлеге шул оратор (бик сусаган булса кирәк), сүз йомгагын төйнәгәч, бер стакан су эчеп бетерергә өлгерә алмады, Васил кул күтәрде. Председательлек итүче аны шундук күреп алды.

Васил да, трибунага чыгып баскач, беркадәр каушаудан котыла алмады. Әмма бара-тора теле тиз язылды. Урындагы төзү материалларыннан хуҗаларча дөрес файдалану турындагы фикерләрен әйтеп, рационализаторлык мәсьәләләренә күчкәч, Васил тагы да иркенләбрәк сөйли башлады. Аңа коммунистлык намусы кешенең күзенә туры карап әйтергә куша иде:

— ...Тормышта һәрвакыт әзер юл гына булмый. Күбесенчә юлны безнең үзебезгә салырга, сукмакларны үзебезгә ерырга туры килә. Шулай итмәгәндә, бер урында озак таптанып тору котылгысыз. Ә безнең кайбер житәкчеләребез яңалык кертүгә бик сагаеп карыйлар яки аны читләтебрәк, әйләнебрәк үтү ягын артыграк күрәләр... Бу аеруча иптәш Юлдашевка кагыла. Мин аның тәҗрибәле житәкче, оператив мәсьәләләрне оста хәл кылуын инкарь итәргә җыенмыйм. Ә менә ни өчен безнең хөрмәтле баш инженер иптәш Юлдашев эшчеләрнең рационализаторлык тәкъдимнәрен әллә ничә айлар буенча карамый, хәл итми? Бу миңа аңлашылмый. Ул тәкъдимнәр өстәл тартмасына салып тозлау өчен кертелмәгәннәр бит. Яшерен-батырын түгел, кай чагында бик кителә күнел, бик төшә. Төзелеш «арбасы» болай да авыр. Аны тарту өчен...

Юлдашев, бөтенләй түземен югалтып, реплика ташлады:

— Фактлар?..

— Фактлармы? — дип шундук сүзен ялгап китте Васил: — Әлеге дә баягы термопорит, аңа хәтле теге ни... металл-конструкцияләрне тимер-бетон балкалар белән алмаштыру... Саный китсәң...

Юлдашев тагы да нидер әйтте, әмма ул тиклесен Васил ишетмәде. Ул салмак кына башлаган сүзен кайнап, ярсып тәне кызган хәлдә очлап куйды.

Юлдашевның чыраена ачу чыгып катты. Ул инде кем сөйләвенә дә әһәмият бирмәде. Бераздан күтәрелеп караса, трибунада Солтан Сабировны күрде. Ул аның: «...Тиешле иптәшләр үзләренә карата әйтелгән

тәнкыйтьне дөрес аңларлар һәм кимчелекләрен төзәтерләр, яңадан кабатламаслар дип ышанасы килә»,— дигән сүзләрен генә колаклары белән тотып алды. Бу «ташлар»ның да аның бакчасына атылганын бик ачык төсмерләде. Кәефе кырылган, кашлары җыерылган Юлдашев белешмә өчен сүз сорады һәм авыр хәрәкәт белән урыныннан күтәрелде.

15

Бер тапкыр Васил әнисе белән улы Ринатны Игнатларга алып барган иде. Шунда Зиннур хатыны Хәмидә дә үзенең балалары белән туры килде. Балалар тиз танышып киттеләр һәм гөрләшеп уйный да башладылар. Моңарчы күрше-күләннән гайре монда беркем белән дә якыннан таныш булмаган Гашүрә җиңги дә үзенә яңа ахирәт тапты. Ир-ат һәм алар белән бергә Хәмидә дә китеп баргач, ике карчык дөньяларын онытып, рәхәтләнеп сөйләштеләр. Шуннан бирле карчыклар үзара йөрешә торган булып киттеләр. Коры-сары пешерәләрме, кунак-төшемеме буламы — алар бер-берсен чакырып алалар.

Варвара карчык килеп кергәндә, Гашүрә җиңги керләр үтүкләп маташа иде. Теге-бу турыда гәп ачып белгән-күргәннәрне телгә алдылар. Бер арада Варвара карчык үзенең улы өйләнмәүдән зарланырга да җитеште:

— Минем Гнатым ни уйлый торгандыр инде? Югыйсә аның ишеләр күптән инде башлы-күзле булып беттеләр. Әле безнекенең бер генә дә исендә юк. Белмим, күпме сазап йөрергә була торгандыр!

— Әйтеп караганың юкмыни? Исенә төшергәләп торырга кирәк,— диде Гашүрә җиңги.

— Әйтеп тә карыйм инде, кая ул әйтмәгән, акыйрәт, дәшми. Башын саламга тыккан кире үгездәй тик тора шунда.

— Ничә яшьтә инде синең Игнатың?

— Утызның өстендә инде, яше бара.

— Аның соң күздә тоткан кызы юкмыни?

— Әйтми бит, безнең таш маңгайның авызыннан сүз тартып алып кара, әйтер ул сиңа! Әле төнәгенәк әйтеп тордым тегеңә, мин әйтәм: инде түбәндә чәчләреңә сирәгәя башлаган. Бөтенләй коелып беткәнен көтсәң, кызлар куркырлар үзеңнән. Аңа ни, дивана кебек тик кашларын җыерып утыра. Әр эштә бер багыты үткәчен соң була бит ул, дигәндәй.

— Бәй, шулай булмыйни.

Варвара карчыкның теле һаман саен чишелә барды:

— Элек, без яшь чакларда, безнең авылда үмер буена катын алмаган Бәчели дигән бер кеше барые. Тәки картайды, өйләнмәде. Үләр алдыннан гына бер карчыкка йортка керде бу. Менә, акыйрәт, бер мыскал да ялганлап әйтүем түгел, шуларның балалары булды. Үзләре капкарт, балалары япь-яшь. Безнең Гнат та шулай булмаса инде, кодаем.

— Аңа кыз димләп карарга кирәк. Шулай итеп муенын бөгеп булмасмы,— диде Гашүрә.

Варвара карчык ирен читләрендәге сырларны арттырып елмайды гына:

— Аныкын белмәссең, дигәндәй. Үзе шундый сау-сәламәт, типсә тимер өзәрлек. Башында кибәк дисәң, укый алмаган булырые. Инженер бит, инженер. Әллә берәрсе сихерләде инде. Алай дисәң дә булмый. Белмим инде, әллә күәс төбе булганга шулай микән? Төпчек бит.

Ни хәтле сүз куертсалар да, Игнатны өйләндерү әмәлен таба алмадылар. Аннары Гашүрә җиңги Варвараны юатып куйды:

— Әйдә, артыгын борчылма, Барбара кордаш, хәзерге яшьләрне белмәссең. Синең улың да бер истә-оста юк чакта берәр пумала башны җитәкләп кайтыр да керер әле. Менә күрерсең...

— Берүк шулай булсын, пәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килсен,— диде Варвара карчык.

Керләрне үтүкләп бетергәч, хужа карчык ахирәтен өстәл янына чәй эчәргә чакырды. Ике карчык, шулай эчләрен бушатып, берничә чынаяк чәй эчәргә дә җитештеләр. Бераздан Гашүрә җиңги карават астыннан кечкенә-җыйнак кына кара чемодан чыгарды, шуңа күлмәк-ыштан кебек әйберләр сала башлады. Ул улы Василның шәһәргә китәргә җыенганын әйткәч, Варвара карчык янә телгә килде:

— Әллә җәмәгатен алып кайтырга барамы?

— Эш белән бара. Белмим, ай-һай, алып кайтыр микән. Башта тегене ялындырды, хәзер малайның да исе китми бугай. Һич кенә дә килентегә телгә алып сүз катмый. Яшьләрнекен белмәссең тагы, бер җеннәре кибәрсә, килешеп куюлары да бар. Югыйсә, килен үз янында булса, ныгыбыз өчен дә әйбәт булыр ие.

— Киленегезнең хаты киләме?

— Килми. Кош теле хәтле дә хат салганы юк, бер авыз сүз язганы юк.

— Алма кебек баласын сагынмый микәнни ич тә?

— Сагынса килер иде. Сагынмый торгандыр, ике ятып бер төшенә дә керми торгандыр, күрәсең...

— Киләп тә алмый.

— Алып карасын, аңа әзерләп куйган артык бала бар, ди менәтәкә. Әтисе үлеп ярата аны. Бала үзе дә бер дә әнисен юксынмый. Ничек булып бетәр инде эшләре, татуланып, бер ояда торырлармы — бер алладан гайре аны кем әйтә алсын?

Васил кайткач, Варвара карчык озак юанмыйча китеп тә барды. Аны озатканда әнисенең барлык уйлары, барлык кайгыртулары улының киләчәгә турында, аның гаилә тормышы турында икәнен бик ачык сизәйлады Васил.

Озакламый ул, кечкенә кара чемоданны кулына алып, юлына чыгып китте. Улы киткәч, карчыкка бик ямансу, бик күңелсез тоелды. Ичмаса, гадәттә бер килгәч, аларда озак утыра торган Варвара карчыкның да тиз китеп баруы хафаландырды аны. Ул тагы үзенең үткән гомерләрен исенә төшерде, ямансулаган хәлдә, авылын сагына башлады. Аннары кичкырын балалар бакчасыннан кечкенә Ринатны алып кайтачагын исенә төшерде дә кителә башлаган күңеле әкренләп үз урынына утырды.

Василның күңеле икеләнде. Таныш йорт, таныш тәрәзәләр якынлашкач, ниндидер бер эчке сизенү, бер эчке тавыш аңа чигенергә кушкан кебек булды. Һәм ул якындагы гостиницага таба юнәлде. Номерга урнашырга ордер алгач, бүлмәгә дә кереп тормастан, чемоданын әйберләр саклау бүлмәсенә тапшырды да төзелеш кирәкләре белән баглы булган мөһим йомышларын юлларга кереште. Баштарак аңа кирәкле кешеләр туры килмәделәр, төштән соң һәркайсы диярлек үз урынында иде.

Васил кичкырын гына гостиницага әйләнеп кайтты. Бүлмәгә кереп, юынып, өс-башын рәтләгәч, бер кавым кая барырга, нишләргә белмичәрәк аптырашлы минутлар кичерде. Әллә беркая да чыкмыйча, шушында гына калыргамы? Аның бу соравына үзеннән башка җавап бирүче булмаячак, билгеле.

Ул урамга чыкты.

Тагы таныш йортлар, таныш тротуарлар... Ул, үзләренең квартиры подъездына җитәрәк, аңа каршы кызу-кызу килүче берәүне күрде. Көн хәтсез салкын булса да, аның башында эшләпә, аягында гадәти җәйге туфлиләр генә иде. Төз гәүдәле, борын астыннан гына калдырып мыек җибәргән бу кешегә ул артык әһәмият бирмәде. Очраган бер кешене

жентекләп карауның ни кирәге бар? Коридорга керде. Аны җәен агартканнар булса кирәк, стеналары чиста. Үз квартиры ишегенә җитү белән нигәдер ул шундук звонокка басмады, нидер кирегә тарта сыман иде аны. Эчтән бер төрле дә тавыш ишетелмәде. Ниһаять, ул звонокка басу белән ишекне ачтылар. Бер мәлгә сүзсез-нисез калган кебек күренгән Нурзилә үзен бик тиз кулга алды. Салкын гына күрештеләр. Өйдәге тәмәке төтенен әле генә сизгән кебек, Нурзилә форточканы ачып җибәрде. Өстәлдә көл савыты, ниндидер журналлар. Василга калса, кайчандыр үзе торган бу квартирның һавасы ят, үзе дә ят сыман иде. Аның исенә кылт итеп бая үзе бирегә кергәндә очраган нечкә мыеклы кеше килеп баскандай булды. Бәлки, ул монда папирос тарткан, төтен дә, ят ис тә аннан калгандыр. Бәлки... Васил шундый уйлары белән тартышып утырганда, Нурзилә икенче як бүлмәгә үтеп, авызына папирос кабып чыкты. Нурзилә папирос кабызып җибәргәч, Васил, бер яктан, аптыраса, икенче яктан, куанып куйды. Димәк, ул ялгыша. Аңа калса, Нурзилә калынаебрак киткән сыман, чәчләрен дә очлы кибәндәй кабартып куйган, тик менә күзләрендә ниндидер аңа аңлашылмый торган төссезлек арткан кебек... Ул Василга анда-санда гына карашын сала, аннары әледән-әле бер бүлмәдән икенчесенә йөренә иде. Нәрсәдер эзлидер булса кирәк. Аннары ул йөрүеннән туктады, стена буена куелган диванга барып утырды. Бу минутларда аның күз карашы ят һәм салкын иде. Урнаша башлаган күңелсез тынлыкны башлап Васил бозды:

— Тормышларың ничек?

— Күрәсең, исән. Ә сезнең?

— Синең хәер-фатихада, картлар әйтмешли, әгәр дә шундый хәер-фатиха булса. Кычкырып зарланышлы түгел хәлләр.

— Ринатны ник алып килмәдең?

— Ул детсадта, эше во малайның! Ә алып килү... Ничек инде кышкы салкында баланы җәфалап йөртергә? Аннары бит аның белән синең кызыксынуың да шуның хәтле генә...— Әллә нинди чәнечкеле сүзләр ычкындыруыннан сагаеп, Васил бу турыда артык сөйләшмәскә булды.

Нурзилә, берничә тапкыр төтенгә тончыккач, бер башы ирен кызылына буялган папиросны тиз генә көл савытына батырып сүндерде. Көл савытында папирос төпчекләре байтак һәм алардан өйгә ят ис бәреп тора иде кебек. Василның күңеленә тагы да эчпошыргыч шөбһә сөрем үрмәләде. Бар уйларны, бар исәпләрне, бар икеләнүләрне бер якка куеп, аның соңгы мәртәбә өзеп сөйләшәсе килә, тик менә шул турыда ничек башлап җибәрергә генә белми иде. Васил монда килгәнче, Нурзилә уллары турында аның үзәгенә үтәр, урлап киткәнсең, фәлән-төгән дип күзне ачырмас, рәвешендәрәк уй йөрткән иде. Ләкин Нурзилә, икеөч сүз белән генә сораштыруын искә алмаганда, Ринат хакында артык төпченмәде. Димәк, аңа барыбер. Васил Нурзиләне үз баласына карата бу кадәр салкын күңелле, бу кадәр таш бәгырьле булыр дип һич тә уена китермәгән иде.

Нурзилә үзе үпкәләп тә, башкача да бер төрле дә сүз башламады. Аңа, мөгаен, барыбер иде булса кирәк. Бары шул турыда башына ныклы фикер туплагач кына, Васил күңелен борчыган хәл турында әйтергә булды.

— Безгә ныклап сөйләшергә кирәк, аңлашырга, Нурзилә. Безнең семья тормышыбыз болай дәвам итә алмый. Кайсыбызга булса да беребезгә уступкага килергә кирәк.— Васил Нурзиләнең төзелешкә барудан баш тарту турында яки аның үзен янә шәһәргә кайтуын кирәк санап, катгый сүз әйтер дип көткән иде. Ләкин моңа кадәр булган сөйләшү-бәхәсләрдә Нурзилә гел тукып торган фикерләрен кабатламады. Ул, бераз тын торып, шуны гына әйтте:

— Белмим, нәрсә сөйләшергә кирәктер безгә? Безнең семья тормышы синең арканда, синең кирелегең аркасында күптән җимерелде инде.

— Әйе, гомер буе бер-беребезне аңламый яшәгәнбез икән.

— Хәзер инде аңладык,— диде Нурзилә. Аннан кинәт сүзне икенчегә борды: — Бәлки ашыйсың киләдер, әзерләп бирим.

— Кирәкми. Мин тук.

— Алайса мина төнге дежурга китәргә кирәк.

— Бәлки берәрсен үз урыныңа күндерә алырсың. Болай аңлашмыйча ярамый бит инде. Шалтыратып карасаң нишләр?

— Кеше юк. Мин барырга тиеш,— диде Нурзилә һәм җыена башлады.— Ачыксаң кухняда барысы да әзер. Кирәк булса җылытырсың, кофе дә шунда.

— Соң кайчан без ныклап сөйләшәбез, ныклап аңлашабыз?

— Соңыннан. Иртәгә.— Шул сүзләрне әйтеп, Нурзилә өйдән чыгып китте.

«Ни дә булса бар, моның психикасында ниндидер алмашыну...» дип уйлады Васил. Бүлмәдән бүлмәгә ишекле-түрле йөренде. Утырды. Торды. Тәрәзәдән карады. Бүлмәдәге әйберләргә күз йөртте. Әллә ни алмашыныш юк шикелле, һәммәсе элеккечә, тик бала караваты һәм коляскасы гына күренми. Бераздан ул гаилә альбомын карады. Анда да әллә ни үзгәреш сизелми, Васил кайчандыр үзе рәтләп, үзе тәртипкә салып куйганча. Тик соңгы битләргә группалап һәм аерым төшкән берничә фото өстәлгән, алар арасында Нурзилә дә бар. Иң соңгы фотога күзе төшкәч, әллә нишләп китте Васил... Карточканың бер почмагына «Сочи истәлеге» дип язылган. Ял итүчеләр... Алар арасында Нурзилә... һәм аның артында нечкә мыек, төз гәүдә... Әйе, шул үзе. Өйгә кергәндә очрады ул Василга. Кабаланып китеп бара иде. Димәк...

Василның күз алдына моннан берничә ел элекке тормышлары килеп басты. Ул шушы бүлмәләргә сагынып кайта, шушы өстәл артына утырып ашый-эчә, шушы диванга утырып ял итә торган иде. Хәзер инде ул, бу бүлмәдә утырган хәлдә, Яңа Наратлыны, андагы квартирын юксына башлады. Ринат белән әнисен каршына китереп бастырды. Нигәдер аның тора-бара әйберләрне актарып чыгасы, барлыйсы килде. Аннары ул бу исәбеннән кире кайтты. Алай да шифоньерны ачып карамыйча булдыра алмады. Кыйммәтле хушбуй исләре, Нурзиләнең кешелеккә кия торган яңа киемнәре... Тиз үк аны ябып куйды. Гадәти киемсалымнар куела торган искерәк шифоньерны ачса, аптырап калды. Саргылт төстәге болоний плащ һәм соңгы модадагы сай гына ирләр эшләпәсе. Хәтере ялгышмаса, аның үзенең мондый әйберләре юк иде кебек. Болар монда кайдан килеп пәйда булганнардыр,— ул тиклесенә Васил җавап таба алмады. Тик аңа Нурзилә генә һаман чит була барды. Вакыт-вакыт аның күңелендә көнләшү очкыннары да уянып куйгалый һәм мондый тойгы шундук читләшү, ерагаю белән алмашына бара иде. Василның ашыйсы да, эчәсе дә килмәде, бернигә кулы бармады. Ул гостиницага кайтып куну турында уйлап, өстенә киенә башлагач, кире чишенде. Шул чагында телефон шалтырады. Васил сагаеп кына трубканы алды. Ир-ат тавышы, юк, хатын-кыз тавышы... Ул икеләнеп торды. «Надя, Надечка, исән-сау гынамы?» Бер кадәр сүзсез торгач, телефондагы тыныч тавыш һаман бер сүзне кабатлады. Васил Нурзиләнең эштә икәнен әйтте. Телефонда тавыш яңадан ишетелмәде. Кем булыр?

Аңа калса бу да шикле иде. Элек алар Нурзилә белән бер караватта ята торганнар иде. Пөхтә урын. Бәлки анда хәзер теге нечкә мыек... Башына әллә нинди күңелсез уйлар килде, караваттан карашын алды да диванга урын җәеп йокларга ятты. Күзләренә йокы эленмәде. Хәзер инде ул монда ят, чит кеше иде. Очына барып чыкмаслык әллә нинди авыр исәпләр башын кайнатудан ул озак кына йокыга китә алмый ятты. Әмма күзен бер йомгач, йокысы татлы булды.

Кайда гына булма, кайда гына йөрмә, күнегелгән гадәт һаман да үзенекен итә. Яңа урында йоклаган Васил нәкъ иртәнге алтыда сикереп урыныннан торды. Мәскәү радиосы командасын тыңлый-тыңлый физзарядка ясады. Бер дә ашыкмыйча, бер дә исе китмичә генә озаклап салкын су белән бил тиңентен тәнен юды. Чәй эчте. Вакыт-вакыт сәгатенә күз төшереп алырга да онытмады. Бара-тора аңа вакыт бик озак үтә сыман тоелды. Ләкин Нурзилә кайтмады да кайтмады. Эх, уңмаган нәрсә, соңгы тапкыр сөйләшәсе иде, көймәне урталыктан алып, я уң якка, я сул якка чыгарасы иде бит. Васил бары сәгать теле унга үрмәләгәндә генә, квартир ачкычын күршеләргә куеп, китеп барды.

Төзелеш эшләре белән тегендә чабып, монда сугылып йөри-йөри, көннең ничек үткәне сизелми дә калды. Аның бу йөрүләре нәтиҗәсез калмады. Тимер-бетон һәм арматура материаллары белән тәэмин итүдәге өзеклекләр яңадан кабатланмас кебек күренде. Өстәмә рәвештә кече механизмнар алу турында да уртак тел тапты. Яңа белгечләр, монтажчылар җибәрү турында да мәсьәлә уңай якка чишелде. Шулай да әле аның эше бөтенләй тәмамланып үк җитмәгән иде, тагы да берәр көн тоткарланырга туры килер. Бәлки театр яки концертка барып килергәдер. Васил Сафин үз номерында шулайрак ниятләп торганда, ишек шакыдылар.

— Керегез.

Бусагада Нурзилә күренде. Өстендә Василга таныш җиңел, җылы, хәзерге модача кыска итеп тегелгән кышкы пальто, аякларында биек үкчәле мех итек, баш түбәсенә күпертеп куелган чәчләре мамык шәл астыннан бераз тузгып чыккан. Артистларча осталык белән пудраланган булуына карамастан, Нурзиләнең күз төпләре нигәдер кара янып тора, иреннәре никадәр җыйнак һәм килешле итеп буялган булса да, көлсудер, күкселдер кебек. Утырыштылар. Васил вакытында кайтмавы, аны көтеп шактый вакытын югалтуы, хатынның илтифатсызлыгы турында үзенең ризасызлыгын белдермәкче иде. Ләкин ул башлаганчы, Нурзилә алданрак өлгерде:

— Беләм, син ачуланган сыңдыр инде. Вакытында кайта алмадым. Эш. Ярый ла, ул синең төзелештә — план. Безнең эштә план-мазар кулланып булмый. Ана. Бала. Бүген дә биш кеше туды дөньяга. Шуның берсе бик авыр туды...

Бергә тату яшәгән чакларда да һәр көн эштән кайткач, шушынар охшашлы хәлләр турында сөйли торган иде ул. Аның сүзләрен тыңлап, Васил, теләктәшлек күрсәткәндәй, башын селкеп утырды. Ә Нурзилә сөйләде дә сөйләде. Һаман үзенең эше, сабыр һәм гасаби хатыннар турында, тыныч һәм елак балалар турында сөйләде. Васил, башта әллә ни илтифат итмәсә дә, бара-тора Нурзиләнең үзен тотышында ят, аңа аңлашылмый торган ниндидер яклар чагылуын абайлап алды. Ахры, теле дә аз-маз көрмәкләнә иде бугай. Василның борынына ят ис килеп бәрелде. Аның күз карашыннан, үзенең мондый халәтен өнәп бетермәвен сизенеп, ахры, Нурзилә гафу үтенде:

— Бер яшь анага ире бер шешә коньяк китергән иде. Нишлисең, кешеләр шатлыгы — безнең дә шатлык. Берәр рюмка миңа да тотарга туры килде. Эчми эчкәнгә башка тиз китә икән...

Бергә торган чакларында дежурлык үткәреп кайтканда аның эчү ихтималларын бер дә хәтерләми иде Васил. «Бу да, бәлки, очраклы хәл түгелдер». Нурзилә аңа якынрак килеп утырды. Бүлмә җылы иде. Ул пальтосын салып, шифоньерга элде. Васил үз-үзенә төшенеп җитә алмады: шул хәтле үк бизгәнмени ул аннан? Аның бу куллардан тотып иркәлисе дә, бу муеннардан кочып үбәсе дә килмәде. Эчендә ниндидер бер кату, йөрәгендә ниндидер салкынлык үсә бара иде.

— Ярый, кичә башлаган сүзне ялгап китик алайса,— дип авыз ачты

Васил: — Син инде мединститутка укырга кергәнсеңдер. Төп хыялың шул иде кебек... Минем белән китмәүнең дә төп сәбәбе шул иде бугай?

— Юк, әлегә кермәдем.

— Димәк, бу планың киләчәккә кала бирә? Калган эшкә кар яумасмы?

— Әйтә алмыйм. Белмим...

— Хуш, шулай булсын.— Васил күптән әйтәсе килгәнне әлегә әйтә алмыйча интегә, ничектер унайсызлана иде. Ул учын бер йомарлады, бер ачты, аннары шулай башлады: — Димәк, араны өзәргә генә кала...

— Ничек, ничек?

Нурзиләнең калтыранып әйткән бу сүзен ишетмәгән шикелле, Васил туктамастан сөйли бирде:

— Безгә инде рәсми рәвештә аерылырга вакыт җиткәндер дип беләм мин. Иң элек шул тиклесен хәл кылыйк, кайсыбыз судка бирә: синме, минме? — Васил бу минутларда мөмкин кадәр Нурзиләнең күзенә карамаска тырышты. Тегесе җавап кайтармагач, ул үзенең сорауына үзе үк җавап бирергә тиеш тапты: — Миңа барыбер, кайсыбыз да ярый. Безнең тормыш юллары аерылды инде... Узганнарны искә төшереп, баштагы сөйләшүләрне кабатлауның кирәге юк хәзер. Бу — җыелган тузанны җил туздырган кебек кенә булыр иде, ә тузанның файдасы юк...

Васил шулай, барлык бәхәсләргә, барлык тартышларга чик куярга тырышып, үзенчә иң кирәге турында гәп алып барганда, Нурзиләнең берничек тә сүз катмавы, авыр уйларга бирелгән шикелле тын утыруы гажәпләнерлек иде. Васил үзенең сораулы күзләре белән Нурзиләгә күтәрелеп карады:

— Ник дәшмисең? Эндәшмәү — риза булу билгесе диләрме әле? Әгәр шулай икән, суд алдында миңа эш кузгатырга туры килер. Ләкин, бел, Ринатны үземдә калдыру өчен мин кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырышырмын. Чөнки мин аннан башка тора алмыйм.

— Аңа бер ана да үз анасы кебек була алмас,— диде моңарчы тын утырган Нурзилә, авыр караш ташлап.

Васил җавап кайтармады. Тынлык. Авыр тынлык.

Нурзилә тагы бер кат күтәрелеп Василга карады. Аның күзләре яшьле һәм болганчык иде. Хатын калтыранган тәне белән Василның кочагына ташланды. Ләкин Васил ничек хәрәкәтсез утырган булса, шулай утыра бирде. Нурзилә үксеп еларга кереште, берөзлексез сулкылдый башлады. Аның эчке калтырануы ниндидер кайнар дулкын шикелле Василга күчәр төсле, аны да хәлсезләндерер сыман иде. Ләкин алай булмады. Шул арада Нурзилә телгә килде:

— Болай булыр дип уйламаган идем. Хәзер инде терсәкне тешләп булмый. Ләкин бер мин генә гаепле түгел. Синдә дә, миндә дә бар ул гаеп. Бәлки миндә күбрәктер дә... Инде соң... Шулай да, әгәр теләсәң, син мине гафу итә аласың әле.

Аның бу томанлы сүзләренә каршы Васил җавап бирмәде. Нурзилә, хисләреннән айныган кебек, кинәт кулларын ычкындырды да янә урынына барып утырды.

Һәммәсен дә башыннан үткәрде Васил. Бер караганда Нурзиләнең әйткәннәрендә әллә ни баш ватарлык, аңлашылмаслык бер ни дә юк иде кебек. «Күрәсең, ул язмышын башка берәү белән бәйләргә тели яки бәйләгәндер дә инде. Төпчеп сорауның кирәге юк»,— дип уйлады Васил. Ул инде тыелып кала алмады:

— Тормыш бик катлаулы нәрсә шул. Кешеләрнең кавышулары табигый булган кебек, аерылышулары да табигыйдыр бәлки. Урынсыз үпкәләр дә, урынсыз тартышлар да булмас. Чик куярга вакыттыр инде мондый хәлгә? Аңлаштык шикелле...

Нурзилә бер мизгел тынып утырды, иреннәрен бер тешләде, бер җибәргән итте, ара-тирә күзләрен сөртеп алды. Василның: «Шайтанның күзе юеш була, имеш. Шушыдыр инде ул»,— дип әйтәсе килде. Кинәт Нурзилә моңарчы түбән иелгән башын югары күтәрде:

— Ә әйберләрне нишләтәбез?

— Нинди әйберләрне? — дип сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды Васил.

— Мебель. Кием-нәр, йорт өшәнчеге, теге-бу.

— Әйберләр ничек бар, шулай калыр. Мин инде үземнең барлык киемнәрне алдым шикелле.

— Димәк, син бер нәрсә дә алмыйсың?

— Әйе.

— Һич тә салпы ягына кыстырып әйтүем түгел, яхшы күңелле кеше син, Васил Закирович. Вакчыл түгел, синең бу ягың миңа электән үк ошый иде.— Нурзилә тагы аны барып кочу нияте белән урынныннан торды. Тик Василның күзләрендә усал чаткылар күреп булса кирәк, кире чигенде. Ничек кенә булмасын, хатынның төсенә елмаю сызыклары чыкмый калмады.

Василның күңеле кайный, гасабилыгы арта бара иде. Алай да ул үзен салкын һәм игътибарлы тотарга тырышты. Югыйсә, Нурзиләнең аның өстеннән урынсыз шелтәләр, урынсыз гайбәтләр тагып төзелеш җитәкчеләренә шикаять язуы турында да бик басым ясап әйтәсе килгән иде. Барын, барын да эченә йотып калды.

— Әлегә аерылышу хакында эш кузгатмый тор. Мин үзем барысын да әйтеп хат язармын, бик тиздән язармын,— диде Нурзилә, бүлмәдән чыгып киткәндә.

«Мин монда ят кеше. Беркемем дә юк, таныш урамнар да, таныш йорт та, кайчандыр семьям белән шаулашып торган квартиры да— һәммәсе дә ят, һәммәсе дә чит мина...» Василның тел очында шундый сүзләр әйләнде. Нурзилә аңа һаман саен ерагая барып, бер арада бәтенләй томан артында калды, күренмәс булды. Хәер, Василның аның турында башкача уй йөртәсе дә килмәде...

16

Картаела башлаган, күрәсең. Соңгы вакытларда нервылар да какшагандыр. Еллар, артта калган еллар йөрәккә үз эзләрен салып калдырганнардыр...

Юлдашевның күңеле тыныч түгел, бигрәк тә эштә әледән-әле очрап торган каршылыклар, ачык партия җыелышында аның исеменә әйтелгән тәнкыйть сүзләре чыгырыннан чыгаргандай булды аны. Баштарак ул таркалган уйларын җыеп ала алмый гажиз булды. Төзелештә кемнәрнең-дер башбаштаклыгы аркасында баш инженерны читләтеп узулар тәмам теңкәсенә тиде, тәмам ярсытты аны. «Болай булгач, мин бар ни, юк ни! Хәер, мин булмасам да эш барыбер туктalып тормас иде. Әмма төп җаваплылык кем өстендә? Яшьләр моны уйлап та карамыйлар». Әнә шулай кәефе кырылган хәлдә, Юлдашев өч көн, өч төн өеннән чыкмый ятты. Азрак төшергәләп тә алды. Вакыт-вакыт аның йөрәге кадап, әллә кай җирләре чәнчи, сызлый, хәле бетә кебек иде. Ләкин бу төгәл кеше үзенең хәле турында һәр көн секретарь-машинисткага хәбәр итә торды.

Бары тик дүртенче көнне генә Юлдашев хезмәтенә чыкты. Дөрес, аның тагы да ятарга исәбе юк түгел иде, әмма өйдә яту туйдырды. Никитин янына кереп, төзелеш хәлләре, алдагы эшләр турында беркадәр киңәшеп чыкканнан соң, ул машина чакыртты.

Төзелешнең диспетчерлык пункты идарә бинасыннан артык ерак түгел, уртача зурлыктагы бер катлы йортта иде. Юлдашев машинадан

төшүгә шунда керде. Тар гына коридорның иң аргы башында ишегенә «Баш диспетчер» дип язылган бүлмәгә узды. Дина телефоннан кемгәдер төксе-төксе генә итеп җавап кайтара иде. Ишектән керә-керүгә, аның болай начальниклык тоныша куанган шикелле, Юлдашев әйтә салды:

— Шулай, ипташ Гурская, каты тот беренче көннәрдән үк дилбегәне. Машиналар сорап та аны дөрес файдалана алмыйлармы? Кайсы цех? Ярдәмче предприятиеләр цехы дисен. Бор колакларын, яңадан онытылырлык булмасын. Шулай кирәк аларга.

Дина ана урын күрсәтте. Юлдашев кечкенә бүлмәдәге яна диванга җәелеп утырды. Канәгатьләнү һәм юксыну хисләре белән бер-берсенә караштылар. Юлдашевка калса, Динаның кәефе шәп булуы күзләреннән үк күренеп тора. Алай да Юлдашев сорап куйды:

— Ну, ничегрәк соң яңа урында, Диночка? Күнегәсеңме? Кара аны, кыенлыклар чыкканда турыдан-туры үземә шалтырат. Бер дә тартынып торма.

— Билгеле, Зариф Салихович, минем төп таяныч сез инде. Эшләрмен кебек. Рәхмәт! Диспетчерлык эше барыбер шул үк диспетчерлык эше булып кала инде ул. Күнегелгән хезмәт димәсәм. Тик монда колачы гына кинрәк, болгавыры гына күбрәк аның.

— Колач! — дип йомгаклап куйган шикелле әйтте Юлдашев. Аннары яңә машиналардан дөрес һәм хуҗаларча файдалану мәсьәләләренә кайтып төште: — Һәр участокта ничегрәк гора бу эш? Кызыксын. Төзүмонтаж идарәсе прораблыкларын аеруча күзәтү астына алырга кирәк булыр. Чөнки машинаны алардан да күбрәк сораучы юк. Ә менә ничек файдаланалар? Бу тиклесенә диспетчерлык пунктының ныклы күзәтүе булсын. Теге кем... прораб Данилов участогын аеруча күзәтеп торырга кирәк булыр. Машиналарны бушка куу фактлары очрый кебек анда. Сигналлар бар...

— Тынлыйм, Зариф Салихович, күзәтербез. Эш урыннарына үземә барырга туры килер.

Юлдашев хәйләкәр генә көлеп куйды:

— Син, Диночка, хәзер начальник кеше инде. Үзең бик күп йөрмә. Синең кул астында рядовой диспетчерлар бар, күбрәк аларны йөртергә тырыш. Гел бер урында утырып кына үзләре дә туялар булыр. Селкенгәләп кайтсыннар. Аларга да файда, производство интереслары да хүздә тотыла.

Дина Гурская өстәлендә әллә тагы биш-алты телефон тора. Шуларның берсе шалтырап, ул трубканы алгач аларның әңгәмәләре тагы өзелеп калды. Дина сөйләшкән чагында, Юлдашев тәрәзә төбендә яткан «Крокодил» журналын актарып утырды.

Дина сөйләшеп бетергәч, Юлдашев сүзен дәвам итте:

— Безнең начальниклар арасында кирәгеннән артык уздырып жибәрүчеләр юкмы? Бик артык мөгез чыгармыйлармы, артык үз белдекләре белән эшләмиләрме? Син дә һәммәсенә бик күп яктан күз-колак булырга тиеш хәзер. Производствога зарар китерерлек эшләр булмасын. Беләсең, төп җаваплылык Никитин белән минем өстә. Шулай булгач...

Дина аның бу сүзләренә әллә ни гажәпләнмәде. Башлык кешеләр шундый була торганнардыр инде, һәр нәрсә белән кызыксыналар. Диспетчерлык пунктына килгәндә Юлдашевның болай сөйләнүе беренче мәртәбә генә түгел иде инде. Дина Гурская мона күнеккән иде. Тагы телефон шалтырады. Дина телефон трубкасын куйгач, ул иркәлап кенә аның җылы һәм йомшак кулларыннан тотты, ышанычлы, ягымлы күзләренә карап торды да, яшәргән шикелле, җиңел адымнар белән чыгып китте.

Баш инженер утырган кара машина кислород цехы янына килеп туктады. Бөтенләй аның катнашыннан тыш, дөресрәге, ризалыгыннан тыш ябылган тимер-бетон түшәм-түбәләр зур бинаны балкытып торалар иде. Юлдашев әле бу бинага нигез салынган чакта гына килеп караганын исенә төшерде. Ул цехка керде. Эчке җиһазлау эшләрен башкаручы катлаулы приборларны монтажлаучы кешеләр күтәрелеп тә карамастан, «казыналар, чокчыналар» иде. Кемнәр беләндер берничә сүз алышкач, Юлдашев китәргә ашыкты. Стенага кызыл комачка язып элгән сүзләр шактый вакыт аның күз алдында торды: «Кислород цехын 1 Майга тапшырырбыз!»

...Берничә тапкыр шулай булды инде — баш инженер теге-бу мәсьәлә буенча берәр төгәлсезлек яки хата ясагач, сигналлар парткомга ишетелә дә, Юлдашев үзенең мондый ялгыш карашыннан ваз кичә һәм хатасын үзе үк төзәтергә мәҗбүр була иде. Уйлап табучылык эшендәге бутавыннан яки аңлы рәвештә тупас юлга басуыннан соң да шулай булыр дип уйлаган иде Солтан Сабиров. Ул мәсьәләне ачыклау өчен башлап Васил Сафин белән сөйләшергә булды. Һәм озакламый форсаты туры килеп, бер очрашканда сөйләште дә. Сафин аңа һәммәсен дә дөп-дөрес итеп әйтеп бирде, ләкин икенче каршылык китереп куйды:

— Ул турыда сүз куертып маташуның хәзер әллә ни кирәге булмас. Бәлки баш инженерга мин шәхес буларак ошамыймдыр. Бәлки минем эш стилем аның таләпләренә туры килмидер. Юлдашевның яман атын сатудан түгел... Ләкин гаять авыр аның белән эшләве.

Төзелештәге иң зур төзү-монтаж оешмасы башлыгы белән баш инженер арасындагы каршылыклар турында Сабиров яхшы үк белә һәм бу хәлгә чын күңеленнән көенә иде. Ләкин моңарчы әллә ни катгый тартышлар булмавы да мәгълүм иде аңа. Бәлки производство мәсьәләләрен хәл кылганда, төрле катлаулы эшләрне гамәлгә ашырганда Сабиров төшенеп, төгәл белеп җиткермәгән очраклар да була торгандыр. Аныңча бу да бик ихтимал иде.

— Беләм,— диде ул.— Юлдашев авыррак табигатьле кеше. Мондый характерлар белән хәзерге шартларда җитәкчелек итү дә җиңел түгелдер. Анысы шулай. Әмма ул белгеч. Төп җаваплылык анда. Бәлки ул шуңарга таянып эш итә торгандыр. Аннары, дөньяда һәр яктан да килгән кешене табуы да бик кыен бит.

— Бәхәсләшмим. Идеаль кешеләр юк. Ләкин кимчелекме ул, яхшы сыйфатмы — һәрберсенең чиге, чамасы була.

Солтан Сабиров Сафинның бу сүзләре белән ни әйтергә теләгәнен ачык абайлый алмады. Аныңча Юлдашевны һәрхәлдә чамасын белми торган җитәкче дип тамгаларга урын юк иде шикелле. Бәлки алар арасында ул белми торган әллә нинди хәлләр бардыр. Булса Сафин аларны үз эченә йомып калырга тиеш түгел, партком бар, административ җитәкчелек бар. Бу турыда кабатлап сорау да әллә ничек урынсыз булыр кебек тоелды аңа. Аннары төрле техник мәсьәләләрне хәл кылганда эшнең майлаган кебек шома гына бармавы да табигый иде. Әмма баш инженерның барлык очракта да, башка төрле мөмкинлекләр булган сурәттә дә, проекттагы күрсәтмәләргә генә теше-тырнагы белән ябышып ятуы Сабировка да ошап бетми иде. Ул шуны күздә тотып әйтә куйды:

— Мин, төзелеш яки техника мәсьәләләрендә әллә ни белдекле булмасам да, гомуми агышка карап, эшне бераз аңлыйм, төшенәм. Бу яктан мин ике куллап сезне яклыйм. Урындагы инициативага, кешеләрнең ижади талпынуларына киңрәк юл ачарга кирәк. Ничек әле, «тырышып елаганда сукыр күздән дә яшь чыга» диләрме?

Сафин әйтергә ниятләгәнен оныткан шикелле бераз уйланып торды да янә тел тибрәтте:

— Сүз минем яисә башка берәүнең теге яки бу сыйфатлары турында гына бармый. Сүз гомуми эшне ничек итеп яхшырак көйләү, яхшырак оештыру, барлык резерв һәм мөмкинлекләрдән хуҗаларча файдалану турында бара. Минем баш инженер белән килешмәгән чакларым була. Тик андый хәл бетә барырга тиеш. Ә ул киресенчәрәк килеп чыга. Сездән һич яшерен-батырын түгел, мин соңгы вакытта байтак кына зур мәсьәләләрне хәл кылганда Юлдашевны читләтеп үтү ягын карыйм. Нигә? Ул я проекттан бер карыш та чыкмау ягын каера, я булмаса, мәсьәләне хәл кылуны кирәгеннән артык суза.

— Бәлки ул беренче чиратта эшнең сыйфаты яхшы булсын дип пошынадыр? — диде Сабиров.

— Сыйфат өчен кем тырышмый, ул барыбызны да, шул җөмләдән мине дә, бик уйландыра,— дип дәвам итте Сафин.— Белмим, куркаклыкмы, бюрократлыкмы, икесенең берсе, я шулар икесе дә бар шикелле безнең баш инженерда. Мин сезнең алда кабатлап әйтәм: һич тә гайбәт сатарга теләмим. Эштә шулай килеп чыга.

Партком секретаре, Сафиннан аерылгач, аптыраган кыяфәттәрәк уйланып утырды. «Димәк, аралары әллә ни шәп түгел. Берсе картаеп бара, икенчесенең авыр йөкне төпкә жигелеп тарта торган чагы. Тарта да. Бу барыбызның да күз алдында. Бәхәс-тартышка китсә, гомуми эшкә зарар килүе дә бар. Ничек кенә булмасын, житәкчеләр уртак тел табарга тиешләр. Бу тиклесенә чик-чама куюда партком өстенә зур жаваплылык йөкләнә...»

Бер яктан һич тә олыгаеп бара торган кешеләргә охшамый бу Юлдашев. Аның кабинетына еш керергә туры килмәсә дә, анда булгалый Сабиров. Моннан элек бер керүендә мебельләр яңартылган булса, бу керүендә дә үзгәреш күзенә чалынмый калмады аның. Кабинетның түр яктагы зур тәрәзәсе каршына чүлмәкләр белән берничә гөл утыртылган һәм алар, җәйнең бер кисәген алып кергән кебек, үзенә генә хас сафлык, ямь биреп торалар. Тагы шуңа каршы як стенадагы электр станциясе панорамасы да Сабировның дикъкатен үзенә җәлеп итми калмады. Кабинетка кереп исәнләшүгә шул панорамага карашын салды. Зур сулыкның бер өлеше. Яр буйларында өянкеләр, таллар һәм арырак арыш кырлары. Алгы планда мәһабәт биек торбалары, мәгърур бинасы, ярдәмче корылмалары белән зур мәйдан биләгән электр станциясе. Ул әйтерсең лә бөтен тирә-юньне яңартып һәм яшәртеп, әле генә каршыга килеп баскан яшь тимер батыр кебек күңелне үзенә тарта. Торбалардан сизелер-сизелмәс кенә аксыл төтен чыгып тора шикелле.

Юлдашев бу күренешләр, бу яңалык Сабировның игътибарын тартуын сизенде булса кирәк, ул да картинага карады.

— Безнең элекке чабаталы, ярлы бу яклар бөтенләй танымаслык булып үзгәрә, Зариф Салихович,— дип куйды Сабиров.

— Билгеле, шулай,— дип күтәреп алды Юлдашев.— Бер миллионнан артык киловатт электр энергиясе бирәчәк бит ул. Беләсегез килсә, патша Россиясендәге барлык электр станцияләре биргән куәткә тиң булачак ул. Бу гаять уникаль төзелеш, гаять үзенчәлекле гигант булачак.

— Бабайларны уятып күрсәтәсе иде. Ышанмыйча, куркып, кире каберләренә йөгерерләр иде,— дип өстәде Сабиров.

Юлдашев көлеп жибәрде:

— Кеше кабердән бер чыкса, анда кире йөгереп керер иде микән? Киресенчә, зираттан ераккарак йөгермәс иде микән?

Саулык-сәламәтлек, теге-бу турыда тагы берничә сүз алышкач, Сабиров төп кызыксынган мәсьәлә хакында сүз башлады.

— Хуш, Зариф Салихович, беркөн партия җыелышында кайбер иптәшләр тарафыннан кузгатылган теге уйлап табучылар турындагы төгәлсезлекме, хата дип әйтимме... әнә шул хакта минем ачыграк беләсем килә иде. Иптәшләрнең сүзләренә колак салмыйча ярамастыр.— Сабиров инде үзе ике икең дүрт кебек итеп ачыклаган әлеге шул рационализаторлар турында баш инженер алдына мәсьәләне кабыргасы белән куймакчы иде. Ләкин аның бу сүзен ишетү белән Юлдашев эшнең нәрсәдә икәнен шундук төшенеп алды һәм чыраен да сытмыйча әйтә салды:

— Гаять игътибарлы кеше сез, Солтан Сабирович. Партия җитәкчелегендәге кешегә шүнсыз булмый да торгандыр.— Юлдашев русчалатып дәвам итте: — Разобрался я в этом вопросе, выяснил и исправил допущенную ошибку или так сказать, путаницу...

Ул сак кына өстәл читендәге ак кнопкага басты. Шундук ишек ачылды һәм секретарь күренде:

— Тыңлыйм, Зариф Салихович.

— Приказлар папкасын китерсәгезче.

Бу төзәтмә приказда термопоритны уйлап табучылардан төп кеше итеп Васил Закирович Сафин күрсәтелгән һәм аңа карата тиешле хөрмәтләү сүзләре әйтелгән, аңа өстәп акчалата бүләк бирү турында да акка кара белән язылган иде. Приказны укыгач, партком секретарена әллә ни әйтер сүз калмады кебек.

— Ходайга шөкер, тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьнең һәркайсыбызга су кебек, һава кебек кирәген күптән аңлыйм мин. Иптәшләрнең хаклы сүзләренә колак салмыйча һич тә ярамый, һич тә ярамый. Күрәсез: төзәттек,— диде Юлдашев күтәренке тавыш белән.

Үзенең бу әйткәннәре белән Сабировны бик канәгать дип фикер йөртте ул. «Әйтер сүзең калмадымы, бәйләнерлек урын юкмы»,— дигән кебек Сабировка карап-карап куйды. Сабиров шундук эндәшмәде, бераздан соң гына әйтте:

— Хатаны төзәтү ярый, шәп. Ләкин аны башта үк җибәрмәү чарасын күргәндә тагы да яхшырак булыр иде. Җыелышта эшчеләр дә, Андрей Акимович та башлап тырышлык салучыны белми калдылар...

Секретарьның бу сүзләре Юлдашевны беркадәр икеләндерә иде, ахры. Ул мондый сүз көтмәгән иде. Алай да аның белән бәхәскә керүне мәгъкуль күрмәде.

— Мин инде приказ белән Андрей Акимовичны таныштырдым. Ул белә,— диде.

Кемдер, телефоннан шалтыратып, аларның сүзләрен бүлдерде. Юлдашев теләр-теләмәс кенә сөйләшеп, телефон трубкасын куйды да янә секретарьга карады. Баштагы әңгәмәне беткәнгә санап, бу юлы сүзне икенче төрлерәк башлады:

— Бу кем... безнең Сафинның гаилә мәсьәләсе ничегрәк соң? Хатынннан жалоба да килгән иде бит...

Сабиров аның тел төбе кай якка каерганын бик ачык чамалады. Бу турыда Сафин белән бик нык гәпләшкән булуын әйтте.

— Димәк, тозлап-борычлап сөйләштегез?

— Ничек әйтергә... Билгеле, җитди төстә.

— Ник килми соң аның хатыны?

— Бөтен бәла дә менә нәкъ шунда шул, Зариф Салихович.

— Монда, минемчә, Сафин үзе гаепле.

— Мин мондый фикерне расларлык фактлар күрмим,— диде Сабиров.

— Э хат?

— Андый хатка гына ышанып бетәргә ярамый торгандыр. Кешенең семья тормышы бик четерекле, бик катлаулы мәсьәлә ул. Алай да кеше

ялгышса, аны бәладән тартып алу безнең бурыч. Ләкин Сафинның семья мәсьәләсенә килгәндә...

Юлдашев, секретарьның нинди фикердә икәнен белгәч, бу турыда артык казынмады, сүз куертмады. Мәгәр һәркайсын үз эченә сала барды. Юлдашев ничек уйлагандыр, Сабировка калса, ул баш инженер кабинетыннан күңелсез уйлар белән чыкты.

Берничә көн үткәч, Андрей Акимович Никитин Юлдашевны үз кабинетына чакыртты. Бу турыда сөйләшүне хәтсездән көтеп йөргән иде ул, менә вакыты да житте. Сабиров та шунда иде. Тиздән постройком председателе дә килде. Никитин салмак хәрәкәт белән урыныннан кузгалды, әллә кабинетны эссе санап, әллә һава алмаштыру нияте белән форточканы барып ачты. Җәен булмасын, кышын булмасын, гади генә киенеп йөрүчән, хәзер аягына озын куныч лы йомшак унталар кигән калын гәүдәле Никитин кай ягы беләндер төньяк кешеләрен хәтерләтә иде. Ул үз урынына барып утырды да, хезмәттәшләренең әле берсенә, әле икенчесенә карап, сүз башлады:

— Сугыш вакытында без еш кына сүзне һөҗүм дәвам итә дип башлый торган идек. Шуның шикелле, безнең монда да төзелеш һөҗүме дәвам итә. Химиклар шәһәрендә электростанция төзүнең безнең оешмага йөкләтелгәне һәркайсыгызга мәгълүм, әлбәттә. Менә шул төзелешне житәкче кадрлар һәм квалификацияле эшчеләр, белгечләр белән тәэмин итү дә безнең өстә булып чыга бит инде. Үзебезнең төзелешкә зыян китермәслек итеп оештырырга кирәк безгә анда эшне.— Ул карашын Юлдашевка салды: — Я, Зариф Салихович, башлап жибәрегез. Иң элек исемлеккә кергән барлык инптәшләрнең фамилияләрен ишетик. Аннары һәр кандидатурага аерым тукталырбыз. Шулай барамы?

— Бара, бара,— диделәр өстәл артында утыручылар.

Юлдашев укыган исемлектә төзелештә шактый күренекле хезмәт башкаручылар бар иде. Никитин әйткәнчә, кандидатларны берәм-берәм тикшерә башладылар. Берничә кеше турында фикерләр бердәм булды, каршылыклар сизелмәде. Бу хәлгә куанып, кадрларны сайлап алу һәм урнаштыруда шактый тәжрибәсе булган Юлдашев күтәренке күңел белән, күтәренке тонда сүз йөгертте:

— Инде инптәшләр, төзү-монтаж идарәсе начальнигы Васил Закирович Сафин кандидатурасына кидик. Аны барыгыз да беләсез, характеристика биреп торуның кирәге юк. Химиклар шәһәрендә төзелачәк электростанция төзелеше начальниклыгына, минемчә, аннан да муафыйграк кешене табу кыен булыр.

Әйтәсен әйтеп бетердеме, юкмы, ләкин бер арада Юлдашев кинәт кенә тукталып калды. Әллә моңарга сәбәп Андрей Акимовичның кинәт кенә тамак кыруы булды инде, кем белсен? Кешеләр бер-берсенә карадылар. Үзенең озын кылыч борыны белән башкалардан аерылып торган постройком председателе, бүтәннәр ни әйтерләр дигән сыман, башка инптәшләренә күз йөртте. Андрей Акимович Никитин сүзне партком секретаренә бирде:

— Солтан Сабирович, рәхим итегез.

— Химиклар шәһәрен һич тә читләтеп үтә алмыйбыз без. Ныклы, көчле кадрлар белән тәэмин итү — иң мөһиме шул. Шулай булгач, без анда һәр яктан булдыклы, көчле һәм намуслы инптәшләрне тәкъдим итәргә тиешбез. Билгеле, Васил Закирович Сафин — әле генә мин әйткән сыйфатларга ия кеше. Ләкин... Ул монда да бик кирәк. Шулай әйтергә яраса, ул монда төп терәкләренең берсе санала һәм ул шулай да. Аны жибәрсәк, үзебезне шактый уңайсыз хәлгә куярбыз кебек. Башка кандидатура турында уйлау яхшырак булыр иде...

Сүзне Никитин үзе алды:

— Бу турыда мин үзем дә озак баш ваттым. Химиклар шәһәренә тәжрибәле һәм көчле оештыручы һәм белгеч табарга кирәк. Анда телләсә кемне тәкъдим итеп булмый. Бу турыда, билгеле, Зариф Салихович та уйлагандыр.

— Ничек кенә әле! — дип кыстырды Юлдашев.

Монда да, анда да бездән сораячаклар. Әйтик, Сафинны тәкъдим итсәк, аның урынына куярлык кеше табып булмасмы? Шунысын да уйлышыйк әле,— диде Никитин.

Постройком председателе, блокнотын чыгарып, нидер яза башлады. Сабиров форточка янынарак барып утырды, папирос кабызды. Юлдашев, бер урыныннан торып янә утыргач, үз фикерен әйтте:

— Минемчә, иптәшләр, Сафин урынына, ягъни төзү-монтаж идарәсе начальнигы итеп куярлык кешеләр табылмый калмас. Дипломлы инженерлар байтак бездә.

Сабиров, гадәти сабырлыгын югалтып, сорап куйды:

— Ә сез кемне тәкъдим итәр идегез, Зариф Салихович?

Юлдашевның әзерләп куйган кандидатурасы тел очында гына торса да, сер бирәсе килмәде, ул бераз уйланып торгандай итеп әйтте:

— Мәсәлән, Касаткин.

Никитин, җиңелчә генә тамак кырып алгач, икеләнгән төстә шулай диде:

— Үзәк лабораториядә җитәкчелек итү — бер хәл. Анда ике кулга бер эш. СМУда хәл катлаулырак, оештыру көче, оештыру сәләте булырга тиеш анда җитәкчелек итү өчен.

Юлдашев үзе тәкъдим иткән Касаткинның эшлелек сыйфатлары турында тыныч кына сөйли башлауга, кинәт телефон шалтырады һәм Никитин трубканы алды. Юлдашевка сүзеннән бүленергә туры килде. Исәнләшү сүзләреннән соң, Никитин чыраена елмаю чыгарып дәвам итте:

— Әле менә киңәшеп утырабыз. Рәхим итегез, Григорий Исакович.

Баш инженер урынбасары Брагинский иде бу. Ул озак сроклы командировкадан кайтып төшкән икән. Кабинетта әллә ни күп фикер алышырга өлгермәделәр. Кара чәчле, кара күзле, очлы борынлы, күзләре белән генә көлә торган Брагинский ялт итеп килеп тә керде. Төп эшләрен бүлеп, аның кыскача гына отчетын тыңладылар. Брагинский төрле шәһәрләрдә, төрле заводларда булып, яңа җиһазлар, яңа механизмнар кайтарту буенча байтак эш башкарган булып чыкты. Моның өчен һәркайсы канәгатьләнү белдерде. Юлдашевка калса, ул аеруча куанды шикелле. Аннары янә төп мәсьәләгә — химиклар шәһәрендә төзеләчәк электр станциясенә җитәкче кадрлар сайлау-билгеләүгә күчтеләр. Юлдашев һаман үз фикерен яклады, төрлечә мисаллар китерде. Шунда кинәт җиңел гәүдәле Брагинский урыныннан күтәрелде һәм тиз-тиз әйтеп ташлады:

— Бу мәсьәлә минем өчен дә билгеле. Минемчә, Сафинны һич тә үз урыныннан кузгатырга ярамый. Анда кемне куйсаң да, озак, бик озак үзенә яр тапмый йөзәчәк тә йөзәчәк. Әгәр менә...

Юлдашев аның әйтеп бетергәнен көтмәстән, сүзен ашыгып бүлдерде.

— Кемне җибәрик, сез шул турыда әйтегез, Григорий Исакович.

Брагинский аны ишетмәгән кебек сөйли бирде.

— Җитәкчелек ышаныч биргән тәкъдирдә, мин үзем, мәсәлән, бу эшкә күчүгә каршы килмәс идем. Инде минем урынга кеше табу мәсьәләсенә килгәндә, шул ук Васил Закирович Сафинны вакытлыча билгеләргә була. Ул яшь, энергиясе җитәрлек. Йөкне тарту аңа авыр булмас, минемчә.

Кабинетка Брагинский килеп кергәч, Никитинга ничектер рәхәтрәк булып китте. Нигә соң алар үзләре, бигрәк тә Юлдашев бу турыда

башта ук уйламаган. Ул Брагинскийны алай артык күптән белмәсә дә, аның турында күп тапкырлар ишеткәне бар иде. Яңа Наратлы төзелешендә дә ул үзен гел унай яктан күрсәтә килде, үз вазифаларын үтәүдә тел-теш тидерерлек түгел. Хәтсез генә вакыт тарткалаштылар һәм, Брагинский тәкъдимен мәгъкуль күреп, аны химиклар шәһәренә җибәрергә булдылар.

Юлдашев мондый хәл булыр дип һич тә көтмәгән иде. Ул үз фикерен Никитинга да, Сабировка да, постройком җитәкчесенә дә көчләп тага алмый бит инде. Бәлки бу җил кебек теләсә кайдан керергә үзенә урын тапкан Брагинский көтмәгәндә кайтып төшмәсә, мәсьәлә аныңча да хәл кылынган булыр иде. Ул һәр вакыт төгәл, әйткәнен ерып чыга торган бу кешене үз урынбасары булудан ычкындырырга теләми, икенче берәүне үз янәшәсендә күрәсе дә килми иде. Ул төзелеш башлыгы кабинетыннан авыр хисләр, күңелсез уйлар белән чыкты.

17

Ак шәлен селкеп февраль керде.

Буран. Җил...

Атнага якын бер котырынып, бер тынып дәвам иткән буран кешеләрнең кәефен бик нык бозды. Каралты-кураларга, чормаларга, өйалды һәм чоланнарга әллә кайлардан гына яшерен тишекләр табып кар тулды. Йон төпләренә кар инәләре үтеп кергәнгәдер инде, этләр булып этләр бөкерәешеп, шинең йөри башладылар.

Көртләр. Һәркайда ак сырганаклар. Төзелештә юллар ачарга, кар өемнәрен туздырырга бульдозерлар, грейдерлар чыкты. Аерым урыннарга зур агач көрәкләр белән кешеләр ябырылды. Чөнки һәр җирне кар басу аркасында бигрәк тә тышкы эшләр, ачык һавада башкарыла торган эшләр тукталып калган иде. Буран басылуның беренче көннәрендә «карга каршы көрәш»нең ничек баруы турында башлык Никитинга һәр сәгать саен хәбәр салып тордылар.

Үзе җитәкчелек итә торган төзү-монтаж идарәсенә караган әле бу, әле теге объектта йөргән чагында, шактый калын яткан ак сыртлы көртләр Василның исенә ерак Норильскине төшерделәр. Шулай да монда кар катламының төньякка караганда сай ятуын һәм карның йомшак булуын уйлап, ул җиңел сулап куйды.

Ә ерак Норильскидә...

Харап иде анда эшләр... Кыска җәй көннәрендә дә тауларда сыртларын кабартып карлар ята анда. Атналар буена дәвам иткән каты бураннар шәһәрдә һәм промышленность участокларында тормышның бөтенләй рәтен чуалтып җибәрәләр. Шундый хәвефле бураннарның берсеннән соң, Васил яңа җитәкчеләрнең каушап калуларын исенә төшерде... Котып төнен тагын да куертып, җир белән күкне тоташтырып, бер атна буена каты давыл котырынды. Давыл басылгач, күп җирдә электр чыбыклары өзелгән, бер катлы тәбәнәк биналар бөтенләй кар астында калган, юлларда таулар хасил булган, хәтта Горстройдагы өч катлы бер йортның түбәсе яртылаш каерып алынган һәм каядыр километр ярым ары тундрага илтеп ташланган иде. Барак тибындагы йортларның моржалары гына, кабер ташлары кебек, күренеп калган иде. Тирән кар көртләрен көч-хәл белән казып, кар астында калганнарга ярдәм күрсәттеләр. Ләкин давылдан соң өч-дүрт көн вакыт үтсә дә, кар стихиясе тудырган тәртипсезлек бетеп җитмәде. Күп кенә предприятиеләр тулы куәтләренә эшли алмадылар. Чөнки кар басып киткән урыннарны тиз генә чистартып бетерерлек түгел, аларга тиз генә юл салырлык та түгел, җитмәсә кары тыгыз һәм боз кебек каты иде. Җитәкчеләр киңәшләләр, хәрәкәттән туктамыйлар...

Бер атнага якын дәвам иткән киеренке хезмәт кенә кар бәласеннән арындырган иде ул чагында. Васил Сафин шуларны хәтереннән кичергәч, тагы бер мәртәбә җинел сулап куйды. Мондагы бураннар котып бураннарының баласы гына шул. Бер-ике көн тырыштылар — һәммәсе тәртипкә керде, һәммәсе үз юлыннан китте.

Васил төньяк кыйссасын Никитинга сөйләде. Андрей Акимович көлеп куйды.

— Мондый хәлләр дә таныш миңа, Васил Закирович. Безнең монда да кар калын салды быел. Үзегез беләсез, вакытның сәгате генә түгел, һәр минуты кадерле. Барысы да әлеге шул сез әйткән планга кайтып кала. Аны үтәмәсәң, дәүләткә зыян китерәсең, дигән сүз.

...Кичтән үк белдерүләр ябыштырып куйганнар иде. Халык күп җыелды. Чаңгычылар ак карны чуарлап һаман саен алга элдерделәр. Иске Наратлыга килеп төртелә торган урман итәге буйлап киттеләр. Поселокны чыкканда төркем куе, кешеләр янәшәрәк шусалар, бара-бара таралыштылар, сибелештеләр. Әнә Алып батыр — Виктор белән Люда ничек күңелле сөйләшеп янәшә генә шуып баралар. Бер караганда әллә ничек көлке дә сыман тоела. Виктор бик озын, киң җилкәле, Люда җыйнак кына, кечкенә гәүдәле, берсе иелеп, икенчесе үрелеп карый, дигәндәй. Алар инде сөйләшәләр, көлешеп тә алалар. Викторның адымнары шул хәтле зур — бичара Люда көчкә житешә, Гулливер егет менә-менә аны кесәсенә салып китәр төсле. Аларга күз салып, көлешеп алучылар да юк түгел. Бу икене инде шактый вакытлардан бирле йөриләр, бик нык дуслашып баралар дип сөйлиләр...

Яшьләр арасында Карчыга да бар. Ул күбрәк нигәдер Диләрә тирәсендә урала. Тик кыз гына аңарга әһәмият бирми, тегенең мең такылдавына әллә нидә бер җавап кайтара.

Рафис белән Мәдинә янәшә баралар. Аларның йөрүләре турында баштарак сөйләделәр дә хәзер артык игътибар бирүче юк сыман. Бу икене клубта бергә күрмәсәләр генә гажәпләнәләр. Рафис та башка егетләр кебек җинел, җылы спорт костюмыннан, тик аның башында бүтәннәрнеке шикелле йон башлык түгел, колаклары кайтарып куелган мех бүрек. Ул Мәдинәдән озынрак һәм нечкәрәк. Мәдинә турында сүз ачсак, болай да юантыграк гәүдәле бу кыз спорт костюмы кигәч, тагы да түгәрәкләнә төшкән, гүя туп сыман тәгәрәп бара төсле. Икесе дә бригадир булгач, егетләр, кызлар арасында аларны шаяртып «Бригадир в квадрате» дип тә йөрүчеләр бар. Рафис эшне коры тотарга уйлый, ди, аның тизрәк башлы-күзле буласы килә икән. Ә Мәдинә һаман да сузып килә, төзүчеләр көне үтсен, аннан күз күрер, дип әйтә, ди. Төзүчеләр көненә нинә ай бар әле, күз төпләрең күгәреп бетәр аңарчы. Шулай берсе кызулый, икенчесе суза да суза, ди.

Васил Сафинның да күптән чаңгыда йөргәне юк иде. Кар өстенә ак сызык салып барган чаңгылар башта аңа нигәдер авыр сыман тоелды, әмма беркадәр киткәч, аяклары язылды һәм ул тагы да катырак алдыра башлады. Тәне дә кызыша барды, җинел кыска сырмасының изүен чишеп җибәрде. Һава шул хәтле саф, шул хәтле татлы, аны һич тә сулап туймассың!

Чыр-чу, көлешү, шаян сүзләр, кай арада тоник кына ишетелгән җыр авазлары — болар һәммәсе дә күңелгә якын, күңелгә үз иде!

Башта урман кырыеннан бардылар. Монда ышык, һава талгын иде. Аннары читкәрәк каердылар. Ниһаять, бераздан инде урман күксел төскә кереп күренә иде. Бер калкулыкны үтүгә, алда кечкенә басу күпере күренде. Аны чыккач, бөтенләй ачык кыр башланды. Монда җиләс, тәннәргә яхшы ук суык дулкын бәрелә иде. Алай да кырны икегә аерып торган күпер чокырыннан артык ерак китмәделәр. Җәйләрен

тасма кебек кенә сузылып тар инеш ага торган бу чокырның үзенә генә хас бер матурлыгы да бар: инеш буйлап агачлар үскән иде. Ап-ачык жирдәге бу агачлар, әйтерсең, кышкы салкыннардан, зәһәр жилләрдән куркып чокырга посканнар иде. Тик шулай да монда инде кырдагы шикелле жансыз тынлык юк, монда сирәк кенә булса да кош-корт та күренгәли. Төптән үсеп чыккан куе яшь үсентеләр баштанаяк мамык шәл бөркәнеп утыралар. Шундый аклык, шундый аклык — хәтта ул офык зәңгәрлеген тоныкландырып, үзенең ак шәүләсе белән бизи. Шулай тын гына күзләр һәм күнелләр белән ял итеп барганда кайсыларыдыр һаваны ярып кычкырып жибәрде:

— Куян! Озын колак!

— Тотыгыз! Тот!

— Әх, шайтан алмасы, мылтыгыбыз булса...

Куян куаклар артыннан килеп чыкты бугай. Ул яшен тизлеге белән үргә таба ыргыла, түя үзенә керер тишек тапмый, кычкырган авазлар аның котын алган иде. Кайбер шаяннары куян артыннан куып та карадылар. Кая ул житү, тоттырыр сиңа койрыгын бу житез мәхлук! Бер ничә минут үтүгә, бичара куян бөтенләй күренмәс булды.

Авылга житәрәк Васил адымнарын әкренәйтте. Аның күзенә кызлар арасында ашыкмыйча гына чаңгыда барган Гөлзадә ничәмә-ничә чагылып китте. Ләкин кыз белән янәшә бару һәм тора салып сүз кушу ничектер уңайсыз тоела иде. Ул аны бер үзды, бер ул барган кешеләр тирәсеннән артка калды, бер тигезләнде. Әлеге шул салмаграк баруында, үзенең сул ягында таныш чырай, таныш гәүдә күреп, бер эсселәде, бер суыксыды. Сүзне башлап Гөлзадә кушты:

— Ай, жиңел йөрисез икән, Васил абый!

Кызның жылы сүзе Василны канатландырып жибәргәндәй булды. Арттырып әйтми микән? Василның бер артка калуын, бер алга узып китүен чамалап барган, күрәсең. Аның кайдалыгы кызны кызыксындыра иде, ахры.

— Ә сезгә ничегрәк, кыен түгелме?

— Юк, кая ул! Мәктәптә укыганда ук чаңгы походларына катнаша торган идем мин. Алай да сезнең кебек жиңел йөрсәң иде аны.

— Монысы инде артыграк шикелле...

— Нишләп? Ихлас менә...— Гөлзадә бит алмаларына кызыллык йөгерүен сиздеме, юкмы — мәгәр бу минутларда рәхәт иде аңа.

Озакламый үзенең ак шәл бөркәнгән өйләре, шәһәрчек булып сузылган ферма каралтылары, мал-туар биналары белән жәелеп яткан авылга килеп керделәр.

— Менә Сазлы Елга,— диде Гөлзадә.

— Бу авылдан ничә тапкыр үткәнем бар. Үзенең сазлы елгасы да юк. Нилектән килеп тагылган икән бу исем? — дип сорады Васил.

— Аны кем белеп бетерсен инде?! Бу авылдан соң башкача бармыйбыздыр бит?

— Шушыннан борылырбыз.— Васил нәрсәдер хәтерләргә тырышып та, исенә китерә алмый аптыраган кеше кебек сорый куйды: — Моннан соң инде авыл тагы?

— Казаклар.

— Аның теге ягында?

— Бишмунча. Аннан Сарайлы, Жилкәнле күл...

— Аннары?

— Ераграк киткәч, бутыйм инде мин, әллә Таллык, әллә Комлык — икесенең берсе.

Инде тагы авыл исемнәре юк: Дүрт Мунча, Күпербаш, Чокырлык, Теләнче Тамак, Ярлы Аймак. Гөлзадә, шуларны уеннан кичереп, әйтә куйды:

— Минемчә, Васил абый, хәзерге күп кенә авылларның исемнәре җисеменә туры килми.

— Ә минемчә, бу исемнәрнең тарихи яктан әһәмиятләре бар. Дөрес, авылларның күбесе электән хәерче булганнардыр. Бу исә бүгенге тормышның кадерен белү өчен яхшы...

Кыз җавап кайтармады. Чаңгычылар авылның урта бер жирендә иде инде. Тыкрык буендагы сиртмәле коедан киеме-салымы шәһәрчә, төсе-бите чибәр генә бер кыз су алып тора иде. Безнең чаңгычылар шуның чиләгеннән чиратлап иелә-иелә су эчтеләр дә көлешә-шаярыша кире борылдылар. Гөлзадә янында ни хәтле күңелле булмасын, әмма Василга ничектер уңайсыз сыман тоелды. Ул бераздан читкәрәк китте һәм егетләр белән бергәләп бара башлады. Ләкин күңеленнән барыбер Гөлзадә чыкмады.

Кинәт аның күзе Карчыгага төште. Ул башкалардан читтәрәк бара иде. Василның хәтеренә Тын елга буенда үткәрелгән өмә килеп төште. Ул кар өстенә егылган Гөлзадәне машинасына утыртып алып кайткан иде. Тегесе кызга бик нык бәйләнеп йөргән ул көннәрдә. Гөлзадәне үзенә карата алмагач, карга салып еккан. Кыйнап та өлгергән. Шуның өчен Карчыга унбиш көн утырып та чыкты. Хәзер инде ул азмы-күпме тәүфыйкка килгән кебек күренә иде.

Чаңгычыларның бер өлеше яхшы ук алга китте, бер өлеше арткарак калды. Алдагылары кыр буйлап элдерделәр, икенчеләре урманга керде. Васил белән Гөлзадә да әлеге шул арттагылар арасында иде. Васил арттарак, кыз төркемнең алдындарак. Васил урманга күз салгалап барганда, кемнеңдер артка калуын күреп алды. Ул кеше иелде. Аягында бер генә чаңгы бугай. Тагы башын калкытуга, артта калучының Гөлзадә икәнен чамалап алды Васил. Ул да, күп уйлап тормастан, бүтәннәрдән артта калды һәм кире борылып Гөлзадәгә таба китте. Гөлзадә, бер аягындагы чаңгысының каешы өзелү сәбәпле, туктап калган икән. Кулда бер корал, бер запас булмаган килеш, каешны урманда ялгарлык түгел иде. Васил, эзләнә торгач, кесәсеннән ниндидер бау тапты һәм шуның белән чаңгының каешын тоташтырып куйды да алар тагы да әкрен генә кузгалып киттеләр. Бу арада башка чаңгычылар борылмалы урман юлында күздән югалган иде инде. Бераз баргач, чаңгы бавы тагы өзелде. Тагы тукталып аны рәтләделәр.

Урман каравылчысының хатыны Гөлзадәләргә кардәш кеше тия иде. Тиздән шулар турына җитәргә тиешләр. Бу апасын кызның күптән күргәне юк. Аларга кереп чыксалар... Васил абыйсы ни әйтер икән? Гөлзадә бу турыда әйтергә уйлап та, ничектер кыюсынмады.

Урман...

Серле ак сукмаклар...

Әкият дөньясын хәтерләткән төрле-төрле рәвештәге агачлар.

Эзләр...

— Бу нинди эзләр булыр? — дип сорады Гөлзадә.

— Пошый эзләре. Пошый юл аша чыккан. Әнә кырыйда ботагы кимерелгән яшь усак тора. Анысы да шул җәнлек эше.

Карга тирән-тирән кергән эзләрне узып, беркадәр баргач, юлның бер читендәге агачта тукран күрделәр. Шунда ук шып сүздән туктадылар. Кош каралып торган кәүсәгә тырнакларын батырган да тук-тук итеп чукыпмы чукый. Буй-буй «костюм кигән» егетне хәтерләткән бу матур кошны кызыксынып, хәйран калып хәтсез карап тордылар. Тукран әллә боларны күрде, әллә күрмәде. Һәрхәлдә, китәргә ашыкмады. Куркытмадылар да. Гөлзадәгә калса, тукранның түбәсендә кызыл чукмы, кикрикме кебек «түбәтәе» дә бар иде бугай.

Кинәт ниндидер кошның бик матур, бик аһәңле аваз салып сайравын ишетеп тагы туктап калдылар. Бар икән соң! Бар икән нечкәлек!

Алар, шул хисләрдән айнып житмәгән килеш, салмак кына барганда, юлның уң ягындагы урман киңлегеннән әйтерсең лә уелып эчкә кергән бер урында киң ишек алдылы ихата күренде. Юан бүрәнәләрдән салынган өй, шуның белән янәшә башка каралтылар китә. Артта ындыр, киртә белән әйләндереп алынган печән кибәннәре... Васил шул күренешләр белән мавыгып барганда, Гөлзадә сүз кушты:

— Тукталабызмы? Керәбезме?

— Кайда? — дип сорады Васил.

— Урман каравылчысына.

— Чаңгы бавын ныгытып чыгаргамы?

— Әйе. Сез читенсенмәсәгез, лесникның хатыны безнең агай-эне тиеш кешебез була.

Васил каршы килмәде. Алар капка төбенә якынлашу белән ишек алдыннан яман котырынып эт өргән тавыш ишетелде. Икесе дә азрак каушый калдылар. Ул арада урыс капканың кечкенә ягы ачылды, башына шәл бөркәнгән хатын күренде.

— Бәй, Гөлзадә, син түгелме соң бу? Нинди җилләр ташлады. Хәзер...

Хатын тиз генә ишек алды түренә атлады, өрүенә-шыңшуына карамастан, бәйдәге усал этне оясына япты. Янә кечкенә капканы ачты. Керделәр. Шактый салмак хәрәкәтле, яшь булса да инде калынаерга өлгергән хатын, кунаклар күргәч, сузып-сузып сөенеп сөйли бирде:

— Менәтерәк, һич уйламаган җирдән. Мактап кына йөрисез икән. Тиздән токмачым да кабарып чыгар. Әйдәгез, утырышыгыз, түрдән узыгыз. Сине күптән күргән югые, Гөлзадә, бөтенләй тулып житкәнсең икән...— Шул сүзләрдән соң ул әз генә кызарынды.

Утырыштылар.

— Җизни кайда? — дип сорады Гөлзадә.

— Урманда, яшь наратлыкларны карап кайтырга китте. Аның ни, тап ату белән шул урманда инде.

— Балалар?

— Укуда. Икесе дә интернатта. Җәен генә безнең янда торалар.

— Ялгыз гына күңелсез түгелме соң?

— Төрле чак була...

Хуҗа хатын белән Гөлзадә сөйләшкәндә Васил өйне күзләре белән сөзеп чыкты. Һәр нәрсә үз урынында — караваты, өстәле дә җыйнак кына. Гадәти әйберләр арасында көзгеле яңа шифоньер бик нык аерылып, бөтен өйне ямьләндереп тора иде.

Гөлзадә, юлдашының кем икәнен әйтергә беренчә мәртәбә тел кыймылдатырга талпынып караса да, ничектер уңайсызланды. Ахырында хуҗа хатын сорагач кына әйтте:

— Ул безнең башлыгыбыз, начальнигыбыз Васил абый була,— диде.

— Менә сеңелегезнең чаңгы каешы өзелде дә шуны рәтләргә кердек әле,— диде Васил тиз генә.

Хуҗа хатын чоланнан каеш табып алып керде.

Тегеләр сөйләшкән-сайрашкан арада Васил чаңгыга ыспай гына итеп яңа каеш беркетеп куйды.

Василга хуш исле юкә балы белән чәй эчү бигрәк тә ошады. Инде китәргә җыенгач та, хуҗа хатын кунакларга кыстый-кыстый чәй ясады. Урман бүләкләре булсын дип, Гөлзадәгә чикләвегеннән, кипкән шомыртыннан, кипкән җиләгеннән аз-маз өлеш чыгарды, һәммәсен дә кечкенә капчык белән биленә такты кызның.

Өйдән иң элек Васил чыкты. Ләкин аңа капка төбендә кызны байтак вакыт көтәргә туры килде. Ул ерак чыбык очы кардәш апасы белән Гөлзадә арасында булган сөйләшүне тыңлап торса ни әйтер иде икән?

Ерак тутасы кыздан:

— Йөри торган егетеңме? — дип сорады.

Гөлзадә ни дип җавап бирергә гажиз булып торды да, кыюсыз гына тел какты:

— Ничек дим... Ул безнең начальник. Әйтәм бит, чаңгы походына чыктык.

— Ул синең белән юкка гына кермәгәндер инде. Күзләре гел синдә менәтерә. Алдап куймасын — ирләргә ышанма...

— Юк... без иптәшләрчә генә, түти.

— Беләм инде, беләм, кыз чаклар кайсыбызның гына башыннан үтмәгән. Йөрәгем белән тоям: сезнең арада ни дә булса бар.

— Юк, түти, син теге...

Гөлзадә өйдән чыкканда Васил үзенең кул сәгатенә карап тора иде. Кызның яңакларында ерак тутасы белән сөйләшкәндә кабынган алсулык әле һаман да сүнмәгән, бу минутларда ул, Василга калса, бүтән чакларга караганда да чибәррәк һәм ягымлырак иде. Бу алсулыктан, бу кызарып янудан Васил әллә ни абайлый алмады. Һәммәсен дә сулап туя алмаслык урман һавасына кайтарып калдырды. Гөлзадә, озын керфекләрен күтәреп, оялып кына аңа карады:

— Бик озак көттермәдемме сезне, Васил абый?

— Кызлар көттерәләр инде алар,— диде мәгънәле генә итеп Васил.

Алдагы төркемне куып җитү турында уйлап та карарга ярамый иде инде. Ашыкмадылар. Алар урманны чыкканда кичке энгер-меңгер җиргә соры шәлен ябарга әзерләнгән иде инде. Ачык кырдагы җиләслек битләрен, муеннарын кытыклый башлагач, адымнарын ешайта төштеләр.

Кай ягы беләндер үзенә тарта иде бу кыз Василны. Шул очраса, күңеле үз урынына утыра, җаны, йөрәге тынычлана. Юк, тынычлана да, тынычланмый да, аның үз уты бар...

Бер чокырлыкны чыкканда Гөлзадә алдындагы түмгәклеккә абынып егылуын да сизми калды. Васил шундук аны күтәреп торгызды. Ничектер бик уңай туры килеп кызның биленә кулларын салды. Шунда инде үбештеләр... Беренче мәртәбә үбештеләр алар. Ачык кырдагы җиләслекне, салкыная барган һаваны әйтерсең лә ялкын чорнады...

18

Никитин химиклар шәһәренә электр станциясе төзелешенә җибәрелергә тиешле кешеләр турында приказга күптән кул куйган иде инде. Тын Елга буйларында эшләүче кайбер җитәкче хезмәткәрләр, инженер-техниклар һәм квалификацияле эшчеләр икенче эшкә күчү сәбәпле, алар урынына бүтәннәрне билгеләделәр. Кемне күтәрделәр, кемне күчерделәр. Шулай итеп кыенлыктан чыгу юлын таптылар. Бу приказ үзенең бер кырые белән барлык жепләрне үзенә туплаган баш конторага да килеп кагылды. Брагинский химиклар шәһәрендәге электр станциясе төзелеше начальнигы хезмәтенә күчерелү сәбәпле, аның урынына, ягъни идарәнең баш инженеры урынбасары постына Васил Сафин билгеләнде. Бер үк вакытта ул төзү-монтаж идарәсе башлыгы хезмәтендә дә калды. Никитин: «Яшь, энергияле. Әлегә ике көймәне сөйрәү дә авыр булмас аңа. Соңыннан, бара-тора күз күрер»,— диде.

Баш инженер урынбасарының төп конторада кечкенә генә үз кабинеты бар. Ул әлегә бикле тора. Чөнки, урынбасар буларак, аңа пар казаннарын һәм турбогенераторларны монтажлау, җыю эшләре белән җитәкчелек итү, шул эшләргә контроль ясау йөкләнгән иде.

Юлдашев үзенең яңа урынбасары белән ничек эшләр? Ул Никитин белән бер сөйләшүендә әллә ничек шунда теленнән сүз ычкынып әйтеп ташлады: «Егет бик кайнар. Алай да ике йөкне сөйри алырмы икән?» — диде. Никитин үзенә бик нык ышанган хәлдә: «Эшләр. Ул инде үзен

бик күп унай яктан күрсәтеп өлгерде»,— диде. Аның болай кырт кисүе Юлдашевны тагы да сагая төшәргә мәҗбүр итте.

Уртак эштә әллә ни каршылыклар килеп чыкмады. Көннәр үткән саен тәзелешнең үсә баруы, Васил Сафиннын үз хезмәтен тырышып башкаруы һәммәсенең күз алдында иде. Моны Юлдашев та бик ачык күрде. Ул үзенең хәзерге урынбасарын элеккесе белән чагыштырып карады. Һәркайсының үзләренә күрә кыйммәтле сыйфатлары бар иде. Анынча, Брагинский барыннан да элек техник тәэминат мәсьәләләрен хәл кылуда өстенлек ала, башка оешмалардагы кешеләр белән уртак тел табарга маһир иде. Ә Сафин хәзергә эшчеләр арасында хезмәтне оештыра, көннең кадагына суккан мәсьәләләрне үз вакытында тотып ала белүе белән аерылып тора шикелле иде. Тик менә... кирәк вакытта аның «койрыгына басарга» кирәк, шунсыз булмый. Аның күңеленда тагы каршылык туды. Монысында инде Юлдашев тирән сулап, көрсенеп куйды: «Нишлисең? Булган хәл белән ризалашырга туры килә». Никитин тарафыннан кул куелган приказны ул үзгәртә алмый бит инде.

Бер тапкыр Юлдашев баш диспетчер белән шактый коры сөйләште:

— Кадерле Диночка, мин синең белән килешеп бетә алмыйм. «Ун»га, «сул»га каеручылар бер шоферларның гаебе аркасында гына түгел, монда гаепнең авыр ягы участок житәкчеләренә, прораблар жилкәсенә дә төшә...— диде һәм баш диспетчерга, транспортны файдаланудагы барлык материалларны туплап, үз кабинетына килергә кушты.

Икенче көнне Дина Гурская, Зариф Салихович әйткән материалларны туплап, баш конторага килде. Ул үзе укып чыккач, Юлдашев кашларын жыерды. Аннары, үзенең ризасызлыгын сиздермәскә тырышып, ясалма төстә елмайды:

— Йомшаграк чыккан бу, Диночка. Тешсезрәк чыккан. Әйтик, фактлар бар икән, аларны кискенрәк гомумиләштерергә кирәк иде.

— Тагы ни әйтәсең, минемчә, әлегә шушы ярап торыр, Зариф Салихович.

— Житми шул, Диночка. Синдә хатын-кызларга хас булган сентиментальлек бар, жәлләү хисе бар. Аннары син Данилов кебек шома егетләрнең телләре бик озын икәнен дә онытма. Аларны тыебрак тормасаң, бөтенләй муенга менеп утырырлар,— Юлдашев моннан хәтсез вакытлар элек булган партия жыелышын һәм анда үзенә каршы тәнкыйть белән чыккан прораб Даниловны әле һаман да оныта алмый иде. Ул жае килгән саен аның гаярьлеген суыта барырга исәп тотты.

Шул сөйләшүдән соң бер-ике көн үтүгә инде «Транспорттан файдаланудагы кимчелекләрне бетерү турында» бөтен тәзелеш идарәсе буенча баш инженерның приказы чыкты. Анда үзбушаткычлар һәм башка автомашиналардан дөрес файдалануны тәэмин итмәгән өчен прораб Даниловка каты шелтә белдерелгән иде.

Тагы да бериичә көн үткәч, Дина Гурская Юлдашевка үзе шалтыратты:

— Приказның файдасы налицо, көн кебек ачык, Зариф Салихович. Тәртип ныгый төште. Шоферлар арасында намуссызлык фактлары сизелми.

— Приказның бөтен максаты да әнә шунда шул, Диночка,— дип канәгать калганын әйтте Юлдашев.

— Әмма әлеге приказ Игнат Даниловның башына кинәт күсәк белән китереп суккан кебек булды. Барлык бүлекләргә, барлык участокларга жибәрелгән приказ ул житәкчелек итә торган прораблыкка да килеп төшкән иде. Игнат булган хәлне тиз генә башыннан кичерде дә иренәрен бөрештерде. Баш диспетчер белән сөйләшеп караса, бәлки хатаны төзәтерләр, дип уйлады. Ләкин бу сөйләшү берничә дә файда бирмәде. Нишләсен инде ул? Василга зарланса, бәлки ул берәр төрле ярдәм

итә алыр иде. Зариф Салиховичның үзе белән сөйләшеп караса... Юк, инде ул үзе кул куйган приказны юкка чыгармас...

Югыйсә, Игнатның фикер йөртүенчә, приказдагы шикелле әллә ни кычкырып торган фактлар юк иде. «Фактлар» дөреслеккә туры килми иде... «Прораб Даниловның контроль ясамавы, игътибарсыз карашы аркасында...» Бу юллар аның хәтерен бик нык калдырды. Бер үзбушаткыч, баллоны бушау сәбәпле, ярты көн поселок белән төзелеш арасында эшли алмый яткан. Тагы бер намуссыз шофер измә ташый торган жиреннән бүленеп, кемгәдер утын китергән. Болар турында диспетчерга үзе хәбәр иткән иде бит ул. Менә хәзер шулар үз башына чукмар булып төште.

Ул теге җыелышта Юлдашев исеменә карата әйткән тәнкыйть сүзләрен оныткан иде инде. Юлдашевның усал хәтерле икәнен Игнат исенә дә китереп карамады...

Дүртенче бүлек

1

Кызлар кебек көлеп яз килде...

Элек-электән Тын елга буендагы карт усакларга, өянкеләргә оя ясый торган кара каргалар агачлары киселгән урыннарда очышып йөрделәр. Таныш агачларны күрмәгәч, ниндидер ямансу тавышлар белән кычкыра-кычкыра, икенче урыннарга очып киттеләр. Алардан соң килгән башка кошлар да кайчандыр бала чыгарган урыннарын таба алмадылар.

...Акъяр һәм тагы шул тирәдәге берничә авылның урыны гына калган, барлык йорт һәм каралты-куралар яңа жиргә күчерелгән иде инде. Сыерчыклар да, ерак көньяклардан безнең бу тарафларга килгәч, үз ояларын карап, нигезләре генә күңелсез утырып калган өйләр тирәсендә очышып йөрделәр.

Әле гөрләвекләр ага башлаганчы ук, булачак сулыкның ярларын, Никитин приказы буенча, гел карап, гел күзәтеп тордылар. Тиешле урыннарны кыш буе тәртипкә китерделәр, тирән жирләргә бетон салдылар. Яр буе корылмаларына тәүлек буе дежурлар куелды. Үзәк лабораториядә су басымын сынау кебек эшләр дә даими рәвештә алып барылды.

Кешеләр быелгы кар суларының сусаклагычта тотылып калачагын көздән үк беләләр иде.

Әле елгаларда боз кузгалгач та, беренче көннәрдә Тын елга элекке рәвешен үзгәртмәде. Ләкин инде берничә көннән соң хәл бөтенләй үзгәрде. Ул гына түгел, гүяки әкияттәге тизлек белән гаять зур күл хасил булды. Яр буйларында кичен-иртәсен кешеләр кайнашты. «Ниндидер кодрәт белән» әле яңа гына пәйда булган «диңгез»не карарга хәтта тирә-як авыллардан да килә башладылар. Элекке Акъяр кешеләре кайчандыр үзләре гомер сөргән урыннарның су астында калуларын күргәч, бераз моңсуланып та алдылар. Ләкин аларга моңаеп йөрергә вакыт юк: яңа авылда, яңа күчкән жирләрендә бик хәтәр яңарту, төзү эшләре бара иде.

Баштарак байтакларны, йөзләгән километр ераклыктан ташу сулары агып килеп, сусаклагычта коточкыч боз таулары тыгылыр, хәтта буага да куркыныч тудырыр дигән уй борчыган иде. Әмма ул хәл булмады. Бозлар сусаклагычның югары башында утырып калдылар. Анда бер-берсеннән өзек-өзек аерылып торган зәңгәр-ак төстәге «таулар», карап туймаслык бер матурлык биреп, тирә-якны сихри төсләргә керттеләр. Ләкин алар кечерәйгәннән-кечерәя барды.

Яр буендагы кешеләр арасында безнең таныш лардан Рафис белән Мәдинә дә бар. Алар яр чите буйлап салынган асфальт юлдан салмак кына атлыйлар. Әле моннан бер ел элек кенә бу урыннарда резин итекләр белән бот төбеннән саз ерып йөри торганнар иде. Аларны хәзер искә төшереп сөйләргә генә калды инде.

Ике яшь йөрәк... Икесе дә язга хас жиңел киемнән — Рафисның өстендә плащ, тар балаклы чалбар, аягында очлы борынлы туфли, Мәдинәнең зәңгәрсу төстәге кыска ефәк күлмәге, шул ук төстәге йон свитеры үзенә бигрәк тә килешә. Ул биек үкчәле туфли дә кигәч һәм чәчләрен баш түбәсенә күпертеп өеп куйгач, бер дә юантык түгел, үсеп, озынаеп киткән сыман күренә. Кай ара житди генә сөйләшәләр, кай ара көлешеп тә алалар, кай ара күзләре дә очраша. Рафиска калса, Мәдинәнең елмайган чагында авыз кырыйларында күренеп китә торган чокырлары да, мөлаем карашы да, үзенә генә хас бераз калынрак көр тавышы да — һәммәсе дә, һәммәсе дә ошый, якын ана.

Алар яр буйлап баралар, адымнар салмак, тыныч... Рафис үз күзләренә ышанырга да, ышанмаска да белми. Ярлар... Кызларның басмада кер чайкаганнарын искә төшереп, соры бетон ярларга йөгерек дулкыннар килеп бәрелә. Алар, ерактан килгәндә бик көчле, бик гайрәтле сыман күренсәләр дә, килеп житкәч, бетон ярлар алдында иректән баш ияләр. Чигенәләр. Чигенәләр дә икенче каршы яктагы күксел урманлы ярларга таба ашыгалар. Су нинди киң! Ул мәгърур Идел буйларын, Кама ярларын иректән егетнең хәтеренә төшерә. Көнчыгышка таба сузылып киткән урманлы-таулы ярлар да шул ук Идел — Кама буйларының бер өлеше сыман. Әнә теге борылмадан, бик зур аккош кебек йөзеп, теплоход килеп чыгар төсле... Рафис шулай уйланып, ләззәтле кичерешләргә бирелеп барганда, Мәдинә кычкырып жибәрде:

— Акчарлаклар!

— Акчарлаклар! — дип кабатлады Рафис та, кинәт кенә уйларыннан бүленеп.

Яр буеннан ерак түгел, канатларын салмак кына кагып, өч-дүрт акчарлак сулык өстендә очалар иде. Кешеләргә бу яңа хәл ничектер гажәп тоелды. Шушы Тын елга буйларына акчарлаклар алып килгән яз бигрәк тә күңелле, бигрәк тә йөрәк хисләрен ташыта иде. Мәдинә, үзалдына бер төрле моңайган шикеллерәк итеп, әйтеп куйды:

— Бу болыннарда яңадан сабан туйлары булмас инде. Кичке уеннар да булмас. Бары да су астында калды...

Рафис аңа, бер дә исе китмәгән кебек, көлемсерәп карады:

— Исең киткән икән. Озакламый монда көймәләр йөзәр, су трамвайлары... Тагын да күңеллерәк булыр. Ә балык! Шундый күп үрчер, кармагыңны салып кына өлгер...

Ничек кенә булмасын, бу талгын язгы көндә, бу иркенлектә, үзләрен шушы тарафларның хужасы тоеп, ике сөйгәннең бергә атлавы гажәеп күңелле иде. Һәр икесе әлеге үз тормышларыннан канәгать, тик алар һәркайчан бергә генә булсыннар, шулай яңәшә атласыннар. Аларга иң кыйммәтлесе шул иде.

Ике көн...

Ахырында, күп тарткалаша һәм сүз куерта торгач, Рафис ягы өстенлек алды. Моңарчы гел сузып килгән һәм төзүчеләр көне житкәч кенә бергә булырга ризалык биргән Мәдинә көннәрдән бер көн риза булды да куйды. Һәм алар киләчәк көннәрен, киләчәк тормышларын, киләчәк язмышларын бергә бәйләделәр. Алдан килешенгәнчә, сүз куешканча, Виктор вакытлыча, кысылу-тараю хисабына булса да, бүтән бүлмәгә күченде. Рафис берничә сәгатькә бүлмәгә үзе генә хужа булып калды. Ә аннары инде көньяктан талгын гына жил исеп торган, бихисап күп йолдызлар бизәгән кичләрнең берсендә тулай торактагы бүл-

мәгә шул җан сөйгән Мәдинәсен җитәкләп кайтып керде. Кызның чемодан кебек әйберләрен соңыннан гына барып алды. Хәер, аларны бик җиңел, җыенысын бер кулга күтәрерлек иде.

Ике көн...

Һәм ике төн. Алар башлы-күзле булдылар да куйдылар. Бу көннәрдә аларның ашамыйча тамаклары, йокламыйча йокылары туйды, эштә дә ару-талуны белмәделәр. Ни әйтсәң дә яшьлек — яшьлек шул.

Чәчәкләрнең төрлесе була: кызылы да, алы да, зәңгәре дә, сарысы да, күге дә, шәмәхәсе дә, күгелжеме дә... Әмма нинди генә төстә булмасыннар, аларга һәрвакыт сафлык, хушлык хас. Үзләренә каршы жырлашып килгән бер төркем таныш кызларны күргәч, Рафисның башында әнә шундый фәлсәфә туды. Бергә-бергә җитәкләшеп килгән бу кызлар — Гөлзадә, Люда, Лиза, Диләрә — һәркайсы үзенчә пөхтәләп, кызларга гына төс булган бер купшылык, зәвык белән киенгәннәр. Алар, килеп җитү белән, Мәдинәнең кулыннан җитәкләп алдылар. Рафис кырыйда калды. Ул бүтән чакларда Гөлзадәне күрүгә кызара, ояла, үзенең аңа карата кайчандыр тупас кылануын исенә төшерә һәм шуның өчен керер урын тапмый торган иде. Бүген алай булмады. Җитмәсә әле, Гөлзадә үзе башлап сүз катты:

— Чын дусларча котлыйбыз сезне! Тик менә...

Гөлзадәгә башлаганын әйтеп бетерергә туры килмәде, сүзне Диләрә ялгап алып китте:

— Туегыз кайчан була? Без белми дә калдык, бигрәк астыртын йөрттегез эшне...

— Комсомол оешмасыннан рөхсәт тә сорап тормадылар,— дип шаяртты Лиза.

Бу сүзләрне ишеткәч инде Рафис яхшы ук кызарды. Иптәш кызлары кабатлап сорагач, Мәдинә аларны җавапсыз калдыра алмады:

— Туйнымы? Туйны төзүчеләр бәйрәме килеп җитми үткәрмәбез әле.

— И аңа хәтле әле төз жирләрең түмгәк булыр,— диде Людамы, Лизамы шунда.

Мәдинә аңа да каршы төште:

— Җитә ул, вакыт бик тиз үтә.

— Синең гел бар белгәнең шул төзүчеләр көне инде, Мәдинә. Әллә дөньяда шуннан башка бәйрәм юкмы? Алай ук кичекмәбез,— диде Рафис.

— Дөрес, дөрес! — дип хупладылар кызлар.

(Ахыры бар)

Виктор Щекачев — безнең якташыбыз. Ул Зеленодольск шәһәрендә туып-үскән. Хәзер Мәскәүдә яши. Татар шагыйрьләрен русчага тәрҗемә итүдә актив катнашып килә. Озакламый аның тәрҗемәсендә шагыйребез Фәнис Яруллинның шигырьләр китабы Мәскәүдә, рус телендә чыгачак. Иҗади дуслык йөзеннән Фәнис Яруллин да журналыбызга В. Щекачевның ике шигырен тәрҗемә итте.

Виктор Щекачев

Мостафа авылында

Мостафа авылы
Болдино кебек:
Кая карама —
Иркенлек, киңлек.
Елгалар, таулар,
Өйләр, урамнар
Кояшның якты
Нурына чумганнар.
Мостафа авылы
Болдино кебек —
Шундый ук киңлек,
Шундый иркенлек.
Һәрбер жирендә
Шигърият тулы!

Ул бит Жәлилнең
Туган авылы.
Сөйләшсәләр дә
Татар телендә,
Пушкин авылы күк
Тоела күңелгә.
Туганлаштырган
Сезне бер язмыш.
Икегез дә миңа
Якын һәм таныш.
Тиң күреп сине
Болдино белән,
Сиңа, Мостафа,
Килеп баш иям.

Шагыйрьнең сеңелесе

Метеоролог Хәдичә Жәлиловага

Шагыйрьнең сеңелесе булу
Бик олы бәхет, беләм.
Саклыйсыз аның намусын
Сез сизгер йөрәк белән.
Ерак Урал артларында,
Игеннәр уңган якта —
Хәтерлисездер Мусаны
Бәләкәй малай чактан.
Сөйләгез миңа, Хәдичә,
Сорыймын сездән шуны:
— Гап-гади авыл малае
Ничек зур шагыйрь булды?
Яшьләр белән жырлар жырлап
Урамнар ураганын,

Сөйләгез, аның картлардан
Киңәшләр сораганын.
Өмәләргә катнашканын
Калмыйча һичберөннән.
Шигъриятне алдымы ул
Шушы туган жиреннән?
...Әңгәмә китте озакка,
Сораулар әллә ничә.
Шагыйрь рухын саклаганга
Рәхмәт сезгә, Хәдичә.
Күрсәттегез матурлыгын
Муса туган якларның.
Шушы хатирәләрне мин
Гел күңелдә саклармын.

Самат Шакир

ДАЛАДАГЫ СОВХОЗДА

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ

Еракка-еракка сузылган киң дала. Кая карама — яңа төзелешләр: әнә уңда терлек фермасы кораллар, ә арырак торак йортлар салына, сулда — зур гараж... Ара-тирә тирмәләр дә күренгәли. Болары — көтүлектәге чабаннар өчен.

Даланы кыл урталай ярып таш юл үтә. Без Павлодар ягыннан автобуста киләбез. Олы яшьтәге бер казакъ салмак тавыш белән җыр башлады. Аңа башка казакълар да кушылдылар:

Бул домбыра тогыз перне тагылган,
Естіген жан үнін аңсап сагынган...

Моңлы кей йөрәк кылларын чиртә, дала күгендә канат җәя, аннары еракка-еракка китеп тарала, югала. Казакълар җырына русча «Яблочка», анысына исә татарча «Исле гөл», аннан соң тагын-тагын бүтән җырлар кушыла бара...

Белогорье поселогына килеп җиткәчне сизми дә калдык. Автобус ике катлы таш йорт — «Шыган» кафесы янында туктады. Казакъларның берсе шаяртып әйтә куйды:

— Пушкінның Белогорский крепостена життек.

— Пушкин монда кадәр килеп җитмәгән шул,— диде икенчесе.— Уральскида туктап калган.

— Пушкин булмаган жир юк хәзер,— дип елмайды яшь кенә кыз.

— Дөрес, сеңелем! Дөрес!

Пассажирлар бераз ашап-эчкәннән соң, автобус тагын кузгалып китте. Озакламый, алда текә ярлы Иртыш елгасын күрдек. Нәкъ шул елга буеннан аз гына читтәрәк кайчандыр кечкенә генә колхоз булган. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең чирәм җирләрне үзләштерү турындагы карары чыккач, бу урынга Татарстаннан да бик күп кешеләр күчеп киләләр. Чирәм җирләрне күтәреп бик күп иген чәчелә һәм беренче елны ук мул уңыш алына. Колхозның чикләре шулай киңәя торгач, монда зур совхоз оештырырга булалар. Татарстаннан килгән хезмәт ияләренең соравы буенча, аңа «Казан» дигән исем бирелә.

Без шунда килеп җиткәндә кояш кызгылт-сары нурларын җәеп таулар артына өкрен генә төшеп бара иде. Казакъ стилендә эшләнгән аркалар, колонналар, орнаментлар белән бизәүле яңа биналар — икешәр катлы таш йортлар төзелешкән. Культура йорты, магазиннар, мәктәп, больница, балалар бакчасы, контора... Бакчалар, скверлар, төз урамнар.

Совхоз директоры Зекеш Кажкенов белән аның шушы үзәк усадьбадагы квартирында очрашабыз. Каратут йөзле, киң кара кашлы, урта буйлы, кунакчыл җитәкче.

— Хуп килдегез, хуп! — диде ул, түрдән урын тәкъдим итеп.— Ерактагы Казаннан безнең «Казан»га килүчеләрне без бик яратып каршы алабыз.

Зекешнең тормыш иптәше, Казан, Татарстан хәлләрен сораша-сораша, чәй өстәлә. Аннары совхозның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгә турында гәпләшергә тотындык.

«Казан» совхозының беренче нигез ташлары 1954 елда салына башлый. Бу вакытта Татарстанның комсомол путевкасы белән килгән яшьләр башта далада палаткалар корып тораллар. Беренче тракторлар беренче буразналарны сыза, беренче таш йортлар калкып чыга, яңа урында беренче матур семьялар барлыкка килә. Дала уяна, дала яшәрәнә, алтын бодай дулкыннары уйната башлый. Татарстаннан каникул айларында ярдәмгә килгән студентлар хезмәте аерата зур була. Социалистик ярышта Казан университеты студентлары алгы сафта баралар. Аларны биредә әле дә мактап искә алалар. Совхоз үзәгендә беренче елда ук беренче урам барлыкка килә. Аңа «Тыныч-лык» дип исем кушалар... Ә хәзер бу совхоз өлкәдә алдынгы хуҗалыкларның берсе инде. Аның 90 мең гектар җире бар. Бу — бездәге зур бер районның чәчүлек мәйданы дигән сүз.

Совхоз директоры Зекеш Кажкенов, баш агроном Афанасий Ожегов һәм партком секретаре белән бергәләп ерак басуга киттек. Кызу урак өсте. Далада эссе. Тирәякта бер генә елга яки күл әсәре юк. Иксез-чиксез бодай басулары гына күренә.

— Бу урыннар ташландык җир иде,— ди баш агроном.— Беренче елны аны эшкәртү аерата кыен булды. Ник дисәң, бердән, түмгәкле, икенчедән, ташлы иде ул. Тиешенчә эшкәртеп, ашлама керткәч, искиткеч мул уңыш бирә башлады. Әнә нинди матур, нинди киң бодай кырыбыз!

Ерактан саманнан эшләнгән йортлар күренде. Якында ук комбайннар эшли. Без килеп җиткәндә, татарча җыр ишетелде.

Сарман буйлары ла яшел алан,
Печәннәре җитәр бер заман...

— Илдар Галимуллин җырлый,— диде Кажкенов.— Совхозның алдынгы комбайнчысы. Узган ел да, быел да рәсеме Почет тактасынчан төшкәне юк.

Каерылып үскән бодай ура-ура, комбайн безнең янга якынлашты. Баш агроном күл изәүгә, комбайнчы рычагны тартты. Пыяла күзлек кигән Илдар, комбайннан төшеп, безнең янга килде һәм күл биреп күреште.

— Бик авыр түгелме? — дим, Илдарның елмаеп торган тузанлы йөзенә карап.

— Беренче елларны авыр иде. Хәзер ул кадәр түгел. Кырдагы игенне күргәч, йөрәк ашкына, тизрәк җыеп аласы килә.

Галимуллин 1935 елны Лаеш районы Атабай авылында туган. Армия сафында хезмәт иткән. Чирәм җиргә 1959 елда килгән. Башта комбайнчы ярдәмчесе булган, соңыннан штурвалны үзенә ышанып тапшырганнар. Әтисе Галимулла, әнисе Мәслимә башта аның бик ераккка китүен өнәп тә бетермәгәннәр. «Монда гына үзебездә генә кал»,— дигәннәр. Ләкин комсомолда тәрбияләнгән егет үзенекен иткән — Павлодәр өлкәсе Май районында төзелгән «Казан» совхозында үз бәхетен тапкан. Наилә исемле кыз белән никахлашып матур тормыш корганнар. Һәр елны сабан туенда алар туган якларына кайталар, колхоз хәлләре белән танышалар һәм ерак даладагы «Казач» совхозы турында бик яратып сөйлиләр икән. Елның-елында булмаса да, ике-өч елга бер тапкыр Илдарның әтисе Галимулла агай да Казагыстандагы улын, киленен һәм оныкларын күрергә килеп чыга.

Тормышны мактаулы эш белән күңелле ял бизи.

Ун елдан артык инде Илдар комбайнда эшли. Ул СК-4 комбайнында нормаңы 130—150 процентка үтәп бара. Аның ярышташы — Николай Бережнов. Ул Украинадан килгән, «Казан» совхозында тырышлыгы белән үзен шулай ук тиз таныткан, Коммунистлар партиясе сафына кергән. Хәзер ул биш бала атасы. Бережнов исемен Май районында яхшы беләләр. Әйбәт эшләгәне өчен елның-елында бүләкләнеп килә.

Дала. Очсыз-кырыйсыз дала...

Җиңел машина тигез урыннардан элдерә генә. Без ераккa күз төшерәбез һәм горизонтта җәйрәп яткан күл күрәбез.

— Су юк дисез, ә менә каршыда гына нинди зур күл бар,— дидем мин. Совхоз директоры Кажкенов сөрле генә елмаеп куйды. Ул баш агрономга карап алды да сөйли башлады:

— Бу күл булса, без җирләрне әллә кайчан бакча итәр идек. Шулай бит, Афанасий? — диде. Тегесе «әйе» дигәнне аңлатып баш селекте. Аннары директор күлнең тарихын сөйләп бирде.

Бу күл тоз күле икән. Ләкин тозы бернәрсәгә дә яраклы түгел. Әгәр дә белмичә күл суына керсәң, шунда ук тәнең тоз кристаллары белән каплана. Заманында бу күл тирәсенә күчмә казакълар килеп тирмәләр корганнар. Ләкин күлнең суын эчү аркасында куйлар, дөяләр кырылган, кешеләр арасында авыру башланган. Хәзер күл тирәсендә бер генә дә җан иясе юк. Күл кара-кучкыл төсе һәм зәһәр дулкыннары белән күңелгә шом салып тора. Аның тирәсендә бер генә үлән дә үсми, суында бер генә балык та юк.

— Киләчәктә менә бу күлне киптереп, җирен эшкәртеп, анда иген чәчәргә мөмкин булачак,— дип сөйләп китте Кажкенов.— Ләкин хәзергә бу «Зәһәр су» (казакълар шулай дип атыйлар икән) бернигә яраксыз.

— Совет кешеләре космосны яулаган бер чорда мондый гына күлләрне авызлыкларга мөмкин булыр,— диде баш агроном.

— Әйе, бик дөрес, Афанасий! — дип хуплады аны Кажкенов.— Тиздән бу урында да шаулап бодай үсеп утырыр.

Кайтышлый кукуруз җирендә булдык.

Казагыстанда терлекчелек төп урынны алып тора. Бу борын-борыннан килә. Ләкин даладагы кылганлы үлән терлекләрне кыш ашату өчен җитми. Шуның өчен биредә күпьеллык үлән һәм кукурузны мул чәчәләр. Чабаннар тәҗрибәләре турында сөйләгәндә иң беренче итеп күпьеллык үләннәрне мактап телгә алдылар.

Монда яз айларында аз гына яңгыр була, аннан соң тамчы да таммый икән. Табигатьнең бу кырыслыгы күп кенә авыл хуҗалыгы эшләренә зыян китерә. Әмма совет кешеләре корылык алдында баш имиләр, «Казан» совхозында да, туфракта дым саклау өчен җирне дөрес эшкәртү, язгы чәчүне иртә тәгәлләү һәм минераль ашламалар кертү нәтиҗәсендә, уңыш алу елдан-ел яхшыра бара.

...Икенче көнне без ерак көтүлеккә — куйлар җәйләвенә бардык. Совхозның 20 мең баш куе бар. Бу куйлардан килгән табыш елдан-ел үсә бара.

Без борылмалы юлларны узып шактый ераккa киттек. Чөнки куйларны үләнле далада асрыйлар.

Шофер Вәли машинаны саманнан эшләнгән йорт янына туктатты. Йорт алдында тезгененнән баганага бәйләнгән иярле ат тора. Ат янындагы елкән яшьтәге агай, кулын каш өстенә куеп, көтүлектәге куйлар ягына төбәлгән.

— Аманмысыз? — диде аңа Кажкенов казакъчалап.

Карт керәктәй кулларын сузып исәнләште, һәм «аман, аман» дип, безне йорт эченә алып керде. Түрдә, идәндәге киездә, зур яшел сандык тора. Аның өстенә мендәрләр өелгән. Хуҗа безгә түрдән урын тәкъдим итте, үзе чәй кайнатырга ишек алдына чыкты.

Бу өлкән аганың исеме Кабдыл иде. Ул инде 64 яшендә. Пенсиядә булуына карамастан, һаман үз эшен дәвам итә. Усманов Кабдыл — баш чабан. Яхшы эшләгәне өчен медальләр һәм Почет грамоталары белән бүләкләнгән. Усмановның шәкертләре Бурыкбаев Шәмән, Бурыкбаев Курмаш һәм Кәменов Түлебекләр дә куйлар көтүдә тырышлыклары белән танылганнар.

Кабдыл агай, шаулап торган җиз самоварны өстәлгә китереп куйды да, чәй ясый-ясый, куйларның көр булып үсеп килүләренә аерым бер шатлану белән сөйләп бирде. Ул барлыгы җиде йөз баш куй карый икән. Һәр йөз куйдан елына йөз уналты кузы

(күй бәрәне) алып үстерә. Һәрбер күйдан 3 килограмм 500 грамм урынына 4 килограмм 200 грамм йон ала...

Кабдыл агай патша заманындагы авырлыкларны да күп күргән кеше. Революция булу белән алар Совет республикасын нығыту өчен җиң сызганып эшлиләр, басмачыларга каршы көрәшәләр. Колхоз төзүдә Усманов зур активлык күрсәтә. Бу турыда өлкән аксакал бик сәран гына итеп сөйли: «Минем кебек эшләүчеләр совхозда күпләр, кулдан килгәнчә тырыштык, аның нәрсәсен сөйләргә инде»,— генә ди. Сүзгә күбрәк совхоз директоры катнашып, бу хөрмәтле чабан турында ул аңлатмалар биреп барды.

Кояш инде төшлектән авышып килә. Без яңадан юлга чыктык. Каршыда шул ук киң дала пейзажы!

Машина сикелтәле, түмгәкле сазак тау битеннән бара торгач, ниһаять, иң ерактагы көтүлеккә килеп чыкты. Монда без баш чабан Каратай Кайсынов белән очраштык. Кара чүен кебек йөзле, кап-кара күзле, кара кашлы бу кеше сүзгә бик җор икән. Ул Татарстаннан килгән чабаннарны мактап телгә алды:

— «Казан» совхозының данын бөтен Казагыстанда күтәрү өчен бергәләп көрәшәбез! Татарстан белән дуслыгыбыз бик борынгыдан. Уральскида Тукайны күреп белгән аксакалыбыз әле дә бар.

Каратай, кечкенә шкаф янына барып, аннан Тукай һәм Муса Җәлил китапларын алды. Казакъ телендә басылган бу китаплар Каратайның яратып укый торган китаплары икән. Үзен Казанга кунакка чакыргач, Каратай, кысык күзләрен тагын да кыса төшеп һәм елмаеп, йөрәк түреннән чыккан сүзләрен әйтте:

— Безне «Казан»нан Казанга чакыруыгыз өчен рәхмәт, жолдас. Шунда барып Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә «Казан» совхозы чәчәкләрен куярга, әлбәттә, телибез.

Совхозда кызу эш бара. Урып-җыелган яңа ашлык дәүләт амбарларына агыла. Ябык ындыр табагында көнен-төнен машиналар гүли. Ләкин, сменадан бушап, ял сәгатьләрен күңелле үткәргәннәрне дә күп очратырга мөмкин.

Ике катлы, таштан салынган культура йорты. Аның капкасына эре хәрефләр белән казакъча һәм русча язылган зур афиша да эленгән: Бүген «Моабит дәфтәре» дигән кино күрсәтелә. Киномеханик Иван Чернов казакъ, рус, украин, татар, немец балаларына кендезге сеанс күрсәтә. Без дә, мәктәп директоры Куандык Казыханов белән, кино карыйбыз.

Менә экранда Муса күренде. Балалар дәррәү кул чабалар: Кайберләре «Муса абый», «Дядя Муса» дип кычкырып та куя. Муса Җәлил бөтен халыкның шундый сөекле шагыйре, батыр көрәшчесе, ул һәркемнең йөрәк түренә тирән кереп урнашкан.

Аннары экранда — Алиш. Аны күрүгә берәү, жиңемнән тартып, әйтергә ашыкты:

— Алишны мин күреп беләм. Сугышка кадәр Казанда электр станциясе төзү эшендә бергә булдык. Аннан соң мин Казагыстанга киттем, Бөек Ватан сугышында катнаштым. Менә хәзер «Казан» совхозы гаражында слесарь.

Кинодан чыккач, кечерәк буйлы, елмаеп кына сөйләшә торган бер кеше белән очраштык. Ул, тамырлары бүртеп торган сәяллә кулларын сузып:

— Ике куллап күрешик, якташ! — диде һәм үзенең бакчачы Исмәгыйл булуын әйтте. Гажәеп яхшы, киң күңелле кеше. Безнең Норлат белән чиктәш Шынталы якларында туган. Бөек Ватан сугышында — разведчик. 1950 елдан коммунистлар партиясе члены. Совхозның Иртыш елгасы буендагы ул үстергән бакчасын карарга, жимеш остасының эш тәжрибәләрен өйрәнергә хәзер бик күпләр килә.

Исмәгыйл абзыйның чәчәкләр арасында утырган йорты тирәсендә — алма, чия, карлыган, шомырт агачлары!.. Кешеләр коры комлы, сусыл далага чәчәкле тереклек алып килгәннәр.

...Исмәгыйл абзыйлардан чыгып ындыр табагына барган, якташыбыз Розалина Гомәровананы очраттык. Казаннан комсомол путевкасы белән чирәм жиргә килгән бу ханым унбиш ел инде шушы совхозда эшли. Ул дистәгә якын Почет грамотасы белән бүләкләнгән. Аның турында район газетасында мактап язганнар. Розалина монда төпләнеп, тамырланып калган. Белоруссиядән килгән шофер егет Иван Лодотько белән матур семья корганнар. Розалинаның сеңелесе Венера да Казаннан эшкә килгән.

Совхозның икенче бүлекчәсендә күбрәк казакълар тора. Бу урында алар 1931 ел
ук колхоз төзегәннәр. Соңыннан ул «Казан» совхозына кушылган.

Клубта участок управляющие Ходайбирде Пшембаев белән сөйләшеп киттек:

— Мин сезне үзәк усадьбада да күргән идем. Бик вакытлы килдегез. Сезнең якт
шыгыз да бездә әле.

Мин шатланып сорап куйдым:

— Кем ул?

Ходайбирде, елмаеп, клуб алдына куелган зур афишага күрсәтте дә:

— Мостай Кәрим,— диде.

Семипалат шәһәреннән артистлар килгән икән. Алар башкорт халык шагыйр
Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» дигән трагедиясен күрсәтәчәкләр. Мин б
трагедияне рус, башкорт, татар телләрендә күргән идем. Хәзер исә казакъ телен
күрү бәхетенә ирештем.

Казанга китәсе көнне партком секретаре белән Май районы үзәгендә булды
КПСС райкомы секретаре Кәмеш ханым Балтекова «Казан» совхозының олы юл
чыгуын, елдан-ел үсә бару перспективаларын саннар белән аңлатып бирде.

— Сезнең якташлар сынатмыйлар! — диде ул.— Киләчәктә дә без татар дусла
ның тагын да күбрәк ярдәм итәчәкләренә ышанабыз.

...Ә совхозның дирекциясе миңа зур әманәт тапшырды. Бу «Казан» совхозы эш
челәренең, инженер-техник работникларының КПССның Татарстан өлкә комитетын
язган хаты иде. Анда мондый юллар бар:

«Безнең коллектив Татарстан хезмәт ияләренең безгә ярдәме, безне һәрвакыт иск
алуы белән шатлана һәм горурлана. Ерак Казагыстанда төзелгән «Казан» совхоз
соңгы елларда бик нык үсте, танымаслык булып үзгәрде. Палаткалар, саманнан эшлән
гән йортлар урынына берәр-икешәр катлы таш йортлар салдык. Кәртиралар пар бела
җылытыла, кухняларга газ кертелде. Совхозда терлекчелек елдан-ел үсә: куйла
20 меңгә, мөгезле эре терлек 2500 башка җитте...»

Әйе, якташларыбыз яшәгән совхозның эшләре дә, уңышлары да казакъ далалары
ның үзе кебек үк киң колачлы!

Шәйхи Маннур

ҺАМАН ДА ИСТӘ

«Кайтып торырга...»

Бөтенесе кичәле-бүгенле генә булып узган төсле... Кичелгән юллар — күз алдында. Югалткан дуслар, юлдашлар — күңел түрендә. Хәтта уйлаган уйлар да хәтердә — берсе дә онытылмыйлар... Үземне мин сизгер кеше дип саный идем. Дөнья хәлләренең һаман куера килүеннән, сугыш машинасының һаман киңрәк мәйданнарда гөрелди баруыннан үземчә бик белдекле бер нәтиҗә ясап, кичке чәй янында сөйләшеп утырганда әйтә куйдым:

— Бу Гитлер белән озакламый безгә дә сугышмый булмаячак...

— Әйе, әйе! — дип кабатладым, икеләнер урын калдырмыйча.— Сугыш котылгысыз. Бик күп булса — өч ел, дүрт ел узар! Аннары...

Ә бу вакытта немецлар Польшаны басып алганнар һәм Франциянең дә үз тылларына әйләндергәннәр иде инде... Суык яз узып, суык җәй килде. Соң гына яфрак ярган алмагачлар июнь урталарын үткәреп кенә чәчәк койдылар. Көннәрне әле һаман җылыта алмасак та, июньнең дүртенче якшәмбесендә язучы Абдулла Әхмәт белән Түбән Осланга дачага чыктык. (Матбугат кешеләре сугышка хәтле шунда тула иде.) Урнашу мәшәкате белән көн узды. Ул чакта әле авыл өйләрендә радио дигән нәрсә безнең шигырь яки хикәяләрдә генә була иде... Бер тәүлек тулып узгач, дүшәмбе көнне кичке уңайда гына «Сугыш башланган икән» дигән хәбәрне авыл хатыннарыннан ишеттек.

Фаҗиганең болай тиз башланып китүе һәркемне хафага салды. Сораулар күп, җаваплар юк иде. Ул төнне күзгә йокы кермәде. Мин таңга чә үземнән көлеп, үземне әрләп чыктым:

— Менә сиңа дүрт ел! Ай-яй, шәп күрәзә икәнсең!.. Пычагыма дип сөйрәлеп йөрергә иде соң? Дача, имеш!..

Сишәмбе көнне Казанга киттек. Шулай да Абдул көлдерергә маташып карады:

— Ундүрт баланы ташлап, ничек сугышка китәрсең, малай...— дигән булды ул. Ләкин аның тавышы бик хәсрәтле яңгырады. Дүрт баласын ундүрткә әйләндереп әйтсә дә, көләсе килмәде.

Минем хәрби билетта «Сугышның өченче көнендә...» дип язылган иде. Военкоматта: «Сабыр итегез, үзебез чакырырбыз»,— диделәр. Бу сабыр итүләр бик озакка сузылды: көз килде, октябрь бәйрәмен дә уздырдык. Немецлар Мәскәү тирәсенә килеп җитте. Хафалы көннәр, йокысыз төннәр туды, нервлар һаман киерелә, какшый барды. Шушындый кыен һәм жаваплы көннәрдә, бары тик шигырь генә язып, авылларга чыккалап, урман кискән булып, сау-сәламәт көеңә өйдә яту әллә ничек жинаять кебек тоела башлады... Шул беренче керүемдә үк Бауман военкомына өйдәгеләрдән яшереп кенә гариза калдырган идем — чакырмадылар бит. Кергән саен бер сүз: «Сабыр итегез». Ә сабыр төбе тишелеп бара...

Ноябрь ахырларында булса кирәк, Казанга Фадеев килеп чыкты. Ул, СССР язучылары союзының житәкчесе буларак, вакытлыча монда тулган Мәскәү язучыларының хәлен белергә килгән. Үзе инде баштанаяк хәрби киемдә, комбриг чинында.

Хәзер белмим инде, кайсыбызның башына алданрак килгәндер, без, Әхмәт Фәйзи белән икәүләп, Фадеев аша Кызыл Армиянең Баш политик идарәсенә, Мехлис исеменә, гариза жибәрмәкче булдык. Бу хакта Александр Александровичның үзе белән дә сөйләштек. Ул хуп күрде. Тора-бара безгә Әхмәт Ерикәй дә кушылды. Фадеев китеп бер унбиш көн узганнан соң безне чакырып телеграмма килде. Нинаять! Һич төчеләнми әйтәм: ул чакта бу бик зур шатлык булды. Чөнки ул көннәрдә бөтен ил беренче зур куанычын кичерә иде. Чөнки Мәскәү тирәсендә жәелеп киткән каты сугышларда безнең гаскәрләр, дошманның беренче тапкыр көчен сындырып, аны уңга-сулга яңаклый-яңаклый куа башлаганнар иде. Биш айдан артык зарыгып көткән беренче куаныч иде бу. Биш ай буена әкрен-әкрен һаман иелә барган башны беренче тапкыр югары күтәреп, беренче тапкыр горур елмаю, яшь аралаш горур елмаю иде бу!

Безне бик зурлап озаттылар. Банкет өстәле бай, ак башлы «снаряд»-лар да юк түгел. Гитлерга нәләт яудыра торган речьләр дә аз булмады.

Әлбәттә, шулай инде. Сабан туена бару түгел. Кулыбыздан килгәнчә тырышачакбыз. Шулай да шаян сүзне бик ярата торган Әхмәт Фәйзи поездда барганда үз-үзебездән көлмичә булдыра алмады:

— Ну, кырабыз инде без синең белән немецларны, — диде ул, теф-теф иттереп төкергәләп. — Без барып тотынгач та, берсе бер калмаячак, теф-теф!

Чынлап та, аның тышкы кыяфәте бер дә шул фронтка барып, мылтык яки автомат күтәреп, дошманга каршы сугышырдай кешенеке төсле түгел иде. Озын буйлы булса да, элеп киптергәндәй какча гәүдәле иде ул. Өфе каласындагы итекче Сафа агайның ярым подвал өендә үскәнлеге, авыл кояшын, басу жилләрен татый алмаганы әллә каян күренеп тора аның. Шуның өстенә ул бармак калынлык пыялалы күзлек кия, шулай да кәгазьнең өстенә үк ятып яза. Ә минем белән биллиард уйнаганда, йодрык хәтле шарның янына үк барып карый да, бик озак төзәп торганнан соң, «уң почмакка!» дип сугып жибәрә, ләкин шар бөтенләй сул якка тәгәрәп китә иде. Баштарак, шаяра бу, дип уйлый идем. Бактың исә, аның чыны шул икән.

Уен-көлке сүзле, мәзәкчән юлдаш белән юл кыска тоелса да, без тәүлек узганда гына Мәскәүгә килеп төштек. Бөтен Мәскәү эче урам сугышларына әзерләнгән. Ул чактагы башкала үзенең дошманына каршы корыч чәнечкеләрен тырпайтып, һәр минутта еланның башын чәйнәргә әзер торган тирән уяулык белән йомарланып яткан ниндидер гигант керпе төсле булып күз алдында калган.

Без Әхмәт Фәйзинең Калашный тыкрыктагы суык квартирында байтак көннәр уздырдык. Политик идарәдә безне тиз генә җибәрә алмадылар. Ә вакыйгалар һаман зурая, сугыш һаман кыза бара. Безнекеләр дошманны һаман ераккарак куалар. Тик без генә иске йорттагы суык бүлмәдә корыга кызышып ятабыз. Алай да бер юаныч бар: үзләрен күрмәгән-белмәгән батырлар турында, белгәндәй-күргәндәй, шигырьләр язабыз. Дошманга каләм белән атабыз.

Кичләрнең берендә без, ике беспартийный шагыйрь, мондый фикергә килдек: гражданнар сугышы чорында «Кызыл Армия», «Кызыл сугышчы» һәм башка исемнәрдә чыккан милли газеталар татар-башкорт кызылармеецларының сыйнфый аңын тәрбияләүдә, дошманга нәфрәт уятуда үз ана телләрендә күп хезмәт күрсәткәннәр. Бөек Ватан сугышының бүгенге иң киеренке, иң җаваплы көннәрендә дә, әгәр шундый газеталар чыга калса, бик зур патриотик эшләр башкара алырлар иде...

Иртәгесен, шушы фикерләрне кинәйтеп, политик идарәнең ул чактагы начальнигы Мехлис исеменә хат яздык та аның ярдәмчесе полковник Баевка кертеп бирдек. Тимерне кызуында сугарга, оясыннан кубарылган һәм үҗәт каршылыгы сына башлаган әшәке ерткычны үзлексез куарга, карга чумдырып кисәргә, азау тешләрен сындырырга кирәк иде ул чакта! Без дә шул пафос белән яшәдек.

1942 елда, январьның уннары микән, Муса килеп керде. Ул баштанаяк хәрби кеше хәзер. Шинелен салып куйгач, бөтенләй кызыктырып җибәрде ул безне: өстендә энәдән-җептән генә чыккан һәм үзенә таман гына килгән яшел китель, зәңгәр галифе чалбар, аягында хром итек, якаларында берәр шпал — өлкән политрук! Ул хәтта үсеп-калкынып, житдиләнеп киткән төсле тоелды миңа. Фәйзинең алгы бүлмәсендә озак сөйләшеп утырдык. Сүзләр дә гел житди темаларга барды бугай. Ул инде Марьино-Курск янындагы хәрби курсларда чакта сугышны күргән, хәтта дары исен татыган кеше дип әйтергә була. Ә без әле сугышны газета битләрендә генә кичерә торган яшел «батырлар». Өсләрдә дә Казан иске-москысы.

Авыз чылатырлык бер нәрсәбез дә юк иде безнең. Сүзне, диванга утырып, «коры кашык» белән генә алып бардык. Озак утырдык. Ниләр сөйләштек икән? Алар бит икесе дә шаян сүзне, мәзәк сөйләүне, көлүне яраталар иде. Ләкин ничектер хәтердә андый картина калмаган, сүзләрнең эчтәлеген дә тулысынча искә төшерү мөмкин түгел хәзер. Тик Мусаның бик житди итеп әйткән соңгы сүзләре генә онытылмаган һәм шул чактагы борчулы кыяфәте генә күз алдында тора. Ул болайрак дигән иде: «Политрук ул солдат белән бергә сугышка керергә тиеш. Үлүдән дә артык курыкмыйм, авыр яradан гарип булып калуың да мөмкин, сугыш — сугыш инде ул, мәрхәмәтсез. Әмма иң курыкканым — дошман кулына төшеп, мәңгелеккә рисвай булу. Дошманы да нинди бит аның — фашист! Ул синең бөтен кешелегеңне изеп таптаячак!..»

Мусаның мондый сүзләрен мин ул чакта бик үк аңлап бетермәгән идем. «Нигә болай нык борчыла икән Муса? Сугыш бит хәзер безнең файдага борыла бара. Беренче дәһшәтен өстән алып ташлап, немецка без тудырабыз хәзер куркынычны. Аларны алабыз пленга. Ә безнең кешеләр камалыштан меңәрләп чыга бара...» — дип уйладым. Әмма бу уйларның лаеш шулпасы эчмәгән кешедә генә булу мөмкинлегеп фронтка барып байтак хәлләрне күргәч кенә аңладым мин. Һәм Мусаның нинидер эчке интуиция көче белән үз язмышын алдан сизенгән булуын да төшенергә туры килде миңа.

Гәрчә бу сүз сәер яңгыраса да, мондый хәлнең мөмкинлегенә ышанып әйтәм. Чөнки кеше ул — әле үзе дә белмәгән олы талантлар серен, искиткеч могжизалар тудырырдай сәләтләр кодрәтен потенциядә саклый торган, берәү тарафыннан да әле тулысынча өйрәнелмәгән, ачылып

бетмәгән һәм, ихтимал, ачылып бетүе мөмкин дә булмаган бөек көч Акыл көче, эмоцияләр көче, физик көч. Хәер, физик көч буларак, хәзер Кеше әллә ни зур роль уйнамый. Бу эшне ул үзе тудырган һәм идарә итә торган техникага тапшыра. Аның идарә итү сәләте көннән-көн көчәя бара хәзер.

Әйе, Кешедә интуиция көче булуы бик мөмкин. Һәм ул көч булмаса ачышлар да, саклана белү дә, каршы тору көче дә булмас иде шикелле.

Кеше тулысынча өйрәнелеп һәм ачылып бетмәгән бөек көч диюем дә, үземчә, очраклы түгел. Мусаны мин биш бармагым шикелле белә дип уйлый идем. 1928—1941 еллардагы шактый еш һәм якынтын ара лашулар — әле егет чакта ук Мәскәүдәге Габделбәр Шәрипов бүлмә сенең идәнендә җыен яшь шагыйрь, тезелешеп ятып, төн буе уен-көлке сөйләшеп чыгулар, комсомол Үзәк Комитеты бинасының беренче ка тындагы бәләкәй генә бер бүлмәдә «Кечкенә иптәшләр» һәм «Ударник лар» журналын чыгарып ятулар, «Коммунист» газетасында берг эшләү, шул чорларда хәтта бер кызны яратып йөрү, Казан чорында өч-дүрт тапкыр бергәләп Васильевода, Түбән Осланда коллектив поэмалар язып яту һәм күп кенә бүтән эшләрдә, гаилә мәҗлесләренд бергә булулар миңа шулай уйларга нигез бирә иде.

Минем бер начар гадәтем бар: әгәр кеше бик җитди булып күренсә саран сөйләшсә һәм сүзләрендә елмаю яки иптәшлек җылысы сизел мәсә, мин ул кеше белән уртак тел таба алмыйм. Ул мине яратмый хәтта дошман күрә шикелле тоела башлый. Аннан инде бөтен җепләр кырылып төшә. Муса андый салкын холыклы булып чыкмады. Бе аның белән гади генә аралашып киттек. Дөрес, аның миннән өсте яклары шактый күп иде: ул инде күптән җыентык чыгарган кеше шагыйрь буларак танылган, журнал җитәкчесе, комсомол Үзәк Коми тетында да эшли, МГУда да укый — студент! Иң кызыктырганы һәм иң буй житмәслеге дә шул: Мәскәү университеты студенты!

Ә минем әле урта белемем дә юк. Мин әле кавалерия солдаты гына Тагын елдан артык хезмәт итәсем бар. Минскидагы вузга эзерлек курсларында укып йөргән булам. Белорусча укуы икеләтә кыенрак Хезмәтне тутыргач та тиз генә укырга кереп буламы әле?..

Шулай да танышлыкка ун ел тулганда мин дә вуз бетергән кеше булып киттем. Шул еллар эчендәге ижагыбыз да бер тирәдә, бер күләмдәрәк барды шикелле. Кыскасы, мин Мусаны үзем шикелле үгади бер шагыйрь итеп саный идем. Холкы да кырыс яки текә түгел хәтта йомшак яклары да, дилбегәсенең салпырак булуы да сизелгәли шуның нәтиҗәсендә ычкындыргалаган шәхси төгәлсезлекләре д күренеп куя һәм үзен еш кына әрнетә иде.

Бактың исә, Мусаның мин тышкырт-тышын гына белгәнмен икән Әнә бит ул нинди булып чыкты! Болай караганда гап-гади булы күренгән иптәшеңнең эчендә мәгълүм бер шартларда гына кабынып үсеп китә торган нинди потенциаль көчләр яткан. Аның тоткынлыкта – ерткычлык һәм үлем каршында уянган ирек көче, каршылык көч шундый хәтәр һәм изге көрәшне оештыра белү көче мине таң калдыра Күз алдына, беренче Муса урынына, бөтенләй икенче Мусаны, гажәп ләндерә торган мәһабәт Мусаны китереп бастыра. Шул ук үлем кар шына баскан килеш, юк, гади һәм табигый үлем генә түгел, ә дошман тоткынлыгындагы вакытсыз һәм тирән үкенечле, мең җәрәхәтле үлем каршына баскан килеш, шундый искиткеч лиризм, мәхәббәт һәм нәфрәт, кайнар пафос һәм ягымлы елмаю белән язылган шигырьләрендәге гажәеп көч мине шулай ук таңга калдыра. Бу ике дәфтәрне укыгач саен, минем күз алдыма тагын да яңа Муса, соклангыч олы талантлы мин белмәгән яңа шагыйрь килеп баса.

Гажәп хәл, корычны утта чыныктырган шикелле, әллә шагыйрьләрне дә «утка салырга» кирәк микән? Ниндидер бер җәнлек бар

имеш: аучылар аны башта бик озак куып йөриләр дә шул үлем куркынычы астында жәнлекнең тиресе тәмам агарып житкәч кенә атып алалар икән, чөнки шунда гына аның тиресе кыйммәтле була, имеш. Ә шагыйрь соң жәнлекмени?.. Борынгыдан килә торган мондыйрак сүз дә бар: шагыйрьне, имеш, бәхетсез мәхәббәт сагышы белән жәзаларга, кайгы-хәсрәт дәрьясына салырга, зинданга ташларга кирәк, шунда гына аның күңел жәүһәрләрен сыгып алу мөмкин...

Муса кичергәннәр боларның барыннан да көчлерәк һәм катлаулырак. Ихтимал, шуңа күрә дә, әгәр югарыдагы «фәлсәфә»гә ышансак, аның без белмәгән шундый сокланғыч сыйфатлары ачылгандыр дип уйларга була. Ләкин әлеге «фәлсәфә» һәр шагыйрь өчен уртак «закон» була аламы соң? Андый хәлләрдә бик күпләрнең бик тиз югалып калуы да мөмкин. Бар бит андый мисаллар да: кайберәүләр яу килгәндә ярга посалар да жан саклап калалар, ә яу узгач, батыр булып, барабан кагалар. Күрәсең, куркыныч авырлыклар һәм фажигале бәхетсезлекләр алдында коелып төшмәү рухи яктан бик көчле һәм бик талантлы шәхесләр өчен генә мөмкин эштер. Әнә шундый катлаулы шагыйрьләр, үзләренең алгы язмышларын мәгълүм бер дәрәжәдә интуитив сиземли алып, киләчәк адымнарына билгеле бер юнәлеш бирә белсәләр — бу гажәп түгел. Мусаның бөтен көче дә шунда: ул үлем куркыныч алдында айнык акылын жуймаган, хәрәкәт юлын, яшәү юлын эзләгән һәм тапкан. Аның әнә шул көче элек без белмәгән Мусаны китереп тудырган...

Мәскәүдә безгә аның белән еш очрашу мөмкин булмады. Ул Донской тыкрыктагы политсостав резерв йортында тора, анда хәрби тәртипләр кырыс булганлыктан, сирәк һәм кыска вакытка гына чыгаралар иде. Шуның өстенә, Мусага Столешниковтагы элекке квартирында да (Әминә белән Чулпаннан хат шунда килергә тиеш), Загорскидагы әби-бабаларында да булырга кирәк иде әле. Шул сәбәпле ул Калашный тыкрыкка еш килә алмый иде. Ә политик идарәгә чакырылуга ай тулып килгәндә микән, безнең кулга мондыйрак язу тоттырдылар: «До особого распоряжения вернуться в Казань...»

— Менә сиңа, теф-теф, кырык мимечне! — диде Әхмәт Фәйзи, язуны күз төбенә үк китереп укыгач.— Жиңде, кайтты Әхмәтша! (Ул шулайрак сөйләшә иде.)

Уйга калдык. Көтелмәгәнрәк хәл булды бу. Нишләргә соң? Сине шулай зурлап, банкетлар ясап, изге теләкләр белән озаткач, ничек итеп кире кайтып керәсең? Оят булыр шикелле төсле — уен эш түгел бит, фронтка дип чыгып киттек. Жир йөзендә моңарчы тиңе күрелмәгән канлы фажига бара. Язучы булган кешенең ничек моңа катнашмавы, ничек моны үз күзләре белән күрми калуы мөмкин? Англия шагыйре Байрон грекларның азатлык сугышына нигә барып керде икән? Ә бүгенге рус язучыларының инде нихәтлесе фронтта! Дөрес, без үзебезне Байрон яки Хеменгуэй белән чагыштыра алмыйбыз һәм алар чорының максаты да башка булгандыр, ләкин бүгенге максат ап-ачык: ул бер дә экзотика эзләү түгел:

Ничә югы, хәрби газеталарның әдәби хезмәткәре булып китү турында фикер алышып карадык та иртәгәсен яңадан политик идарәгә киттек. Сөйләшә торгач, минем бәхет «чиертте» — 61 нче армиянең «Боевой призыв» газетасына жибәрергә булдылар. Ә Фәйзигә урын табылмады. «Бәлки, бераздан...» — диделәр.

— Теф-теф,— дип кенә куйды ул, ачуы килде бугай.

Бер-ике көн эчендә мин язуларны ясатып, юл хәражатлары алып, хәрби киемдә киенеп жибәрдем. Шинель якасында минем дә бер яшел шпал хәзер — «интендант III ранга»! Сәер булып китте: бу «чин» язучы яки газетачы булуны бер дә аңлатмый инде, медик та түгел, ә бәлки азык-төлек — провизияләр кешесе булып чыгасың... Моның үзенә күрә

унайсыз яклары бар: сиңа «фәләнчәрәк» карыйлар: «Интендант — «тыл күсесе»,— ди усал теллеләр. Әйдә, хәерле булсын — кабыктамы ни эш!

Муса белән саубуллашырга теләп Донскойга киттем. Коридорда утырып кына сөйләшергә туры килде. Аның кайчан китәсе әле билгеле түгел икән. Политрук итепме, әллә матбугат эшчесе итепме жибәрү мәсьәләсе һаман хәл кылынмаган. Ул шуңа пошына иде. Язучы сугышта үз сөңгесе белән солдат булырга тиеш, аның сөңгесе — каләм, дигән фикердә идем мин. Мусаны да үземчә шул эшкә кыстадым. Бу мәсьәләнең шактый катлаулы икәнен, Фадеев аша гына хәл ителүе мөмкин леген әйтте ул. Бу хакта ул аңа язган да иде бугай инде... Без, тик арада яңадан күрешәсе кешеләрдәй, бик гади аерылыштык. Хәтта адреслар да алышмадык бугай. Чөнки минем дә «кыр почтасы» билгеле түгел иде әле, ул да резервта озак ятасы кеше түгел иде. Менә бу очракта инде безнең интуицияләр йоклаган булган, күрәсең. «Актык күрешү түгелме?» — дип, уйлап та карамаганбыз...

«Ничек итеп?..»

«Газета редакциясе Белев шәһәрендә»,— диделәр. Кайда икән ул бер дә артык телгә кергән шәһәр түгел, ул тирәләрдән йөргәнем дәюк. Шулай да бу исемнең кайчандыр колакка чалынганы искә төште. Уйлабрак карасам, моннан биш-алты ел гына элек тарих дәресеннән студентлык имтиханнары тапшырган чакларда булган икән. Алтын Урданың Олуг Мөхәммәт дигән ханы тәхет өчен үзара сугышларда жиңелгәч, Сарайдан куылып, шушы Белев тирәсенә килеп чыккан. Өч мең гаскәре белән шәһәрне камап торган, ләкин ала алмаган. Үзенә ясалган һөҗүмнәрдән саклану өчен боз кальга (ныгытма) корып шунда кыш чыккан. Ә язлыкта шуннан Казанга юнәлеп, аны сугышып алган. Тарихчылар Казан ханлыгын шуннан башлап йөртәләр. Мөхәммәтне казакъ ыруыннан булган, имеш, диләр...

Күпме гасырлар узганнан соң шул бәләкәй генә билгесез бер шәһәр тирәсендә тагын сугыш давыллары үкерә. Бөтенләй икенче төрле сугыш. Мин, гади бер татар улы, шул шәһәргә юл тотам.

Поезд Тула каласын үтеп китте. Ярты лаш яндырылган йортларны кара корым сарган: жимерекләр, күңелгә яра салып, ыржаеп калалар. Без боларны товар вагонының ачык ишегеннән карап уздык. Мондый картиналарны Мәскәүдән үк күрә башласам да, һаман ияләшеп булмый, ямьсез уйлар тудыра...

Горбачево станциясендә бомбежкага туры килә яздык. Ярый ла эшелон вакытында тукталып өлгерде, ут астына барып кермәдек. Моңа да күнегеп булмый. Мәскәүдә чакта мондый хәлне берничә тапкыр күрергә туры килгән иде инде. Бигрәк тә беренчесе хәтердә нык уты рып калган.

Әхмәт Фәйзинең шул суык бүлмәсендә яңа ел каршылый идек. Ерикәй дә килгән иде. Михаил Иванович Калинин сөйләде, курантлар сукты, беренче бокалны күтәрдек, авызга Казан колбасалары керде. Кинәт радио: «Һава тревогасы, гражданнар, бомбоубежищеларга!..» — диде. Аннан-моннан киенеп урамга чыктык. Аяз салкын төн. Күктә — самолетлар гөрелдәве. Зениткалар ата. Әле анда, әле монда шартлаган снарядларның кара бүрке, төнлә дә күренеп, һавада эленеп кала. Менә шул чакта нәкъ безнең баш очында гына, сыкылы һаваны чыңлатып яра-яра, ачы сызгырып бомба төшә башлады. Өчебез дә бер сулыш эчендә койма төбенә сыендык. Каядыр качу, убежищега чабу — мөмкин түгел, баш очында гына чыңлый бит. Тын да алмый көтәбез. Ниһаять,

һәләт суккан бомба каядыр төшеп, «чыңк!» итеп кадалды да шартлап ярылды. Безгә, бәхеткә каршы, бер җиле дә кагылмады.

— Бетте баш, теф-теф! — диде Фәйзи, чүккән жирдән беренче буларак калкынып. Мин дә көлеп куйдым, ә үзем эчтән калтыранам. Тик Ерикәй генә эндәшмәде. Гомумән, ул үз хәлен алай тиз сиздерергә яратмый иде. Шулай да өйгә кергәч, аның төсе ап-ак булганын күреп, без яңадан көләргә — үртәшергә тотындык. Иртәгесен газеталардан мәгълүм булды: әлеге безнең «баш очында» чыңлаган бомба каядыр Останкино тирәсенә төшеп ярылган икән...

Төн урталары күптән узган, инде кышкы таң беленер чакта, поезд Ока ярына килеп туктады. Ул артык бара алмый, бу тирәдә әлерәк кенә булып узган каты сугышларда тимер юл күпере шартлатылган. Капчыкларны аркаларга киеп, вагоннардан төштек тә шпал буйлап атладык, күпер төбеннән боз өсләтеп елганы кичтек. Анда эшләп яткан хәрби саперлар безгә ашыгырга куштылар. «Таң яктыра башлау белән немец бомба коярга тотына, күперне аякка бастыртмаска маташа»,— диделәр. Аргы яктагы текә ярга күтәрелеп, бәләкәйрәк бер авылга килеп кердек. Ул шәһәргә орынып кына тора диярлек, ә исеме Дураково икән. Сәер булып куйды. Бик ерак заманнар тиз генә күңел күзеннән узды. Мондый исем хәзер көлке дә булып яңгырый кебек, ачуны да китерә. Нигә алыштырмадылар икән?.. Хәер, мин иртәрәк кытыкланганмын, озакламый белергә һәм күрергә туры килде — бу районда Дурнево дигән бер авыл бар икән әле. Ул гына да түгел: Хлоповка, Глуповка, Балдаво, Блохино дигән авыллардан да узган чаклар булды. Әллә ничек, Гоголь һәм Щедрин романнары эчендә йөрим шикелле тоела башлады...

Битләрне шактый нык куырып ала торган җилле иртәдә шәһәрнең олы урамыннан атлыйм. Белев — күпчелеге агач йортлардан торган гади бер өяз каласы икән. Сугыш аның яртысын диярлек утка ялматкан. Тимер юл эчендәге элеваторның янгыннан калган хәрабәсе янында кап-кара бер очлы тау күренә. Шул көнне үк белдем: бодай көшеле булган икән ул. Немецлар чигенгәндә яндырып киткәннәр аны.

Шушы олы урамның аргы башына урнашкан редакцияне эзләп таптым. Халык иртәнге эш белән мәшгуль иде. Мине дә утырттылар. Өстәлгә чикмәнле бәрәңге, бәләкәй бер тозлы вобла һәм көйдереп тарткан имән чикләвегеннән пешерелгән төсле кап-кара ипи килде. Бу — әлеге янган бодай икмәге икән...

Аралашып китү кыен булмады. Газета редакторы Пекерман иптәш тә караңгы чырай күрсәтмәде. Дөрес, минем язучы булып та хәбәрчелек хезмәтенә килүем аны беркадәр сәерсендерде булса кирәк, шулай да ул моны артык төпченмәде. Аның яныннан чыгуга, шагыйрь Павел Железнов белән сөйләшеп киттек. Ул бик әйбәт, кече күңелле егет булып чыкты. Үзенең вокзалларда, кесә тирәләрендә, детдомнарда һәм чекистлар тәрбиясендә булуларын сөйләп көлдереп бетерде. Шул чакларда шигырь яза башлап, Горькийга мөрәҗәгать иткән һәм Алексей Максимович аны олы юлга чыгарган. Без аның белән дуслашып алдык. Калган иптәшләр төрлесе төрле милләттән: редактор урынбасары Пинчук — белорус егете. Редакция секретаре Яковенко — украин, аның ярдәмчесе Петр Евдокимов — чуваш, хәтта татарча да сукалый. Димәк, халыклар дуслыгы җыелган монда!

Ике көннән соң Павел Железнов мине алгы кырыйга алып барды. Урәчәле, кабыклы гади бер авыл чанасына шактый мул итеп салынган печән өстенә кырын ятып чыгып киттек. Үрле-тигезле ап-ак кырларга бормаланып яткан авыл юлы. Кичке эңгер-меңгер һаман куера бара. Ул елны имансыз кышның сулышы да куырып ала торган сыкылы суыгы гәүдәләрне капшамакчы була. Ләкин миңа тиз генә үтәрлек түгел. Аякларда әле Казаннан ук алып чыккан бик жылы мех унта белән резин галош, сырган чалбар. Өстә яңа шинель, аның астыннан мех сырма,

аның астыннан җылы эчле күлмәк-ыштан. Башта — яңа мех колакчын, Железновта да кыска тун, сырма чалбар, киез итек. Карылып карасын суыгың!

Бу — якын позиция икән. Без инде бер-ике сәгатьтән тау өстендәге бер авылның кырыйдагы бер кирпеч йортында — батальон штабында яши идек. Железнов та, мин дә, блокнотларны чыгарып, командир һәм политруклар белән сөйләшә башладык. Железновка фашистлардан көлә торган кызыклы хәлләр кирәк. Ул газетада «Андрей Снарядкин» имзасы белән сатирик фельетоннар-парчалар биреп бара икән. Миңа — яхшы сугышкан, батырлык-кыюлык күрсәткән солдатлар турында хәбәрләр кирәк. Мин шуларны язам һәм алар шактый күп булып чыкты.

Шулай сөйләшеп-язып утырганда ишектән озын буйлы, шадра йөзле бер кеше килеп керде. Өс киемнәрен салып ташлагач, бу кеше миңа таныш булып чыкты: сугышка хәтле нәшриятта эшләгән һәм матбугат йортында һәр көн очраша торган Ишиев иде ул. Билгеле, шау-гөр килеп күрешү, Казан хәбәрләрен сорашу китте. Ул «Смерш»та эшли икән. Ә мин аның нәрсә икәнен белмим.

— Смерть шпионам! — ди ул. — Особый отдел кешесе.

Аңладым...

Без сөйләгән арада ул нәрсәдер «мәтәштерә» башлады. Һәм, озак та үтмәстән, өстәлгә бер зур табада кыздырылган, бик тәмле май исе чыгарып торган итле карабодай боткасы килеп утырды, аннары каяндыр бер фляга пәйда булды...

Безне табынга чакырдылар. Алюминий һәм эмаль кружкалар белән чәкештек. Беразга гына икеләнеп тордым да эчеп җибәрдем.

Боткалары чынлап та шәп булып чыкты. Мин аның ләззәтле тәмен бүген дә тоям шикелле әле. Гажәп: кешеләр, вакыйгалар, сөюләр һәм үлемнәр генә түгел, ашаган ашның да кайбере озак вакытлар онытылмый икән...

Шул ботканы мактап, көлешә-көлешә утыра идек, атыш башланды.

— «Кичке салют», — диде берсе. — Мина яудыра...

Өстәл тирәсендәге егетләр, берәм-берәм, шау-шусыз гына өй базына төшеп тулдылар. Моны алар, инде йөз тапкыр кабатланган табигый һәм мәҗбүри кагыйдә сыман итеп, ашыкмый гына, паникасыз гына эшләделәр. Павел Железнов та алар артыннан иярде. Мин ике тәрәзә арасында утырам. Калын стеналы итеп кирпечтән салынган өй (бу якта шундый өйләр еш очрый). Минем арка артында да шундый ук калын, ышанычлы калкан — мина да, снаряд та тишеп үтәрлек түгел... Алгы кырыйга беренче килгәндә үк, беренче атыш тавышын ишеткәч тә базга йөгерсәң, куркак дип, күзеңне дә ачырмаслар, һич югы, артыңнан көлеп калырлар, редакциягә дә ишетелер...

«Шөр-шөр» дигәнең эчне бик тырнаса да, ике тәрәзә арасыннан кымшанмаска тырышам. Юк, батыр булып күренер өчен түгел, куркак булып күренмәс өчен! Аның өчен дә шактый зур тырышлык кирәк икән. Әгәр йөзендәге кан алсуы качып, күзләрең чәйнек калаедай елык-елык килә башласа, әгәр гәүдәң нормаль хәрәкәтен жуеп, калтыравык ыгы-зыгы башласа, беттем диген, син инде фаш буласың, сиңа кызганычлы һәм түбәнсетүле көлү белән карый башлыйлар...

Атыш басыла төште. Баздагылар, тәмәкеләрен суыра-суыра, өскә менделәр. Павел Железнов кайту ягын ашыктыра башлады. «Белеп булмый төнгә каршы нәрсә буласын...— ди ул миңа, ярым пышылдап.— Тыныч чакта ычкынып калыйк... Синең бит әле кулында коралың да юк. (Чынлап та, минем пистолет фәлән юк иде, хәтта винтовка да алып чыкмадым.) Бәлки, ата да белмисеңдер әле...»

Моңысына инде минем хәтер калды. Сөзәеп бер карап куйдым да: «Я — ворошиловский стрелок!» — дип, авызын капладым тегенең. Бу — шапырыну түгел иде. Студентлык елларында мин, чыннан да, ул нормаңы тапшырып, күкрәккә значогын кадап та йәргән идем.

Өйалдына чыктык. Ишиев кесә фонаре белән безгә юл яктырта. Килеп кергәндә абайламаган идем: монда өйгә орынып ук торган абзар бар икән. Бер-ике метр читтәрәк ала сыер басып тора, аның муеннынан кара-куе кан тама, үзе пуф-пуф килә...

— Бәрәч, бу сыер нишләгән? — дип, Ишиев аның янына атлады. — Яраланган бит бу, понимаешь! Ул фонарен өскә таба борды, салам түбә зур гына булып ачылып киткән, шул турыдагы агач аратаның бер өлеше коелып төшкән.

— Аңа каян осколок килеп кергән! — дип аңлатты ул мишәрчәләбрәк.

Монда инде минем эчкә бөтенләй куян керде. Железнов та ашыкты. Тиз генә ишек алдына чыктык. Печәнгә кушып калдырган атыбыз исән-сау икән. Җәһәт кенә борып, чанага аудык та авылдан чыгып ычкындык...

Соңыннан белдем: минаның траекториясе — конус рәвешендә икән: вертикаль турылыкта диярлек өскә менә дә һәм шул тикәлектә жиргә төшә. Шулай булгач, минем тәрәзә арасындагы калын стенага аркаланып минадан саклануым кәмитнең дә кәмите булган икән. Бу әле батальон штабы гына иде бит, ә алгы кырыйның үзендә, солдат янында ничек икән ул?

Иртәгесен солдат батырлыгы турындагы хәбәрләремне бик һәйбәтләп, кыска-кыска язып, редакция секретарена тапшырдым. Ул аларга күз йөгертеп чыкты да сызгырып куйды, хәтта әче итеп сызгырды. Аннары миңа карады.

— Нәрсә, бер дә хәбәр язганыгыз юкмыни сезнең? — дип куйды бу. Ни диргә белмичә, аптырап калдым. Ниндидер мыскыллау сымак тавыш бәгырьгә тукынды шикелле... «Язганым юкмы? Әле 1922 елдан ук башлап «Азат Себер», «Коммунист» (Урал), «Эшче», «Игенчеләр», «Крестьян газетасы», «Кызыл яшьләр» һәм башка газеталарда күпме хәбәрләрем чыкты икән минем! Үзем дә редакцияләрдә аз эшләмәдем. Э хәзер, фронт газетасына килгәч — шушындый сорау». Кызармаслык та түгел шул. Секретарь, минем хәлемне үзе дә аңлагандай, аз гына елмаеп алды да бер хәбәрне укып чыкты: «Кызылармеец Моргунов фашистларга каршы батырларча сугыша, күренгән берсен чүкеп кенә тора, иптәшләре кыен хәлдә калса, аларга да булыша. Ул күптән түгел «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде...»

— Бик әйбәт сүзләр! — диде ул аннары. — Ләкин гомуми сүзләр. Моны укыган солдат нинди үрнәк ала үзенә? «Ничек итеп?» дигән сорау алдында аптырап кына кала инде ул. Менә шул «Ничек итеп?»кә җавап бирергә кирәк. Ничек итеп батырлык күрсәтә? Ничек итеп кенә чүкеп тора? Ничек итеп иптәшләренә булыша? Нинди шартларда, нинди сугышта нинди тапкырлыклар күрсәтеп медаль алган? Кайсы бүлекчәнеке, исеме ничек? Хәбәр менә шушы сорауларның барына да ачык һәм бәйнә-бәйнә җавап бирергә тиеш. Хәбәр ул — кечкенә генә хикәя дигән сүз. Моның өчен политрук яки командир белән сөйләшү генә житми, ә сугышчының үз янына, окопка хәтле барып житәргә һәм үзе белән сөйләшергә кирәк!..

Бу минем өчен онытылмас сабак булды һәм хәрби хәбәрчеләрнең беренче серләре шуннан ачылып китте. Шуннан соңгы дүрт ел буена, кайсы гына частька барсам да, кем белән генә сөйләшсәм дә, «Ничек итеп?» дигән бик кирәкле сорау колак төбендә гел яңгырап торучан булып калды...

«Хәбәр дә яза белмәүче жебеки булып чыктың!.. Менә сиңа «шагыйрь!» — дип, үз-үземне әрләп кире жибәрүләреннән шактый куркып йөрсәм дә, алай тиз генә юкка чыгармадылар тагы.

Дивизияләр буйлап берүзем сәяхәт итә башладым һәм китергән материалларым да гел яраксыздан булмыйлар шикелле. Эшли башлавыма ай да тулмастан, күп хәбәр һәм зарисовкалардан тыш, «Лейтенант Косинский» дигән беренче очеркым басылды. «Бу бит Армия газетасында, рус телендә — өч колонкалык!» — шул сүзләрне авыз эчемнән генә кабатлый-кабатлый, сабыйдай сөенеп йөри бирәм.

Бу армиянең күпчелек дивизияләре Урта Идел буе шәһәрләрендә формирование үткән. Шуңа күрә кайсы гына частька килеп чыксаң да, таныш яки таныш булмаган якташлар белән очрашырга туры килә. Менә бүген, Косинский турындагы очерктан соң 15—20 көн узып, шул ук артполкка яңадан сугылгач, мине бер «интересный кыз» белән таныштырдылар. Хәрби врач Зенин бу кызның соңгы бер айлык сугышларда йөздән артык яралыны ут эченнән алып чыгып, беренче ярдәм күрсәтеп, тиз арада санбатка озатуын, хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителүен, сугышчыларга карата кече күңелле, йомшак телле булуын, партия сафына алынуын һәм тагын бик күп әйбәт сыйфатларын сөйләп узды. Ә кыз үзен бик ныклы йозакта тота, аңа тел ачкычы табу шактый кыен булып чыкты. Берет астыннан ташып чыккан кыска кара чәче, гел елмаеп торган кара кашлы кара күзләре, киң, якты маңгайлы түгәрәк йөзе тик торуны белмәгән жиңел-жыйнак гәүдәсе — бу кызның эчкерсез гади һәм саф күңелле булуын, эчке бер сөйкемлелеген һәм «ут борчасы» икәнлеген күрсәтеп тора иде. Билгеле инде, мине «Ничек итеп?» мәсьәләсе кызыксындыра. Ә кыз ничек итеп батырлык күрсәткәнен сөйләми. «И, аның нәрсәсен сөйлисең, абый,— дип, жилкәләрен жыерып кына куя.— Батырлык дисәләр, көләсе килә... Хәрби фельдшер булгач, сугыш кырындагы яралыга ярдәм итмичә, нишлисең инде, сызгырып торырсыңмыни?..» Үзе ут күзләрен елтыратып көлә...

Сүз авыл өендәге медпунктта бара. Анда башкалар да бар, тышта сөйләшеп булмый — кыш. Шулай да аны бер почмаккарак алып татарча сөйләшә башлыйм:

— Исем-фамилияң ничек? Кайсы яктан?

Ул, әлеге якты күзләрен тутырып, миңа карады.

— Суфия Нәбиуллина... Татарстаннан... Красный Бор районы, Умга авылы...

— Менә бит, нинди якын якташлар икәнбез! Мин — Казаннан, кырыгынчы елны гына авылыгызда булдым...

Суфия инде яныма ук елышып утырды.

— Нәрсә, әллә кунакка барган идегезме, абый? — дип куйды ул, сабыйларча беркатлылык белән.

— Юк, әкиятләр жыеп йөрдем...

Кызым бөтен өй эчен яңгыратып көлеп жибәрде:

— И, сөйлисез дә инде, әкият жыеп йөргән, имеш!.. Нәрсәгә кирәк ди ул?..

Аңлатырга туры килде. Аның авылдашы Тажи абзый Гыйззәт белән кара-каршы йортта торуыбызны, аның әсәрләрен бик яратып каравымны, хәтта дус булуыбызны әйтеп уздым...

Без озак утырдык. Ниһаять, аның да теле ачылып китте һәм үз башыннан кичкәннәрне ашыкмыйча гына «сүтә» башлады. Әле бары тик егерме яшьлек бу кыз балага — өстенә яшел гимнастерка киеп, билен киң каеш белән буган, якасына ике кубик кадаган, сырма чалбар һәм киез итек кигән бу хәрби фельдшерга сокландым мин. Турыдан-туры ут

эчендә йөргән һәм миңа беренче тапкыр очраган татар кызының озын хикәясен блокнотка яза-яза куллар талчыгып бетте...

Тик бу материал шул көйгә ятып калды. Ул, һич югы, бер ай утырып, әдәби әсәр хәленә китерүне сорый иде, армия газетасындагы хәбәрчегә андый мөмкинлек каян тисен? «Татар кызы» дигән егерме юллык шигырь белән генә чикләнергә туры килде. Калган эшкә кар ява... Ява торгач, 28 ел узып та киткән.

Ә мәнге тере, шат һәм уенча күңелле Умга кызының сөйкемле сурәте күз алдымда һаман басып тора... Сүзне мин аның үзенә бирәсем килә:

— Аның инде бер дә әллә нәрсәсе юк, абый, — дип башлады ул, әкрен генә тавыш белән. — Авылда җидене бетергәч, Казанга килеп медтехникумга кердем. Туганнарым бар иде — ярдәм иттеләр. Тәмамлап, больницага эшкә керешүгә, фин сугышы башланды. Коллектив исеменнән үз теләгем белән фронтка китеп бардым... Анда эшләр кызу булды: көн-төн баш та күтәрми яралыларга ярдәм күрсәтү, госпитальләргә озатудан бушамадык. Сугыш кырында мина кыйпылчыгы үземне дә яралады... Яхшы әле, ул сугыш тиз бетте. Ярам төзәлгәннән соң, мин кадрда калдым, укырга җибәрделәр. Тик тәмамлап булмады — менә бу сугыш башланып китте. Аның беренче көннәрендә үк безне, өч хәрби фельдшерны, майор Гараган командасындагы артполкка җибәрделәр... Фин сугышы репетиция генә булган икән, бусы үзәкләргә үтте. Искиткеч авыр һәм әрнүле чигенү көннәрен һич онытасым юк. Әйтеп бирә белермен микән: корал тотып сугышучылар дошманны туктата алмауга, позицияләрен, туган җирләрен калдырып чигенергә мәҗбүр булуларына үкенәләр, ә мин күзләре мөлдерәп җирдә яткан яралыларны калдырып китәргә мәҗбүр булуым өчен елый идем. Мин генәме соң? Һәр санитар, һәр фельдшер, һәр медик шулай. Сабыйдай тилмереп сиңнән коткару көткән яралыны калдырып китүдән дә авыр һичнәрсә юк. Шәфкатьсез, имансыз булып тоеласың, вөҗдан газабы изә...

Сентябрь башлары иде бугай, Чернигов өлкәсендәге сугышларда камалышка эләктек. Прилуки шәһәреннән тәртипсез чигенгәндә өченче дивизионны югалттык. Капитан Волобойко җитәкчелегендә 15 кешелек төркем аны эзләргә китте. Төркемгә мине дә алганнар иде. Абайламастан немец автоматчыларына эләгеп, көчкә котылдык, машинабыз сафтан чыкты. Җәяүләп бара торгач, дивизионны эзләп таптык. Алар, туры наводка белән атып, бик каты сугышып яталар иде. Шул чакта безнең тылдан немец танклары килеп чыгып орудиеләргә ата башлады. Капларга пехота-фәлән дә юк, дивизионда исән калган берничә орудие ике фронтка атыш алып барырлык түгел. Аларның боевой частьларын сафтан чыгардык та төрле якка йөгердек, үзәнгә таба үрмәләдек. Бер заман, якын-тирәмдә беркем дә юк, үзем генә калдым бугай дип, куркынып баш калкытсам, артымнан дивизия командиры Брыга килә. Әй, сөендем дә соң шул чакта!

Башкалар каядыр таралып бетте, без икәү генә юлдан атлыйбыз. Кичке якта, икенче дивизион машинасы очрап, безне утыртып алып китте. Әмма кая гына борын төртсәң дә — немец, чыгар юл юк. Оржица дигән урында безнекеләр оборона коралар иде, дүрт көн аларга булыштык. Авыл читендә зур сазлык, шуның аркылы переправка ясаганда үзебезнең тылга чыгарга мөмкин иде, ә дошман һич кенә дә ирек бирми... Бик күп яралы калды безнең анда, бик күп... Чөнки беркая озатырга мөмкинлек юк... Бәйлим, юаткан булам, ә кулымнан берни килми. «Сестра, голубушка, отправь нас»... — диләр өзелеп. Ә минем кычкырып елыйсым килә! Ә медик каты күңелле булырга тиеш, яралы солдат аның күз яшен күрмәсен...

...Шулай да без моннан китәргә, бу җәһәннәмнән тизрәк ычкыну юлын эзләргә тиеш булдык. Егермеләп кеше җыелдык: сугышчылар,

командирлар — төрле часть кешеләре — бергәләп юлга чыктык. Кичке эңгердә бер агымсу буена килеп житкәч, немец десантына эләктек. Котырып ут ачтылар. Биш кешебез яраланды. Караңгы төшкәч, мин аларның яраларын бәйләдем. Төнлә ул елганы кичтек. Яралыларны мылтыкларга аркылы бәйләгән каеш носилкалар белән алып чыгарга туры килде. Иртәгесен, таң белән үк, исән калган иптәшләр алга юнәлде. Мин яралылар белән калдым.

— Син кайгырма, Соня, — диде Брыга. — Беренче машина очрау белән үк мин аны монда алып килермен һәм без, яралыларны төяп, төркемне бик тиз куып җитәрбез...

Су буенда утырып көн буе көттек, командирыбыз да килмәде, бүтән берәр машина да күренмәде... Кичен салкын төште. Сентябрь бит, туңа башладык. Якында бәләкәй бер авыл күренә. Ике авыр яралыны ике ягыма култыклап алдым, хәлләре җиңелрәкләр аларны икенче яктан култыкладылар, шулай җитәкләшеп атлый торгач, кырыйдагы бер өйгә килеп кердек. Өйдә һичкем юк, урамда да күренмиләр. Арыган, ачыккан килеш йокларга яттык. Иртәгесен: «Русь, фестафай!», — дигән тавышка күзләремне ачсам, котларым чыкты — автоматларын безгә төзәгән ике немец ишек төбендә басып тора. Тиз генә комсомол билетымны яшереп өлгердем. Шуннан безне икенче бер авылга китерделәр дә, анда җыелган яңа төркемгә кушып, җәяүле колонна белән алып киттеләр. Утыз биш километр буена гел йөгертеп алып бардылар. Минем белән булган яралыларны, йөгерә алмыйча егылган саен, ата бардылар. Ата бардылар... Борыласым, алар янына чүгәлисем килә — булмый. Үзең дә шунда ятып калачаксың... Шулай итеп, төркемдә мин белгән беркем дә калмады хәзер...

Суфияның кинәт тавышы сынып китте, башын түбән иеп, читкә борды. Озын керфекләрен сирпелдергәләп куйды. Бу аның күз яшен күрсәтмәскә теләве һәм тиз генә, керфек очларын кагып, төшерергә тырышуы иде. Ул үзен шундук кулга алып өлгерде булса кирәк, яңадан әвәлге тавышы белән дәвам итте:

— Безне Хорол дигән шәһәргә китереп, биек таш коймалы бер ишек алдына тутырдылар. Монда инде әллә нихәтле әсир бар иде... Аннары мине хатын-кызлар янына — бүлмә сымак бер жиргә керттеләр. Анда ничаклы гына кысан булса да, шундый газаплы юлдан соң бер почмакка баш төртеп, үлеп йокыга киткәнмен. Иртәгесен алтыдан үк дөбер-шатыр куып ишек алдына чыгардылар. Озакламый шәһәр хәлкы икмәк белән бәрәңге китереп койма аркылы ишек алдына ташлады. Монда инде кешеләр атна буе икмәк төсе күрмәгән булганнар, мин дә өч көн ашамаган идем... Китерелгән ризыкка бар әсир кинәт ябырылды. Сакчылар атарга тотынды. Ач кешенең ачуы яман дигәндәй, безнекеләр дә ташмы, таякмы белән каршылык күрсәтә башлады. Шул чуалыш вакытында халык, дәррәү йөгерешеп, коймаларга ташланды, мин дә йөгереп килеп коймага сикердем, ләкин менә алмыйм, кабаланам, кулым калтырый. Бөтенләй мине белмәгән сугышчы әсирләр күтәреп менгерделәр. Мин алар белән бергә теге якка егылып төштем. Койма эченнән чыккан кешеләр тиз генә төрле якка кача баралар. Немецлар хәзер утны бу якка да күчерделәр. Мин дә, күз ачып йомганчы якындагы бер ишек алдына ятып, абзар почмагына сыенып тордым. Бер өч сәгатьләрдән соң ату тавышлары тына төште. Бу ишек алдындагы өйнең ишек төбендә бер хатын күренде. Нидер тыңлап торгандай итте дә тагын өйгә кереп китте. Нишләргә соң? Һаман бу почмакта посып торып булмый, немецлар эзли чыксалар, хәзер үк тотып алачаклар... Өйгә керсәм ни булыр? Андый-мондый дошман кешеләргә эләкмәмме?.. Шулай да, шикләнә-куркына булса да тәвәккәлләп, әкрен генә өйгә барып кердем. Анда өч хатын-кыз бар иде. Алар мине тиз генә өй базына яшерделәр. Шунда кичкә хәтле утырдым, шунда тамагыма ашаттылар,

шунда украинча кием киендерделәр. Өйдә кичке ут алынган иде инде — мин бөтенләй украин кызы булып баздан чыктым. Ул өчәүнең берсе минем шикелле үк яшь бер кыз иде. Исеме Катерина, үзе студентка һәм комсомолка икән. Ул мине калырга кыстый: «Бергә эшләрбез, немецларга каршы астыртын көрәшербез»,— ди. Ә мин аны үзебезнең якка чакырам.

— Мин хәрби фельдшер, мин анда кирәгрәк, — дим. — Сина да бик тиз эш табылыр: үзебезнең артполкта ук медсестра итеп урнаштырам!

Икебез бер урында яткан килеш төн буе бәхәсләшеп чыктык. Чынлап та, партизан булып яшерен көрәштә мин ни дә булса зур эш майтара алырмынмы — белә алмыйм. Ә менә яралыны сугыш кырыннан алып чыгу, бәйләү, коткару — бу иң изге эш минем өчен! Яралының бит актык өмете генә кала: сафтан да чыктым, гарип тә булып калырмын, инде тик үлмәсәм генә ярар иде...» — дип уйлый ул. Менә шул актык өметең сүндермичә, аны әҗәл авызыннан тартып ала белсәң, ин зур бәхет шунда.

Катяны күндерә алдым. Иртәгесен без юлга чыктык. Немецлар шоссе буйлап Полтавага киләләр иде. Без, украинча авыл киемендә булгач, алардан бик курыкмасак та, саклык өчен авыл юлларын уратып, сукмаклардан атладык. Кунган җирләребездә окоптан кайтучылар булып сөйләшәбез. Сүзне күбрәк Катя алып бара. Җирле телдә сөйләшү безгә күп ярдәм итә. Һәр урында безнең хәлебезгә керәләр. Тыныч йоклатып, тамагыбызны туйдырып, юлыбызга да биреп чыгаралар. Шулай итеп без тугыз көн буена килдек. Тугыз көн буена ниләр генә сөйләшмәдек икән без! Биографияләр дә ачыкланды, егетләр мәсьәләсе дә тикшерелде, тик икебезнең дә өзелеп сөйгән кешесе юк булып, күңелләр әле буш булып чыкты ул чагында...

— Ә хәзер ничегрәк соң, буш түгелме? — дип шаяртып куйдым мин.

Суфия оялган чырай белән башын түбән иде:

— Бүлдерәсез бит, Маннур абый, сүзне саташтырасыз... — дигән булды ул һәм яңадан хикәясен дәвам итте:

— Ә шулай да тугыз көн бик озак икән ул, тора-бара сөйләшер сүз бөтенләй бетеп китә, ә сүз беткәч, арыганлык-алҗыганлык икеләтә ныграк сизелә башлый. Моны икебез дә аңлыйбыз, шуна күрә авызларны йомык тотмаска тырышабыз. Шундый чакларда Катя «Катерина» дигән озын шигырь укый. Ул бик матур яңгырый, украин теленең йомшак музыкасы күңелне тибрәндерә. Катя әйтеп бирде: Тарас Шевченко язган поэма икән ул. Шунда мин дә үз Тукаебыз белән мактанырга телим, аның «Шүрәле»сен укып күрсәтәсем килә. Мин аны әле бала чактан ук яттан беләм бит, югыйсә... Ләкин булмый, мин татарча укудан нәрсә аңлар ул? Ә русчасы бар микән — мин белмим. Катя тынып калгач, авызны тик тотмас өчен мин бүтән бер эш уйлап табам: сумкада калган бинт кисәкләрен тартып чыгарам да яралыны шчек бәйләргә икәнен күрсәтәм, санитарлык кагыйдәләрен сөйлим.

— Өйрән, картайган көнендә бер кирәге булыр! — дигән булам. Көлешәбез, тагын җанланып китәбез, арыганлык онытыла, юл да кыскаргандай була...

Ахырда бер иртәне туп тавышлары ишетелде, снаряд ярылып, төтене югарыда эленеп калды. Шулхәтле сөендек: турыдан-туры шул төтенгә карап басулар өстеннән элдертә башладык. Ул төтен бик ерак, егерме биш-утызлап чакрымда булып чыкты. Ул көнне без илле чакрымлап бардык, аяклар кабарып бетте. Юлда сораштырып белүебезчә, дүрт чакрым алда Псел елгасы, анда фронт сызыгы икән — бу якта дошман, теге якта безнекеләр... Төнге икеләргә хәтле печән кибәне астында яшеренеп яттык та елгага үрмәләдек. Күпер, әлбәттә, юк. Комсомол билетларын су үтмәстәйрәк җиргә кыстырып, киемнәрне башка урадык та сак кына йөзеп киттек. Немецлар берни сизмәде, ә безнекеләр — теге ярга чыгу

белән тотып алдылар. Егерме тугызынчы сентябрь иде бу. Сакчы кызылармеецлар ышанмыйлар — кулларны күтәртеп штабка алып киттеләр. Чыланып беткән шәхси таныклык белән комсомол билетларыбызны күрсәткәч, анда ышандылар. Шундук ашарга китерделәр, коры киемнәр биреп, бер өйгә урнаштырдылар. Тәүлек буена уяна алмый йокладык. Тагын бер тәүлек ял иткәннән соң, безне Харьковка җибәрделәр. Анда безгә аерылышырга туры килде... Юлда өйрәткәннәрнең бер файдасы тиде тагы: Харьковта Катя яңа оеша торган частька үз теләге белән санинструктор булып урнашты. Мине Куйбышевка җибәрделәр. Аерылышканда, кочаклашып бик озак елаштык... Ул чакта адреслар да алмаша алмадык — юлларыбыз билгесез иде. Исән микән ул хәзер, хатлар да алышу мөмкин түгел. Мин аны бик сагынам һәм күңелемнән тирән рәхмәтләр укыйм. Шул батыр украин кызы Катя юлдаш булмаса һәм үз киемнәрен киендереп алып чыкмаса, мин ничек шундый ерак һәм куркыныч юллардан әйләнеп кайта алган булыр идем?..

Суфия, чынлап та, әле генә шул авыр газаплардан котылган һәм җиңеләеп киткәндәй бер хәрәкәт белән башын калкытып елмая төште һәм:

— Менә, медицина солдатының гади хикәясе шушында бетте дә инде, — дип куйды ул. — Куйбышевта миңа артполктагы элекке командирым майор Гараган очрады. Полк, каты сугышларда күп югалтуларга дучар булып, хәзер формированиегә күчерелгән икән. Командир мине янадан үз частена чакырды һәм мин бик теләп риза булдым. Чөнки яхшы кеше ул, кыю артиллерист, аны яратмаган кеше юк...

Мәскәү тирәсендә каты сугышлар башланып, безнекеләр немецны көн-төн куа башлагач, без дә озак юанмадык — Ефремованың бу ягында сугышка кердек тә, яу кырында үрмәли-үрмәли, Волхов урманнары төбенә килеп җиттек...

Кызның шушы урында сүзе бетте. Мин дә, бу әйбәт хикәяне нишләтергә кирәклеген күз алдыма китерә алмыйча, аптырап калдым. Чөнки ул чакларда камалышта калу да, аннан шундый кыенлыклар белән чыгу да батырлыктан саналмый, шуңа күрә язуы да кыен иде. Ичмаса, газетада аның хакында берәр зарисовка шикелле нәрсә бирәсем килеп, соңгы сугышларда күпме яралыга «ничек итеп» ярдәм күрсәтүен белергә теләдем. Суфия кул гына селтәде:

— Аның сөйләп торырлыгы юк бит, абый, бәрәңге ашау төсле үк гади эш инде ул, — диде...

Шуннан соң ничектер мин аны очрата алмадым. Аннары бөтенләй икенче фронтка китеп бардым. Еллар узды, сугыш бетте. Бер заман миңа илле яшь тулды. Юбилей ясап, котлап та алдылар. Шул көннәрнең бер кичендә телефон шалтырады. Трубканы алуыма, таныш булмаган бер тавыш сөйли башлады:

— Иптәш Маннуров, сезне бәйрәмегез белән чын күңелдән котларга рөхсәт итегез...

— Кем соң бу? — дидем аптырап, тавышны һаман таный алмыйча.

— Бу — элекке лейтенант, хәзерге полковник Косинский, — диде ул шаянрак тавыш белән.

Тагын да аптырабрак калдым. Чөнки унөч ел гомер узып киткән. Шуның өстенә — ул Ленинград егете иде, ә сөйләшүе моннан...

— Ничек соң сез Казанда? — дип кычкырдым механик рәвештә.

— Соня алып кайткан иде мине... Без аның белән өйләнешкән идек... — диде ул, инде бөтенләй икенче бер сагышлы һәм хәсрәтле тавыш белән.

Озак сөйләштек. Сугышны бергә бетергәннәр, Берлин юнәлешендә. Өч балалары булган. Косинский, кадрда калып, һаман да хәрби командир икән... Ә Суфия, җиңел-җыйнак гәүдәле, мәңге тере, мәңге житез

хәрәкәтле Умга кызы, утны-суны кичкән хәрби фельдшер Суфия ханым... юк икән инде... Ул Кара диңгездә спорт вышкасыннан сикерү ярышларында уңайсыз төшеп, бик үкенечле рәвештә һәлак булган...

Мондый хәлләр дә була иде

Армиянең ноябрь ахырларында башлап өч айга якын алып барган һөҗүм сугышлары инде тына төште. Көн саен шәһәр һәм авылларны азат итү хәбәрләре урынына аерым солдат яки бүлекчәләрнең кичәге сугышлардагы батырлыгы турында күбрәк яза башладык. Өзлексез ут давыллары сирәк атышларга калды. Алгы сызыкларда оборона оешты. 356 нчы дивизиягә баргач, моны миңа 85 нче полк командиры майор Хренников үзе күрсәтеп йөрде.

Бу майор сәеррәк холыклы, хәтта шактый «үзенчәлекле» бер кеше булып чыкты.

Полк комиссары Сапейкин иптәш белән парткомиссия утырышында булганнан соң, без алар икесе торган йортка кайтып кердек. Ишектә мине күрү белән:

— Бу нинди хәчтерүш ияртеп йөрисең тагы? — дип куйды тәкәббер тавышлы, мәһабәт буйлы бер майор.

Мин, җир тишегенә керерлек булып, сүзсез калдым. Бик кыен булып китте, шулкадәр мокыт күренә идем микәнни соң? Әллә өстәге интендантлык формасы, аяктагы морж унтасы шулай итеп күрсәтә микән мине?..

Комиссар, аның сүзенә тиз генә жавап кайтарырга ашыкмыйча, өстен чишенде, миңа да шуны ук тәкъдим итте. Аннары без алгы якка уздык. Тик шунда гына комиссар авыз ачты:

— Таныш булыгыз: армия газетасыннан корреспондент. Безнең полкның сугышчан эшләре белән кызыксына, — диде.

Мин, елмаерга тырышып, майорга кул суздым. Нишлисең, хәбәрче кешегә андыйларны гына күтәрергә туры килә...

— Приятно, — дип куйды ул, куыш тавыш белән һәм илтифатсыз гына кулны кыскандай булды. Аннары: — Есть у нас дела боевые, пиши хоть целый месяц! — дип өстәде.

Әлбәттә, полк командиры алдында мин бик бәләкәй кеше идем һәм үземне җиңеп:

— Миңа нәкъ шул кирәк тә инде! — дип, тагын да ачылыбрак елмайган булдым.

Өстәлгә аш китерделәр. Майор янәшә койкадагы мендәр астыннан шинель тышлы, каеш баулы фляга тартып чыгарды. Бөкесен ачып, кырлы стаканга нәрсәдер койды да бер сулыштан шуны каплап куйды. Аннары хикмәтле савытны комиссарга таба этәрде. Без дә авыз чылатып алдык. Мин хәзер ачык сизә башладым: бу мәһабәт гәүдәле, кырыс һәм кыргый холыклы «чаптр»га комиссар һәрвакыт авызлыклы йөгән һәм каеш дилбегә булырга тиеш. Юкса, аның бер «урам әйләнү»дә үк тәртәләреңне сындырып, чаналарыңны кырып ташлавы мөмкин. Соңыннан мәгълүм булды: полкның күптәнге командиры госпитальгә киткәч, әле бер ай гына элек фронт резервыннан жибәрелгән икән ул. Майорның битләре кызарып, кәефе бераз языла төшкәндәй булды.

— Ә син кстати килдең, корреспондент, — дип куйды ул. — Бүген бездә «эш» була... Телисеңме, барын да үз күзең белән күреп, кайнар кулдан кайнар табага салып укучыларны сыйларга? Только яңгыраш-лы булсын!..

Мондый кызыклы «эш» буласын белгәч хәбәрче түзәме соң? Билгеле, шунда ук риза булдым. Һәм миңа бу майор шактый ук ошый башлады хәзер. Чөнки ул куыш тавышның эчендә әллә нинди яшерен сәләтләр ятадыр һәм миңа бик шәп бер очерк язарга мөмкин булыр шикелле тоела иде.

— Алайса, хәзер рекогносцировкага китәбез, комиссар. Корреспондент та барыр, — диде ул, боергандай итеп. — Төнлә «тел» алабыз. Хәлләрен белергә кирәк фрицларның: аяклары өшеми микән, муенналарын бет кимерми микән?..

Без табыннан кузгалып киендек тә авылча итеп диярлек жигелгән терәкле чаналарга чыгып утырдык. Аның әлеге жор сүзләре елмайтып куйды мине. Алдагы чанада ике автоматчы белән ул бара, артта — комиссар белән без. Ә комиссар аеруча житди кеше күренә. Майорның көлдерергә тырышуына да игътибар итмәде шикелле, әлеге планнарын да артык хуплап бетерми төсле, әмма каршы килеп сүз дә кыстырмый. Ихтимал, минем алда андый сүз килешми торгандыр, полк командиры булган кешенең хокукларына кагылмау кирәктер...

Майор безне Ока елгасының көнбатыш ярында плацдарм тоткан бер батальонына алып китте.

Бу тирәләрдә тар гына булып яткан Оканы боз өсләтеп кенә чыктык та текә яр башындагы Толкачи авылына күтәрелдек. Аннары, ачык басулардан жилдереп узып, яшь нарат урманының аргы кырыена чыктык. Монда, взводларга бүленеп, солдатлар тезелеп ята. Алар карны казып үзләренә ячейка ясаганнар да мылтыкларын кар «бруствер» өстенә салып, шул чокырга сузылып ятканнар. Өс-башлары жылы: киез итек, сырма чалбар, кыска тун, мех бияләй, мех бүрек, авызларында тәмәке, күнелләре көр.

Майор мине бер кырыйгарак китереп юан агач төбенә ышыкландырды да кулга бинокль бирде, үзе урман читенә чыгып басты. Янындагы комбат һәм разведка командиры белән уңга таба китте. Мин дошман ягына карадым: алда ике чакрымнарга сузылган уйсулык, ап-ак кар астында калган басулар ята. Кырның теге чите яңадан үргә күтәрелә һәм шул үр өстендә беренән-бер илле метр чамасында булырлык блиндажлар тезелеп китә. Алар авыл читләрендә була торган тәбәнәк мунчаларны хәтерләтәләр, түбәләрен кар күмгән, берничә ниргә жирдән калкып торган стеналары гына каралып күренә. Блиндажлар арасында немецлар йөренгәли. Тик аларның башларын гына күрәсен.

— Нигә гәүдәләре күренми? — дип сорадым якындагы бер сержанттан.

— Алар блиндаж белән блиндаж арасына траншей-хәбәрләшү юлы казыганнар, — диде ул.

Мин, артка борылып, үзебезнең солдатларга карадым.

Сәер уйлар туды: нигә безнекеләр шәрә кар өстендә яталар. Никадәр генә жылы киенмәсеннәр — барыбер суык бит... Нигә безгә дә шундый ук блиндажлар булдырмаска, нигә траншеялар казымаска? Солдатның бер өлеше шулар буйлап сакта йөрсә, өзлексез күзәтү алып барса, икенче бер өлеше жылы блиндажда ял итәр иде ләбаса... Аннары, дошман ут ачкан чакта да шәрә кар өстендә ничек сакланмак кирәк? Янәшәдә траншея һәм землянкалар булмагач, кая яшеренәләр икән?..

Бу хакта кемгәдер, нәрсәдер әйтеп карыйсы килде. Ләкин якында әлеге сержанттан башка беркем дә юк иде. Мондый сүзне аның белән сөйләшү урынсыз булыр. Сапейкин исә батальон комиссары һәм политруклар тирәсендә арттарак калды... Алда яткан ул мәйданны бинокль белән тагын бер кат айкап чыктым да, эчкәрәк чигенеп, агач төбенә чүгәләдем, тәмәке чыгардым.

Баягы юлдашлары белән тагын жиде-сигез разведчик ияртеп, майор килеп житте. Юлда башлаган сүзен дәвам иттергән шикелле:

— Әнә, үзегез дә күрдегез, — диде ул, — фриц, көрт күмгән чыршы төбендәге кылый куян шикелле, корышып йоклый, тәпие туңадыр мескенкәйнең, кузгаласы да килми, күпме күренеп йөрсәк тә, бер тапкыр атып карамады. Ничево, йоклый торсыннар, төнлә без алар белән әз генә кети-кети уйнап, аркаларыннан пар чыгарырбыз, мунча кергән күк булырлар!..

Аннары ул «Казбек» чыгарып кабызды. Командир һәм разведчикларга да өләшеп чыкты. Солдатлар, тартыныбрак булса да, бик сөенеп, юан папиросны авызларына каптылар. Әллә ничә зажигалкадан берьюлы ут кабызып командирга суздылар. Бу хәрәкәтләр һәммәсе дә командир белән солдатның «үз кешеләр», яудаш иптәшләр икәнен күрсәтәләр кебек иде.

— Ну, пока! — диде полк командиры. — Задача барыгызга да ачык. Төнгә хәтле тиешле чараларның барысын да күрегез. Кирәк була калса, ут ноктала ры әзер булсын. Безгә ин хәерлесе эшне шау-шусыз гына бетерү. «Тел» алу шәһәр алу түгел. Ярый, күз күрер. Парадом командовать буду сам! — дип бетерде ул сүзен.

Әлеге төркем аны бик яратып, елмаеп озатып калды. Без, карда яткан солдатлар тирәсеннән узып, атлар янына килдек. Берәр кимчелек күреп эчем пошса, шуны әйтми кала алмый торган начар гадәтем бар минем. Бу юлы да шул гадәтем кытыклап жанга тигәч, бая туган борчулы уйларымны майорга әйтеп биргән идем, һич кенә дә ошатмады:

— Учить каждый мастер! — диде бу, көтелмәгән ярсу тавыш белән. Күзләренә дә каяндыр шундый ук ярсу ялтыравык чыгып өлгергән иде.— Без әллә кар өстенә мәнгелеккә ятканмы? — Бәлки, иртәгүк, фрицның жилкә тамырына атланып, әллә кайларга хәтле куа китәрбез! Һе, Ока ярында мунча казып ят, имеш! Ләүкәсендә чабып, яшел себерке, кайнар пар! Ә Берлинга Пушкин барырмы? Кайчан барып житәр?!.

Миңа, әлбәттә, бик житди рәвештә гафу үтенергә, үземнең хәрби эшләрдән бик ерак торучы, бик тә штатский кеше булуымны кат-кат әйтеп майорны тынычландырырга туры килде. Ярый әле, чаналарыбыз аерым. Юкса, ул мине бөтенләй ашап ташлар иде. Без комиссар белән бер чанада кайтабыз. Ул һични эндәшми. Ихтимал, аңа шулай тиешледер. Ә мин ут йотып кайтам: ник авыз ачтым? Бәлки, чынлап та, майор хаклыдыр, бөтен фронт күләмендә оборонага күчү юк бит. Бу нәрсә безнең армия участокларында гына сизелә. Әгәр якын арада сугышлар яңадан башланып китсә, бүген солдатны жир казытып тинтерәтүнең кираге бармы? Мин уйлаганча ук авыр микән аларга кар өстендә яту?

Кышкы көн бер карыш дигәндәй, без кайтып житкәч кинче караңгы да төште. Майор төнге «эш»кә барасы разведчикларын жыйды. Алар бер унбишләп кеше. Командирлары — лейтенант Карпов. Ул озын буйлы, ташып торган сары чәчле, күк күзле яшь кенә егет. Түшендә немец автоматы. Бу корал тагын биш-алты егеттә күренә. Ул чакта әле трофей автомат яки парабеллум иясе булу — зур дәрәҗәдән һәм батырлыктан санала, андыйларга сөкланып карыйлар иде. Күрәсең, бу егетләр дә сыната торганнардан булмаса кирәк.

Полк командиры башта аларга көндез үзләре күзәткән урыннардан ничек тып-тын гына барып, тып-тын гына төнге сакны арттан әләктереп алу, тавыш чыгара башлаганчы авызын томалау юлларын өйрәтте. Монысын икс кеше эшли, өченче кеше шул чакта тиз генә олы матрас капчыгын фрицның башына кигезеп өлгерә, дүртенче кеше шуны, жәлт кенә жилкәсенә салып, артка тәгәри башлый. Монысын әлеге лейтенантка караганда да озын һәм таза гәүдәле, жирән, сирәк сипкелле сержант Баһманов эшләргә тиеш иде.

— Карагыз аны, фрицны ипләп кенә, сак кына күтәреп кайтыгыз, тыны бетмәсен, тәне авыртмасын, бик кадерле «кунак»,— дип көлдерде майор.

Аннары ул кәбестә-кыяр китертеп тамак чылаттырды. Шул чакта егетләрнең байтагысын мактап чыкты. Мин аларны блокнотыма терки бардым. Әлбәттә, аның мактавының төп максаты да шул иде. Әйтергә кирәк, без инде майор белән уртак тел табып, шактый ук килешкән идек. Шунсыз мөмкин дә түгел.

Егетләрнең күзләре ялтырап, сүзләре кайнарланып, шау-шулары күбәеп китте. Тик комиссар Сапейкин гына тып-тын иде. Хәер, егетләр юлга җыенып, өйдән чыгып киткәч, ишек төбендә майорны туктатып:

— Бәлки үзең дә анда булу мәҗбүри эш түгелдер, командир? — дип, киңәш рәвешендә сорап куйды.

Майор, аңламагандай гажәпләнеп, аңа карап алды да:

— Што син, комиссар, маленький, што-ли! Парадом командую сам! — дип ишектән чыгып китте.

— Ашыкма! — дип кычкырды Сапейкин. Ниһаять, ул телгә килде. Майор ишектән кире керде.

— Исеңдә тот! — диде комиссар, катгый тавыш белән.— Бу хәтлесе белән мин килешмим! «Югары» белән сөйләшергә туры килә...

Сүз болайга борылгач, мин чыгып киттем. Майорның: «Все согласовано!» дигәне генә ишетелеп калды...

Төнге берләрдә без инде әлеге батальонның алгы кырыенда идек. Бөтен позиция буенча шомлы тынлык яткан. Караңгы — ай да, йолдыз да юк. Теге кырыйда немец ракеталарының калтыравык яктысы гына урыннан-урынга чагылып тора. Март башының җепшек сыман күбәләк кары, жилсез төндә ялкау гына төшеп, битләрдә эри. Майор аттан төшү белән комбатка, тупчыларга, миномётчыларга тиешле әмерләрен биреп йөри башлады: кирәге чыга калса, бар да әзер булсын! Ләкин аның приказыннан башка бер генә мылтык та атмаска тиеш! Аннары ул егетләре янына килде дә:

— Ну, орлы, налетим! — диде. Һәм алар, көндез билгеләнгән уң тарафка китеп, караңгылыкка чумдылар. Ике сәгать вакыт тып-тын узды...

Шуннан соң теге яктан автомат «чираты» чәчрәп куйды, ракеталар яктысы ешрак бии башлаганы күренде. Тагын биш-ун минут вакыт тынлык. Аннары кинәт әллә ничә автомат берьюлы шашына башлады. Ниһаять, безнең разведчиклар ягыннан да автоматларның кыска жаваплары ишетелде. Мондагы командирлар тирән бер аптырашта калды: бәлки, алар анда бик авыр хәлдәдер, каплау уты кирәктер, ә приказ юк, майор боерыгын берәү дә үзгәртә алмый. Шактый озак вакыт аптырап торганнан соң, комбат егерме кешелек бер төркемне ярым автомат, кул пулеметы һәм гранаталар белән коралландырып, үз урынбасары житәкчелегендә разведчиклар юлыннан жибәрде. Алай-болай берәр житди хәл була калса, шундук эшкә керешергә кушты.

Ә тегендә атыш һаман кыза барды. Тавышлар хәтта болай таба якыная килгән сыман да тоела башлады хәзер. Ниһаять, төнге кар өстендә, урман итәкләбрәк, кара күләгәләр күзгә чалынгандай булды:— Үзебезнекеләрме, тегеләрме? — Командирлар сагая төште. Озак та үтмәде, шул тарафтан полк командиры килеп чыкты. Хәер, аның чиксез ярсыган, тузынган тавышы үзеннән алданрак килеп житте. Күзләреңең йодрыктай булып ут уйнаганын төнге караңгыда да сизәрлек иде. Башта бик каты сүгенде ул, дошманны тел бөлән куркытты, аннары:

— Әзер булыгыз! Разведка боем! — дип, тиздән эшкә күчәчәген белдерде.

Бераздан соң карацгылык эченнән разведчиклар төркеме һәм алар артыннан бая киткән егетләр күренде. Хәбәрче эшнең үзәгендә булырга тиеш — каршыларына ашыктым: дүрт яралыны житәкләп жиде кеше авыр гына атлап килә иде. Кайберенең ак халатлары дегеттәй кара тапка буялган — балчыкмы, канмы? Арттагы берәве кемнедер жилкәсенә салган. «Тел»дер! дигән уй мине аның янына ашыктырды. Бу егет әлеге иң озын буйлы, таза гәүдәле сержант булып чыкты. Жилкәсенә салган кеше дә матрас капчыгында түгел, разведчик халатында... Ул бер дә кыймылдамый, тавыш-тын бирми, куллары озын, жансыз булып аска салынып төшкән... Бик уңайсыз булса да сорамый булдыра алмадым: атаклы разведчик лейтенант Карповның үле гәүдәсе икән ул... Ә «тел»?.. «Тел»... юк иде...

Яралыларны санитарларга тапшыргач, сержант Баһманов теләр-телемәс кенә әйтеп бирде:

— Хәерсез юлга чыктык... Карповны — Валентин дустымны югалттым... Тагын өч-дүрт үлек анда калды әле... Ай, хәзерсез юл!.. Ике арадагы тирән үзәндә бәләкәй генә инеш барлыгын белә идек. Әмма аны шундый мәкерле булыр дип кем уйлаган?.. Кызган мәлгә шул елгага барып төштек. Ә ул текә ярлы тар гына тирән су икән. Ике ярына да калын кар өелеп, шул кабарынкы көрт инеш өстен дә каплап алган. Килеп керүгә билдән карга чумдык, аннары көрт астындагы юка боз шатырдап ватылды да чупылдап суга төшеп киттек. Көч-хәл белән үрмәләп, теге ярга чыгып аудык. Итек лач су, бөтен кием күкрәктән алып манма юеш... Немец блиндажларына йөз метрдан ары юк — тик ничек барып житәсе?.. Көчкә үрмәлибез. Бөтен киемгә кар укмаша бара, әйтерсең ак аюлар без хәзер... Булмады. Ул тирә шәп-шәрә, ышыкланырга агач-фәлән юк. Траншеяга утыз метрлар калгач, немец сагының кайсыдыр сизеп алды һәм автоматын тырылдатырга кереште. Шуннан китте инде... Эх, лейтенант жалко! Сугыш башыннан бирле бергә идек, алтын дус, батыр егет иде...

Баһманов дустының гәүдәсе янында утырып калды. Мина комбатның күзәтү пунктына юнәлергә туры килде. Әйе, мин кергәндә майор һаман шул ярсыган тавыш белән командирларга әмер бирә, немецларның ата-аналарына янап:

— «Тел» барыбер булыр! — дип кычкыра иде.

Комбатның да, башкаларның да чырайлары сүрән. Һичкем һични эндәшми.

Шулай итеп, таң аллыннан «разведка боем» башланды. Туплар, миномётлар, пулемётлар эшкә тотынды. Бераздан төркем-төркем булып, пехота алга юнәлде. Теге яктан да ажгырып ут яудырырга тотындылар. Бөтен операцияне полк командиры үзе алып бара.

Киңәт немецларның туп һәм миномет уты бермә-бер көчәеп китте. Якын тирәдә шартлап ярылулардан һәм яктырткыч пулялар эселдәвеннән ут бураны уйный башлады. Роталардан «дошман контратакага күчте» дигән хәбәр килде. Хәлләр шактый житдиләнеп китте. Озакламый, «НП»га полк комиссары Сапейкин килеп житте.

— Ипташ майор, син нишлисең?..— диде ул, кырыс тавыш белән.

— Сам отвечу! — дип кисте майор. Ул һаман шул ярсу хәлендә килеш «НП» тирәсендә таптана, теле белән дә, кулы белән дә төрле команда бирә: «Уңга ут!», «Сулга ут!» Ә хәлләр һаман кискенләшә бара. Тиздән танклар гөрелдәгән тавыш та ишетелде. Инде беленә башлаган кышкы таң яктылыгында аның сул канатта күренүен хәбәр иттеләр. Кырык биш калибрлы пушкаларның утын шунда яудырырга команда бирелде. Дошман танклары килә башлавы ул чакта безнең пехотага аеруча нык тәэсир ясый, чөнки солдат кулында, яндыргыч сыекча шешәсеннән башка, аларга ерактанрак каршы торырлык ышанычлы һәм ныклы корал юк иде әле. Бая алга юнәлеп кар өстенә

ятарга мәҗбүр булган солдатларның сул кырые чигенә башлавы, гомумән, дошманның батальонны бик нык кысрыкларга тотынуы мәгълүм булды... Майор полкның икенче участокларындагы батальоннарыннан берничә рота өстәмә көч чакыртты. Ләкин ул көчләр килеп житкәнче, бу драматик вакыйга шомлы тизлек белән чишелеп тә өлгерде. Башта дошман шашкын артналет ясады. Аның артыннан күктә өч-дүрт «мессер» күренде. Алар, түбәннән генә очып, кардагы пехотаны кырып йөрделәр. Аннары өч төштән өч танк, әшәке гөрелдәп, болай таба килә башлады, алар артыннан немец пехотасы ярым бөкрәеп йөгерә иде... Батальонның эчке ныклыгы сынды — күпләп артка тәгәрәү китте. Безгә Ока ярына төшеп ышыкланырга һәм аның бу ягына урнашырга туры килде. Дошман Оканың теге ярында туктап калды. Анда әле генә безнең плацдарм иде. Без аны югалттык. Күршедәге икенче полк батальоны да чигенергә мәҗбүр булды. Плацдарм гынамы соң? Күпме алтын егетләр калды анда... Майор үзе дә... Әйе, аны Ока ярыннан санитарлар ут тынгач табып китерделәр. Якында гына мина ярылган булса кирәк, зур кыйпылчык аның күкрәк сөяген умырып киткән иде...

«Совет власте тәмам жиңелде!»

Туры килде, мондый сүзне ишетергә дә туры килде. Хәер, бу сүзне немецларның күп чәйнәве турында безнең газеталарда да языла һәм ул бер көлке булып кына калган иде. Ә без аны немецтан түгел, колхоз хисапчысыннан ишеттек. Ул аны хәл-әхвәлне анализлап, үзенчә бик белдекле булып әйтте. Аны дошман койрыгы дип тә булмый иде — болай честный кеше күренә, укый, тыңлый, күзәтә, күп сөйләүне яратмый. Житмәсә, безнең фатир хуҗасы иде ул. Хатыны да, үзе дә әйбәт кенә кешеләр. Без аларда Габделхәй Хәбиб белән торабыз....

Хәбиб дигәннән, мин аны 85 нче полкта очраттым. Сугышка кадәр «Кызыл Татарстан»ның секретаре булып эшләгән журналист, ә мин күрешкәндә 120 калибрлы миномётта рядовой солдат иде ул. Кышкы калын киемнәрдән Хәбиб ничектер тәбәнәк, юан гәүдәле, кыска муенлы, күзләрен маңгай астыннан гына йөртә торган бер «бүкән»гә әйләнеп киткән шикелле иде. Беренче күрүдә көләсе килде. «Малай, син хәзер шушы кыска юан миномет көпшәгезгә охшап киткәнсең», — дип, үзенә дә әйттем бугай. Соңыннан ул партиягә керде, кыска вакытлы политкурсларда укыды һәм, якасына кубиклар тагып, политрук булды. Август башларында аны безнең газетага жибәрделәр, бергә эшли башладык... Ә хуҗаның әлеге сүзен ишеткәч, Хәбиб тә шаккатып калды — бер аңа карый, бер миңа... Сүгеникме, бәхәсләшикме, әллә, якасыннан жилтерәтеп, «Смерш»ка озатыйкмы? — дигән шикелле карады ул.

Ләкин берсе дә ярап бетмәс кебек. Без, офицерлар, хәл-әхвәлне киңрәк аңлыйбыз. Каршыбызда исә элеп киптергәндәй шыр-сөяк гәүдәле иллеләр өстендәге күзлекле бер карт. Бигрәк өтек бер жан иясе инде, өрсәң очып китәрдәй тавык йоны!.. Әмма теле ачы: «Хәлләрне үзегез үк күреп торасыз ич, каршылык күрсәтеп маташу — мәгънәсез. Артык корбаннар гына!..» — дип тә өстәде әле ул.

Ә хәл-әхвәлләр ул чакта, чыннан да, шәп түгел иде шул. Белмим, бүтән фронтларда ничек булгандыр, әмма безнең армия участогында яздан ук эшләр шактый мөшкеләнеп китте. Кар сулары юлларны тарката башлагач, армияне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе кинәт бик кыенлашып куйды. Озак оборонада ятып, алҗып беткән солдатны туйдырырга икмәк житми башлады, сохарига калдык, ул да

кеше башына 100 генә грамм тия иде. Көненә бер тапкыр пешә торган концентрат ашы да бик сыекланды. Котелогындагы ашның уртасында кашыгы аягүрә басып тормаса, солдат аны ашка да сапамый бит. Солдат хәтта басудагы бәрәңге жирләрен һәм бакча түтәлләрен актарырга кереште. Балчыкта калып өшегән вак бәрәңгеләрне җыеп, крахмал көлчәсе пешерә башлады. Офицерларның хәле шундый иде. Миңа да ул көлчә белән беркадәр сыйланырга туры килде: балчык сыман кара төстә булуы бер хәл, тәмсез төче булуы һәм шытырдап тешкә тиюе яман. Хәзер моны елмаеп сөйләү күңелле, ә теге вакытта жанны бик борчый иде. Чөнки солдатның сугышчан рухы какшый, чырае караңгылана, эчке ныклыгы йомшый иде. Ә дошман ягы моны белеп тора: фронт сызыгы якынрак урыннарда, штык очына элеп, зур түгәрәк калач күрсәтәләр иде безнең солдатка. Баш очында немец «култыксасы» (разведка самолеты) оча. Ул бомба ташламый, пулеметтан сиптерми. Ул тар, озынча кәгазь чүбе яудыра. Бомбадан да куркыныч чүп! Анда күп сүз язылмаган: «ШВЗ (штык в землю). Ачка үләсегез килмәсә, безнең якка чыгыгыз! Тамагыгыз тук булыр, сугыштан да котылырсыз. Бу — сезгә пропуск. Шушыны күрсәтсәгез, беркем дә тимәс!»

Алданучылар да булмый калмады. Төнлә киткәләделәр. Бигрәк тә туган жирләре шул якта калган кешеләр... Әмма бер эпизод кинәт жаннарны тетрәтеп жибәрде. Авылы теге якта, жиде-сигез чакрымда гына булган бер яшь солдат, әлеге калач богауларга кызыгып, кичке эңгер төшкәнче үк кырыйдагы бер канау буйлап үрмәләп китә. Иптәшләре аны «үз йомышы» белән читләшкәндер дип абайламый да калалар. Ике арадагы ярты юлны узгач, әлеге егет аягүрә калкып, теге якка йөгерә башлый. Нәкъ шул чакта ату тавышы яңгырый. Егет, каерылып чалкан төшкәндә, ачы кычкырып кала. Шунда гына иптәшләре, сискәнеп, хәлнең нәрсәдә икәнен аңлап алалар. Ләкин ату кайсы яктан яңгырады соң? Моны беркем дә ачык белми... Шулай да алар әле генә яннарында булган һәм күпме вакыт бергә сугышкан иптәшләрен анда калдырырга теләмиләр. Взвод командирыннан рөхсәт алып, төнге караңгы тәмам урнашып житкәч, ике комсомолец алга үрмәли һәм озакламый хаин үлекне монда сөйрәп алып кайта... Күпләрнең күңелендә берәүгә дә әйтелми торган бер төен туган була: «Үзебезнекеләр атып еккандыр мескенне...» Шуңа күрә аның ин элек шинель чабуларын, күлмәкләрен актарып ярасына ташланалар. Пуля йөрәгенең нәкъ уң кырына килеп кергән, калак сөяге астыннан барып чыккан була. Менә шул тетрәтә дә инде! Өстәвенә, егетнең чалбар кесәсе төбеннән бармак башыдай гына итеп бөгәрләп салынган «швз» килеп чыга. Күрәсең, ул, факыр, дошман яхшылыгына нык ышанып эш иткән. Ә немецлар аны калач урынына кургаш белән каршы алалар...

Тамак мәсьәләсе — жәйгә таба рәтләнде. Ләкин башка хәлләр тагын да кискенләшә төште. Безнең фронт солдатлары әллә ничә ай буена оборонада ята-ята йончып бетте. Ә бездән ерак көньякта каты һәм безнең өчен куанычлы булмаган сугышлар бара. Харьков операциясе дә, Керчь десанты да уңышсыз бетте. Дошман шашынып Донга, Сталинградка ябырыла иде инде. Ул безнең фронт өстенә көн саен әллә нихәтле листовкалар яудыра. Әлеге безнең операцияләрне ничек тармар итүе, күпме әсир алуы турында рәсемнәр һәм схемалар белән күрсәтеп, саннар китереп шапырына. Ул кәһәр суккан агулы чүпне жыеп яндыра-яндыра жаннар чыга иде безнең.

Көньяктагы шул авыр хәлне беркадәр булса да жиңеләйтү максаты белән дошман көчләрен үзебезгә тартмакчы булып, август башларында «алдавыч» (отвлекающий) һөжүм ясап карадык. Ул да хәерле булып чыкмады. Америкадан китерелгән 18 «Шерман» танкысы бер көнлек һөжүмдә, шырпы кабы шикелле «пышт!» итеп, янды да бетте. Бу бездә

шактый бер әшәке тәэсир калдырды: «Нәрсә соң бу? Америка шушы танкларын бүгенге сугыш коралы итеп саныймы? Әгәр шулай булса, икенче фронт ачкач немец «тигр»ларына каршы бу әржәләре белән ничек сугышыр ул? Әллә янки агай безгә җыен иске-москысын озатканмы?..» Солдатта союзниклларга караш элек тә бик үк ышанулы түгел иде, ә бу хәлдән соң кул гына селкә башлады ул.

Бу һөҗүмгә каршы немецлар контр һөҗүм белән җавап бирделәр. Аларның теләге — безнең армиянең уң канатындагы өч дивизияне, ике кырыйдан ертып кереп, камап алу иде. Бу участок шактый бүлтәеп дошман тылына кереп тора иде. Көн буе барган каты сугыштан соң сулдагы 44 нче дивизия флангысыннан өзеп кереп, үрдән Сорокино авылына төштеләр, андагы инешне кичеп, урман аркылы Ульяново авылына — 87 нче дивизиянең тылына килеп чыктылар. Ул көннәрдә мин шул дивизиядә идем. Камалышта калу куркынычы көн кебек ачык булса да, дивизия урынныннан кымшанмады. Аның язгы-җәйге оборона чорында эшләнгән блиндажлары нык, траншеялары тирән, ут ноктала-ры, терәк пунктлары ышанычлы иде, шуңа күрә немецлар «маңгай»дан ясалган атака белән генә һич ни эшли алмадылар. Танклары да уза алмады, авиациясе дә куркытмады. Тик әнә шул сулдан бүселеш кенә камалу куркынычы тудырды. Шулай да дивизия үз позициясендә калып сугыша бирде. Арттагы «капчык авызы» 8—10 чакрымнар чамасы гына калгач, политбүлек начальнигы полковник Гриценко, бүлекнең бөтен архивын һәм парткомиссия документларын, техник персоналны һәм мине дә төятеп, бер-ике инструкторы белән төнге караңгыда тылга чыгарып җибәрде: «Сез миңа кирәксез хәзер. Бернәрсә дә эшли алмыйсыз. Тыл белән элемтә өзек. Обстановка бик җитди».

Теләсәң-теләмәсәң дә килеш! Чөнки иң хәтәре — дошман кулына эләгү... Киттек. Караңгы төн, көндезге эсседә кубып калган тузанлы юл. Төнлә дә тынмаган атыш. Ике яктан да әледән-әле чөелеп торган немец ракеталары... Шулай чокыр-чакырлы авыл юлларыннан арып-талып бара торгач, иртә белә 16 нчы армиянең тылына барып чыктык. Аларның сул канатын да дошман атакалап караган, ләкин тешләре үтмәгән, күпмегәдер тынып калганнар...

Миңа, юлдашларымнан аерылып, редакциягә юл тотарга туры килде. Уң кырыемнан сугыш килә. Әле бер атна гына элек мин узып йөргән тыныч авыллар хәзер ут эчендә. Немец авиациясе котырып эшли: бер төркеме туп-туры алгы кырыйга, солдат башына бомба яудырса, икенче төркемнәре фронт сызыгы артындагы якын тыл авылларын җир белән тигезли. Тузанга батып, сусап-әлсерәп Жуковка авылына килеп кенә кердем, шундый тәмле салкын суның рәхәт ләззәтен дә татып өлгерә алмадым, баш очымда инде алты «юнкерс» тырылдый иде. Юл бер генә: авыл эченнән бик тиз чыгып китәргә кирәк. Юкса, монда хәзер җәһәннәм гарасаты кубачак. Йөгерергә оят — маржа түтәйләр күренә, мин бит офицер киемендә. Шулай да, бар кызулыгым белән җәһәт-җәһәт атлап барганда, сулда бер тыкрык күрдем һәм ялт шунда, борылып чаба башладым. Үзем көләм: Лермонтовның «Гарун бежал быстрее лани...» дигән юлы миңа әйтелгәндер кебек тоела. Ниһаять, бакча башларын узып, ачык мәйданга чыктым да бер канау сымак иңкелгә мәтәлдем. Әлеге кара козгыннар, авылның теге башыннан түбәнәеп, пикега керделәр. Беренче бомбалар салам түбәле «хәрби объектлар» өстенә томылды. Дөнья куркыныч әшәке тавышлар белән күмелде. Шул чакта зур гына, матур гына бер эт, каяндыр чыгып, чыйный-чыйный җан-фәрманга чабып килешкә минем өстән сикереп узды. Аннары, шундук борылып карады да, кире килеп яныма сыенды, шактый вакыт елавыннан туктый алмады. Без хәзер икәү булдык. Нишлисең бит, икебезнең дә хәлләр бер төслерәк... Икебезнең дә күзләр авыл өстенә текәлгән. Аның зур булып ачылган һәм яшь белән елтыраган күзләре:

Һич ни аңламыйм, ни өчен бу шундый зур кара кошлар, биек күктән килеп, шундый әшәке, куркыныч тавышлар чыгарып, шундый йөрәк өзгеч чыңлап төшә торган һәм жир селкетеп ярыла торган нәрсәләрен авыл өстенә коялар, шундый кара төтеннәр чыгарып, авылны яндыралар?.. Минем өем дә шунда иде бит...» дигән шикелле тилмереп карый... Мин дә аңламыйм шул. Мин анда үземә су эчерткән әби карчыкны күрдем, аркасына яшел печән күтәреп кайткан бабайны күрдем, миңа тәжәпләнеп караган юеш борынлы бер-ике малайны күрдем шикелле, әмма бер генә солдат та, бер генә хәрби нәрсә дә күрмәдем... Соң бу хәтле ерткыч булу нигә кирәк икән? Шул салам түбәләрне жир белән тигезләгәндә генә жиңү мөмкин микәнни? Һич аңламыйм. Хәер, мин аңлый алмаган нәрсәләр сугышта бик күп булып чыкты...

Редакция Белев шәһәрендә юк иде. Фронт сызыгы болай үзгәргәч, армиянең тылын Ока елгасының көнчыгыш ярына күчергәннәр. Мин аны шәһәрдән 12 чакрым артта, «яңа авыл» дигән урында эзләп таптым. Иптәшләр янына исән кайтып житүемә бик сөендем. Алар да минем өчен хафаланып торганнар икән. Чөнки шушы атна эчендә күп кенә үзгәрешләр булып өлгергән, шактый позицияләр югалтканбыз, безнең газетада исемнәре чыккан байтак солдатлар, командир һәм политработниклар батырларча һәлак булган. 87 нче дивизия камалышта авыр сугышлар алып барса да, үз сафын исән саклап, шул ук 16 нчы армия тылына чыга алган. Тик теге төнне безне камалыштан чыгарып жибәргән политбүлек начальнигы полковник Гриценко гына һәлак булган. Бу хәбәр миңа бик авыр тәэсир ясады...

Армия участогында шулай башланып киткән операцияләр көзгә хәтле тынмады. Әкрен-әкрен үз позицияләребезне кайтарырга, фронт сызыгын тигезләргә омтылыш ясалды. Ә көньяк фронтларында хәлләр һаман начарлана барды. Дошман Сталинградка килеп керде, Төньяк Кавказга хәтле үрмәләде.

Үзәк газеталар «Ватан куркыныч астында!» дигән рубрика белән чыга башлады. Радио да тапшыру саен шул хакта сөйли иде. Ихтимал, шушы кыен һәм катлаулы хәлләр, матбугат һәм радионың шундый нык борчылулы авазлары безнең хужаны уйланырга, барлык обстановкага үзенчә анализ ясап, әлеге нәтиҗәгә килергә мәжбүр иткәндер. Ул чорда икеланучеләр юк түгел иде бит. Бәлки, ул бездән берәр уңай жавап яки бик нык бәхәсләшү көткәндер. Һәм шуның белән эш бетте. Яңадан бу мәсьәләгә кайтырга туры килмәде, чөнки октябрьның 20 ләрендә Политидарә мине, Мәскәүгә чакырып, татар газетасына жибәрде. Хәбибне дә, минем арттан ук чакыртып, Волхов фронтында чыгасы газетаның редакторы итеп жибәргәннәр.

Әйтеп бетергесез авыр һәм югалтулы еллар узып китте. Шомыртлар чәчәк атканда күз яшьләрен кояшта жемелдәтеп, яз жиледәй жилфердәп бөтен ил буена күкрәгән салют булып, жиңү килде! Белев тирәсеннән башлап Берлинга барып житкән, рядовойдан башлап майор булган, коммунист булган, күкрәген орденнар белән бизәгән Габделхәй Хәбиб белән яңадан Казан урамында очраштык. Һәм беренче сүзебез әлеге хужабыз турында булды:

— Исән микән ул «бичаракай!»

— Үкенмәде микән Жиңү килгәненә?.. — диештек.

Без аны әле дә искә төшергәлибез. Рәхәтләнеп көлешергә бер сәбәп була. Ул үзе халыктан бер тамчы булса да, шул күп миллионлы, күп телле мәһабәт халыкның нинди гаҗәеп көчкә ия булганын аңлый алмаган, күрәсең.

Ахыры киләсе санда.

ХАЛЫКЧАН ШАГЫЙРЬ

Гамил Афзалның
иҗат биографиясенә эскизлар

Әлмәттә, шәһәр читендәге биек таш йортларның берсендә, шагыйрь Гамил Афзал яши. «Шәһәр читендә» диюем бик дөрес үк тә булмас, чөнки берничә елдан хәзергә «кырый, чит» саналган бу урам-чатлар шәһәрнең үзәгенә әйләнәчәк. Ул чак язарга-сызарга насыйп булса, беркадәр горурлык белән «Шагыйрь Гамил Афзал яши шәһәрнең үзәгендә» диярбез. Биш катлы йортның иң өстәге чат бүлмәсе — шагыйрьнең эш урыны. Бу бүлмә, миңа калса, тыштан шактый шыксыз күренгән шушы таш йортның иң тынгысыз, иң ялкынлы төше, йөрәк урнашкан төшедер шикелле.

Биредә шигырьләр туа. Биредә яхшылык белән яманлык күзгә күз очраша, Таһир-Зөһрәләр утында янучы гашыйклар өзгәләнә, ил явында авып калган уллар, терелеп, телгә килә, кышкы буранларда сыерчыклар әйләнеп кайта, борынгы алмаз кылычлар, айбалталар уйный, абагалар чәчәк ата, космонавтлар ялга китәргә тукталый. Биредә шигырь туа! Биредә төннәр буе, «таң нурлары җиргә тамганчы халкына нур көлтәсе бүләк итәргә» хыялланып шагыйрь иҗат итә. Ул «матурлык эзли, ил туена сүздән чәчәкләр җыя!» Яхшы җыр, яхшы шигырь туган җир — изге җир үзе!

Шагыйрь бүлмәсендәге тәрәзәдән карасаң — Зәй әрәмәлекләре, Бигәш кырлары, Урсала таулары, арырак күз атсаң, күкселләнеп, томанланып торган офык читләре күренә, аста — Чистай — Казан якларына таба тасма юллар сызылып китә. Бу күренеш, бу панорама байтак татар шагыйрьләренә, каләмнәрен әле яңа тибрәтә башлаган бик күп яшь авторларга таныш дип беләм. Казан яки күрше-тирә районнардан Әлмәткә килеп тә Гамил Афзалларга керми киткән язучы сирәктер... Аңа килүләр, гаиләсен күреп чыгалар, хәл-әхвәл сорашалар, шигырь укыйлар, чәй эчәләр... Бер уйлаганда, гаилә-көнкүрешкә генә караган бу хәлнең икенче бер мәгънәле ягын күрәм мин, күптән эчтә йөртә торган уема терәк, дәлил табам: кешеләрне сөймәү, ялгызак, үз-үзенә бикләнгән кеше яхшы шагыйрь булалмыйдыр; эчкерле, хәсетле, эгоист, заман һәм халык уй-тойгыларына битараф кеше, хәтта талантлы булса да, шагыйрь түгел ул. Шагыйрь күңеле әнә күзе кебек тар булалмый. Тар күңелгә ваклык, мәкер сыя алса да, халыкның шатлык-кайгыларына бүтән күңел — киң, ачык күңел кирәк. Кешеләрне ярату, аларны чыннан да табигать тәҗы итеп күрү, акылына инану кирәк. Бер шагыйрь

үзенең китабына автограф итеп болай язган иде. «Кешеләрне ярату, һәй, кыен эш! Шул эштә без чын кешеләр булып калалсак икән!» Еллар үткән саен бу сүзләрнең мәгънәсен тирәнтен тоя барасың. Г. Афзалның да кешеләр турында мондый юллары бар:

Йөз кабат сөртенәм, абынам,
йөз кабат таянам кешегә.
Йөз кабат кимсенәм, алданам,
йөз кабат ышанам кешегә.
Йөз кабат чиксенәм, шикләнәм,
йөз кабат кизәнәм кешегә.
Йөз кабат сөенәм, хушланам,
йөз кабат сокланам кешегә.

Яки менә икенчесе:

Язам-сызам, язам-уйлыйм, ярармы, дим.
Кешеләргә файдамы бу, зарармы, дим.
Хурлыймммы мин, зурлыймммы мин аларны, дим.
Ак намусым күзен тутырып карап тора.

«Ак намусың күзен тутырып карап торганда» кеше күңеле түрендәген туры итеп әйтми кала аламы соң! Менә Г. Афзалның «Үзем турында» дигән шигыре:

Күзләремнең нуры,
Йөрәгемнең моңын
Кураема салып җыр итәм.
Йөзем аклыгы да,
Күңел шатлыгы да
Минем өчен шәян җыр икән.
Бәхет балкыр заман.
Ә мин ятып язам.
Күпме сагыш килде өстеп!
Үзем сүнеп ятам,
Үзем көлеп ятам
Кеше бәхете өчен сөенеп.

Гамил Афзалларга килгән кеше аның язу өстәленде, китап шкафларында яткан амбар кенәгәләренә игътибар итми калмыйдыр. Аларда — булачак шигырьнең өйрәнчек шигырьләре дә, татар шигъриятенә кәрәрлек нәфис эшләнгән соңгы дәвер шигырьләре дә бар. Алар — 16 дәнә. Һәммәсендә, борынгы язма китапларга хас пехтәләк белән, тигез юллар тезелгән. Дөресен әйткәндә, ул кенәгәләр миңа башта бераз сәерсендергән дә иде,— айга менгән заманда, язу эше белән шөгыльләнгән һәр кешенең диярлек «Оптима» яки «Эрика» кебек язу машиналары булган чорда, дебет-кредит графалары сызылган, соргылт битләре чабырчыкланып торган бу шыксыз кенәгәләр гажәпләндергән иде. Хәзер инде алай түгел. Хәтта әерым-әерым битләргә караганда, бәр язганың бергә теркәлеп бару ягыннан, хуп та күрәм.

Шулай да бер көн, ярым шаяртып: — Гамил абый, бу амбар кенәгәләренә каян табып бетерәсең? — дигән идем, ул балаларча җитди һәм беркатлы итеп:

— Менә бусын, кызыл тышлысын, балдыз Урта Азиядән алып кайтты, ә менә бу икесен үзебезнең Миңнур биргән иде,— диде.

Әйе, кемнәрдер акча ясарлык шыгырдап торган кәгазьләргә, кемнәрдер амбар кенәгәләренә яза. Ул кәгазьләргә төшкәннәрнең хакыйкый бәясен киләчәк әйтер. Кем белә, килер буынның Альберт Фәтхи кебек китапчы-галимнәре, 60 нчы еллар татар шигъриятен өйрәнгәндә, бәлки, беренче чиратта әнә шул амбар кенәгәләренә бик кадерле кулъязмалар итеп өйрәнерләр. Һәрхәлдә, шулай булсын иде дияк, шуңа юрыйк.

Быел шагыйрь Г. Афзалга 50 яшь тула. Бу — аз түгел, гади кеше өчен дә, шагыйрь өчен дә байтак гомер. Бу яшьтә узган-үткән юлга яңадан бер күз ташлау, кылган эшләргә беркадәр исәп-хисап ясап, кайбер нәтиҗәләргә килү дә зарур нәрсә.

Г. Афзал 1921 елда Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туа. Нәк Гамилнең дөнья белән таныша башлавы җирнең шушы ноктасыннан башлана. Монд тел ачылган, чишмәләрнең серле чылтыраулары тыңланган, күзләргә — беренче күр гән таңнарның нурлары иңгән, беренче такмаклар әйтелгән.

Гамилгә өч яшь тулгач, әнисе вафат була. 10 нчы яшькә чыккач, Афзаловла семьясы Урал-Магнитка якларына күченеп китә. Малайның Одессиясе! Беренче мәрт бә идәнә дә, стенасы да, түшәме дә таш йортларны күреп шаккатулар, «электр» дига керосинсыз лампаларга искитүләр, киң, коточкыч тирән Кама — Чулман елгасы, анда гы ап-ак пароходлар, челтәр күперләр, чуен юлларны кыздырып, сызгырып үтүч паровозлар... Туган авылдан китү — булачак шагыйрь Гамилдә мәңге онытылмасл кичерешләр тудырып, онытылмаслык хатирәләр калдырган. Әле быел гына язылга беркадәр Г. Тукайның «Исемдә калганнар»ын хәтерләткән, «Юл башы» дип аталга автобиографик язмасында автор гомеренең бу көннәрен тормышының кискен бе борылышы — зур дөньяга чыккандагы юл башы дип саный. «Бөтен халык утыры беткәч, паровоз ак парлар чыгарып бер-ике пошкырды, озын итеп, ки-и-и-ттек, ди кычкырды да, ләштер-ләштер кузгалып китте. Уралга барабыз, Уралга! Урманнар кырлар, күгелҗем офыклар, кечкенә инешләр, телеграмм баганалары артка йөгерә ләр. Без ак болытларга каршы, биек тауларга каршы, яңа язмышларга каршы йөгерә без. Васила апа әкрен генә, борын эченнән генә җырлап бара:

Телеграмм баганасын
Саныйсым калган икән,
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән...

Без Уралга барабыз. Авыл урамнары, кычытканлы читән буйлары, тыкрык әрек мәннәре, какылы ындыр артларыннан башка берни күрмәгән авыл малаена бу сәяхәт — киң дөньяга чыгу иде. Үсеп килә торган, барын да күрергә, барын да белергә тырыш кан балага, дөньяны тану, тормышны өйрәнү өчен сикәлтәле юллардан йөрү бик кира икән. Бәрелә-сугыла йөреп, күп михнәтләр күрсәм дә, язмышка бер тамчы да үпкә юк, үземчә бик кызык булды минем тормышым. Мин бик бәхетле кеше».

Яңа җирләрнең үзгә матурлыгы һәм кырыслыгы, төрле мәктәпләрдә белем эстә йөрүләр... Башта Магнитогорскида 7 еллык мәктәп. Аннан — Троицк педагогия училище сының беренче курсы, аннан — металл кою заводлары, мартен мичләре. Һәвәскәрләр белән «Галиябану», «Ак калфак»ларны сәхнәләрдә уйнаулар. Тагын завод. Бу юлы инд сугыш ихтыяҗына эшләүче заводлар. Үзгә киеренкелек, үзгә ритм. Үсмер чакта у аягын имгәткән Гамил илленче еллар башында тәмам түшәккә егыла

Сизәм, сызлыйм, сөенәм, тынмыйм һич тә.
Бөтен дөнья сыйган минем эчкә.
Мин түшәмгә карап уйлап ятам
иртән дә, көндез дә, көч тә.

1954 елга кадәр, Башкортстанның ямьле табигать кочагында утырган Шәрип авы лына күчеп кайтканга кадәр — булачак шагыйрьнең тормыш университетлары чоры еның кеше, гражданин буларак чыныгу чоры, туачак әсәрләренә хәзинә-материа туплау чоры. Г. Афзалның «Магнитогорск» дигән беренче шигыре матбугатта 1937 елд ук басылса да, 1955 елларга кадәр шагыйрь үзен таныта алмады. Дөрес, ул язмы тормаган, язган, шигырьләрен газета-журнал редакцияләренә, шагыйрьләргә (бигрә тә С. Хәкимгә) җибәреп торган... Күрәсең, талантның әдәбиятка бәреп керерлек көч әле максатлы хәрәкәткә килә алмаган, ниндидер яңа шартларга кадәр тыелып торган Бу җәһәттән, шагыйрьләр мәйданына чыгар алдыннан бик зарур — кайнап торган әдәби мохитнең булмавы, махсус әдәби белемнең җитенкерәмәве дә, һичшиксез, сәбәп булмый калмагандыр. Г. Афзал гомеренең бу чорын сагыш катыш көлемсерәп, сагы нып, беркадәр горурланып искә ала:

Көрсенмә син, күңел,
Көрсенмә!
Йөгереп үткән якты елларыңның
эзсез диеп булмый берсен дә,
төссез диеп булмый берсен дә.

Бишъеллыкның данлы төзелешләре
Урал даласында ераста...
Күзем йомсам, күз алдымда тора,
Гөрелтесе шаулый колакта.

Дөрес, болар соңрак язылган шигырьләр. Ләкин алар ул вакыттагы тәэсирләрнең, п чордагы уй-хисләрнең нәтиҗәсе, дистә елдан соңыннан кире кайткан кайтавазы. л белән бергә, халык белән бергә булганда, Ватан хакына, җиңү хакына көрәшкәндә ичек итеп ул елларны эзсез, төссез дип әйтеп булсын!

Дулап-дулап кызыл улак буйлап
кызыл ташкын
Аксын әле, егет, синең күлдә,
чәчеп ялкын!
Шушы ташкын җиңү алып барды
Эльба ярларына,
Шушы ташкын ирек алып барды
Карпат тауларына
Корыч кошлар илнең күкрәгендә —
безнең куллар эше,
Корыч линкор диңгез өсләрендә —
безнең куллар көче.
Мин үзем дә завод цехларында
тимер юынган кеше.

Сугышта Кавказ тауларын итәгендә ятып калган яшьлек дусты, яшь шагыйрь Касыйм Тәһиров истәлегенә язылган «Табылдык дәфтәр» шигырендә шагыйрь ул дәһшәтле сынау елларын тагын бер кат хәтеренә төшерә:

...Авыр сулап ваплар ухылдады,
Боерык булып килде бар нарядлар:
— Снарядлар кирәк, снарядлар!
Отпуск та, ял да сораучы юк,
Атып үлү яхшы кол булганчы!
Кара таңны кара төнгә ялгап
сменалар эшли егылганчы.

Авыр еллар, сыналу, чыныгу еллары, барыбер, гомернең бик газиз еллары... Сау бул, Урал!

Бодай кырларына тарта йөрәк,
Гудокларга күңел күнсә дә;
Болыннарның саф һавасы кирәк
Гелләр исен сөйгән үпкәгә.

Теге яки бу дәрәҗәдә шәхси тормышы белән авылга бәйләнмәгән, җиргә мөнәсәбәте булмаган татар шагыйрен табу гомумән кыен. Берәүләр туган җире-авылын яшел бишек, берәүләр алтын бишек, диләр. Һәркем үзенчә хаклы. Эпитетларны һәркем үзенчә сайлый, сүзнең төбе, мәгънәсе бар: авыл чыннан да күпләребез өчен бишек. Г. Афзалның яңадан авылга, табигатькә, ике дистә елдан артык аерылыбрак торган җир кешеләренә әйләнеп кайтуы аның рухи тормышында икенче бер зур борылыш булды.

Бөгелмәдем.
Бирелмәдем чиргә.
Моңын җиңеп кайгы-сагышның,
Тешем кысып,
Шушы туган җиргә
Ун тырнагым белән ябыштым.
Һәм
Җир бирде миңа Салсал көчен,
Иркен сулыш өрде үләннәр...

Ә дөнья шундый матур, шундый киң! Табигатьтә мәңгелек хәрәкәт, мәңгелек яшәү! Яңадан, бала чактагыдай, язлар килә, сыерчыклар бала чыгара... «Җир яшәр сугышлардан туеп, гашыйк булган үзе кояшка!» Яшәргә! Яшәргә! Чөнки:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә ярым,
Сөйгән ярым гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!
Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дус янында кем ятим!!
Күктә нурлар, җирдә шатлык,
Җирдә бәхет гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Авылда бераз яшәп савыгa төшкәч, ниһаять, Гәмил Афзалның да шушы «матур киң дөньяның» шигърият атлы симфониясендә үзенчәлекле авазы яңгырый башлады. «Авыл, табигать тәнемә — сихәт, күңелемдәге уйларымны кешеләргә илтер тел бирде» ди шагыйрь. 1955 елда аның бер цикл шигырьләре балалар өчен язылган шигъри әсәрләргә конкурста премиягә лаек булды. Аларның күбесе шагыйрьнең «Кар сулары» исемле китабында 1957 елда басылып та чыкты. Магнитка якларына китү — киңрәк тормышка юл башы булса, бусы инде зур әдәбиятка юл яру иде. Шуннан соң унбиш елга якын гомер үтте һәм шагыйрьнең татар телендә 15 китабы басылып чыкты. Ул китаплар кибет киштәләрендә кадерсезләнеп, тузанланып ятмадылар, аларның күбесе күңелләрдә урын тапты. С. Хәким дә аның бер китабына язган кереш сүзендә: «Ул әдәбиятка үзеннән алда кергән кайбер өлкән буын шагыйрьләреңә карағанда да үзеңнең укучыларын тизрәк тапты»,— ди. Хәзер, шагыйрь татар поэзиясендә нык урын алгач, аның иҗаты турында уйланып, үзеңне кызыксындырган кайбер сорауларга үзең үк җавап эзлисең. Шагыйрьнең илһам чыганагы, таяну ноктасы кайда? Остазлары кем? Иҗатының нинди сыйфатлары укучыларга газиз? Чагыштырмача тиз арада шигырьләреңнең популярлашып китүенең сәбәбе нәрсәдә?

Шагыйрьгә, гомумән, теләсә нинди жанрда иҗат итүче әдәбият кешесенә таланты ның үрләп китүенә төп шарт — рухына, жанына муафыйк табигый җирлек, табигый мохит булу. Г. Афзал авыл баласы, табигать баласы. Табигатьне бөтенебез яратабыз. Ләкин үз яратуын бүтәннәргә дә күчәрлек итеп ярату, аның гүзәллеген, сафлыгын кешеләр күңеленә күчерә алырлык дәрәҗәдә җырлый алу — талантлыларга гына бирелгән. Г. Афзал табигатьне бик нечкә тоеп, садә һәм халыкчан итеп тасвирлый ала, тасвирлап кына калмый, аны кешеләр күңеленә якынайта, яки кешенең үзен табигатьнең күзгә күренмәс җепләр белән бәйли, аларның берлеген искәртеп тора. Аның тугайлары, болыннары, тирәкләрендә, рәшә булып, кешенең шатлык-сөенечләре уйный, томан булып сагыш иңә, әрем-кураларны иркәләп искән талгын җилләренә кеше тоемы ияреп йөри. Менә берничә мисал:

Соры дулкын булып арыш җитә,
Болыннарда зәңгәр мәк йөри...

Яки:

Урман буйларында соры юрган,
Галиябану монда арыш урган.
. . . . . .
Көтү үткән тугайларга тулып.
Минем моңым агыла томан булып.

Яисә:

Кырлар яшел, күкләр зәңгәр сәтин,
Таңнар комач кебек...
Гомер буе карап торсаң да син
Күреп туймас кебек.

Г. Афзалның 50 еллар ахырында әдәбиятка үзенең юмористик һәм сатирик шигырьләре белән омтылышлы керүе — аның үз геройлары арасында яшәвендә, авыл кешеләренең гадәт-психологиясен нечкәләп белүендә, аларны аңлый алуында. Ул алар турында яратып, сөеп яза. Күпчелек очракта ул кешеләр аңа рухи якын, үз кешеләре.[1] Шагыйрьнең аларга кешелекле эчке бер җылы хисе бар. Юкса, ул аларның рухына, эчке дөньяларына үтеп керә алыр идеме, алар теле белән, алар булып яза алыр идеме! 50—60 нчы еллар колхоз авылының байтак кызык, кабатланмас типларын үзенә буяулар белән калку итеп күрсәтеп бирә алды шагыйрь. Аның геройлары билгеле бер төбәкнеке, әйтик, Шәрип авылы тирәләренеке генә түгел, гомумән Урта Идел, Урал буйлары татар авылларыныкы. Алар типик геройлар. Алар һәр авылда. Кайберәүләрен генә исегезгә төшерегез: ат караудан зур юаныч табучы колхозчы Сабиржан-нар, яшьләрне чак кына сүгеп, картлыкның да яхшы якларын табып, җаннарын тыныч-латучы Фәтхелислам агайлар, махра урап, политика сүткәннән соң, янки-чәнкиләргә ачу итеп «печтек кенә салгалап» кәефләнүне дә читкә куймаучы Гаптелислам агайлар, әйборынча сүз җыеп, сүз чәчеп йөрүче Мәҗидәттәйләр, хәрам малга кулы ымсыныб-рак тора торган Сәлимгәрәй җизниләр, бераз мактанчыграк Сәгәхетдин бабайлар, теленнән очкын, кулыннан ут уйнатып, көләч йөзле кодачаларга ялт иттереп мич чыгаручы җор Шиһабетдиннәр, ава-түнә йөрүче бригадир Ахуннар...

Г. Афзалның авыл кешеләре турында елмайта-көлдерә торган шигырьләре матбугатта чыгу белән, укучы үзенең танышларын, күршеләрен, авылдашларын күрде, бик оста язылганнарын ятлап алды, сәхнәләрдән сөйләде, көйгә салды. Чөнки ул шигырьләр тормышчан иде, халыкчан иде. Шагыйрь халыктан алганны күңеле аша үткәреп, төртипкә, көйгә салып, янәдән халыкның үзенә кайтарып бирде.

Шагыйрьнең типлары турында, авылча-халыкчан тел турында, гомумән, юмористик һәм сатирик шигырьләре турында моңа кадәр матбугатта байтак язылды. Бу төр шигырьләрнең художество үзенчәлекләре хакында махсус мәкаләләр дә булды. Җыйнап әйткәндә Г. Афзалның 50—60 нчы еллардагы юмористик һәм сатирик шигырьләре татар поэзиясендә кызыклы, мәгънәле күренеш иде.

*

Г. Афзал югары уку йортларында махсус белем алган кеше түгел. Ул тумыштан нечкә хисләргә бирелеп, көйләр тыңлап, халык арасында рухи чарланып, хикмәтле сүзләр ишетеп, түбәннән күтәрелгән табигый талант. Ләкин тормышта тиктомалдан гына могҗиза ясалмый, сәбәпсез нәтиҗә булмый. Г. Афзалның да шагыйрь булып китүенә күп факторлар сәбәп. Аның да әйрәтүчеләре, остазлары булган. Шагыйрь нечкә тоемлы күңелгә, чиченнәрнекедәй телгә ия. Ул, беренчедән, бу байлыгы белән табигатьтә һәм гасырлар буена мирас-хәзинә булып килгән уй-фикерләрне сада итеп, ягымлы, тапкыр һәм тәэсирле итеп әйтеп бирергә сәләтле халык теленә бурычлы. Икенчедән, шәхси остазларга бурычлы. Г. Афзал өчен алар — Г. Тукай, Ш. Бабич, Такташ... Хәзерге көндә Тукай традицияләрен тугрылыклы рәвештә дәвам иттерүчеләрнең берсе, һичшиксез, Г. Афзал. Бу — жанрлар ягыннан да, тематик яктан да киң. Мәсәлән, Н. Исәнбәткә багышланган шигырьләр циклында мондый юлларны укыйбыз:

Мин бу җирдә төпле хуҗа, туган,
Рәхмәт әйтеп алдым әзерне.
Тукай, Бабич кулы сыйпап үзган
Һәр чәчәгә миңа кадерле.
Миңа кллэр, еллар сере ачык,
Төсен таныйм акның, караның.
Дәһләрнең иңбашына басып,
Заман үрләренә карадым.

Тукай, Бабичлар үзләренең мираслары — гүзәл шигырьләре белән рухландырып, көч өстәп торсалар, Г. Афзалның әдәбият мәйданына чыгуында күренекле шагыйрь С. Хәкимнең роле бик зур. Ул аның әмәт дусы — киңәшчесе һәм укытучысы.

Бүгенге әдәбиятта Тукай традицияләрен дәвам иттерүче булып саналучылар яки саналырга әзерләр байтак табылырга мөмкин. Ләкин аңа лаек булу кирәк бит әле! Тукай традицияләрен дәвам итү, беренче чиратта, заман һәм халык улы була алу, ил алдында торган иң актуаль мәсьәләләрне үз итеп кабул кылып, хәл итәргә алыну, чын

гражданин булу. Әлбәттә, бу олы бурычларны үтәргә талант кирәк, идеаллы максат кирәк, йөрәк кирәк.

Фәлсәфәне ничек кенә боргалама,
Берәр генә әч нәрсә бар бу дөньяда,
Иң кадерле,
иң мокатдәс,
иң изге зат:
Туган илең,
Туган телең,
Туган ана.

Р. Кутуйның «Ленинга карап» исемле новелласы бар. Анда балаларча беркатлы, әмма рухы нык, күңеле нечкә берәүнең, урта яшьләрдәге авыл кешесенең Мәскәүгә беренче килгәч, кешеләр торганчы, иртүк, бәйрәмчә киенеп, Ленин янына мавзолейга баруы сурәтләнә. Әсәрдә исеме күрсәтелмәсә дә, ул — Г. Афзал. Моннан 3—4 ел элек бер төркем язучылар Мәскәүгә барып татар әдәбияты көннәре үткәреп йөргәннәр иде. Шагыйрь Р. Кутуй Гамил Афзал белән «Украина» гостиницасының бер бүлмәсендә тора. Рөстәм аны натурадан кәгазьгә күчергән. Укып карагыз, көлке шигырьләрен яратып укыган шагыйрегезнең лирик җанын беркадәр аңлый төшәрсез! (Шунысы да кызык, Г. Афзал үзе дә мавзолейны күрү тәэсиреннән нәкъ шул ук исемдә шигырь иҗат итә.)

Шагыйрьнең 15—20 еллык иҗатын яңадан күздән кичереп, китапларын кат-кат укып, анализлап карагач, бәй, дип куясың — юморист Гамил янында лирик Гамил бер дә ким түгел ләбаса! Г. Афзалның 50 нче ел урталарында язылган «Дөнья матур, дөнья киң», «Матурлык эзлим», «Шиһабетдин», «Коммунист йөрәге турында баллада», «Ана», 60 нчы елларда иҗат ителгән «Идел ага», «Ел буе», «Моң» һәм соңгы елларда басылып чыккан «Ленин булып уйлап кара», «Фәлсәфәне ничек кенә боргалама», «Ак күгәрчен», «Үткәннәрне онытырга кирәк», «Искән җилләр сөйли» һәм башка бик күп лирик-публицистик, лирик-интим шигырьләре яхшы дәлил була алырлардыр. Моңа өстәп, республикабызның күренекле композиторлары тарафыннан көйгә салынган «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары», «Гөлмәрьям», «Газинур», «Әлли-бәлли», «Очрашу» кебек җырларын күрсәтеп үтү дә әле әйтелгән фикерне куәтли дип уйлыйм. Шулай да лирик һәм сатирик Г. Афзал хакында уйлаганда яшьтәш шагыйрьләремнән берсенең күптән түгел генә әйткән сүзләре хәтергә килә. «Миңа, укучы һәм әдәбият кешесе буларак, сатирик Афзал кирәгрәк тә, якынрак та. Иҗатындагы һәр ике якның уңышларын инкарь итмәстән, шуны әйтәм: безнең әдәбиятта аның кебек сатирик юк диярлек, ә аның белән тигез яки аннан көчлерәк лирикларны бармак ларны бөгеп санарга була... Нигездә төпле фикер бу. Ләкин шунысы бар: шәхеснең шагыйрьнең объектив иҗади эволюция процессын теләү, кушу яки боеру белән генә капылт үзгәртеп булмый. Инде сүз Г. Афзалның юмор-сатира өлкәсендәге эшчәнлегенең турында икән, минемчә, соңгы еллардагы бу юнәлеш шигырьләре 50—60 нчы елларда иҗат ителгәннәреннән өстен түгел. Кемгә ничектер, минем өчен аның «Мыек борамы», «Өф-өф итеп», «Кызыл балчык» артеләндә», «Тотып җибәр, апаем» кебек әсәрләре соңгы елларда басылып чыккан «Бөркет», «Мине картайткан, йөзне сарганткан ел нәрсә», «Шомакойрык белән Сарытырнак диалогы», «Автор киңәш итми», «Кара пәсинең этлеге» исемле шигырьләренә караганда көчлерәк. Элегрәк язганнарының көлдерү хасияте белән бергә мәгънәләре тирәнрәк, социаль яңгырашлары үткенрәк, көчлерәк иде. Мәгълүм нәрсә: көлүнең, сатираның объекты, гадәттә, конкрет, һәм шуңа да, сатираның үсеше шәхеснең талант дәрәҗәсе белән бергә, җәмгыятьнең тормышның конкрет үсеш этапларына, күренешләренә һәм типларына бәйле. Тәвәккәл әбиләр, бригадир Ахуннар конкрет бер заманның типлары иделәр. Инде ул чорлар үзды. Колхозлар үзгәрде, кешеләре үзгәрде. Ләкин «һәр заманның була сволочь сукин сыны кәһәр суккыры» дигәндәй, бүгенге көндә дә сатираның үткен угына бирелаек типлар бар. Андыйларны авыл җирендә дә, шәһәрдә дә табып була. Тик аларны таный белергә, иң характерлы, гыйбрәтле якларын тотып, җәмгыятьнең алга барышын комачаулаучы көч икәнлекләрен фаш итеп, көйдерә белергә кирәк. Ә аларның үзләрен, психология-гадәтләрен, мәхит-җирлекләрен белмәгәндә, ничек фаш итмәк кирәк

Бу — асылда аныҡ хаҡыйҡать — тормышны тирән белүгә, өйрәнүгә ҡайтып ҡала. Бу безнең бөтенебезгә, шулай ук «кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла» дигәндәй, Г. Афзалга да ҡарый.

Шағыйрьнең сатирасы һәм лирикаһы турындағы фикерне түгәрәкләү алдыннан тағын шуны да әйтү кирәк булыр: лириканың һәм сатираның, төп функциаль аермаларынан тыш, тәэсир итү формалары да шактый үзгә. Юмор-сатира — гаять тиз тәэсир итүчән, чөнки сүз — конкрет, объект — конкрет, тасвирлау, сурәтләү чараларының эффектлы, бай. Шуңа да уңышлы сатирик шигырь сәхнәдән яңгырауға, зал алкышларға, шаркылдап көлүләргә күмелә. Шигырь шартлый, бенгаль утлары кебек балкып ахырынача янып бетә. Кабатлый башласаң эффект югала, кими, тагын кабатласаң — тагын күбрәк кими... Бәлки шуңардыр, авыл сәхнәләреннән бик күп яңгыраган «Ир бала кышымы, кыз баламы?», «Тәвәккәл әби», «Әсмабикә ҡаным, ахирәт»ләр хәзер алай ук тәэсир итми. Чөнки күп тыңланган, күп ишетелгән. Ә менә лирик шигырьнең табигате башкачарак, үзгәрәк. Ул сәхнәдән дә бүтәнчәрәк кабул ителә: озаграк, салмаграк, ләззәте дә «күңелнең хис тартмачыкларына» туфракка сеңүче тамчылар кебек әкрен юл ала... Ни хикмәттер, шағыйрь йәрәгеннән чыккан җитди шигырьләр берҡайчан да туйдырмыйлар. Кабат укыган саен, алар сиңа нидер өсти, яңа кичерешләргә этәрә, яңа ассоциацияләр тудыра. Тукайның «И мәкатдәс моңлы сазым...» яки «Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата...» кебек юлларын инде унынарча кабат укыган булсаң да, һаман күңелнең иң нечкә кылларына ҡагылып тәэсир итү көчен югалтмыйлар. Г. Афзалның «Дөнья матур, дөнья киң», «Моң» кебек башка байтак җитди шигырьләре дә искерер өчен язылмаганнар шикелле. Тууына 50 ел тулу мөнәсәбәте белән шағыйрьнең «Ышанығыз» исемле сайланмасы тиз арада басылып чыгарга тиеш. Ул китап лирик Г. Афзалны бөтенәйтебрәк, калкурак итеп күрсәтә алыр дип ышанабыҙ.

Г. Афзал, үзе әйткәнчә, бәхетле кеше, бәхетле шағыйрь. Әдәбият мәйданына моннан 15 еллар элек кенә килеп, ул шул вакыт эчендә татар поэзиясенең күренекле иҗатчысы, халыкның популяр шағыйренә әверелде. Бу соңгы дистә еллар дәвамында үз репертуарларына Г. Афзал шигырьләрен яки җырларын кертмәгән үзешчән коллективны табуы кыен, аның шигырьләре яңгырамаган татар сәхнәсе, мөгаен, юктыр. Китапларының куллардан кулларга, язганнарының күңелләрдән күңелләргә күчеп йөрүләрен тою — һәр иҗат кешесе өчен зур куаныч. Г. Афзал шул куанычка, шул бәхеткә ия шағыйрь.

Соңгы елларда шағыйрь нәрсәләр язды, хәзер нинди әсәрләр иҗат итә? дип сорарлар. Әлмәттә яшәү дәверендә, 6 ел эчендә, ул җиде шигырь китабы чыгарды. Күп санлы лирик һәм сатирик шигырьләр белән берәттән «Искән җилләр сәйли», «Сәмбикә сылу», «Назыйм Хикмәт» кебек эпик пландагы озын шигырьләр иҗат итте. Үткән елда Г. Афзал чәчмәдә дә үзенең каләмен сынап карады. Унбиштән артык кечкенә күләмле сатирик хикәяләр язды. Язган берсен дәирлек безгә — каләмдәшләренә күрсәтеп килә, җыелышып укыйбыз, кызыксындырырлык хикәяләр! Кайберләре инде «Чаян» журналында басылып та чыкты. Әйе, шағыйрь иҗат итә, үзен төрле жанрларда сынап карый.

Г. Афзалның 16 нчы амбар кенәгәсендә бик кыска гына бер шигыре бар. Ике юлы болай:

И ходаем, хур итәргә теләмәсәң,
Шағыйрьләргә байлык бирмә, власть бирмә!

Әле моңарчы татар шағыйрьләренә байлык дигән афәтнең курыкныч булып килеп басканы юк, һәм, мөгаен, басмас та,— аннан бик әсәсәләнгән юк, минем курыкканым бүтән: берүк, ходай, шағыйрьләргә тынычлану, битарафлык бирә күрмә, «классик-лык чирен» йоктыра күрмә, күңелләренең илаһи пакь чагында язганнарына тугры итеп калдыр!

Шигырь булып туды әманәтем,
Шигырь булып чыкты хәсрәтем,
Матурлыкка — чиксез мәхәббәтем,
Явызлыкка — чиксез нәфрәтем! —

ди безнең Гамил.

...Шагыйрьгә 50 яшь. Бу ел — ил бишьеллыгының беренче елы. Партия съезды ел язучыларның ил күләмендәге съезды елы, зур хезмәт елы. Алда эшләр күп. Галияб нуларны (шагыйрьнең яңа туган кызының исеме) үстерәсе бар. Үскәч алар да «Дөнь матур, дөнья киң!» дип җырлый алсыннар өчен, ил тормышы — тыныч, имин, халы күңеле — көр һәм кешелекле, шигърият бакчасы һәрчак гүзәл булсын һәм җимешл булсын өчен күп көч куеп бергәләшеп иҗат итәсе бар. Яңа уңышлар, яңа иҗади ша лыклар сиңа, шагыйрь дустыбыз Гамил Афзал!

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИ

Гамил Афзал

Җирем

Уйга талып, аппак булып карланган жир,
Тамчы тамып, сулар агып, парланган жир,
Дөнья йөзен туйдырырга ялланган жир,
Ач бәгырьләр өзелә-киселә каргалган жир,
Сине таптап үтте золым, үтте жәбер,
Аланнарың — кемгә бишек, кемгә кабер,
Бәхет тапкан, канат каккан изге жирем,
Сандугачка гөл бакчасы бул син хәзер!

●

Болыннарда билдән үлән үскән,
Яшел яулык болгый зирек, каен,
Жылы яңгыр булып кайтсаң икән
Язлар саен, язлар саен.

Биек-биек тауга менеп життем,
Текә үрләр белән жан сайраша.
Талгын жилләр булып кайтсаң икән
Таулар аша, таулар аша.

Йолдызларда илһам тапсаң икән,
Күзең белән зәңгәр нурлар эчеп.
Кайтавазлар булып кайтсаң икән
Еллар кичеп, еллар кичеп.

●

Нәкый Исәнбәткә

Иртә генә таңнан уяндым да,
Таралуын күрдем томаннын.
Галәмнәргә очтым хыялымда,
Заманнарга карап уйландым.
Кояш нурларыннан нур алдым да,
Салкын чишмәләрдән су алдым.

Яз жилләрен эчеп тауга мендем,
Матурлыгын күрдем дөньяның.
Яшь пәйгамбәр булып җиргә индем,
Гасырларның серен тыңладым.
Идел-Йортның ерак елларыннан
Оныкларга сәлам юлладым.

●

Туган илем,
Туган халкым, дисең,
Үткән үрләр, калган бусага —
Изге аһәң эзләп чапкан хисем
Әйләнә дә кайта Мусага.

Сер сынатмас, димен, безнең буын,
Нинди дошман алда торса да;
Дәрткә дәрман эзләп чапкан уем
Әйләнә дә кайта Мусага.

Була арган,
Күнел төшкән чагым,
Күнел күгем аяз булса да.
Ярдәм-терәк эзләп янган жаным
Таудай терәк таба Мусада.

●

Кеше күңеле фәрештәдәй изге,
Коры түгел,
Шәфкатьсез түгел.
Авыр еллар әрнетсә дә безне,—
Оныта күнел,
Кичерә күңел.

Уникешәр сәгать йөрдек эштә
Куллар туңып,
Аяклар туңып.
Шул ин кыен еллар керә төшкә
Кызык булып,
Күңелле булып!

Бөгелмә аэропортында

Күл төбедәй күк эңгәре төшә,
Фирүзәдән койган ишедер.
Зәңгәр форма,
Зәңгәр берет килешә —
Зәңгәр һаваларның төседер.

Тимер аккош килер вакыт житкән,
Чемоданнар зарыгып көтә бар да.
Үткән заманнарны уйлый микән
Буфет янындагы арба?

Пыяла да бетон —
Бәллүр бина.
Тыгыз жилләр искән бу далада
Айны футбол итеп тибеп була,
Кояш батып торган арада.

Монсу гына кояш баеп бара,
Сүрән, җиләс һава агышы
Шәфәкъ булып тәрәзләрдә яна
Ерак планеталар сагышы.

Марсианнар килеп төшәр кебек,
Уйландыра торган энҗер-меңгер.
Хыял тирән монда, күкләр биек,
Кичке унбер.

Җим чүпләргә төшкән кошлар кебек,
Чирәмлектә тып-тын ял итәләр
Канатлары талган фәрештәләр.

Бөркет канатының салмаклыгы,
Аккош канатының аклыгы,
Офыклардан офыкларга йөзгән
Ак болытларның шатлыгы —

Куш моторлы ак самолетның
Аркасыннан сөясе килә.
Пәри кытыклаган малай кебек
Көләсе килә.

Хыял гына барып җитәр юллар...
Акыл иңнәрендә көмеш канат,
Карлыгачтай кыеп үтәсе бар,
Якты йолдызларга карап.

Прожекторлар кабына күкне ярып,
Төпләрендә күгелҗем күләгә.
Без дөньяны тезгә утыртмадык,
Дөнья йөри безнең тирәдә.

Ыргыласың кинлек, яктылыкка,
Җиңел канатларны җилләр куа...
Утлар янган кичке аэропортта
Галәмнәргә ашар хис туа.

●

Мин яшь әле,
Шатлана да беләм,
Соклана да алам матурга.
Их, бер генә, болын юлы белән,
Малай чактан урап кайтырга!

●

Юллар сүтәбез,
Үрләр үтәбез,
Хыяллар яна нур булып.
Җирдән киләбез,
Җиргә китәбез,
Хыяллар кала җыр булып.

Өченче кызым тугач

Кызлар алып кайтасың да,
Кызларың белән горур;
Кызлы кеше капкасында
Кырык ат бәйдә торыр!

Челлә

Юкә балы коендырган басу алдын, басу артын,
Яшел шәлен ингә салып уйга талган каеннар тын.

Кыр куяны кырлар буйлап кызыл ярга чаба сыман,
Баш өстендә кояш яна утта кызган таба сыман.

Җир жимеше жиргә тамып кулга керә, илгә керә.
Басуларга алтын салып челлә керә, челлә керә.

Күләгәдә көн үтсен дип, күл буенда ята көтү.
Кая инде ул, әйрән эчеп, кибән төбендә ял итү!

Күзне йоммак кай арада, караңгылык инәр-инмәс,
Сызылып кына таң ярала, шәфәкъ нуры сүнәр-сүнмәс.

Печән житте, арыш житте, дулкынланып тора чак-чак,
Печән өсте, урак өсте, кыл кырыкка ярылган чак.

Татлы оеп тәннәр тала, кул-аяклар бер пот кебек,
Тәмугмыни, табан яна, гел ут кебек, гел ут кебек.

Кояшы да баемаган, ае калка урак кебек,
Бөтен кеше бөгелгәндә бил турайту гөнаһ кебек.

Чынлый иген. Кырлар инен көлеп инлә, сөеп инлә!
Безнең илләр матурлыгы — кышын кырлач, жәен челлә.

Тун астында кыюлык

Башны каплыйм диеп тунны тартам,
Исән булсын, димен, баш кына.
Үз кыюлыгымнан куркып ятам,
Кыюлыкка йөрәк ашкына.

Минме, димен,
Миндәй егетләрнең
Дөньяда юк әле булганы.
Власть кына мина тоттырсыннар,
Дер селкетер идем дөньяны!

Гел турыдан ярып торыр идем,
Теге-буны тотмыйм бер грамм.

Рульне мин бик әйбәт борыр идем,
Эш авыр шул,
Бик куркып торам.

Җыелышларда кулга кәгазь тотып,
Сикереп торып тәнкыйть итәр идем,
Трибунада утлар-сулар йотып,
Бюрократның женен тегәр идем.

Квартир аласы бар,
Бирәм, диләр,
Ихтирамым сезгә тирән, диләр;
Тәнкыйть сүзен әйтми каласың,
Әдәп бар бит,
Кая барасың!

Җыелышларда бик тәүфыйклы гына
Бер кырыйда посып утырам.
Миннән генә калмаган бу дөнья,
Мин үлгәч тә шаулар бу урам;
Эш хәтәр шул,
Бик куркып торам.

Премиядән коры калуың бар,
Бөтен кеше көрәп алганда.
Ялгыш фикер әйтеп януың бар,
Бүре бар бит әле урманда.

Әтәчләнеп канат кагырсың да,
Башкаена бәла алырсың.
«Үзен теләп» гариза язарсың,
Ә язмыйча кая барырсың!

Пенсия алганнарның эше җайлы,
Шаулыйлар да алар, даулыйлар.
Тәнкыйть өчен кыскан абзыйлар
Пенсиягә тия алмыйлар.

Пенсиягә чыккач, алла бирса,
Алга таба кыю барырмын.
Тыныч күңел белән тыныч кесә,
Дөреслекне ярып салырмын

Ә хәзергә тун астында ятып,
Теткәлә дә, брат, типкәлә;
Үзе алдында якты чырай атып,
Жизни диеп эндәш эткә дә.

Ияләнгән бөркет

Егерме ел читлектә утыргач,
Ялга чыгардылар бөркетне.
— Бар оч инде, диделәр, әйдә селкен,
Бөтен дөнья хәзер синең милкең!

— Э подъемный кая,— диде бөркет!
— Юк, паегым кала,— диде бөркет,—
Пенсиягә бер ел калыр-калмас,
Берегез дә мине алдый алмас,
Төкерәм мин хәзер дөньясына!

Хәйләкәр елмаеп,
Ипләп кенә,
Көчле канатларын бөкләп кенә
Кире кереп посты оясына.

Читлегендә уңга-сулга бакты,
Кемнәрнедер эрләп мыжгып ятты:
— Тапканнар дуракны!..

Портрет

Исәп-хисап белән ярдәм итә,
Санап бара ярдәм иткәнен,
Бил бөгүне, баш июне көтә,
Эйтеп куя көчле икәнен.

Ахирәт һәм гомерлек дус була
Өстәл тулы сыен бар жирдә.
Былбыл булып түрләренә куна,
Елан булып чага тар жирдә.

Заман белән бәхәс

Ашап туйгач, кулга газет тотып,
Бәхәсләшеп ятам заман белән.
Заман әйтә миңа мораль укып:
— Филгә кизәнәсең салам белән.

Мин кычкырам: — Ялгышасың, тукта!
Якалашып китәм заман белән.
Заман әйтә:— Энем, кулын кыска,
Филгә кизәнәсең салам белән.

Нәкый Исәнбәт

АУЛАК ӨЙ

ХАЛЫК ТЕАТРЛАРЫ ҺӘМ ФИЛАРМОНИЯ ӨЧЕН МУЗЫКАЛЬ УЕН

1 ПӘРДӘДӘ

Аулак өй һәм аны уздыру йоласы, аулак өйләр һәм бу әсәр турында берничә сүз

Авыл кешеләре жәйге көзге кыр эшләреннән бераз бушанга гадәттә, үзара күрше авылга кунакка-фәләнгә йөрешү, бе береңне күрешү дигән яхшы бер йола бар. Шундый чакла да ата-аналар өйне-йортны карап торуны берәр якын ап жиңги кебек кешеләренә яки күрше карчыкларына тапш рып китәләр. Бигрәк тә инде ул кызлы өй булса. Эл заманнарда әнә шундый аулак калган йортларда яшерт рәвештә аулак өй кичәләре ясалган. Шуна күрә анын исеме дә — аулак өй.

Аулак өй — ул аш-сулы, күчтәнәчле мәжлес. Ул, ихтыярый рәвештә, азык-төлек я акча салышып ясалганга, аны кайбер якта «урнаш жыю» диләр. (Урын аш — урын аш димәктән. Яшертен һәм уртын пешерелгән аш булганга, бу сүздә «уртын аш» дигән дә ишарә бар...)

Гадәттә, яз, жәй көннәрендә ачык һавада үткәрелә торган уен-жыеннарны ирлә егетләр оештыра, әмма бу аулак өйне башлаучылар кызлар булган. Кышын әле таг бездә уздырыла торган нардуган кичәләре дә булган. Анысы да аулак өй кичәсе бераз охшый һәм аны да шулай ук кызлар оештырганнар. Тик ул хәзер бетк диярлек.

Аулак өй ничек ясала?

Менә берничә «кемәй» кыз. Башта алар алдан очрашалар, көнен, урынын билгел сүз куешалар. Шул сөйләшенгән буенча, алар кичен караңгы төшәрәк, бәйрәмчә кие нәрен киенеп, бизәнеп-ясанып, үзләре белән кул эшләрен алып, күбесенчә, ата-аналар на белдермичә үк, берәм-берәм генә әлеге аулак өйгә киләләр. Кызлар «серен» кайб

таныш егетләр дә сизеп алалар. Билгеле, кызлар янына һәрбер очраклы егет килә алмый, алар сайлап, сайланып чакырылган яки килүе теләнгән алдан билгеле кешеләр була. Шуна күрә, бу егетләр үзләре дә кызларны яманатка калдырудан бик сакланып, карангы төшкәч кенә киләләр һәм рөхсәт белән керәләр.

Шулай булгачтын, хәер, монысы үзеннән-үзе аңлашыла булыр,— аулак өй күнел ачу кичәсе булып кына калмый, ул элек бездә егетләр-кызларның очрашу, танышу, хәтта кайбер якта шунда кунып калып, бер-берсен сынашу, вәгъдәләр алышу урыннары да булган. Ихтимал, ул болгар бабайлар заманнарыннан калган бер йоладыр. Мондый аулаклану ата-аналардан яшереп ясалганга һәм кызларны яучы аркылы мәһәр түләп, никахлап алу шәригать законы итеп куелган заманнарда, андый иркенлекне, билгеле, тыярга, хәтта таяклап тыярга тырышканнар.

Шуна да карамастан, аулак өйләр һәркайда дәвам иткән. Ник дисәң, элек татар җәмәгатендә театр заллары, клублар булмаганда, бу кичәләр уен-көлке, җыр-бию, тапкырлык һәм ижади осталык күрсәтешү урыны да булган. Кызлар-егетләр бер-берсен сайлаганда, табигый, үзләренең сәнгать, матурлык, талант ягыннан да мәхрүм түгеллекләрен күрсәтергә, кабынырга, балкырга, сынатмаска тиеш булганнар.

Дөрес, яшьләрнең очрашу, уен, җыр, бию, музыка талантлыгын ачу өчен безнең халыбызда башка урын һәм мәйданнар да аз булган. Сабан туе, җыеннар, кыз туйлары, таган асты, карга боткасы, өмәләр һәм һәрьякның юалык, каравыл тавы дигән кебек үз жыен-бәйрәмнәре дә булып торган. Алар бар да язын яки җәйләрен ясалганнар. Татар-болгар бабайлар исламга кадәр табигатьнең рухларына, айга-көнгә, җиргә-суга, ягъни ияләргә табынучы булган кебек, балалары да шушы рухта хәзерге көннәргәчә табигатьне табынып дәрәҗәдә сөюче булып калганнар. Шуны без туган-җир суларын исемләп атап чыгарган бик күп жыр-көйләрдә һәм аларны хәзер дә жырлап торуларында күрәбез. Халыкның йолалары да шуна бәйләнешле булуы күренә. Бигрәк тә сабан беткәч, печәнгә төшкәнче бер араның илдә махсус жыеннар, уен-туйлар, таган аслары, йола-бәйрәмнәр уздыру чагы булуы аеруча игътибарга лаек. Халык «чирәм өстендә, нәкъ чәчәк вакытында, 10—15 көнгә бөтенләйгә эштән туктатып, бер тугарылып ял иткән. Чөнки бит кыз алмасаң, килен төшермәсәң, туй-табын уздырмасаң, өй-гаилә кормасаң, кардәш-кабиләнне күрмәсәң, чирәм өстендә алар белән табышып, күрешеп, бер чөкердәшеп сөйләшеп, уйнап-көлеп, жырлашып-елашып та калмасаң, мин дә бер халкымның баласы дип йөрүендә ни мәгънә дә, яшәвеңдә ни мәгънә? Андый халык үзе дә дөньяда юктыр, булмагандыр![1].

Кыскасы, татар никадәрле эшкә егәр, тырыш, хезмәт сөючән булса, ул шулкадәр үк жыен-тамашалар яратучан. Халкыбызда әнә шундый театраль йолалар саклануы, нәтиҗәдә, бездә жыркай, музыка, бию һәм фольклор сәнгатен, ижат ялкынын сүндермичә дәвам иттерүгә зур сәбәп булганнар. Болар арасында аулак өй нәкъ әнә шундый уен, жыр, музыка, бию, тел осталыгы, милли кием һәм күл эшләре күрсәтешү кичәсе булу ягыннан аерым урын тота.

Шулай итеп, безнең өчен аулак өй йоласының иң мөһим ноктасы да аның үткен, шаян ижади тел, әйтем, такмак-такмаза, жыр-бию, көй-музыка ижатчылыгы, төрле кызыклы халык уеннары һәм фольклор мәйданы булып килүендә. Бу күнел ачу, жыр-уен мәжлесе төн авышканчы дәвам иткән.

Шул традицияләр жирлегендә хәзерге көннәрнең яңа йолалары туа һәм үсә. Минем ни өчен бу аулак өй темасына сәхнә әсәре язарга булуым да шушылардан аңлашылса кирәк.

Халык сәнгатен үстерү юлында, аның жыр, көй, бию, уен ижатын бер сюжетка туплап бирү өчен, аның урыны да аулак өй итеп алынды. Һәм әсәрнең үзенчәлеге дә шуннан килеп чыга: монда тамаша баштанаяк бары тик уен, жыр-бию һәм пантомимага корылган. Репликалар юк, булганы да бары тик биюләр арасында эндәшеп жибәрү кебек, аерым ымлыклар һәм бик зарур берничә сүз генә. Шулай булса да, тамашага бер эзлеклелек һәм үсеш бирү өчен, әсәр бөтен бер драматик вакыйга төсендә бирелде. Ягъни, анда үзенә күрә экспозиция, бәйләнеш, чишелеш бар. Билгеле инде, бу драма-

[1] Хәер, легендаларга караганда, андый бер халык тарихта булмаган түгел. Мәсәлән, бабил (вавилон) манарасын коручы борынгы кол биләүчеләр жәмгыяте. Ләкин алар да анда бер-берсен аңлый алмыйча таралганнар, имеш. (Библия легендасы.)

тизмның ни дәрәҗәдә киеренке булуы мондый әсәрдә текстган гына түгел, музыка һәм биюләрнең ничек куелышына карап булачак.

Әсәр шулай гел уен, жыр, биюләрдән торса да, билгеле, ул этнографик тасвирлама түгел. Югыйсә, аулак өйдә уеннар бик күп. («Каеш ташлау», «почталы», «кем сукты», «тычкан салыш», «яр-ярлы», «булавка яшереш», «күгәрчен ашату» һәм башка уннарча уен.) Шунлыктан, «Аулак өй» булса да, монда уен һәм детальләр булганынча күпләп алына алмый, бары тик вакыйга һәм сюжет сыйдыра алган микъдарда, шул кичә өчен характерлы булганнары гына алына.

Шундый бер сорау бирерләр: халык театрларында башкаручылар житмәгәндә, бу уен-жырларның кайберләрен кыскартып буламы?

Жавап: була. Ләкин шулар арасыннан чигүле яулыкка, Васфига, ата-анасына, Гөл әбигә, Котдуска һәм бәлеш урлауга бәйләнешле булган уен-жыр биюләрне төшереп калдырып уйнарга һич тә ярамый, ул чагында драматик сызык бозылачак. Калган номерларны сайлап алырга мөмкин булсын өчен, кайбер уен, жыр-такмазалар өстәп кертелде.

ВАКЫЙГАДА КАТНАШАЛАР

Васфи — авыл кызы.
Хупжамал — Васфиның анасы.
Гайнетдин — Васфиның атасы.
Котдус — Васфиның сөйгәне.
Дәрри, Мәхүп } — күрше кызлары.
Гөл әби — йорт сакларга калучы.
Садри, Шакир } — авыл егетләре.
Дәүләтша, Салих } — гармунчылар.
Үсмер кыз.

Тагын башка кызлар, егетләр.

Вакыйга элекке заманда бер авылда бара.

Авыл өенең эче күренә. Алда — уң якта ишек, аңа каршы якта тәрәзә. *(Болар шартлы рәвештә рам гына куеп, пәрдә корылган булуы мөмкин.)*

Каршыда — артта ап-ак мич буе. *(Бу да шартлы рәвештә торгызылган фанер гына.)* Өстенә татарча чигүле чаршау эленгән. Ишек ягыннан мич арасы бар. Шул арага кереп үтеп, мич алды ягыннан мич алдына таба бер кадәр чаршау төшерелгән. Аш-су әзерли торган ул як бүленгән кебек күренә.

Алда өстә түшәмгә кашагалап Васфиның чигүле кул эшләре эленгән. Гомумән, кызлы өй икәне беленеп тора.

Мич буенда һәм ян-якта эскәмияләр, бүкән, табурет кебек нәрсәләр.

БЕРЕНЧЕ ЭПИЗОД

Пәрдә ачылганда Хупжамал туйга китәр киемнәрен киенгән. Аш бүлмәсе ягында кин табуретта мич ашларын ашъяулыкка төреп бәйләп маташа. Васфи да шунда. Ул киергегә беркетелгән чигүле яулыгын тәмамларга ашыга.

Хупжамал.

Кызым, жаным, тегү-чигү эшләрең күп,
Күрше кызы Дәрри керер, тагын Мәхүп.
Гөл әби дә кереп житәр.
Чәй эчәрсез. Сезгә житәр, ризыклар күп.

Васфи. Я, я, *(дип тора. Әтисенең кереп килгәнен күреп, киергесен янга куя да әнисенә төенчек бәйләргә булыша.)*

Гайнетдин керә. Кулында чыбыркы.

Гайнетдин *(тәрәзәгә ишарәләп)*.

I

Әлдермешләр турысында болыт тора.
Анда кода безне туйга көтеп тора.
Атым жиккән, я, булдымы күчтәнәчең,
Бөккән, сумсаң, чәк-чәкиең, пәрәмәчең.

(Кызның киергесенә күзе төшә. «Кемгә чигә бу?» дигән уй белән алып-алып кире куя.)

Хупҗамал. Кызым, сезгә мичтә калды ике бәлеш.
Кызларыңа дигәненең авызы чалыш.
Әйе, һе-һе. Аңладыңмы?

Васфи. Әйе, һе-һе.

Гайнетдин *(кызга)*. Аны кара! *(Камчы сабы белән яный-яный кисәтеп.)*
Без китте дип ясамаска берни чыр-чу,
Син аулак өй ясый күрмә! *(Тәрәзәгә карап атып тыя.)* Ту, дим, ту, ту!
Ходай сакла! Беләсең бит егет халкын,
Кыз урлыйлар, чыгаралар яманатын!
(Тышка.) Тырр дим, ләгънәт!

Хупҗамал *(һаман бәйли, кызына)*.
Ике бәлеш таба белән.
Гөл әбиең кереп җитәр каба белән.
Кул эшең күп. Тегәрсез дә чәй эчәрсез.
Тегәрсез дә, әйе, һе-эе...

Васфи *(тизрәк җибәрәсе килеп)*. Чәй эчәрбез.

Гайнетдин. Чәй эчәрсез. Эчәрсез дә, аны кара!
Котдус дигән бер егет бар, йөзе кара.
Якын йөртмә! Сине сорап баерак жирләр.
Бу бик ут күз. Күрәм әле аңа чара!

Хупҗамал. Әйе, һе-һе!

Гайнетдин. Һе-һеләдең, әйдә сәнә!
Көн кичли бит. Куй башына, мә, мә сәнә!
(Төенчеген аның баш түбәсенә куя.)

Хупҗамал. Әй, коясың чәк-чәкием! Чәк-чәкием!
(Башында төенчек, үзе шул килеш селкенми бии башлый.)

Гайнетдин. Елдыр-елыш ишек таба я, я сәнә!

(Янында бии.)

Их син, Хупҗамал,
Яның белән шуа бар.
Пәрәмәч эремчеге,
Галәмәт төенчеге.
Их, киттек без туйга,
Анда көтә бит кода.
Кода көтә Әлдермештә,
Без калып беттек кичкә.

Хупҗамал *(бии)*. Әйе, һе-эе, әйе, һе-эе!

Васфи. Калып беттегез кичкә.

Гайнетдин.
Аш артыннан мунчасы,
Мунча кергәч сумсасы.
Чәй янында хәтта ки,
Кәләвә дә чәлпәки.

Хупҗамал *(бии)*. Әйе, һе-әе, әйе, һе-әе.
Кәләвә дә чәлпәки.

Гайнетдин. Анда булыр кәттәфи,
Чәлпәки дә чәк-чәки,
Корт, бавырсак, кош телләре,
Бал да кояр хәтта ки.

Хупҗамал *(бии)*. Әйе, һе-әе, әйе, һе-әе!
Гайнетдин. Бал да кояр хәтта ки.
Хупҗамал *(биегән килеш чүгәләп)*.
Кул күтәрик догага.

Гайнетдин *(Кул күтәргән. Күзе тәрәзәдә)*.
Түв... дим, нәләт, дулама!
Без кылганчы доганы
Сындыра бит дуганы!

(Йөгереп чыгып китә.)

Хупҗамал. Ярый, кызым, хуш иттек.
Хуш исән бул, без киттек.

Васфи. Хуш, әни, хуш.
Хупҗамал. Хуш торып кал,
Ишегеңне элеп кал!

Бииеп чыгып китә. Васфи ишекне элә, аннан уртага килә, тәрәзәгә карый. Киергесен ала.

Васфи *(ялгыз җырлый)*.
Алтын кайчы белән һай кисәләр
Ахак йөзекләрнең кашларын,
Шәфкатьсез дә ата харап итә
Кыз баланың газиз башларын.
Агыйделкәйләргә басма салдым.
Берсе аның имән, берсе тал.
Әткәем үк шикәр, әнкәем бал,
Бал-шикәрдин татлы сөйгән яр.

И көнлиләр, көнлиләр,
Сөйгәнемне кимлиләр;
Никадәрле кимләсәләр
Күбрәк сөям, белмиләр.
(Чигүен алып.)
Кулъяулыгым тирәген
Чигеп тыктым төнәген,
Шушы булсын Котдусыма
Вәгъдә өчен бүләгем.
Саесканның баласы,
Сырт өстендә карасы,
Сизмәсәләр бик ярасы,
Сизсәләр йөз карасы.
(Кулъяулыгын күтәреп карап, әйләнә-әйләнә бии башлый.)
Киттеләр — күрде микән,
Хәзер ул килер микән,
Ах, вәгъдәле кулъяулыгым
Бүген үк бирим микән.

Ишектә аяк тавышы. Васфи кинәт сискәнә. «Ул?..» Бииеп каршы алырга бара. Ишек ачылып, каба белән орчык күтәргән Гөл әби килеп керә. Васфи «ай!» дип әйләнеп идәнгә чүгә.

ИКЕНЧЕ ЭПИЗОД

Эчке пәрдә янадан ачыла. Мич буе һәм түр чаршау ягында эскәмия, бүкәннәрдә кызлар тегү-чигү белән утыралар. Алар белән Васфи, Дәрри, Мәхүп. Гөл әби ишек ягында, кече эскәмиядә кабада жеп эрли.

Кызлар хоры.

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлжамал,
Житкән кызлар киндер жеп жөрлиләр,
Энже-мәржән кызларның кулбавы,
Авыр жан сөйгәннәрнең булмавы.
Нинди генә егеткә барырбыз дип, Гөлжамал,
Колактан колакларга сөйлиләр.
Ай-һай гына Иделнең агуы,
Басылмыйдыр йөрәгем яныу.

Башларыма кигән такыямның, Гөлжамал,
Сачләремә йога ла буявы,
Энже-мәржән кызларның кулбавы,
Авыр жан сөйгәннәрнең булмавы.
Егет башларына ниләр килми, Гөлжамал,
Белгертмидер егетнең уявы.
Ай-һай гына Иделнең агуы.
Табылмыйдыр йөрәк лә даруы.

Пантомима.

Дәрри эскәмиянең мич арты як башында көзге чыгарып, үз-үзенә сокланып, бизәнеп утыра башлый. Аннан кинәт кызларга карапып ала да, аларга моңсу булып киткәнен күреп, бер хәйлә кора. Мич арасына керә, түбәтәй кия, мыек тарта, өстән жилән кия. Бу вакыт алда бер кыз жеп белән тартып кубыз уйный башлый. Бер кызны биергә этәрәләр. Ул көйне килештермәи, кубызчының колагына пышылдап, үзгәртергә әйтә. Кубызчы үзгәртә, теге кыз тагын аягын ничек башлап алырга төшенәлмый тора. Дәрри мич артыннан егет булып чыгып, песи булып кына, элекке урынына эскәмия башына кайтып утыра. Янындагы кыз да, башкалар да аны сизми кала, чөнки бу вакытта ялан аяклы бер үсмер кыз, беркемнән дә сорап тормыйча, арадан килеп чыга да бии башлый. Ул үргән чәч тәнкәле, башында бер генә рәт вак жиз тәнкә тезгән балаларча яссы калфак, түшендә хәситә, бар да аны карау белән мәшгуль. Аны шундук хуплап такмак әйтеп торалар. Кыз чың-чың килеп чылтыраган тәнкә тавышлары чыгарып бии.

Такмак.

Ала мәче, кара мәче
Кабык араларында,
Сикереп төшеп биеп ала
Халык араларында.

Тыпыр-тыпыр биегәнгә
Авыртмыймы тәпиең?
Монда килеп биегәнгә
Орышмыймы әтиең?

И бу кемнең чәчкәсе,
Чын-чың итә тәнкәсе,
Аккош микән, былбыл микән
Моны тапкан әнкәсе.

Әкрен бие, ипле бие,
Тәнкәләреңә төшмәсен,
Тәнкәң төшеп, әнкәң сизеп,
Түбә чәчең өзмәсен.

И биегез, биегез,
Әнә шулай биегез,
Уйнамагач та көлмәгәч
Нигә монда килдегез.

Үсмер кыз бии-бии кызлар арасына кереп югала. Кул чабу.

Пантомиманың дәвамы.

Шул вакыт егет булып киенгән мыеклы Дәрри, үзенә урын житмәгән кебек, янындагы кызга катылып, аны юри нык кына этәрә. Кыз әйләнеп карауга, Дәрри аны үбеп ала. Кыз үзен ят егет үпте дип белеп, «әнкәем!» дип сикереп тора. Куркып, битен кулы белән басып, йөгереп китә, икенче кырыйга бара да әйләнеп карап тора. Дәрри икәнен танып, «бәлеш!» дип, тагын ана йөгереп килә. Куллар белән чабаклашу. Көлеш.

Пар кубыз.

Васфи чигүле яулыгын ике якка селкеп бии башлый. Аның селкүенә кызлар кубып, күмәк бию китә. Менә Васфи тагын арада ялгыз күренә. Яулыгы белән сөйләшкән кебек бии. Тәрәзә янына житеп, пәрдә арасыннан карагач, ах! Кинәт аның хәрәкәтендә үзгәреш. Күрәсең, урамда Котдус! Васфи аны өйгә чакырып яулыгы белән ымлар ясый да бии-бии ишеккә, аны каршы алырга китә. Кергән егетне Котдус дип белеп, ишек пәрдәсе белән аны каплый, чиккән яулыгын ана бирәм дип, ят егеткә биргәнен күргач, коты очып, «ай!» дип, кызлар янына йөгерә.

Аның чигүле кулъяулыгын тотып бер егет керә. Ләкин курку урынсыз. Кызлар аның егет булып киенгән кыз икәнен беләләр. Музыка дәвам итә, кыз, исерек егеткә салынып, такмак әйтеп аугаланып бии башлый. Хәзер Васфи белән бер кыз ана ике яктан аумаска булышкалап, каршы такмак әйтешеп биләр. Васфи шул арада кулъяулыкны анын кулыннан элэктерергә тырыша.

«Исерек егет» *(былагайланып, альт тавыш белән).*

Эчтем, исердем,
Бер бидерә, бер комган,
Әйләнәм дә сезгә киләм,
Ахры, күзләрем тонган.

Булышчы беренче кыз—Васфи.

Эчкән, исергән,
Бер бидерә, бер комган,
Эчкән егет ярсыз кала,
Шуна күзләрең тонган.

«Исерек егет» *(егетләнеп, биялән шап-шоп сугып салып-күтәреп, сикергәләп).*

Егет булса, мут булсын,
Ике күзе ут булсын,
Егет булып мут булмаса,
Бар булганчы юк булсын!

Булышчы икенче кыз.

Егет булса, мут булсын,
Ике күзе ут булсын,
Эчеп күзе тонган булса,
Бар булганчы юк булсын.

«Исерек егет».

Аракыны эчмәдем,
Шуна күрә үсмәдем,
Хәзер эчә башладым,
Азрак үсә башладым. *(Аны упмәкче була.)*

Булышчы беренче кыз—Васфи *(этәреп).*

Кашын кара галәмәт,
Күзең ала карават,
Йөргән чакта тайгалыйсың,
Аягыңны дагалат!

«Исерек егет» *(былагайланып).*

Син дә чибәр, мин дә чибәр,
Кашың сикертеп җибәр;

Мине кызлар арасында
Иң чибәр егет, диләр!

Чигүле яулык селкеп, былагайланып, аны үпмәкче була.

Икенче булышчы кыз *(этәреп куеп)*.

Агыйделнең аръягында,
Төлке ята чирәмдә,
Акылың-фигылең белдек инде,
Санамыйбыз «чибәргә».

«Исерек егет».

Алай да була егет,
Болай да була егет,
Эч аракы, тарт тәмәке,
Менә булырсың егет!
Эч аракы, тарт тәмәке...

Васфи аның кулыннан чигүле кулъяулыгын эләктереп ала. «Исерек егет» лап итеп идәнгә егыла. Башыннан бүреге төшә. Чәч толымнары килеп чыга.

Ике кыз. Менә булдын да «егет»!

Аны күтәреп алалар. Өстен салып, кыз булып чыга.

Чиләк кагып бию.

Бер кыз тимер чиләк ала, төбенә бармак белән бию барабаны кебек чиртеп-кагып, такмак әйтә башлый. *(Типтәр кызларының аулак өй бию һәм такмаклары.)*

Туйдыр, суйдыр,
Бидрә барабаны,
Әсхәп, Хәлимә,
Ни булды хәленә?
Димтер, димтер,
Габделгани, санитар,
Галия филшер,
Хәяты духтыр.

Арыш, арыш,
Арыш башы бер карыш,
Бии белмәгән кызларның
Аягы-кулы чап-чалыш.

Тау башына тары чәчтем,
Ул да булса бакыра.
Тавык сатып кыз яраштем,
Ул да булса шадра.

Бидрә чирткән бармагым,
Кинәндерә тырнагым,
Барын-югын белмидер,
Май телидер тамагым.

Ат башында нукта,
Кызлар күзе чукта,
Староста узып бара,
Күп биемә, тукта!

ӨЧЕНЧЕ ЭПИЗОД

Чоланда шыбырдау. Бию өзелә, бар да колак сала. Егет киемендәге кыз костюмын салып чигүгә утыра.

Башта үткән «Гөлжамал» жыры кабатлана.

Ишектә Котдус күренә. Гөл әбине ымлап чакыра. Аулак өйгә керергә рөхсәт сорый. Икенче яктан Васфи килеп әбигә ялыну күрсәтә. Әби иңбашын гына кыбырдатып, аны кире кага, Котдуска ым белән «бер үзең генәме?» дип сорый. Котдус башта үзен генә, аннан бер бармагын, ике, өч, аннан икенче кул бармакларын да ача башлый. Гөл әби Васфины аркасы белән артка, Котдусны кулы белән ишеккә этәреп, «бар, бар, алай булса, йөрмә дә!» дигәнне аңлатып, чыгарып жибәрә. Васфида әбигә ялвару ымлыклары. Гөл әби аңа күл гына селти дә үзе дә ишектән чыга. Кызлар, куркынып, бер-берләренә карашалар. Әллә аулак өй булмыйча каламы, янәсе. Гөл әби ишектән кире керә. Алган «сәдака»сын тиз-тиз генә читек балтырына кыстыра да, ишеккә арты белән, кабага утырып, күл күтәреп, күзләрен йома-йома «озын дога» кылырга керешә. Ул шулай утырганда, алдан Котдус, аннан бер-бер артлы егетләр керәләр. Муеннарында бау-бау крәндил, капчык, кесәләрендә чикләвекләр, чуклы кәнфитләр, чабу асларында гармуннар. Берсенең кулында ике тәпиен жәпле чыбыкка таккан чебеш. Кызлар кузгалып «и-и» киләләр. Егетләр мич алды чаршау артына үтеп күчтәнәчләрен тапшыралар. Кызларга чуклы кәнфит, кызыл билле перәннекләр күрсәтеп ыргыталар.

Бию.

Кыз булып киенгән бер егет, кызларча кыланган булып, артын-рын, көлке бию бии башлый. Кызлар жәберсенәләр.

Егетләр *(перәннек-кәнфит жырлары)*:

Шыгырдаган капканы
Шыгырдатмый япмагыз,
Егет биргән перәндекне
Бисмилла итми капмагыз.

И машина, машина,
Илт мине жанашыма,
Алты кәнфит, жиде перәндек
Житә кызлар башына.

Болынлыкка козгын килгән,
Куркытадыр казларны,
Кызыл билле ак перәндек
Кызыктыра кызларны.

Скрипка, музыкан,
Йөз тәнкәлек кыз икән,
Йөз тәнкәлек кыз булса да,
Өч кәнфиткә кыза икән.

Бар егетләр, бар кызлар кара-каршы бер-берсенә төрттереп жырлыйлар.

Бер егет.

Егет, егет, димәгез,
Егеткә сез тимәгез.
Начар кызлар калып торсын,
Матур кызлар димләгез.

Бар кызларның чибәре,
Читек-кәвеш кигәне,
Бар кызларның килбәтлесе,
Итәге жиргә тигәне.

Бер кыз.

Егетләрнең шарыфы —
Ак мамыктан аркавы.
Шәфәкъ батмый ятып йоклый —
Бар егетнең ялкавы.

Бер егет.

Бар кызларның булганы —
Кызарып пешкән алмадай.
Бар кызларның булмаганы —
Изелеп беткән салмадай.

Бер кыз.

Бар егетнең үткене —
Кыелып очкан лачындай,
Бар егетнең азгыннары —
Май ашаган мәчедәй.

Бер егет.

Бар кызларның нәгызе —
Су өстендә күбектәй.
Бар кызларның аламасы —
Тузып беткән чүбектәй.

Бер кыз.

Бар егетнең дәртлесе —
Майлап чәчен тараган.
Бар егетнең җебегәне —
Ятып түшәм санаган.

Бер егет.

Бар кызларның шундые —
Яңа пешкән чиядәй.
Бар кызларның шундые да —
Колын салган биядәй.

Бер кыз.

Акбүз атның яхшысы
Ак чәчәкне таптамый.
Бар егетнең чын булганы —
Сөйгән ярын ташламый.

Кызлар хоры *(кабатлый)*.

Бар егетнең чын булганы —
Сөйгән ярын ташламый.

Бер егет *(кайтарып)*.

Бар кызларның әүлиясе —
Сөйгән ярын ташламый.

Бер егет *(гайрәтләнеп, кызларга таба бер адым алга чыгып)*.

Егет җилкенми булмас,
Кызлар аңа алданмас.
Егет күреп алданган кыз
Әллә кемгә баралмас.

Гөл апа *(эрләп утырган җиреннән, тарәшледән чүбек алып, бер-сенә дә карамыйча.)*

Барса барыр шул егеткә —
Шуның ише чүбеккә.
(Чүбекне кулыннан төшерә).

Бер егет.

Сандугачның балалары
Талдин талга таралмас.
Ярдин ярга йөргән кызлар
Әллә кемгә баралмас.

Гөл апа *(тагын өстәп)*.

Барса барыр шул кешегә —
Чалыш-полыш тешлегә.

(Орчыгын чалыш-полыш итеп күрсәтеп, үзе эрләвенда дәвам ита.)

Күшәгә *(Ырынбур биюе).*

Күшәгәдән күрде кыз,
Күрше кызга төште күз.
Уңлы-суллы бөти киеп
Биер өчен төште кыз.

Уңлы-суллы бөтине
Кем кимәс тә кем салмас,
Кемнәр бармас, кемнәр калмас,
Кемнәр ярын кем алмас.

Чебеш китергән егет *(мич авызы ягында, җәпле чыбыкка таккан чебешен күтәреп, селки-селки):*

Кичә тоттым бер тавык,
Бүген тоттым бер тавык.
Ике тавык китердем,
Берсен басып үтердем.

Карт кыз күрдем,
Кырын карап төкердем,
Яшь кыз күрдем,
Бүркем салып йөгердем.

Йөгердем, йөгердем,
Тез башымны сыдырдым,
Тез башымның авыртуыннан
Кыз куенына тыгылдым!

Бер кызның куенына тыгылмакчы була, кыз яңагына чаба. Көлеш.

Кызлар белән егетләр арасында

Кызлар.

Чики-чики чикерткә
Үлән арасында,
Ал ефәк, гөл ефәк
Кызлар арасында.

Егетләр.

Тукый-тукый тумырка
Урман арасында,
Кәнәфер, бадьян
Егетләр арасында.

Кызлар.

Чети-чети былбыл кош
Гөлләр арасында,
Ым-шым, кыл, кубыз
Кызлар арасында.

Егетләр.

Шыкый-шыкый лачын кош
Чытыр арасында,
Камчы, йөгерек ат
Егетләр арасында.

ТОРНА БИЮЕ

Мич артыннан бер егет торна булып чыга. Ул бер жилән (яка бишмәт)нең сынар жиң эченә уклау яки кыскыч тыгып, очын «торна борыны» итеп, жиң очына чыгарып бәйләгән дә, жиләнне башына ябынып, әлеге жиңне үз борынына туры китереп, төймәләрен каптырган. Билдән түбән аның камзул белән ак күлмәге һәм озын ботлары күренә. Ул, торна булып, идәнгә борыны белән чукып алып, «борчак чүпләп» бии. Үзенә каршы төшкән кызны чукырга иткән кебек хәрәкәтләр ясый, кыз белән ике арада парлы биюгә әйләнә.

Егет.

Ары басма, бире бас,
Кыек басма басмага,
Күркә күреп каныкмасын
Кызыл чуклы тасмаңа.

Кыз.

И абзыем, мыегың
Каткан кижә бөртеге,
Синең белән бер күрешү —
Елдин да артык бер көне.

Егет.

Капка башыннан карыйсың,
Аккош түгелсең әле,
Һаваланма, боргаланма,
Алсам, килерсең әле.

Егет.

Жаныем-жанашым килгән,
Энже калфагын кигән,
Сусыз мунчаларга кергән,
Жаныем кашын көйдергән.

Кыз.

Ике таунын арасы,
Кара песи баласы,
Синең кебек жырлый белә
Безнең чебеш анасы.

Кыз.

Бүген киден буйлысын,
Иртәгә ки аклысын,
Бүрәнәдәй сыйрагыңны
Биемичә саклыйсың.

Көйсез кияү яки киендер-чишендер уены башлана. Бу гадәттә кызлар арасында уйнала торган аулак өй уены.

Бер кыз[1] кияү булып киенгән. Башында күзгә төшереп кигән камалы бүрек, өстендә жилән, билбау буган, эчтән камзул, аягында эчкырлы чалбар, читек, тирән калушлар. Кыз алдында бөреня таянып, аягын типкәләгән сыман «чишендер» дип тора. Чишендергәч, кияү риза түгел, «киендер!» ди. Кыз, азапланып, ана киемнәр дә алыштырып, тәкъдим иткәләп киендерә. Кияү тагын риза түгел, «чишендер», ди.

Уеннын кызыклыгы кияүнең көйсезлеген, хатын-кыз жилкәсенә салынуын күрсәтүдә: әйтик, чишендергәндә кыз анын бүреген салдырыйм дисә, кияү башын гел артка ала. Кыз бер аягына сузылса, кияү икенчесен тоттыра! Кыз читеген тартыйм дисә, бу аяк очларын төрлечә ипсез бөгеп, я катырып, салдырырга бирми. Кыз гажиз булып «уф» дип артка чигеп утыра. Соңыннан кыз чишендермәгәч, кияү һаман биегән хәлдә, билбау белән эчкырын үзе уңга-сулга бер тарту белән жилән-чалбар бар да идәнгә коелып төшә. Ул терсәге белән идәнгә чалкан ята да аякларын як-якка селти, читекләр аяктан оча. Тагын торып басып «киендер!» дигәндә, кыз инде баш тартып, анын киемнәрен берәм-берәм үзенә ата башлый. Шул атуларга бүрек тә, жилән дә «үзлегеннән» киела, өйләнгән арада билбау да биленә урала, читек белән калушларга да аяклар «үзлегеннән» тыгылып, киенү тәмам була.

Өлгер кыз.

Егет башлаган һәр жырны кыз, уртасыннан өзеп, калган яртысын үзе табып, жавап һөжүме ясап бии.

Егет.

Анда басма, монда бас,
Казлар баскан әзгә бас!

[1] Жае табылмаса, кыз урынына егет тә бии ала. Н. И.

Кыз. Казлар баскан эзгә басма,
Кызлар баскан эзгә бас!

Егет. Ары баскан аягыңны
Бире бассаң ни була.

Кыз. Бире баскан аягыңны
Кире бассаң ни була.

Егет.
Бии белгән егетләрне
Алмагачтан ясаган.

Кыз.
Бии белмәгән егетне
Юкагачтан ясаган.

Егет.
Ах-ну, сыдырып сал,
Түгелмәсен тарысы,
Итәгеңә ниләр тигән?

Кыз.
Тигән үлән сарысы.

Аның кул очыннан тотып күтәреп, кушлап биеп китәләр.

Егет *(гайрәтләнеп, бер кызның кулын ала)*.
Ах-ну, ләктердем,
Тешләп өзәм, чәйнәмим!

Кыз.
Синең фигыльләреңнәчар,
Синең белән бәйләнмим!

(Кулын каерып алып бер якка китә).

Рәхмәт белдерү

(Егетләр җырлый. Салмак көй).

Атым бара такырдан,
Дагалары бакырдан.
Рәхмәт төшсен бу хуҗага,
Матур кызлар чакырган.

Бүген атнакич икән,
Кызлар токмач кисәйкән.
Рәхмәт төшсен бу кызларга —
Буйга зифа үсәйкән.

Алмагачы кырларда,
Яхшы парлап җырларга.
Җиде ятны үз итәләр,
Әл дә рәхмәт кызларга.

Кыздырып бию

Егетләр берәм-берәм атылып төшеп такмак әйтеп биләр.

Ах-ну, сыдырып сал,
Түгелмәсен, бетмәсен,
Дары сезгә, җәдрә безгә,
Җинги сезгә, кыз безгә!

Как, сук, ныграк сук,
Талга бәйлә бозавын,
Бозау талны кимерсен,
Кызлар карап тилмерсен!

Безнең әти бай булган,
Аю сатып баеган.
Без үзебез төлкече,
Булмыйк адәм көлкесе!

Атка да бер улак,
Кәҗәгә дә бер улак,
Сарыкка да тәлинкә,
Безгә бүген ярминкә!

Кыз дисәгез кызамын,
Ун кулымны сузамын.
Кыз дигәнем хатын булса,
Кырын карап узамын.

Ике идән бер идән,
Фәризә дә кәй генәм,
Кынакадыр, кынакадыр,
Кынакадыр, кынака!

Базга төштем, май ашадым,
Күршеләрнең базы дип.
Ата казга сәлам бирдем,
Сезнең очның казы дип!

Биек тауның башында
Күренәдер бер авыл,
Җыен яшьләр бергә килсә,
Әнә шулай була ул.

Егет.

Әти мина ат бирде,
Иярлә дә чап диде,
Матур кызны кайда күрсән,
Кочакла да ят диде.

Кыз.

Сандугачлар кайда сайрый —
Юл буенда кырлыкта.
Синең күңелләреңә гажәп,
Бердә түгел, кырыкта.

Егет.

Сөям сине, сөям сине,
Сүрелмәс булсаң гына,
Базга төшеп сөт-катыкка
Үрелмәс булсаң гына.

Васфи Котдуска ымлый. «Әнә Гөл әби янына барып утыр, шәп жырлый, аны жырлат», янәсе. Котдус, Гөл әбинең эскәмиясе төбенә барып, бер кырыйдан идәнгә чүгәли. Күеныннан жиз курай чыгара. Моң гына борынгы озын көй уйнап жибәрә. Бар да тына. Гөл әби борынгы бер көйгә жырлый. («Оичы Фәхри», «Ашказар», «Сакмар» яки башканы.)

Бер егет (яки теге мыеклы кыз) Гөл әби каршысына килеп бии башлый, аны ымлап каршы бергә чакыра. Гөл әби борынгыча салмак итеп шома басып бии. (Әпипә.)

Әйдәүче.

Егет алай алданмас,
Кызлар бизәнми булмас,
Егет белән кызлар барда
Уен-көлкесез булмас.

Уен. «Урам аша».

Васфины, аннары икенчеләрне кулларыннан чылбыр кебек тартып уртага чыгара, жыр белән түгәрәк әйләнәләр:

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү, алтау, уникә;
Уникенең арасында
Иң матуры минеке.

Әйдәүче *(кулын баш өстенә күтәреп)*. «Урам аша!»

Уен башлана. «Капка асты»ннан чыга алмаган парга жәза бирелә, «йолдыз санарга» яки «эткә печән салырга» ишек артына чыгаралар.

Васфи белән Котдус чыгарыла. Котдус ана гыйшкын ачарга тели. Васфи тиз генә ана чигүле яулыгын бирә. Үбеш. Бу беренче парга шулай жәза барганда, капкада тотылган икенче парга да жәза бирелә. Биергә кушалар. (Башка жәза да мөмкин.)

Уен бара. Өченче парга жәза. Бик озын кыз белән тәбәнәк егет. Аларга «моржа ябарга» кушалар. Егет үрелә, буе житми. Утыргыч куялар. Егет урындыкка басып үбешә. Кыз ул егеттән качарга тырыша, аркасыннан этәреп китерәләр.

Уен бара. Дүртенче парга жәза: үзләренә кара-каршы такмак әйтешеп, «кәкре аяк» биюен биергә кушалар. Шук кыз белән шук егет биюе башлана. (Таеп утырып биилләр.)

Егет.

Гидер-гидер гимая,
Таеп утырдым бая,

Таеп утырган кебек итеп, тезләрен кагып, чәпәп.

Жеп-жефәкләреңне киеп
Кая бардың син бая?

Кыз.

Гидер-гидер гимая,
Таеп утырдың бая,
Син таеп утырганда,
Мин дә бар идем бая.
(Аны күтәрешә.)

Егет.

Гидер-гидер гимая,
Син дә бар идең бая,
Ник бу апа житен эрли,
Житен эрләп кем бая?

Гөл апа аның аркасына бер йомгак бәрә. Егет шул унайга атылып торып, аркасы авыртуын язгандай итеп, ыргып-ыргып бии.

Кыз.

Гидер-гидер гимерә,
Гимерә сөяк кимерә,
Староста өйдә микән,
Идәннәрне жимерә.

Егет тагын «таеп», бу юлы инде егыла.

Гөл апа.

Гөдер-гөдер егет кенә,
Инә түгел, жеп кенә,
Бу такмакка биегән кеше
Адәм түгел, эт кенә!

Егетнең аркасына орчык белән төя.

Гомуми бию.

Мимика: бер егет мич арасында мичне исни дә икенчесенә иснәп карарга ымлый. (Сизәсеңме, бәлеш бар, янәсе!) Урларга ымлашалар.

Тәрәзә кагыла. Бар да сискәнә. Гөл әбине жибәрәләр, ул карый, тәрәзәне ача.

Тыштан тавыш. «Әтиләрегез кайтып килә! Күчәрләре сынган!»

Гөл әби *(тәрәзәне яба)*. Күчәр сынган! Я алла! *(Егетләрне этәреп куа башлый.)* Кайталар! Чыгыгыз!

Егетләр тавышы. Юк, юк, юк! Хәйлә! Беркем дә кайтмый! Уйна гармун!

Егетләрнең берләре кызларга крәндил, кәнфит өләшә, сөйләшеп, күреп калырга тырыша. Гармун уйный. Баягы ике мут егет бу чуалудан файдаланып, арттан мич авызы ягына, бәлеш[1] урларга киләләр. Берсе мич буендагы лампаны өреп сүндерә.

Тавышлар: «Әй, әй! Бу ни? Яндырыгыз! Күчәр сынган! Абау, абау!»

Лампа кабызыла. Теге егетнең берсе бер бәлешне мичтән алып куенына тыккан, билен бәйли. Икенчесе аны каплап тора, гармунчыга ымлап күз кыса. Гармун махсус бию кие уйный башлый. Бәлеш урлаган егет бик сакланып, бер аягын шудырып биегән булып, ишеккә таба елыша.

Кызлар *(аның биюенә сокланып)*.

И күрегез, ян белән йөри бу,
Борынгыча нинди шәп бии бу!

Биетүче егет *(кулында пар кашык шакып такмаклый)*.

Таяна төш уң кулың бөергә,
Сулын селтә, җай булыр йөрергә!

Биюче *(гармунчыга)*. Гармунынны суза төш, суза төш!
Биетүче. Ешрак бас, кыза төш, кыза төш!
Биюче. Кызу бассам төшә лә, төшә лә!
Биетүче. Куенгарак тыга төш, тыга төш!
Биюче. Тыга төшсәм пешә лә, пешә лә!
Биетүче. Билбавыңны кыса төш, кыса төш!
Биюче. Пешкән жирем шешә лә, шешә лә!
Биетүче. Иелә төш, уа төш, уа төш!
Биюче. Иелә төшсәм суы чыга, суы чыга...
Биетүче. Суы чыкса, шу да чык! Шу да чык!
Биюче. Пешә лә, пешә лә, пешә лә!

Биеп чыгып китә. Пар кашык тоткан егет тә аның артыннан чыга.

Кызлар *(сокланып калалар)*.

И кызык та егетләр бию,
Шома-шома басарак йөрүе!

Бер егет *(тәрәзә янында тышны күзәтеп торган җирдән, кинәт)*. Кайттылар!

Кызлар. Кайттылар! Чыгыгыз! Чыгыгыз!

Егетләрне этәрә башлыйлар. Егетләр китәргә жыена. Кайберләре чыга башлый.

Гөл әби. Берүк, монда кала күрмәсеннәр. Тукта! *(Кыскыч тотып, мич артын әйләнеп карап чыгарга китә. Котдус аның артыннан сиздермичә шома басып биеп ияреп йөри.)*

---

[1] Бәлеш урлау бию — татарда мәшһүр булып, төрлечә итеп сөйләнә. Төптә аны борынгы Казанга 40 чакрым жирдә торган һәм иң якын татар авылы саналган Әлдермештәге туй вакыйгасыннан алынган, диләр. «Әлдермештә туй төшкән чак, мичтә бәлеш пешкән чак» дигән мәкаль йөрүе дә шуна ишарә итә. Фәтхи Бурнаш үзенең «Яшь йөрәкләр» комедиясендә шул фольклордан өлешчә файдаланган. Мин монда 1938 нче елда Әлдермештә үзем ишетеп язып алган бер вариантын файдаландым. Бу асарнең башында «Әлдермешләр турысында болыт тора» дигән текст булуы да шуна ишарә. И. И.

ДҮРТЕНЧЕ ЭПИЗОД

Ишектән төенчек тоткан Хупҗамал, артыннан Гайнетдин килеп керә. Гайнетдин бер егетләргә, бер Хупҗамалга карый. Хупҗамал, төенчеген ишек төбендәге эскәмиягә куеп, ире алдында аклану өчен, Гөл әби өстенә кабарып биеп бара да «уфф!» ди, аннан шулай Васфи өстенә, кызлар өстенә барып «уфф!» ди дә, хәле бетеп, мич буендагы эскәмиягә утыра. Анда да һаман «уф, уф» килеп, кулларын бер йөзенә басып, бер алып, бер тезенә сугып уфылдап утыра. Янәсе — харап бит болар! (Бу хәрәкәтләр бар да жинел музыка бию көенә үтәлә.)

Бу вакыт кызлар, ике төркем булып чигенеп, берләре тәрәзә як чаршау артына, икенчеләре мич арасы аша карап торалар. Егетләр кайсы бүкәндә, кайсы аякта. Гайнетдин ялт итеп ишектән чыга да, шундук таяк тотып кереп, егетләргә бер айкап ишарә ясый. (Чыгыгыз!)

Алдан гармунчы Дәүләтша белән Салих ишеккә киләләр. Гайнетдин беренче егетне кыйнап чыгарырга әзерләнә.

Дәүләтша аның алдына якын туктап, гармунын уйнап, үз кадерен, дәрәҗәсен югары тотып, такмак әйтә.

Ике кавын, бер кыяр,
Бүген безгә ихтыяр.
Уйнап-көлеп утырганга
Безне монда кем тыяр?

Гайнетдин, сискәнеп, аны сугарга кыя алмыйча кала. Дәүләтша чыгып китә. Аның артыннан килгән Салихны сугам дигәндә, ул гармунын аңа күтәреп, кинәт кенә калыннан нечкәгә хихылдап көлеп жибәргән тавыш чыгарып уйный. (Яки «бака кычкырта».) Бу шайтани тавыштан Гайнетдинның кизәнгән таягы кулыннан төшеп китә. Салих ишектән тыныч кына чыга. (Хәзер гармун тышта бию көе уйный башлый. Өйдәге жырлау-биюләр шунын астында бара.)

Өченче егет *(ишеккә, Гайнетдин алдына килеп)*.

Атың булса дагалат,
Туның булса камалат,
Кызың булса бир кияүгә,
Чыгармасын яманат!

Биеп ишектән чыга. Гайнетдин таяк белән аның тез астына сугып кала.

Дүртенче егет *(шулай ук килеп)*.

Ват, жимер коймасын,
Аркылыга куймасын,
Кызлы кеше кызын тыйсын,
Безне кеше тыймасын!

Ишектән сикерә. Гайнетдин тагын кизәнеп тез астына сугып кала. Башкалар да шулай тәкә кебек сикереп чыга баралар.

Гөл әби *(килә, кулында табагач)*.

Бер кулымда табагач,
Бер кулымда чырагач,
Куам-куам чыкмыйлар,
Хәлем бетте, Гайнетдин!

Ул тез астына суктырмыйча чыгарга юл эзли-эзли, унга-сулга селкенеп биеп тора. Ләкин Гайнетдин хәзер аның артында ышыкланып биеп килгән Котдусны кыйнарга әзерләнә. Бу вакыт Котдус мич авызы ягыннан биеп килгәндә, билгә кыстырган чигүле кулъяулыгы идәнгә төшеп кала. Үзе сизми, башкаларның да күзе бар да Гөл әбигә, Гайнетдиннәргә текәлгән.

Гайнетдин *(кулын угалап, ыжгырып)*. Әй.. *(Әләктеңме, янәсе.)*

Котдус *(Гөл әби артыннан торып, аның әле бер кулбашы, әле икенчесе аша)*.

Кара сарык тиресен
Сум утызга бирерсен.
Ике гыйшык арасына
Тиле булсаң керерсен.

Тыштан егетләр хоры кабатлый.

Кызынны кияү алмаса,
Үзең китереп бирерсең!

Котдус Гөл әбине арка биленнән ялт кына күтәреп Гайнетдин алдына бастыра да үзе ишектән чыгып китә. Гөл әби табагачка абынып, «алла!» дип, Гайнетдин алдына егыла, тагын калкып, «абау, абау!» дип, кинәт Гайнетдиннең йөзен тырнарга өткән кебек, кулларын күтәреп куркытып, ишектән чыгып юк була.

Гайнетдин (*аның артына кизәнә*). Һа! Өй саклаучы! (*Ул үзе дә сизмәстән баядан бирле тышта уйнаган гармун көенә хәрәкәт итә. Биегән хәлдә таягы белән мич артына үтеп, арттан әйләнеп чыга. Аннары идәндәге чигүле яулыкны күреп, «тоттым!» дигән кебек: «Ә!..» ди.*)

Васфи (*күреп*). Ай! (*Арага төшә.*)

Гайнетдин яулыкны таягы белән баса. Васфи ике чигәсен тотып, яулыкка иелгән хәлдә, ничек алырга белмичә чүгеп бии.

Ишектән, бөтерелеп биеп, Котдус килеп керә, шулай түргә уза. Гайнетдин таяк белән аның өстенә бара. Сугам дигәндә һаман чүгәләп биегән Васфи туры килеп, кизәнүе бушка чыга бара. Котдус инде иелеп алды дигәндә, Гайнетдин таяк белән яулыкка баса. Аннан үзе яулыкны эләктереп алып, биегән хәлдә югары күтәреп, шуңа карап тантана итә.

Котдус (*көтмәгәндә яулыкны кулына эләктереп алып*). М-мә!..

Гайнетдин хәзер түгәрәк буйлап биеп, таяк белән Котдусны куа башлый. Гайнетдин аркан әйләнеп ишек ягына киткәндә, тыштан егетләр акрын гына тәрәзәне ачып куялар. Гайнетдин моны сизми, ишеккә барып келәсен эләп бикләп, егетнең чыгу юлын каплап, аны ныклап кыйнарга дип түргә таба кысрыклап килгәндә, Котдус, биегән хәлдә, ялт итеп тәрәзәдән сикереп күздән юк була.

Гайнетдин тәрәзәдән карыйм дигәндә, тышта егетләр көлешә. Ул башын артка тартуга, тәрәзәдән шалтыратып тәгәрәп бер чүен таба килеп керә.

Васфи (*алып*). Әнкәем! Таба!
Хупжамал. Таба? Бәлешең кая?
Гайнетдин (*табаны алып*). Язган! Укы!

Таба кулдан-кул кызларга китә.

Ялан аяклы кыз (*табаны алгач*). Җыр!
Гайнетдин (*гаҗиз булып, ачу белән*). Җыр булса, жырла соң!
Ялан аяклы кыз (*табада язганны укып җырлый*).

Аулак өйдә калдык без,
Ике бәлеш салдык без.
Авызы бераз чалыш икән,
Ярый ашап калдык без!

Хор.

Ул да берсе авызы чалыш.
Ярый ашап калдык без.
И-и!.. Ха-ха-ха!
Уйнап-көлеп калдык без!

Мәжлес гомум көлү белән тәмамлана.

Гали Халит

БЕЗДӘ ИРЕКЛЕ ШИГЫРЬ БАРМЫ?

Социалистик революция кешенең иҗтимагый һәм шәхси активлыгын искиткеч үстереп җибәрде. Шуңа нисбәттән поэзия өлкәсендә дә лирик геройның, лирик характерның яңа ихтыяҗларын, ашкынуларын, уй-тойгыларын гәүдәләндерерлек шигъри чаралар һәм стильләр эзләү киң җәелеп китте. Шуның бер чагылышын, мәсәлән, **ирекле шигырь** мисалында күрергә мөмкин.

Билгеле булганча, вульгар социологизм әдәбият дөньясындагы формаларның үзгәрешен турыдан-туры иҗтимагый строй белән бәйләргә теләде. Шуннан килеп, ул ирекле шигырьне дә буржуаз җәмгыятьнең, бигрәк тә вак буржуазиянең индивидуалистик омтылышларын чагылдыру чарасы итеп кенә карады.

Әйкенче яктан, аеруча пролеткультчылар ирекле шигырьне пролетариат әдәбиятына гына хас форма дип игълан иттеләр, фәкать ирекле шигырь генә завод-фабрикалардагы эшче хезмәтенә ятышлы ритмиканың байлыгын һәм катлаулылыгын бирергә мөмкин, диделәр. Шулай ук бу караш та әдәби форманы вульгар аңлатудан гыйбарәт иде. Революциянең тәүге елларында, яңа җәмгыять белән бергә яңа әдәби формалар туачак, әйскеләре, элеккеләре бөтенләй бетәчәк, дип сөйләнүләр аз булмады. Менә шундый карашларга нисбәтән, кайберәүләр бигрәк тә ирекле шигырьне яңа чор тудырган революцион әдәби форма дип санап, иске ритмик нормаларны тәмам җимерергә һәм алмаштырырга чакырдылар. Аеруча имажинистлар, сурәтне үзмаксатка әйләндереп, ягъни әдәби әсәрдә герой үсешен, лирик характерның «үзгәүдәләнешен» ачуны кире кагып, иске поэзия тудырган барлык кануннарның астын-өскә китерергә маташтылар, хәтта шигырьдәге үлчәм һәм ритм кебек сыйфатларны бетерергә өндәделәр. «**Сурәтләрнең мәгънәне җиңүе һәм сүзне әчтәлектән коткару иске грамматиканы җимерү белән һәм грамматик булмаган фразаларга күчү белән тыгыз бәйләнгән**» [1], — диделәр алар. Моннан аңлашыла ки, имажинистлар тәкъдим иткән ирекле шигырь концепциясе әдәби сурәтне һәм сүзне әчтәлектән, идеядән аерган, ягъни шигырь сәнгатенең чын, асыл табигатен җимергән формалистик башбаштаклыкны гына яклый иде. Шуңа күрә мондый чыгышлар әдәбиятка мөнәсәбәттә үтә сул, анархистик карашларның артык тупас бер гәүдәләнеше генә булды. Үтә суллык чире белән пролеткультчылар да авырдылар. Мәсәлән, аларның күренекле вәкилләреннән берсе болай дип белдергән:

Слепцы!
Поймите, что все то, что замкнуто вами
В условную, беззубую, мертвую догму,

[1] «Литературные манифесты» исемле җыентык. Мәскәү. 1929 ел. 112 бит.

И размерную, ритмичную форму —
Уже не живет...
И что создается по старым законам —
Тотчас умирает...
Мы, восставшие, разбившие рабства оковы,
Призваны разрушить и старые догмы,
И формы...
Ибо созданная нами Поэма,
Сама — Жизнь...[1]

Пролеткультчылык әдәбиятында шигырь белән проза арасындагы аерманы бетерү тенденциясе көчле иде. Бу тенденция ирекле шигырь өчен көрәш рәвешендә тәкъдим ителде. Моның нигезендә билгеле бер ритмик тактка, интонациягә һәм паузаларга ия булган юллар шигъри берәмлек һәм күрсәткеч булып яталар. (Мәсәлән, югарыда И. Садофьевтан китерелгән өзекне карагыз.) Монда инҗек саналары да, басымнары да, строфалар да, рифмалар да сакланмаган. Әмма шулай да шигырьне хәтерләткән пауза, ритм һәм интонация бар шикелле. Ләкин ул, юлларга бүлмичә, тоташтан укыганда, проза әсәре кебек була да кала. Текстның шигырьгә охшаш юлларга бүленүе исә, аны укыганда, эмоциональ интонациягә юнәлеш бирә.

Бернигадәр вакыттан соң, бигрәк тә егерменче еллар башында, татар әдәбиятында да шигырьне аңлауда үтә сул фикерләр күренде. Шуның бик тә характерлы үрнәкләреи, мәсәлән, К. Нәҗми чыгышларында табарга мөмкин:

«Без матурлыкны, гармонияне инҗади сәнгатьнең нәфисәдә дә, тормышның үзендә дә тар рамка эчендәге симметриядән түгел, бәлки сызыкларның, сыннарның, буяуларның, тавышларның, сүзләрнең иркен рәвештә табигый үрелүләрендә, бергә кушылып, дәвамлы тормыш симфониясен тудыруларында күрәбез. Шулай ук шигърияттә дә: җитди кафияле, һәрбер юлга билгеле санда тезелгән инҗеклә, сүзләрнең музыка агымына буйсынып, фикер ягыннан кытыршы чыкса да, үзләренең табигый урыннарын мәҗбүри рәвештә алмаштыруларына нигезләнгән назыннан һәм коры, әчпошыргыч нәсердән өстен булган гаять нечкә аһәңле, гали гармонияле ирекле шигырьгә күчәбез. Иске шигърият исә үзенең чикләнгән канунары, музыкасы, вәзеннәре, кафияләре һәм башка хосусиятләре белән, үзен тудырган иске җәмгыять, иске тормыш белән бергә бетәргә тиешле»[2].

Билгеле ки, иске поэзия законнарын себереп түгәргә чакырган үтә суллык та, алардан ботенләй азат шигырь тудыру турында хыяллану да хәзер инде беркемне шаккаттыра алмый. Әмма ул елларда мондый концепцияләр милли шигырьнең нигезләрен җимерергә маташу кебек куркынычбер төскә дә кергәләде. Футуризм һәм имажинизм йогынтысына тошкән кайбер шагыйрьләр татар шигыренең строфик һәм ритмик нормаларын какшатырга тотындылар. Мәсәлән, үзләрен сулфычы[3] санаган кайбер шагыйрьләр искиткеч дәрәҗәдә ялангач публицистикадан гыйбарәт юллар тезмәсен «яңа, ирекле» шигырь дип тәкъдим итәргә маташтылар:

Таянычыбыз — пролетариат,
Союзыбыз — игенче,
Аларда көч,
Әшләп уку,
Ил төзү — безнең эш.

Дошманыбыз:
Буржуа, дин,
Иске идеология,
Соңгы фронт аларга көрәш,
Аларны җимерү, туздыру[4].

Мондый очраклы халтура, әлбәттә, шигырьнең нәрсә икәнлеген аңламаудан гына килеп чыкмады, ә турыдан-туры бөтен традицион нормаларны, чын шигырь сәнгатен җимерү максаты белән, аңлы рәвештә эшләнде.

---

[1] И. Садофьев. Динамо-стихи. Петербург. Рус теленда. 1918 ел. 15 бит.

[2] К. Нәҗми. Әдәби агымнар һәм тәнкыйть. «Безнең юл» журналы. 1923 ел. 12 сан. 39 бит.

[3] Сулфычы — «Сулф». (Сул фронт) исеме белән йөртелгән әдәби күмәк члены мәгънәсендә.

[4] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1924 ел. 112(1024) сан.

Егерменче елларда да һәм аннан соң да ирекле шигырь тирәсендә байтак каршылыклы фикерләр, бәхәсләр булды. Хәтта хәзерге әдәбият теориясендә дә бу мәсьәлә тәмам ачыкланган дип булмый әле. Берәүләр аны метрик закончалыкларга буйсынмый һәм классик үлчәмнәргә сыймый торган шигырь дип карасалар, икенчеләр исә гомумән ирекле шигырьнең үзен конкрет билгеләү мөмкин түгеллеген дә дәгъва кылалар. Димәк, мәсьәләнең төп асылы ирекле шигырьне шигырь итеп тану-танымауга кайтып кала.

Мәсьәләнең теоретик куелышы һәм күләме ничек кенә булмасын, әмма егерменче еллар совет поэзиясендә киң мәгънәсендә ирекле шигырь формасының урын алуын кире кагу кыен. Чөнки иске, классик һәм традицион шигырьдән ниндидер сыйфатлары белән аерылып һәм күзгә бәрелеп торган яңа формаларның тууы бәхәссез иде.

Мәсьәләнең кыен ягы шунда: **ирекле шигырь төшенчәсе һәм кысалары кайдан башлана да кайда бетә?**

Рус әдәбият белемендә күп вакытлар дәвамында ирекле шигырь категориясенә дольник, тоник, акцентлы (удар) шигырь һ. б. шуның кебек формаларны да кертеп килделәр. Соңгы вакытларда исә аларны ирекле шигырьдән аермалы булган, ягъни рус шигыренең төп ритмик хасиятен билгеләгән басымнар закончалыгына нигезләнүче формалар иттереп карый башладылар. Шуңа күрә дә ул шигырь формалар теге яки бу күләмдә классик нормаларның билгеле бер үзгәреше, үсеше дип саналалар. Димәк, болай килгәндә, ирекле шигырь кысалары бөтенләй тараерга тиеш.

Ирекле шигырьнең күп кенә телләрдә барлыгы мәгълүм. Ләкин аның сыйфатлары аерым телдәге әдәби традицияләр белән бәйләнештә каралганда гына тулырак ачылырга мөмкин.

Революциягә кадәр үк безнең әдәбиятта **нәсер** дигән бер жанр урын алган иде.

Нәсер, төшенчә буларак, гомумән проза, чәчмә әсәр мәгънәсен белдереп, гадәттә шигырьнең киресе итеп аңланган. Тора-бара ул прозаик әсәрнең конкрет бер төрен, жанрын белдерә башлаган һәм шул ук вакытта аның шигырьгә тартым сыйфатлары да барлыкка килгән. Социалистик революция алдыннан безнең әдәбиятта киң таралган нәсер жанрында шул сыйфатлар күзгә нык ташланып тора иде. Егерменче еллар башында бу жанр бик активлашып, аның эмоциональ-риторик яңгырашы, пафосы аеруча күтәренке булып китте һәм заманның революцион рухын чагылдырды. Шунда ук аңарда пролеткультчылык әдәбиятында киң таралган ирекле шигырьгә дә билгеле бер якынлык күренде. Моның характерлы үрнәкләреп, мәсәлән, М. Максуд бирде. Аның нәсерләрендә текстны шигырь юлларына охшаш итеп бүлү еш кулланыла, һәм бу очраклы да түгел иде:

Канлы көрәш бетмәде.
Ленинның үлем хәбәрен китергән көн —
Ерткычлар өчен шатлык көне түгел.
Юк.
Җылый-җылый ант итәм, юк.
Винтовкаларыбыз һаман да күгәрмәс безнең.
Пулеметларыбыз һаман да тырылдар безнең.
Тупларыбыз һаман да ут чәчәр.
Чүкечләребез һаман да дыңгырдар [1].

Әлбәттә, бу — шигырь түгел, ләкин ул туры мәгънәсендә проза әсәре дә була алмый. Әмма шул ук вакытта аның билгеле бер дәрәҗәдә тәмамланган сөйләм кисәкләреннән, сөйләм тактларыннан һәм югары эмоциональлек алган интонация, паузалардан торуы да сизелә. Менә шушы ягы белән ул гадәттәге прозадан аерылып, шул еллардагы поэзия пафосына, аның интонациясенә якын килә иде.

Пролеткультчылар тәкъдим иткән ирекле шигырьдәге кебек үк, бу еллардагы татар нәсерләрендә дә күтәренке лиризм өстенлек итте. Аларның үзәгендә дә

[1] М. Максуд. Безнең чәчәкләр. 1925 ел. 66 бит.

сюжет түгел, ә кичерешләр тора. Бу кичерешләр шул чор героенның чынбарлыкка мөнәсәбәтен бик риторик, гомумән, абстракт итеп чагылдыралар иде.

Безнең әдәбият практикасында нәсер белән шигырь арасындагы якынлыкны, уртаклыкны раслаган фактлар аз түгел. Моның шулай булуына язучылар үзләре үк ишарә ясыйлар. Бер үрнәк итеп, мәсәлән, Тукайның «Мобарәк тәсбих өзелде» (1910) дигән нәсерен алып карыйк. Шагыйрь эпиграф итеп китергән шигырь юлларында: «Мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве», — дип инкърар итә дә Толстой үлеменә багышланган әсәрен нәсер белән яза. Димәк, Тукай бу очракта үзенең фикерләрен гадәттәге шигырь кысаларына сыйдырып бетерә алмаганлыктан, аларны шул форма белән язарга мәҗбүр булган икән. Һәм әйтергә кирәк: әсәрнең бөтен эчтәлеге, эмоциональ яңгырашы, метафоралар һәм композицион кабатлаулар шигырь поэтикасына бик якын, тик аларны ритмга, рифмаларга һәм строфаларга гына саласы калган шикелле. Әмма шагыйрь, шигырьнең әнә шундый иң кирәкле өч канунын кулланудан баш тартып, үзен борчыган үйтойгыларны тагын да иреклерәк форма ярдәмендә әйтүне җайлырак тапкан.

Үзенең сөйләм оештырылышы ягыннан нәсернең шигырьгә якынлыгы тагын да лирик-эмоциональ пафосның аеруча киренке, күтәренке булуында күренә. Шуның өчен дә нәсер күпчелек очракларда романтик настроениеләрне чагылдырга уңайлы жанр булып тора.

Аеруча егерменче елларда нәсернең традицион сыйфатлары һәм яңа яклары тагын да ачылып китте. Аның бигрәк тә шигырьгә якын булганнарыннан бер мисал итеп Ф. Әсгатьнең «Карацгы төн» нәсерен искә аласы килә:

Төн карацгы...
Кояш баешыннан салкын җилләр исә.
Буран да коточкыч бер дәһшәт белән улый иде ул төнне.
— Син кич белән кил, сөеклем, килми калма! — дидең,— көтәрмен,— дидең бит үзең.
Мин килдем. Умарта корты баллы чәчәккә килгәндәй ашкынып килдем.
Төн карацгы... Буран коточкыч бер дәһшәт белән улый иде ул төнне...
Мин килдем. Ләкин тәрәзәң камыш намазлык белән томаланган иде. Мин аның күтәрелгәнен минутлар, сәгатьләр буе сарыгып, интегеп көттем.
Синең тәрәзәңдә ут бар иде бит ул төнне.
Ләкин камыш намазлык күтәрелмәде...
Төн карацгы, җил үкерә... буран, ач балалар елагандай, өзек-өзек сызгыра иде мин сиңа барган төнне...» [1]

Монда нәсернең шигырьгә якын торуын исбатлаган элементлар ярылып ята: композицион кабатлаулар, абзац-строфалар, рефрен, анафора, инверсияләр һәм лирик геройның эмоциональ күтәренкелек белән сөйләве.

Рус әдәбиятында И. С. Тургеневның «Стихотворения в прозе» [2] дигән әсәрләренең әнә шундый сыйфатларга байлыгын истә тотып, белгечләр аларны иркле (верлибр», «свободный стих» мәгънәсендәге) шигырьгә якын итеп саныйлар. Чыннан да, бу тор әсәрләр, теләлеп караганда, кечкенә лирик хикәя, новелла, нәсер һәм хәтта шигырь структурасын хәтерләтәләр. Димәк, туры мәгънәсендә нәсер һәм хәтта шигырь структурасын хәтерләтәләр. Димәк, туры мәгънәсендә проза итеп язылган әсәрләрнең дә шигырь белән күп кенә уртаклыгы булырга мөмкин икән.

Менә шундый хәл иркле шигырьнең (верлибрның) прозага аеруча бәйләнешле барлыгы турында кыю нәтиҗәләр ясарга нигез булса кирәк: «Верлибр прозаның һәм шигырьнең бик катлаулы, хәзергә әле тикшерелмәгән диффузиясе [3], аларның үзара бер-берсенә озак йогынты ясаулары нәтиҗәсендә барлыкка килде, — ди Л. Озеров. — Прозадагы һәм шигырьдәге ритмика һәм синтаксис эволюциясе, аларның даими якынлашуы һәм әтәреше верлибр һәм нәсри шигырь төсендә яңа

[1] Ф. Әсгать. Сүзләрдән чәчәкләр. 1958 ел. 16 бит.

[2] Бу төшенчәне бездә «нәсри шигырь» дип йөртү урынлы булыр шикелле. — Г. Х.

[3] Диффузиясе — үзара керешүе.

күренешләргә китерде. Алар арасында чик, хикәя белән повесть арасындагы кебек үк, үзгәрүчән, тотрыксыз һәм спасылучәнә [1].

Татар әдәбиятында, шуның белән бергә үк, турыдан-туры шигырь итеп язылган әсәрләрне нәсер дип атау да очрый. Мәсәлән, С. Рәмиев үзенең күренекле шигырьләреннән «Мин»не «мәнзум нәсер» (шигъри нәсер), ә «Тац вакыты»н «мәсәҗҗәгъ нәсер» (рифмалы нәсер) дип атаган. Болай караганда, бу шигырьләрнең гадәттә чәчмә формада языла торган нәсер белән, аның кабул ителгән төшенчәсе һәм структурасы белән бнчбер уртаклыгы юк сыман. Ләкин Г. Тукай һәм С. Рәмиевләр заманында нәсер (аны традицион-классик шигырь белән янәш куйганда) байтак киң функциядә кулланылганлыгын да, аны прекле яки сәйләү шигыре итеп карау булганлыгын да истә тотарга кирәк. Шуннан чыгып караганда, С. Рәмиевнең хәтта традицион (15 иҗекле) үлчәм белән, дүрт буынлы итеп һәр буында ритмик ачык иҗеклөр төзеклөгөн (буйдан-буйга: ⏑+⏑⏑||⏑+⏑⏑||⏑+⏑⏑||⏑+-+ формасында), ягъни «төркн аруз»ны саклап язылган «Мин» шигырен «мәнзум нәсер» дип атавының да сере беркадәр ачылыр шикелле.

«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,
Минә бер вур көч керә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

Моның сере — лирик герой монологының романтик пафос белән башкарылуында һәм сөйләү интонациясендә булса кирәк. Югыйсә, гадәттәге нәсергә бнчбер охшашлыгы булмаган һәм бөтен яктан шигырь нормаларын саклаган әсәрнең «мәнзум нәсер» дип аталуын башкача аңлату кыен кебек. Чыннан да, С. Рәмиевкә кадәр «мин»нең болай югары пьедесталга бастырылганы һәм ачык горур монолог белән сөйләгәне юк иде. Шул яктан ул бик прекле шигъри образ булып алга килә. Шуңа нисбәтән «төркн аруз»га тапкыр көйлелекне, мелодик пауза һәм цезураларга бик кирәкле бер сыйфат та — буынара ачыклыгын иҗек аралыгына төшерү ихтыяҗы да калмаган. «Мин» классик шигырь структурасы белән язылса да, буынара ачыклыгының гел сүзләр аралыгына сына туры килүе аркасында, сөйләү интонациясе өстенлек алып киткән. Шул рәвешчә, лирик характерның үзенчәлеге һәм аңа тапкыр шигъри интонациянең билгеле бер прекләлеге авторга «Мин» шигырен нәсер белән уртак бер жанр күренеше итеп карарга мөмкинлек биргәндәр.

Социалистик революциядән соң да мондый фактларны бөтенең поэзиядә очратырга мөмкин. Г. Камал, мәсәлән, «Усал булсаң — асарлар...» дип башланган бер декламациясен «Нәсер» дип исемләгән. Әсәрнең буеннан-буена шигырьгә хас ритм һәм рифма нормалары сакланган, әмма шул ук вакытта монда традицион шигырь нормаларыннан читкә китүнең дә бик әһәмиятле билгеләре бар:

Тор аякка!
Кара як-якка!
Терма еркең!
Ташла капитал тузаннарын өстеңнән селкең!
Бер заман шундый уй белән
Әшче халык, бер үзе генә түгел,
Бөтен мәмләкәт, бөтен ей белән
Басты нык итеп аякка,
Селтәп ташлады бөтен капитал деньясын як-якка [2].

Бу өзектән нәрсә күренә соң? — Барыннан да элек, нәсер-шигырь юлларындагы ритмик үлчәмнәрнең прекләлеге, тигезсезлеге, рифмаларның урыны һәм строфаларның күләме тотрыклы булмавы, ягъни билгеле бер норма, төгәллек белән генә кабатланмавы, чиратлашмавы күзгә бәрелә. Димәк, бу — прекле язылган шигырьнең бер формасы, ә гади нәсер генә түгел. Шулай булгач, Г. Камал аны

[1] «Мастерство русских классиков.» Җыентык. Мәскәү. 1969 ел. 195 бит.
[2] Г. Камал. Әсәрләр. 2 том. 1951 ел. 120 бит.

ни өчен нәсер дип атаган соң? Беренчедән, ул традицион шигырь нормаларын төгәл сакламаган, ә ритмик һәм строфик ирекләклеккә корылган, чөнки, икенчедән, аның эчтәлегендә һәм шигъри чараларында публицистик пафос өстенлек итә. Ул вакытларда мондый шигырьне декламация дип тә йөрткәннәр. Монда инде аның публицистик актуаль рухта булуы гына түгел, ә сөйләү интонациясенә корылуы да искә алынган. Нәсер жанры белән ирекле шигырьне бер-берсенә тиң, тигез итеп карау иде бу.

Шул рәвешчә, сөйләнеп үтелгәннәрне җыебрак алсак, безнең әдәбияттагы нәсернең шигырь белән проза арасында торган жанр функциясен үтәве генә түгел, хәтта шигырьгә бик якын булуы да аңлашылыр дип уйлыйбыз. Моннан инде бездәге ирекле шигырь мәсьәләсенең дә нәсердән читтә каралмаска тиешлеге ачык булса кирәк.

Без югарыда, нәсер белән бәйләнештә, ирекле шигырь төшенчәсен байтак киң мәгънәдә, киң функциядә күз алдына китердек. Әмма аны рустагы «свободный стих» яки чит илләрдәге «верлибр» мәгънәсендә алып карасак, аның нормаларын һәм кысаларын конкрет билгеләү кирәклеге үзеннән-үзе талән ителәчәк.

Әйткәнебезчә, безнең әдәбият белемендә ирекле шигырь төшенчәсенә карата бик тә каршылыклы һәм төрле билгеләмәләр яшәп килә әле. Шулай да без монда аны гомумирәк күз алдына китерүгә ярдәм иткән бер билгеләмәне искә алу урынлырак булыр дип уйлыйбыз. А. Квятковский үзенең «Рус ирекле шигыре» дигән бер мәкаләсендә, мәсәлән, мондый билгеләмәне биргән иде: Метрик шигырь белән чагыштырсак, — ди ул, — ирекле шигырьдә «кабатлануларның эзлеклелеге (периодичность) юк. Монда юллар төрле озынлыкта киләләр һәм аларны сан ягыннан чагыштырып үлчәп булмый. Монда төрле төзелештәге сөйләм тезмәләре алга чыгып, алар үзара тик кайбер конструктив элементлар белән генә беркетеләләр, һәм бер-берсе өстенә салып караганда, бу тезмәләр туры килмиләр. Ирекле шигырьнең төгәл ритмик шигырьдән аермасы менә шунда»[1].

Моннан башка ирекле шигырь, әйтелеп үтелгәнчә, гадәттә ритм һәм рифмалардан азат булып, аның шигырьлек хасиятләре нигездә аерым юлларның, ягъни шигъри берәмлекләрнең тәмамлануы, пауза бөтенлеге һәм эмоциональ өстәмә чараларының интонацион төсмерләре, художестволы экспрессиясе белән билгеләнә. Электә дә һәм хәзердә дә бу типтагы ирекле шигырь киң кулланылды һәм кулланыла. Бүгенге Европа һәм Америка илләре поэзиясендә аның үрнәкләрен күп табарга мөмкин. Мәсәлән, грек шагыйре Яннис Рицосның «Канун солнца» исеме белән русчага тәрҗемә ителгән поэмасыннан бер мисал:

По утрам открываются окна домов.
Простираются руки, как ветви деревьев.
Здравствуйте!
Свое место под солнцем есть у любого цветка,
У любого из смертных есть мечта, есть небо
над зияющей раной
и еще — записка весны, припрятанная в кармане[2].

Шул ук типтагы ирекле шигырь белән эш итү бүгенге совет поэзиясендә дә чит түгел. Татар шагыйрьләре арасында да соңгы елларда аңа мөрәҗәгать итү еш очрый башлады:

Исәнме, улым!
Син гел мин дә,
Мин дә түгел.
Бу күз-карашлар — ул син.
Бу аһ-кул — ул син.

Ә шулай да, беләсеңме,
Син — мин!
Тәнеңдәге һәр күзәнәк
Минем өмет белән тулы...[3]

(Р. Фәйзуллин. «Алмазга».)

---

[1] «Вопросы литературы» журналы. 1963 ел. 12 сан. 63 бит. Курсив авторныкы.— Г. Х.

[2] «Иностранная литература» журналы. 1969 ел. 5 сан. 119 бит.

[3] «Казан утлары» журналы. 1969 ел. 5 сан. 50 бит.

Китерелгән мисаллардан күренә ки, аларда әнә шул югарыда искә алынган ике төп сыйфаттан — шигырь юлларының пауза, интонация бөтенлеген һәм шигырьгә хас эмоциональ чаралар үзенчәлеген саклаудан башка, икенче характерлы элементларга игътибар итү юк диярлек. Шунлыктан рифмалар да, шигырь юлларының ритмик төгәллеге дә, строфаларның тигезлеге дә сакланмаган. Димәк, традицион, классик шигырьгә хас, аның өчен һәрвакыт мәҗбүри, кирәкле сыйфатларның байтагыннан, бигрәк тә ритм гармониясеннән һәм рифма кысаларыннан, мондый ирекле шигырь тәмам азат икән.

Шуның белән бергә үк, татар поэзиясендә традицион көйле шигырьдән үсеп чыккан һәм аңардан үзенең ритмик, строфик һәм рифма структурасы белән байтак аерылып, ирекле шигырьгә интонацион бик якын торган формаларның да революциядән соң аеруча киң колач алуы билгеле. Тыштан караганда, бу да ирекле, ләкин аңа ирекле шигырьдә булмый торган әһәмиятле закончалыкларны һәм нормаларны саклау хас.

Соңгы еллардагы безнең әдәбият белемендә бу төр шигырьгә карата кайбер кызыклы гына фикерләр әйтелде инде. Ләкин шунда ук аңа атама, исем табу кебек мәсьәләнең ачык булмаганлыгы да күренде. Аны «ирекле шигырь», «интонацион шигырь», «сөйләм шигыре» дип, бу атамаларны яңәшә, тиң итеп куллану кебек буталчыклык, төгәлсезлек яши әле. Моңардан ничектер котылырга кирәк иде. Без бу очракта «сөйләү шигыре»[1] дип алуны күпмедер дәрәҗәдә уңайлырак, җайлырак булыр дип уйлыйбыз. Мондый атама да шартлыдыр, ләкин сөйләү шигыренең җирлеге, традицияләре турыдан-туры көйле шигырьгә бәйле булганлыктан, ул атаманың эчтәлегендә шул шигырьгә хас иң әһәмиятле сыйфатлар бар. Шуңа күрә аның ирекләлеге бик шартлы, һәм аны туры мәгънәсендә ирекле шигырь белән буташтыру кыен.

Революциягә кадәр үк инде татар традицион шигыренең интонациясе, ритмик тибешен үзгәртү, ирекләрәк итү мәсьәләсе көн тәртибенә куелып, кайбер әһәмиятле генә тәҗрибәләр дә эшләнгән иде. Бу уңай белән Х. Госман күзәтүләре аеруча игътибарга лаеклы. Куелган мәсьәләнең бер характерлы мисалы итеп, ул С. Рәмиевнең «Таң вакыты» шигырен ала һәм «классик шигырьнең буын араларын ачуда үз юлы белән барып», шагыйрьнең «ирекле, интонацион шигырьгә килеп чыгуы»[2] турында сөйли. Чыннан да, 50 юлдан торган бу шигырьнең фәкать беренче 14 юлы гына 15 (8+7) иҗекле традицион үлчәмнән гыйбарәт булып, калган өлешендәге үлчәм биштән алып ундүрткә кадәр сандагы иҗекләр арасында гаҗәп бер ирекләлек белән алмашынып килә. Классик шигырьдә һич булмый торган хәл бу. Анда бит ритмик стройның төзеклеге шигырь көйлелеге өчен бер кирәкле шарт булып тора иде. Моны какшату инде — шигырьнең сөйләү интонациясенә күчешен җиңеләйтү дигән сүз. Шулай итеп, шигырьнең сөйләү интонациясе аның ритмик үлчәмендәге ирекләлеккә дә юл ача. Менә шуларның һәммәсен күз алдына китерсәк, «Таң вакыты»н С. Рәмиевнең ни өчен «мөсәҗҗәгъ нәсер» дип атавы да аңлашылыр шикелле. Димәк, традицион, классик шигырь структурасын теге я бу төстә үзгәртүне шагыйрь тагын да нәсергә якын итеп күргән.

Бер үк шигырь эчендәге үлчәмнең төрлелеге һәм алмашынышы соңра татар сөйләү шигыренең характерлы бер билгесе булып китте. Х. Госман моны бигрәк тә Һ. Такташ поэзиясе үрнәкләрендә күрсәтеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килә: «Сөйләм шигыре халык ритмик схемасы нигезендә дә, классик шигырь нигезендә дә эшләнде. Дөрес, егерменче елларның икенче яртысы кергәч, ул тик халык шигыре нигезендә генә үсеп китте»[3]. «Классик шигырьне сөйләм шигыренә күчерер өчен, — ди Х. Госман, — башта аның буын араларын ачарга кирәк булса,

---

[1] Русчадагы «говорной стих» мәгънәсендәрәк. «Сөйләм» атамасы бездә русчадагы «речь» атамасына (мәсәлән, «литературная речь» дигән кебек очракларда) туры килә. Шуңа күрә «сөйләү» һәм «сөйләм» атамалары арасындагы мәгънә төгәллекләрен саклау бик әһәмиятле. — Г. Х.

[2] Х. Госман. Татар шигыре. 1964 ел. 102 бит.

[3] Шунда ук, 109 бит.

халык шигырендә эш гадирәк: монда буын аралары болай да ачык, сөйләм җаена күчәр өчен халык шигыре үзе үк алдан әзерләнеп куйган шикелле, аңарда сөйләм интонациясе өчен потенция дә күбрәк» [1].

Моңдый шигырь турында Х. Курбатов та, үзенең «Татар телендәге шигырь төзелеше» дигән мәкаләсендә сүз ачып, А. Квятковский фикеренә якын торган түбәндәге билгеләмәне бирә: «Төрле строфа төрлечә төзелергә, төрле юллар төрле озынлыкта булырга мөмкин, әмма цезуралар кулланышында билгеле бер система саклану — мәҗбүри» [2].

Х. Курбатов фикеренчә, бездәге сөйләү шигыре (ул аны «иректе шигырь» дип ала) рустагы «вольный стих» төшенчәсенә якын, ә «свободный стих» түгел. Бу караш, бәлки, киләчәктә нәтиҗәле тикшеренү һәм эзләнүләр өчен бер таяныч, этәргеч булыр, ләкин хәзергә без аның бәхәсле икәнлеген искәртү белән чикләнә без. Рустагы «вольный стих», классик шигырь принципларын җимермичә, поэзиягә сөйләү стихиясен алып килде, үзенең структурасында билгеле бер иректелекка иреште. Шулай итеп, «вольный стих»та да рус теленә һәм шигыренә хас басымлы инекләрнең кабатлану закончалыгы нигез моментларның берсе булып кала. Ә татар шигыренә исә бу һич тә хас түгел. Әмма шунысы әһәмиятле: Х. Госман да, К. Курбатов та сөйләү шигыре традицион шигырь структурасының теге яки бу якка үзгәртелеше дип саныйлар. Алар фикеренчә, бу үзгәртелешнең иң характерлы ягы — классик шигырьдәге буын аралыгын ачып һәм аның паузасын көчәйтеп, цезуралар системасын саклаудан гыйбарәт икән. Болар һәммәсе ритмик буынларның хәрәкәтчәнлеген үстерә.

Н. Исәнбәттән бер мисал алыйк:

Кич.
Күктә шәүлә.
Җирдә көч.
Алда янгын.
Артта сигнал.
Аңдыра дөһшәтле үч.

Ә югартын, баш очында бер сузылган сын гора.
Кулларын җәйгән. Төтендә карлыгып ул кычкыра:

— Үч!
Тор, изелгән! Күрсәт эш!
Орды чаң;
Кызды бөтен кан;
Куйды дошман көчкә көч;
Чүк, чүкеч!..
Чүкер!
Күтәр дә төшер
дә бәр!
Алласы,
Бае,
Патшасы —
Килсен бир-бәбәр
Барчасы!
У-ра! [3]

Игътибар итегез: монда 8+7 шәр инекле элекке, традицион шигырь үлчәме кулланылган, әмма аның тотәллеге, төзеклеге мәҗбүри сакланмаган: бер урында киметелгән, ә икенчесендә арттырылган. Шигырь юлларының күләме дә, ритмик яңгырашы да, интонациясе дә һәм рифмалау тәртибе дә гадәттәгечә түгел.

[1] Х. Госман. Егерменче елларда татар поэзиясе. 1964 ел. 139—140 битләр.
[2] «Совет мәктәбе» журналы. 1969 ел. 4 сан. 35 бит.
[3] Н. Исәнбәт. Сайланма әсәрләр. I том. 1960 ел. 174 бит.

Шулай итеп, шигырь структурасы билгеле бер ирекле белән тәэлгән, график симметрия ирекле шигырьдәге кебек үк сакланмаган[1]. График композициянең болай булуы, әлбәттә, шигырьнең интонациясе дә башкача булуны таләп итә. Озын юлдан кыскага күчкәндә темп акрыная, ә киресенчә булганда тизләшә. Ә моның нигезендә яткан шигъри стихиянең рухын, пафосын сөйләү интонациясе билгели. Шуңа күрә буын аралары максимум ачылып, цезура һәм паузаларга киң мөмкинлек бирелгән, хәтта аерым сүз һәм сүз тезмәләренең мөстәкыйль юл булып килүе тәэмин ителгән. Мондый интонацион ирекле строфаларның да төгәл тигезлеген таләп итми. Ләкин бу инде, ирекле шигырьдәге кебек, «чамасыз» да түгел: аның иреклелеген чамада, кысада тота торган ритм, рифма нормалары һәм алар таләп иткән строфалар да бар.

«Минем әйберләрнең күпчелеге сөйләү интонациясенә корылган»,— дигән иде Владимир Маяковский. Ул шигырьдә җанлы сөйләмгә хас басымнар градациясен бирергә омтылды. Аның поэзиясендә аерым сүзләрне аерым юл итеп бирү дә очраклы түгел. Аңарда сүз үзенең мәгънә һәм ритмик-интонацион әһәмияте белән хәтта аерым юл булу хокукын алды. Маяковский шигырендә интонация киренкелеге, интонацион контраст көчле иде. Менә шул хасият аңарда ритм масштабын да киңәйтте. Татар сөйләү шигыренең дә формализм һәм имажинизм башбаштаклыгыннан азат өлешендә Маяковский новаторлыгына якын элементларны табарга мөмкин.

Әлбәттә, рус теленең үз закончалыкларына нигезләнгән шигырь формаларын турыдан-туры татар шигыренә күчереп булмый. Ләкин бу хәл рус совет шигырендә барган новаторлык күренешләре белән татар шигыренең бәйләнеше тыгыз булганлыгын кире кага да алмый әле. Һәм, чыннан да, егерменче еллардагы яңа шигырь мәсьәләсе әнә шундый бәйләнешкә ачык бер дәлил була ала.

Гыйсъянчылык татар классик шигырен революциянең беренче елларында киң таралган рус интонацион, сөйләү шигыре рухында үзгәртергә теләде. Сөйләү шигыре мәсьәләсенең нәтиҗәле хәл ителгән ягы да менә шунда иде. Шул рәвешчә, татар поэзиясендә яңа шигырьгә юл ачу, бер яктан, аны барлык иске кануннарыннан коткару рәвешендә күз алдына китерелгән булса, икенче яктан, тик шул кануннарны яңарту, үзгәртү белән генә мөмкин икәнлеге расланды. Беренче тенденция уйдырма иде һәм тиз арада юкка чыга барды, ә икенчесе үзенең яшәргә хаклы икәнлеген күрсәтте, чөнки аның милли поэзиягә бәйле реаль җирлеге, ныклы традицияләре бар.

Икенче тенденция бигрәк тә Һ. Такташ поэзиясендә тулы булып ачыла һәм җитлегә барды. Аның 1923 елда «Жир уллары трагедиясе» белән бергә игълан ителгән «Иҗадиятем турысында» дигән декларациясендә бу тенденциянең төп принциплары саналган иде. Анда шагыйрь, бик әһәмиятле бер принцип итеп, яңа татар шигырендә «такмаклап язу бетәргә, аның урынына «тон» белән «сөйләп» язу юлы кертелергә тиешле» дип куйды. Чөнки болай язуны да ул «татар теле өчен табигый юл» дип аңлый иде. Такташ декларациясе шул вакытларда имажинистлык һәм футуристлык рухында тәкъдим ителгән бөтенләй «яңа», бөтенләй «ирекле» шигырь турындагы карашлардан принципиаль ягы белән аерылып торды: анда сүз һич тә элекке поэзиянең барлык кануннарына каршы куелган «гаять нечкә аһәңле, гали гармонияле ирекле шигырьгә күчү» турында бармады, хәтта «ирекле шигырь» дигән атама да кулланылмады. «Татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиешле» дигән принцип та әле Такташның гомумән иске поэзияне төбе-тамыры белән кире кагуы турында сөйләргә нигез була алмый. Киресенчә, шагыйрь яңа заманга лаеклы поэзиянең стиле (өслүбе) һәм формасы үзгәрергә тиешлеген тоеп, традицион шигырьне яңарту кирәклеген, төгәлрәк әйткәндә, аның интонацион-ритмик иреклелеген таләп итте һәм шуны үз иҗат практикасында тормышка ашыра башлады.

---

[1] Сөйләү шигырен ирекле шигырь белән тиң итеп, янәшә куеп яки аларны аермыйча карауның бер сәбәбе — тегесендә дә, монысында да шигырь юлларының төрле озынлыкта һәм строфаларның төрле зурлыкта килүе, ягъни, тупасрак итеп әйтсәк, шигырь каркасының, тышкы моделенең охшавы булса кирәк — Г. Х.

«Сәнгатьтә революция ясыйбыз» дип җикеренгән беркше эдипләрнең үтә сул, формалистик кыланышларына карамастан, гыйсъянчылык татар шигыренең ритмик төзелешен, строфикасын һәм рифмасын яңартуда, «деформацияләү»дә, әлбәттә, уңай рольне уйнады. Тукташның, Н. Исәнбәтнең һәм башкаларның сөйләү шигыре татар поэзиясенең интонацион агылышын ораторлык экспрессиясе белән баетты. Шигъри сөйләмнең энергиясе, җанлы басымы һәм интонацион контрасты көчәйде. Гомумән алганда, гыйсъянчылык реформасы, ул еллардагы татар поэзиясенең романтик тенденцияләренә бәйле булып, аның риторик-эмоциональ характерына туры килде. Бу максималь киренке шигырь поэзиянең лиро-психологик һәм эпик-хикәяләү мөмкинлекләрен ачарлык сыйфатка ия түгел иде әле.

Тукташ алып килгән шигъри реформа татар поэзиясендә үзенең тирән эзләрен калдырды. Әмма реформа, яңалык керткәндә, Тукташ безнең шигырьнең милли нигезеннән читкә тайпылмады, аерылмады. Монда сүз татар шигыренең ритмик һәм строфик нормаларын баету юрылыда гына барырга мөмкин, ә һич тә аның ана теле закончалыкларыннан һәм үз поэтик стихиясеннән килә торган традицион нигезләрен җимерү хакында түгел.

Үз шигъри осталыгы үсешенең төрле баскычларында нисбәтән, Тукташ ритмика һәм строфика өлкәсендә дә берничә этап үтте. Шулардан беренчесе «Җир уллары трагедиясе» язылган чорга характерлы булып, монда кейле шигырьне кырыкларга һәм сөйләү интонациясенә юл ачарга омтылыш сизелеп калды, ә традицион строфикага һәм аның силлабик бетенлегенә орыну бетенләй юк диярлек иде.

Инде «Гасырлар һәм минутлар» язылган этапта строфика һәм ритмикага тулы реформа ясала: шигъри берәмлекләрнең (юлларның) һәм строфик периодларның (тезмәләрнең) иректә кулланылган системасы барлыкка килә:

Без, бетен дөнья, урамда:
Франция,
Испания,
Дания,
Германия...
Анда ораторлар сөйли,
Монда пионерлар:
— Ул үлмәде,
Ленин мәңге бар!
Ленин — без ул!
Ә без?

— Бетен дөнья!
— Без бар!
Без миллионнар.
Кечле левончылар!
— Кузгал, уян, лагънәт ителгән...
Ораторлар!
Сәгать дүртне сукты!
Эш дөньясы кинәт туктады.
Башлар түбән төбә мендәләр,
Машиналар шымды,
Тын калды.

Монда, һичшиксез, шунысы ачык: «Җир уллары трагедиясе»нә хас строфика һәм ритмикадан тагә и бу якка күләмә белән иректе булган шигырь күзгә бәрелеп тора. Моның нигезендә туры мәгънәсендә сөйләү интонациясенә корылган публицистик-риторик поэтика ята. Классик шигырь төгәллеге белән иректе шигырь «төгәлсезлеге» аралашып, чиратлашып килүе дә табигый яңгырап, полиритмик агылыш ала. Бу очракта инде интонацион берәмлекләр зур роль уйный, паузалар ешая һәм көчәя. Кейле шигырьдә интонацион берәмлекләрнең билгеле бер тигезлеге, чамасы саклану мәҗбүри. Сөйләү шигыреңдә исә алар фикер агылышына буйсынып иректәлек алалар, ораторлык тонына кинрәк юл ачалар. Интонацион иректәлек талабе буенча, шигырь юлларының бер җөмләдән алып бер сүзгә кадәр булуы — сөйләү шигыренә бик характерлы сыйфат. Әмма Тукташтагы иректе шигырь үзенең ритмик мускулатурасын һич тә ычкындырмый. Ә моны тотып торучы ныклы кыршауларның берсе — рифма. «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы үрнәгендә генә дә рифманың ритмик оештыру көче никадәр икәнлеген аңлау кыен булмас. Гомумән, бу әсәр язылган вакытларда Тукташ Маяковскийның чама белән 1923 елларга кадәр, ягъни баскычсыман строфикага күчкәнгә хәтле булган строфикасына һәм ритмикасына якын тора кебек. Шундый ук реформаны төрек шигыреңдә Н. Хикмәт иткән. Рус шигыреңдәге новаторлыктан өтерелеп, ул төрек шигыреңең каенана строфикасына

һәм экспрессив нормаларына нигезле үзгәреш кертте. Н. Хикмәтнең егерменче еллар поэзиясендәге ритм сөйләү-декламация агылышына нык буйсындырыла. Шуңа күрә Н. Хикмәт белән Такташның шигъри реформалары бер юнәлештә баруы гаҗәп түгел иде.

Ләкин Такташ өчен бу реформа хәлиткеч, соңгы этап булмады әле. Монда гыйсъянчылык реформасы рухындагы кискен тон һәм югары пафосның ялангачлыгы күзгә бәрелеп торды. Совет поэзиясеннән безнең чынбарлык талэп иткән лирик һәм эпик колач өчен мондый шигырь мәйданы таррак иде. Ләкин шулай да Такташның һәм аның замандашларының беренче кыю тәҗрибәләре татар совет поэзиясендәге стильләр үсешендә, формалашуында эзсез, нәтиҗәсез калмадылар. Ритмикада сөйләү-декламация башлангычын ныгытып, киңәйтелгән һәм кыскартылган (ирекле) строфиканы файдаланып, Такташ традицион шигырь принципларын яңартты. Шуңа күрә дә аның артыннан күтәрелгән һәм аңардан өйрәнгән яшь шагыйрьләр бу новаторлыкны тиз һәм җиңел кабул иттеләр.

Иҗатының соңгы елларына табан Такташ поэзиясендә татар шигыренең традицион нигезенә игътибарның аеруча көчәюе дә котелмәгән хәл түгел иде. Чынбарлыкның яңа шартларына һәм зур таләпләренә җавап биргән шигырь гадилегенә ирешүнең классик традицияләрдән башка мөмкин булмавын аңлау аның поэзиясендә социалистик реализмның халыкчан тамырлары ныгый барудан аерылгысыз иде, әлбәттә. Полиметрик (күп үлчәмле, ирекле яки киңәйтелгән дип тә әйтергә мөмкин) строфикадан һәм хәрәкәтчеллеге көчәйтелгән цезура, пауза, интонацияләрдән һич тә баш тартмыйча, Такташ силлабик татар шигыренең яңа мөмкинлекләрен, закончалыкларын ачуны дәвам иттерде, укучы белән ачыктан-ачык сөйләшә торган поэзиягә юнәлеш тотты.

Татар әдәбиятында реалистик тенденцияләрнең, яралгыларның үсә баруы милли шигырьнең прозалашуын (прозаизация), лиро-эпик башлангычларның активлашуын мәйданга чыгарды. Шуңа нисбәтән татар шигыренең ритмик-интонацион төзелешендәге традицион нормаларны, аның силлабик төзеклеген һәм строфик бөтенлеген сакларга, үстерергә омтылыш та көчәйде.

Шулай итеп, Такташ нигезләгән сөйләү шигыре егерменче еллар азагында һәм утызынчы еллар башында әйдәүче форма булып ныгыды. Тормышның яңа зур темаларын лиро-эпик колачлы образларда бирү өчен җайлы булган һәм ирекле (җәенке һәм кысынкы) строфикага корылган, һәр очракта да иҗек саннарының, ритмик берәмлекләрнең төгәл тигезлегә мәҗбүри булмаган, әмма милли шигырьнең силлабик бөтенлеген, төзеклеген тулаем саклаган киң интонацияле шигырь иде ул:

Урал!
Магнитлы тауларың
Күтәрде коммуна байрагын,
Яңа юл корыла өстеңдә.
Гигантлар каплады һәр ягың.
Киң сула син, Урал,
Газлардан мартенга
ут ал,
Шауласын чыңгырап
металл,
металл,
металл!!!

(Ф. Кәрим. «Җиденче мич». 1930—31.)

Татар поэзиясендә ирекле шигырь һәм сөйләү шигыре мәсьәләләре турында сүз башлагач, 1965 елның 26 сентябре белән 1967 елның 8 январе арасында «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә булып үткән бер бәхәсне дә искә алу кирәк шикелле. Бу бәхәс «Г. Тукай һәм М. Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән темага багышланды. Шуңа күрә монда без күтәргән мәсьәләләрнең «үтеп барышлый» гына яктыртылуын һич тә кимчелек дип санамыйча, аларны аңлауның соңгы вакытларда ни дәрәҗәдә торуын күрсәткән әһәмиятле бер тәҗрибә иттереп тә карарга кирәк.

Чынлап та, әгәр Н. Фәттах «Ирекле формага өмет багларгамы?» [1] дигән сорауны куеп, гомумән ирекле шигырь формасын кире какмаса, бәлки, аның киңәйгән һәм барлыгын дәгъва кылуга ихтыяҗ да тумаган һәм аны яклап чыгучылар да булмаган булыр иде. Әмма ничек кенә булмасын, хәзерге татар поэзиясендә берише яшь шагыйрьләрнең ирекле шигырьне уңышсыз файдалануларына үч итеп, Н. Фәттахның «тунны утка ягуы» кайбер мәсьәләләрнең көтелмәгәндә генә кискен итеп куелышына да һәм кай яктан өлгергән яки өлгермәгәнлеген ачуга да бер сәбәп булып китте.

Аңа каршы чыккан авторлардан, мәсәлән, Марс Шабаев бик катгый рәвештә ирекле шигырьнең дә тулы сәнгать хокукына лаеклы буларак яшәргә тиешлеген раслады: «Рифмасыз ирекле шигырь ритмиканы яңарта һәм баета, интонацион мөмкинлекләрне арттыра,— диде ул.— Ирекле шигырьне язуы рифмалап язудан кыенрак. Ул шагыйрьдән зур осталык сорый, чөнки аңарда аллитерацияләр, ассонанслар, диссонанслардың билгеле бер эзлеклелеге булырга тиеш, сүзләр, сүз өйләнмәләре билгеле бер ритмик интонациядә килергә тиешләр. Бу форма артык бизәкләүләрне күтәрә алмый, зәвык һәм чама хисе анда гадилек белән үлчәнә» [2].

Башка авторларның да күпчелеге шушы фикерләргә теләктәшлек итеп, бүгенге поэзиябездә ирекле шигырьнең яшәргә һәм үсәргә тиешле форма икәнлеген исбатларга тырыштылар. Ләкин шуның белән бергә, күп кенә чыгышларга ирекле шигырьне конкрет итеп, аның тарихи җирлеген һәм милли традицияләрен күз алдына бастырып хөкем итү җитмәгәнлеге дә сизелде. «Монда,— диде Н. Юзиев бәхәсне йомгаклау урынындагы мәкаләсендә,— ирекле шигырь белән сөйләм шигыре арасында тигезлек билгесе куелды» [3]. Н. Юзиев фикеренчә, ирекле шигырь традицияләре татар халык иҗатына һәм борынгы төрки поэзия үрнәкләренә барып тоташкан. Тагын, Х. Госманның [4], ирекле шигырь һәм ак шигырь төшенчәләренә билгеле ачыклык кертеп, ирекле шигырь белән нәсер арасындагы якынлыкка игътибар итеп чыгуы да әһәмиятле иде.

Сөйләп үтелгәннәрдән нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин соң? Әйе, бездә ирекле шигырь бар һәм аның яхшы ук бай, катлаулы гына тарихы да, традицияләре дә бар икән.

Татар поэзиясендә социалистик революция булганнан соң кин таралган «ирекле шигырь» төшенчәсен гомумән түгел, ә конкрет караганда, аның әйтәлегенә туры мәгънәсендә ирекле шигырь һәм теге я бу тестә аңа якын торган сөйләү шигыре кертелүе күренә. Һәртөрле формалистик эксперименталардан, ясалмалыклардан иерып алганда, аларның икесе дә татар поэзиясенең үз милли традицияләренә нык бәйләнгән яңа шигъри эзләнүләр, тәҗрибәләр булганлыгы аңлашыла. Ул тәҗрибәләр бер ноктада гына торып калмадылар, ә билгеле үзгәреш, үсеш кичерделәр һәм үзләренә хас, тиешле сыйфатларының тотрыклылыгын саклап, безнең поэзиядә һаман да яшәргә хаклы булуларын күрсәттеләр. Шуңа күрә дә, хәзерге көн ноктасыннан караганда, хәтта инде традициягә әйләнгән бу ике шигъри форманың безнең поэзиядә бүген дә дәвам итәргә һәм үстерелергә тиешле булуларын шик астына алу бөтенләй мәгънәсез бер нәрсә булыр иде. Һичшиксез, алар икесе дә безнең шигырь хәзинәсендә заман рухындагы уй-хисләрне чагылдыру өчен яраклы, кирәкле формалар булып калырга лаеклар һәм калачаклар.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы. 1965 ел. 14 ноябрь.
[2] Шунда ук, 5 декабрь.
[3] Шунда ук, 1967 ел, 8 январь.
[4] Шунда ук, 1965 ел, 31 декабрь.

Әбрар Кәримуллин,
филология фәннәре кандидаты

«ЯШЬ ГОМЕР» ДРАМАСЫ ҺӘМ ПАТША ЦЕНЗУРАСЫ

Патша цензурасының татар драматургиясе һәм театрына каршы көрәшен чагылдырган документлар әле тиешенчә өйрәнелмәгән. 1905 елгы революциядән соң ижат ителгән аерым драма әсәрләребезнең хөкүмәтнең сәхнә цензурасы тарафыннан сәхнәгә куярга рөхсәт ителмичә тоткарланып калдыру фактлары аз булмаган. Мондый тоткарлауларның чын сәбәпләрен ачыклау ниятә белән без Ленинград, Казан архивларында саклана торган драма әсәрләре һәм сәхнә цензурасы фондларына мөрәҗәгать иттек.

Билгеле булганча, 1862 елга хәтле аерым әсәрләрне сәхнәгә куярга рөхсәт бирү-бирмәү мәсьәләсе җирле губернаторлар карамагында булган. 1862 елдан башлап бу эш губерна полицмейстерларына тапшырыла. Казан, Оренбург губерналарының җирле архивларында татарча концерт, кичәләр үткәрергә рөхсәт сорап язылган үтенечләргә полицмейстерларның мөнәсәбәтен ача торган материаллар булса да, без алар арасында татар сәхнәсендә куярга рөхсәт ителгән әсәрләр турында документлар очратмадык. Башка халыклар сәхнәсеннән үзгә буларак, татар сәхнәсендә куелырга әзерләнгән пьесаларга рөхсәт алу өчен Петербургның Драма цензурасына мөрәҗәгать итәргә кирәк булган[1]. Бу аңлы рәвештә шулай эшләнелгән һәм царизмның татар театрына каршы өстәмә тоткарлыклар ясавының бер формасы булган.

Татар театры туган чордан, ягъни 1906 елдан башлап аерым кешеләрнең теге яки бу әсәрне сәхнәгә куярга сорап язган үтенечләре барысы диярлек СССР Үзәк дәүләт тарих архивының Матбугат эшләре үзәк идарәсендә тупланганнар. Болар арасында Н. Гогольнең «Ревизор», Я. Вәлинең «Оят, яки күз яше», Ф. Халидинең «Морад Сәлимов» пьесаларын сәхнәгә куярга сорап язган үтенечләр бар. Бу документлар 1906 елның 6 апреле белән билгеләнгәннәр. Шулай ук Әхмәтгәрәй Хәсәни, Габдулла Кариев, Мөхетдин Исхаков, Гомәр Кугушев һәм башкаларның 1906—1917 елларда язган гаризаларында сәхнәгә куярга ниятләнелгән йөзләгән әсәрләр искә алынган. Сәхнәгә куярга цензура рөхсәте соралган шушы йөзләгән әсәрләрнең яртысыннан күбенә рөхсәт бирелмәгән. Алар арасында без Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре», «Бәхетсез егет», «Бүлек өчен», «Уйнаш», И. Богдановның «Помада мәсьәләсе», С. Рәмиевнең «Низамлы

[1] Губерналардагы рус театрлары җирле властьлар рөхсәт бирмәгән очракта гына Петербургтагы Драма цензурасына мөрәҗәгать иткәннәр.

мәдрәсә» һәм тәрҗемә әсәрләрдән Гейненең «Әльманзур», Гогольнең «Ревизор», Мамин-Сибиряк, Рутковский һәм башкаларның әсәрләрен очратабыз[1].

Патша цензорлары башлыча иске тормыш тәртипләрен тәнкыйть иткән, яңалыкка өндәгән әсәрләрне сәхнәгә үткәрмәгәннәр. Архивларда саклана торган документларны өйрәнгәндә, без күренекле пролетар әдибе Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» драмасын сәхнәгә куярга сорап драма цензурасына үтенеч кергән булуын ачыкладык. Дөрес, аны кем язуы, кем соравы билгесез, чөнки үтенеч үзе хәзергә табылмады. Бу әсәрнең сәхнәгә куярга яраксыз булуы турында цензорның Матбугат эшләре үзәк идарәсенә җибәргән доклад язуы табылды. Татар театрының революциягә хәтле репертуар тарихын өйрәнү, царизмның татар театрына каршы, демократик идеяләргә каршы ничек көрәшүен күрсәтү ягыннан характерлы булган бу документның текстын, татарчага тәрҗемә итеп, биредә тулысынча китерүне кирәк саныйбыз.

«Матбугат эшләре Үзәк идарәсе начальнигына
... 3. «Яшь гомер». Драма биш пәрдәдә. Мөхәррире Габделгафур Коләхметов. Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкъдирдә язылмыштыр. Казан. Харитонов типографиясе. 1908. 125 б.[2]

Авторның фикере буенча, пьесаның героиняcы саналырга тиешле кызның эти-әнисе аны әсәрнең шулай ук герое хисапланган сөйгән егетеннән аерып бер бай, бозык кешегә кияүгә бирәләр. Әсәрдәге бер персонажның шуларга карата бер урында әйтеп үткән сүзе драманың исеме итеп алынган булырга кирәк.

Пьесаның барышында югарыда күрсәтелгән әнә шул каршылык нигезендә бернинди яңа драматик үсеш юк, шуның өстенә әсәр бернинди нәтиҗәсез, чәчелешсез тәмамлана. Әйтик, хәрәкәт урынына сезнең алдыгыздан төрле персонажлар сөйләшеп үтеп торалар. Кемнәр соң бу кешеләр — мина монысына аерата игътибар итәргә кирәк. Алар барысы да пролетарийлар — эшчеләр һәм аларга теләктәш кешеләр, татарлар, хәтта руслар да. Алар барысы да бернинди бәйләнеше булмаган речьләр сөйлиләр, шуның өстенә кайберләре исерек килеш сөйләнәләр: янәсе, дөньядагы бөтен бәйлык эшчеләр кулы белән тудырылган, шуның өчен аларның дөньядагы барлык нәрсәгә хаклары бар (34 бит, Гали һәм Йосыф сүзләре); хәзер, имеш, хөррият һәм эшчеләр нәрсә телисәләр шуны эшли

---

[1] Сәхнәгә куярга сорап язган үтенеч белән бергә әсәрнең кулъязма яки басма текстлары да җибәрелгән. Алар арасында Г. Камал, К. Тинчурин һәм башкаларның кулъязма хәлендәге пьесалары да булган. Бу материаллар Императорский Александрийский театр каршындагы драма цензурасы фондына кала торган булган. Хәзерге көндә бу театр А. С. Пушкин исемендәге Ленинград академия драма театры исеме белән йөртелә. Бу пьесалар исә, театр каршындагы китапханәдән алынып, Ленинград дәүләт театр китапханәсенә тапшырылганнар һәм бүгенге көндә дә шунда сакланалар.

[2] Цензор драманы китап итеп бастырган типографиянең исемен әлегә күрсәтә. Китапның үзеннән күренгәнчә, ул «Бораҙәран Кәримовлар» типографиясендә басылган. Шушы ук факт башка материаллар белән дә раслана (ТАССРның УДА. 420 фонд. 105 эш. 44 кәгазь; шунда ук, 109 эш. 28 кәгазь; Книжная летопись. 1908 ел. 16 сан.). Драманы бастыручы «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе», ул шул нәшриятның «Театр мәкмугасы» сериясеннән 8 нче китап булып чыккан. Басманың үзендә әсәрнең ничә данә басылуы күрсәтелмәгән. Архив документлары аның 3 мең данә тираж белән басылуын сөйлиләр. «Яшь гомер»не сәхнәгә куярга сорап кем үтенеч белән керүе ачык билгеле булмаса да, бу кешә Әхмәтгәрәй Хәсәни дип шикләнми әйтергә мөмкин. Әхмәтгәрәй Хәсәни үз исемендәге ширкә тарафыннан бастырылып чыгарган пьесаларны сәхнәгә куярга рөхсәт сорап һәрвакыт үзе мөрәҗәгать иткән. Архив документларыннан күренгәнчә, ул нашир гына түгел, әдип тә булган. «Хат болгатты» пьесасы авторы да шул ук Ә. Хәсәни. Архив документларында ул үзенең «Г. Ильяс» псевдонимы белән язуын күрсәтә. Бу псевдоним белән басылган әсәрләр бер «Хат болгатты» гына түгел. Шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк, документлардан күренгәнчә, «Яшь гомер» әсәре 1908 елның февраль азакларында басылып беткән. Шуңа күрә әдәбиятта аны 1908 елда язылды дип күрсәтү бик үк дөрес булып чыкмый. Ул 1908 елга хәтле, иң соң дигәндә 1907 елда язылып беткән.

алалар, бер кеше дә кол түгел, бернәрсәдән курыкмаска кирәк (41—42 битләр, рус әшчесенең сүзләре); байлар да, янәсе, әчәләр, ләкин аларны участокка япмыйлар, чөнки алар байлар, акчалары күп; гади халыкны алдыйлар, төрле сайлау партияләре оештырган булып йөриләр (47—48 битләр, Йосыф сүзләре); әгәр әшчеләргә мәсьәләнең нәрсәдә икәнен аңлатсаң, байлар болай кылана алмаслар иде (54—58 битләр, рус әшчесенең сүзләре.). Ярлылар һәм байларның социаль тигезсезлеге турындагы шул ук теманы митингларда лыгырдап йөрүче Галинең анасы, карт татар хатыны Фатима үзенең озын диалогында да чәйни. Ул таш пулатлар, кибетләр тулы алтын-җәүһәрләр турында, күпме халыкның ач-ялангач, мужикның җирсезлеге турында лыгырдый (61—62 битләр); ә менә гади әшче белән сөйләшеп кенә кара — алар барысын да аңлыйлар, ә укымышлы туташларга ел буе тукы — алар бер нәрсә аңламыйлар; кара әшче кызы укымышлы туташлардан күп тапкыр акыллырак, имеш (79—80 битләр, шул ук Вәли сүзләре); кая карама — акча да акча, бар нәрсә акчага сатыла, ләкин килер, имеш, бервакыт: тик моның өчен әшчеләрнең ныклы бердәмлеге генә кирәк (81—82 битләр, Гали һәм Йосыф сүзләре); капиталистлар да тик ятмыйлар: 17 октябрь манифестына таянып, фабрик-заводлар төзи бирәләр (87—88 битләр, Кайраучы сүзләре).

Автор фикере буенча, күрәсең, бу сукбайлар әсәрдә уңай геройлар һәм төрле хәрәкәтләргә игътибарга лаеклы кешеләр. Ә бит аларның барлык геройлыгы — казематта я полиция участогында утырып чыгу. Гали дә утырып чыккан, аннан башка бродягалар Дәүләт думасын тарату уңае белән җыелган митингка да барырга теләмиләр, янәсе, аннан башка беркем калмаячак (31, 93 битләр, Вәли сүзләре): чыннан да, янәсе, Гали бернинди гаепсез кулга алына, казематка ябыла, алты ай буе төрмәдә ятып чыга (109, 118 битләр, асрау карчык сүзләре). Сукбай Йосыф төрмәдә пролетар такмагын такылдый (49 бит). Болар белән берәттән шундый эпизодик күренеш тә бирелгән: ике кеше социализмны өнәмиләр. Берсе хәтта болай ди: «Падишаһ юаш. Мин падишаһ булсам социалистларның (В. Смирнов өстәве) барысын да асып бетерер идем!» Ә икенчесе аңа: «Аларның партияләре гадел партия булса, бөтен муллалар социалист булырлар иде!» — ди. Соңыннан беренчесе начар сүзләр белән сүгенеп җибәрә (84—85 битләр). Менә шушы инде, имеш, авторның социализм дошманнарына сатирасы. Шуның белән бергә үк, шәһәр бакчасында яшь рус егете яшь рус кызына министрның алдакчы булуын, депутацияләргә төрле вәгъдәләр биреп борып җибәрүен, ә соңыннан әйткән сүзендә тормавын тәнкыйтьли (15—16 битләр), ә либераль Гали шул ук бакчада әсәрнең героинясы Зөләйхага бәйләнгән бер кешегә ташлана, аны сәхнәдә әйтергә ярамый торган «Сукин сын!» дигән сүзләр әйтеп сүгә.

Шулай итеп, бернинди бәйләнешсез очрашулар, мәгънәсез чыгышлар, сөйләнүләр җыелмасы булган нәмәрсә ни өчендер «биш кәрдәле драма» дип аталган.

Ә ул чыннан да әшче-пролетариатка һәм аның реаль яки әле бөтенләй тормышта булмаган, төрле митингларда лыгырдап йөрүче, төрле сроклларда участок һәм төрмәләрдә утыручы, шуңа үзләренең җырында зарланучы, үзләренең, янәсе, хак әше, намус хыяллары һәм өметләре жиңү тантанасына ышанучы коноводларына дифирамб җырлаучы әсәр бу. Бу социаль күренешләрнең татар тормышында булуына ышандыру өчен автор пьесага рус пролетарийларын — пропойцаларны да керткән. Һәм менә шунда инде, янәсе, китапның тышында тантана белән әйтелгән «мәшһүр рус мәхәррирләреннән Максим Горький тәкъдимдән язылмыштыр» дию күренә булып чыга.

Бу «драма»ны сәхнәгә куярга рөхсәт бирү турында нинди булса да сүз булу мөмкин түгел, аңа башка дәлилләр китереп торуның кирәклеге юк икәне кәнә кебек ачык.

Әсәрнең төп максаты — пролетарийларда, турысын гына әйткәндә, бродягаларда мәлкәтле сыйныфларга бернинди нигезе булмаган дошманлык тудырырга тырышу һәм шул ук фикергә татар массаларын да ышандырырга маташу.

Тик шунысы шактый сәер тоела: дөньяга чыкканда ук бу әсәр ничек җирле цензура игътибарыннан читтә калды, чык-

кан уңайга ук юк ителмәде икән, халык арасында таралуына ничек юл куелды икән?[1]

Январьның 19 көне, 1909 ел. Смирнов (имзасы)»[2].

Документтан күренүенчә, бу доклад язуын В. Смирнов төзегән. В. Смирнов — XIX гасырның 80 еллар башыннан 1905 елгы революциягә хәтле Петербург цензурасында татар китаплары цензоры булып эшләп килгән, патша цензорлары арасында иң реакцион цензорларның берсе. 1905 елгы революциядән соң татар китаплары цензурасы Казанга күчерелгәнлектән, ул эшсез кала һәм үзен драма цензурасына эшкә алуларын үтенә[3]. Үз вакытында ул алдынгы татар культурасын буу, татар укучыларының кулына М. Лермонтов, Н. Гоголь, Л. Толстой кебек алдынгы фикерле рус язучыларының әсәрләре кермәсен өчен тырышса, дистәләрчә кулъязмаларга «бастырырга ярамый» дигән тамга салып, әсәрләрне дөньяга чыгармый тоткарлап, томалап яткырырга хөкем чыгарып килә. 1905 елгы революциядән соң инде заман бүтәнрәк, ялгыз бер шәхес башбаштаклыгыннан гына тормый иде. Шуңа күрә, элекке тыныч, рәхәт заманны сагына торган карагруһ цензорның 1909 елда инде бер ел чамасы элек китап булып басылып чыгып укучылар кулына ирешкән, җитмәсә шуны сәхнә аша тамашачыга күрсәтергә әзерлек күреп йөрелү фактына очрагач: «Тик шунысы сәер тоела: дөньяга чыкканда ук бу әсәр ничек җирле цензура игътибарыннан читтә калды, басылып чыккан уңайга ук юк ителмәде икән» дип чәч сугарга тотынуы бер дә гаҗәп түгел.

Бу язулар кәгазьдә генә калмый. Смирнов доклады килеп керү белән, Матбугат эшләре Үзәк идарәсе Казан губернаторына әсәрне чыгарырга рөхсәт биргән гаепле кешеләргә чара күрүне таләп итеп яшереп күрсәтмә җибәрә. Әсәрне дөньяга чыгарырга рөхсәт биргән кеше Казан университеты профессоры Катанов булып чыга. Ул үзенең бу мәсьәлә буенча язган аңлатмасында, әсәрне чыгарырга рөхсәт биргәнче, аннан «эшчеләр союзы һәм социализм» турында күп юлларны сызып ташлавын белдерә. Бу Казанда татар китабы цензурасы әле яңа оешкан еллар була. Татар китабы буенча цензор итеп алынган Катановтан тыш татар культурасын яхшы белгән ышанычлы кешеләр булмау сәбәпле, Казан Матбугат эшләре вакытлы комитеты председателе Пинегин Катановны бу балалардан аларга тырыша, аның цензурада әле генә эшли башлавын да искә алырга сорый. Нәтиҗәдә күерган җиллләр басыла, әсәрне патша чиновниклары юк итә алмый кала, ләкин аны яңадан бастыру яки сәхнәгә куярга сорап карау өчен инде бөтен юллар киселә.

Смирновның «Яшь гомер»гә язган доклады, күреп үткәнчә, әйтелеп бетмәгән фикерләр, кинаяләр белән тулган (аны тәрҗемә иткәндә без цензорның үз стилен сакларга тырыштык). Ул әсәрдәге теге яки бу фикерләрне берникадәр бәйләнешсез, кайдан әләксә шуннан тартып алып, янәсе, нихәтле томаланы, нихәтле күп тутырылса шулай яхшырак дигән принциптан чыгып яза. (Цензорның теге яки бу татар әсәрләрен дөньяга чыгармас өчен әмәлләгән барлык гаепләүләре дә шушы принцип белән языла торган булган).

Цензор фикеренчә, «Яшь гомер» берникадәр бәйләнешсез очрашулар, мәгънәсез чыгышлар, сөйләнүләр җыелмасы гына. Янәсе, анда берникадәр яңа драматик үсеш юк, ул, имеш, берникадәр нәтиҗәсез, чишелешсез тәмамлана. Смирнов үзе үк Я. Волынец «Оят яки күз яше» пьесасына язган докладында: «Бу әсәр драматик яктан балта кебек тупас, шулай булгач, аны (татар — Ә. К.) сәхнәсендә куярга цензура тарафыннан каршылыклар юк», дип чыга[4]. Янәсе, әсәр әдәби яктан нихәтле түбән булса, татарлар өчен шулхәтле яхшы. Бу да Смирновның татарларга карата тоткан политикасы.

Аның икенче дәлиле — әсәрдә сукбайлар, бродягалар, исерек башлар (пропойцалар) образлары чагылган. Янәсе, мондый образлар кергән әсәрләр сәнгать әсәре була алмый. Чынлыкта исә цензорны татар пролетар әдәбенең үз әсәрендә

---

[1] Бу юлларның астына кулъязмада кызыл кара белән сызылган.
[2] ЛҮДТА. 776 фонд. 26 тасвирлама. 85 эш. 2—3 кәгазьләр.
[3] Смирнов ялда вакытта цензор булып Заһид Шамил дигән кеше дә эшли.
[4] ЛҮДТА. 776 фонд. 26 тасвирлама. 85 эш. 18 кәгазь.

нәкъ менә тарихның алдынгы бер көче — эшчеләр сыйныфын, дөньядагы барлык материал һәм рухи байлыкларны тудыручыларны, үзләренең хокукларын даулап сыйнфый көрәшкә чыккан сыйныфның теләкләрен чагылдыруы котын алган. Алар үзләре нәкъ менә шундый эпитетлар тагып, эшче сыйныфын әхлаксыз, эчкече, талаучы итеп күрсәтергә тырыштылар, шуның белән үзләренең интересларын якларга тырыштылар. Цензор Г. Коләхметовны әсәрдә «Сукин сын» дигән сүз кулланган өчен гаеплә ргә, андый сүзне сәнгать әсәрендә куллану эстетик нормаларны бозу дип күрсәтергә азаплана. Шулай да бу «культуралы» профессор үз докладында эшчеләрне «пропойца», «бродяга» дип сүгүдән һич тә тартынмый. Царизм лакейлары, патша охранкасы Максим Горькийны да «сукбайлар» язучысы дип санарга тырышкан иде бит.

Патша самодержавиесе рус булмаган халыклар арасында социаль-демократизм идеяләре таралуга каршы бөтен көче белән көрәшеп килде. Бу максатын тормышка ашыру өчен, патша жандармериясе бернинди уйдырмалардан да чирканмады, төрлечә коткы таратуга барды. Рус булмаган халыклар арасыннан үсеп чыккан революционерларны алар рус халкы алдында «пантюркистлар», «панисламистлар» итеп күрсәтергә тырыштылар, рус халкының милли хисләре, халыкның бер өлешендә булган дини хисләр белән уйнадылар. Шушы ук нәрсәне без Смирнов докладында күрәбез. «Бу социаль күренешләрнең татарлар тормышында булуына ышандыру өчен, автор пьесага рус пролетарийлары — пропойцаларны да керткән» — дигән сүзе патша жандармериясенең әнә шул методларының чагылышы. Бу уйдырмаларның фальшьлеген татар хезмәт ияләренә төшендереп бирер өчен үз заманында большевикларыбыз Х. Ямашев, Г. Сәйфи-диновлар бик зур аңлату эше алып бардылар. Цензорны иң нык өркеткән нәрсә — рус һәм татар эшчеләренең сыйнфый дуслыгы. Шуңа күрә дә ул авторны әсәренә рус эшчеләре, рус халык вәкилләре образларын керткән өчен күралмый. Милләтләрне капма-каршы тоту, талаштыруны үзенең изү политикасында бер метод итеп кулланган патша хөкүмәте халыклар дуслыгыннан уттан курыккан кебек курыкты, аның лакейлары шул дуслыкны җимерергә тырыштылар. Смирнов та Г. Коләхметовның рус һәм татар эшчеләренең бергә эш алып баруларын, аларның үзара дуслыгын чагылдыруын әсәрнең җитешсезлеге итеп күрсәтергә маташа.

Смирновның эшчеләр сыйныфы вәкилләрен «пропойцалар» дип, аның җитәкчеләрен «коноводлар» дип хурларга тырышуы әсәрнең сәнгать ягыннан эшләнешенә түгел, бәлки аның идеясенә каршы көрәшүнең бер методы гына. Төрле юллар, төрле кинаяләр белән әсәрне юк итәргә тырышып карагач һәм шул эшне булдыра алмагач, цензор әсәрнең көчен танырга мәҗбүр була: «Эшче-пролетариатка... аның коноводларына дифирамб җырлаучы әсәр» дип күрсәтә. Әйе, «Яшь гомер» драмасы эшчеләр сыйныфына, аның алдынгы вәкилләренә дифирамб җырлый, революцион хәрәкәткә чакыра торган бер әсәр. Аның барлык көче дә, аның югары идеялелеге дә әнә шунда. Моны цензор бик яхшы сизенгән, менә шул аның котын алган.

«Яшь гомер»нең сәхнә цензурасында тоткарлануына караган бу документ әсәрнең революциягә хәтле ни өчен сәхнәгә менә алмавын ачык күрсәтә (әсәр татар театры сәхнәсендә Октябрь революциясеннән соң гына, бары тик 1918 елда гына тамашачыларга күрсәтелде). Бу бер фактта патша сатрапларының революцион хәрәкәткә, бигрәк тә рус булмаган халыклар арасындагы мондый хәрәкәткә каршы ничек һәм нинди методлар белән көрәш алып баруын чагылдыруы белән дә әһәмиятле.

Патша самодержавиесе шартларында халык интересларын чагылдырган күп кенә пьесалар сәхнәгә менә алмады. Татар театрының революциягә кадәр булган репертуар тарихын өйрәнгәндә патша цензурасының татар театрына карата тоткан политикасындагы менә шушы кайбер специфик моментларны исәпкә алырга кирәк.

КЕШЕ ҺӘМ СУГЫШ

Шамил Рәкыйповның документаль повестьлары турында

Бөек Ватан сугышы темасы безнең әдәбиятта аерым бер урын алып тора. Язучыларыбызның иҗатына ул фашист тупларының беренче залплары, самолет моторлары гөрелтесе, фугаслы бомбалар шартлавы белән бергә килеп керде.

Сугыш беткәннән бирле инде чирек гасыр гомер узды, ә шулай да бу тема кулларына корал тотып немец илбасарларына каршы сугышкан өлкән әдипләребезне дә, зур сугыш ялкынын бала чакларында гына күреп калган урта буын һәм яшь язучыларыбызны да һаман дулкынландыра әле.

Бу хәл, әлбәттә, дәһшәтле фашизм белән аяусыз көрәштә халкыбызның тарихи зур җиңүгә ирешүе, сугышка каршы көрәшнең елдан-ел тагын да көчәя, кискенләшә баруы белән генә аңлатылып бетми. Моның төп сәбәбе шунда: сугыш ялкыны эчендә, үлем белән кара-каршы очрашканда совет кешесенең бөтен асыл сыйфатлары — эчке рухының матурлыгы, батырлыгы, олы җанлы һәм көчле ихтыярлы булуы ачылды. Шуңа күрә узган сугыш темасының әһәмияте тарихилыкта гына түгел. Бу тема бик күп әхлак мәсьәләләрен яктыртырга мөмкинлек бирә.

Әмма Бөек Ватан сугышы темасына якын килү һәм аны ачу төрле вакытта төрлечә булды. Әйтик, сугыш вакытында, дошманны тизрәк җиңеп чыгу максатын күздә тотып, публицистик рухта язу өстенлек итте. Бу зур сугыш вакыйгаларын һәрьяклап тирәнтенрәк ачуга, сугышка катнашучы кешеләрнең тулы канлы характерларын күрсәтүгә нигездә сугыш беткәннән соң керешелде. Соңгы ун елда исә бу гаҗәп бай теманы яктыртуда яңа бер аспект сизелә башлады. Биредә мин конкрет тормыш фактлары, документлар, ягъни чын, булган хәлнең үзе белән эш итәргә омтылуны күздә тотам.

Безнеңчә, мондый омтылыш очраклы гына килеп тумагандыр. Соңгы ун елда элек без гадәтләнеп беткән күп кенә караш һәм фикерләр үзгәрде. Шул сәбәпле кешеләрдә дә вакыйга-хәлләрнең чынлыкта ничек булганлыгын белү теләге туды. Сугыш турында мемуарлар язу күбәйде, мәсәлән, атаклы полководецларыбыз Г. Жуков, К. Мерецков, генералларыбыз Ф. Булатов, Г. Сафиуллин һәм башкалар үзләренең истәлекләрен язып бастырдылар.

Әдәбиятыбызга героик очерк жанрының яңадан кайтуын, документаль жанрларга — документаль повесть, хикәя һәм әдәби эзләнүләргә күбрәк мөрәҗәгать итүне дә әлеге омтылышның нәтиҗәсе дип карарга кирәк.

Шамил Рәкыйпов соңгы берничә ел буена шушы жанрда эшләп килүче язучыларыбызның берсе.

Бу эшен ул исемнәре халыкка ачылмый калган геройларны эзләүдән башлады, совет кешеләренең Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары турында радио һәм телевидениедән сөйләде, Советлар Союзы Геройлары — татар халкының уллары турында матбугатта очерклар бастырды. Әнә шул очерклар соңрак аның «Геройлар эзеннән» исемле китабының (1968 ел) нигезен тәшкил итте.

Бу китапны язу дәверендә авторга тикшеренүче-казынучы тарихчы да, түземле-сабыр архивчы да булырга туры килде.

Мәсәлән, «Татарстан уллары — Советлар Союзы Геройлары» дигән китапта 267 герой турында кыскача белешмә бирелгән, аларның батырлыклары турында әйтелгән. Шул 267 геройның 57 се татар. Ләкин бу китапка башка өлкә һәм республикаларда туып үскән герой татарлар кертелмәгән икән. Ш. Рәкыйпов, әнә шул мәсьәлә белән кызыксынып, берничә ел буена хәрби комиссариатлар, башка өлкә һәм республикалардагы газета-журнал редакцияләре белән хат языша, СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге Үзәк архивына берничә тапкыр бара, ун меңләгән

карточка һәм бүләкләү документларын карап, 173 герой татар булуын ачыклый (герой татарларның саны шушының белән чикләнә дип булмый, автор әле һаман эзләнүен дәвам итә). «Геройлар эзеннән» дигән китапта әнә шул батырларның берничәсе турында сөйләнелә.

Шулай итеп, Ш. Рәкыйповның бу китабы әйбәт фактик нигезгә корылган. Яхшы сыйфат бу. Геройларның гомер юлы, кичереш-хыяллары, эш-көрәшләре, аларның ялкынлы патриотлык тойгысы — болар, бернинди әдәби бизәксез дә, үзләре генә дә зур кызыксыну уята. Нинди сыйфатлар, сәбәпләр аркасында бу кешеләр зур батырлыклар күрсәткәннәр, иң кыен, хәлиткеч вакытларда нинди көч аркасында алар кешенең кешелеген юк итә торган тойгыларыннан арына алганнар — укучының әнә шуларны беләсе килә. Һәм беренче чиратта бу мәсьәлә яшьләр өчен әһәмиятле, чөнки алар герой кешеләрнең бу сыйфатларын үзләренә үрнәк итеп алырга омтылалар һәм, табигый, мондый очракта алар уйлап чыгарылганнарга түгел, бәлки чын тормышта булганнарга таянып эш итәргә телиләр.

Тузанга батып беткән белешмә булсын, фронттан язылган хат яки икенче берәүнең үз күзе белән күргәннәрне сөйләве булсын — документның көче бик зур.

Документта сөйләнгән вакыйга-хәл яисә анда телгә алынган кеше гыйбрәтле, әһәмиятле икән, бу табыш үзе генә дә һәм аны матбугатта игълан итү генә дә сенсация булуы мөмкин (мәсәлән, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең тормышы турындагы чын документлар табылгач шундый хәл булды).

Ләкин мондый жанрда язучының иҗат фантазиясен документ чикләми микән соң? Юк, чикләми. Ш. Рәкыйповның очеркларын игътибар белән рак укысак, язучының батырлык эшләгән кешеләр турында безнең күз алдыбызда булган кебек чын итеп сөйләргә омтылуын күрәбез. Документка нигезләнеп, ул чын хәлне вагы-төягенә хәтле күз алдына китереп тасвирлый, вакыйгаларның киренкелеген бирә, безне дә батырлык эшләнгән вакыйга эченә алып керә. Ләкин бу нәрсә укучының ышанычын киметми, бәлки, киресенчә, документаль фактларның тәэсир итү көчен генә арттыра.

Менә, мәсәлән, китаптагы «Үлемсез Батыршин» дигән очерктан бер өзек:

«...Тирә-якта берсеннән-берсе биек, берсеннән-берсе мәһабәт сопкалар. Атлар ак, кызыл, зәңгәр һәм башка төстәге чәчәкләр белән чуарланган үзәндә бөдрәләнеп, берсе икенчесенә уралып үскән үләннәрне күкрәкләре белән ерып баралар. Билгеләнгән урынга килеп җиткәч, кораллар, өчаяк сыман итеп, бер-берсенә сөяп куелды. Сузып-сузып чалгы янаган тавышлар ишетелде. Аннары чик сакчылары, киек казлар кебек тезелешеп, үзәнлекне иңли башладылар. Иң алдан урта буйлы, киң җилкәле, җитез хәрәкәтле бер егет атлый. Ул — отделком Батыршин».

Автор Ерак Көнчыгышның кырыс һәм шул ук вакытта үзенчә матур табигатен шулай тасвирлап безнең күз алдыбызга китерә, алдагы вакыйгаларда ачылачак кешеләрнең, кечкенә-кечкенә төгәл штрихлар белән, характерларын билгели. Дөрес аныысы, китаптагы барлык очеркларны да бер үк дәрәҗәдә яхшы дип булмый. Кайберләрендә автор фактларны санап, газета теле белән сөйләп кенә чыга. Ләкин тулаем алганда китап һичшиксез үзенең максатын үти. Укучылардан авторга килгән йөзләгән хат шул турыда сөйли. Ш. Рәкыйпов китабында сөйләнгән геройларның исеме шәһәр һәм поселок урамнарына бирелә, аларның батырлыгына багышлап пионер сборлары җыела. Шушы хәл үзе генә дә язучының куйган максатына ирешкәнлеген күрсәтә.

Соңга таба язучы үз алдына катлаулырак бурыч куя. Ул инде батырлык турында сөйләп кенә калмый, төп игътибарын геройның характерын формалаштырган сәбәпләргә юнәлтә.

Яшь буынны тәрбияләү күзлегеннән караганда, бу момент бик әһәмиятле.

Мәсәлән, «Чәчәкләр сөйли белә» дигән документаль повестьта (1967 ел) халкыбызның батыр улы Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Барый Шәвәлиев турында сөйләнелә. Биредә автор төп игътибарны булачак геройның бала чагына бирә (моның белән геройның киләчәктә формалашу һәм үсүен күрсәтүгә беркадәр зарар да итә). Шушы беренче документаль повестьта, башкалары белән чагыштырганда, яшь авторның җитешсезлекләре, жанрның кимчелекләре дә ачык күренә. Мәсәлән, автор, геройның биографиясе генә укучыны артык кызыксындырмас дип курыккан сыман, повестьның сюжетына ятышмый торган детектив бер момент — документлар салынган сумканы яшереп кую вакыйгасын кертә. Бу вакыйга, әсәрдә кирәгеннән артык урын алып, укучының игътибарын читкә тарта, урыны-урыны бе-

лән хәтта кечкенә Барый образын да арткарак этәрә. Шуңа да карамастан повестьны укучылар да, әдәби тәнкыйть тә жылы каршы алды. Барыннан да бигрәк, повестьны уңышлы иткән сәбәп — язучының үз героена, аның характеры үсүе һәм формалашуына зур игътибар итүе булды.

Алдарак фактның, документның әдәбияттагы роле турында әйтеп киткән идек инде. Әмма шул ук фактик нигездә ижат ителгән әдәби образның тәэсир көче башкачарак. Әдәби персонаж укучының аңзиһененә генә кереп калмый, бәлки, иң элек, аның хис-тойгыларына тәэсир итә, күңел-кичереш дөньясына үтеп керә. Мәкалә яки очерктан моңарчы билгеле булмаган яңа герой турында укып мәгълүматлар алу бер хәл булса, шул вакыйгаларны үз күзең белән күрү, пуля яңгыры астында герой белән бергә дошман пулеметына таба шуышу, аның белән бергә сөенечен дә, кәенечен дә кичерү һәм нәтиҗәдә үз кимчелекләреңнән арынып, рухың яңару, батырлыкка, яхшылыкка омтылу теләге туу — бөтенләй икенче хәл. Чын мәгънәсендәге матур әдәбиятның тәэсир итү көче дә шулай укучының күңел дөньясына үтеп керә алуында чагыла.

Ләкин документаль повесть шушы төп максатын үтәсен һәм укучының күңелендәге тойгыларын кузгатсын өчен фактларны чәчми-түкми, дөрес итеп язып чыгу гына аз. Моның өчен матур әдәбияттә моңарчы тупланып килгән тәжрибәгә таянып эш итәргә, әдәби алым һәм тасвирлау чараларының бөтен байлыгын куллана белергә кирәк. Батырлыкның нинди хәлләр эчендә эшләнүен вакыйганы күргән кешеләр сөйләвә буенча да тасвирлап биреп була. Әмма геройның эчке дөньясын, тойгы-кичерешләрен, уй-фикерләрен ачу өчен икенчерәк нәрсә — язучының әдиплек фантазиясе, ижади уйлап чыгара белү кирәк.

Әйтик, язучы үз әсәрендә геройның сөйләшкән сүзләрен бирә. Хәлбуки, автор үзе аны күрмәгән дә, ишетмәгән дә. Ул чын тормышта, нәкъ шул вакытта шул рәвешчә әйтелгән сүзләрне әсәрендә китерә алмый, чөнки геройның ничек, нәрсә сөйләшкәнен беркая да язып, теркәп калдырмаганнар. Язучы геройның характерыннан, тормыш тәжрибәсеннән чыгып мондый хәлдә ничек сөйләшү ихтималына таянып кына яза. Шул рәвешчә, геройның сөйләм характеристикасы аның хакында мәгълүмат бирү максатына түгел, бәлки күңелдә калырлык тулы канлы образ тудыру бурычына хезмәт итә.

Менә «Чәчәкләр сөйли белә» исемле повестьтан бер-ике мисал: Барыйның әтисе Гани абзый ишек алдында утыра, тәртип белән бик пөхтә итеп җыештырылган йортта вак-төяк тормыш кирәк-яракларын күзеннән кичерә. Иректездән аның уйлары авылларында төзелеп яткан колхоз хәлләренә күчә. Автор аның уй-фикерләрен бер дә шомартмыйча, психологик яктан ышандырырлык итеп һәм үз хуҗалыгына ябышып яткан урта хәлле крестьянга хас рәвештә бирә:

«Миңлевали сөйләгән колхозга эләгеп, йөз төрле эш коралы болгана-болгана бер казанда кайный башласа, ай-һай, мондый ялт итеп торган тәртип булырмы икән? Боламыктан башканы кетәргә дә ярамый. Энекәшенең генә моны аңламавы гажәп. Тәки үз сүзен итә дә тора. «Бергә-бергә эшләвә дә, яшәвә дә күңеллерәк булыр»,— ди ул. Шахта бозды егетне, шахта. Җыен тузга язмаганны шуннан өйрәнеп кайтты. Ел буе маңгай тирен түгеп тапкан хәләл акчасын чыгарган да салган, ахмак...»

Автор үз исеменнән бер сүз өстәмәсә дә, бу эчке монолог ярдәмендә каршыбызда шактый тулы һәм эзлекле итеп тасвирланган образ килеп баса. Менә, Гани абзыйны калдырып, автор хикәяләүне икенче герой күзлегеннән дәвам итә. Бу юлы инде интонация дә, җөмлә төзелеше дә киная үзгәрә:

«Ул, әнисенең кисәтүен онытып, капкага таба кыяклады. Келә шапылдап төшеп, арттан кычкырмыйлармы дип беркавым тыңлап торгач, бәйдән ычкынган яшь бозау төсле сикергәли-сикергәли, түбән очка карап чапты. Хәзер аның Барый абыйсы мәктәптән кайтырга тиеш. Әллә ничә тапкыр барды инде ул мәктәпкә. Габделвәли инде чутын да югалтты. Көн саен бер үк эшне эшләү ялыктыра булыр ул. Өстәвенә көне буе диярлек бер дә селкенмичә утырып тор әле сиңа! Гомергә барасы юк Габделвәлинең андый күңелсез җиргә! Рәсемле китаплар гына җәл, мәктәпкә йөрмәүчеләргә аларның читен дә күрсәтмиләр...»

Нечкә юмор белән сугарылган кыска гына бу эчке монологта да без һәни геройның үзенчәлекле характерын тоябыз. Күрәбез: әсәр документаль дип аталса да, бернинди документларда да бу эчке уй-кичерешләр теркәлеп калмаган. Автор аларны үз хыялы белән тудырган һәм дөрес эшләгән.

Соңрак язылган «Кайдан син, Жан?» (1969 ел) һәм «Таңнар һаман матурмы?» (1970 ел) исемле китапларында Ш. Рәкыйповның каләме шактый ныгый төшә, ә документаль повесть жанры өкренләп үзенең чын хосусиятенә керә бара. Мәсәлән, язучы, төрле уйдырма нәрсәләр белән сюжетны катлауландырудан баш тартып, төп игътибарын геройның тормышында булган чын вакыйга-хәлләргә туплый. Ләкин бу хәл ижади уйлап чыгаруның әһәмиятен киметми, киресенчә, арттыра гына. Мәсәлән, «Кайдан син, Жан?» повестенда геройның беренче мәхәббәте, аның Тамарага булган матур хисләре турында лирик бер җылылык белән, нечкәләп языла. Бу мәхәббәтне ачудагы күп кенә эпизодны автор үзе уйлап чыгарган. Ләкин алар төп геройның характер логикасына каршы килми. Соңга таба инде әсәрдә Иван Кабушкинның чын үз хаты бирелгәч, без фактларның авторның мөмкинлеген чикләмәвенә, аңа ижади таяныч бирүенә кабат ышанабыз. «Таңнар һаман матурмы?» повестенда да автор материалны ничек табуын, геройның туганнары, дуслары-иптәшләре белән очрашуын укучыдан яшерми. Аны материалның **чынлыгына** ышандырганнан соң, автор, хикәяләү рәвешен кинәт үзгәртеп, һәлак булган **герой исеменнән** сөйли башлый. Әйтергә кирәк, язучы үз героеның теге яки бу вакытта ниләр уйлаганын, ниләр кичергәнен үз күзе белән күрә, ишетә алмаса да, ул сайлаган эчке монолог формасы үзен тулысынча аклый. Ш. Рәкыйпов чын тарихи шәхеснең тормышындагы төп нәрсәгә — аның батырлыгына таяна. Калганнарын — персонажларның сюжет эчендәге мөнәсәбәтләрен, төрле теләк-омтылышларын, гадәт-холыкларын урыны-урыны белән чамалап, урыны-урыны белән үзеннән өстәп тулыландыра һәм шул нигездә батырлыкның күп яклы, тормыш хәлләре белән тулы атмосферасын барлыкка китерә.

Димәк, документаль повесть жанрының үз хосусияте, үз кыенлыклары һәм авырлыклары бар. Язучы бик җентекләп белешкән, эзләп тапкан чын тормыш материалына таянып эш итә. Ул аны ничек тапканлыгын укучылардан яшерми, кайвакыт исә материалны ничек тапканлыгын, чынлыгына ышандыру өчен, укучыга юри дә сөйләп бирә. Ләкин фактлар аңа башлангыч ориентир булып кына хезмәт итә. Шуларга таянып, ул героеның күңел дөньясын, аны батырлык эшләргә этәргән сәбәпләрне эзли. Өстәвенә, «гадәти проза»дан үзгә буларак, ул төп персонажларының характер сыйфатларын үзе теләгәнчә үзгәртә яисә чынлыкта герой эшләмәгән зур эшләр уйлап чыгара алмый. Шулай итеп, үзеңнән уйлап чыгаруның чамасы билгеле бер дәрәҗәдә документ булып расланган фактларның күләменә бәйле. Ш. Рәкыйпов чын тормышта булып узган вакыйгаларны яңадан корганда күпчелек очракта образ логикасы белән тарихи факт логикасының табигый ярашуына ирешә. Аның әсәрләре укучы күңелен әнә шул ягы белән яулап ала да.

Әмма, документаль проза, сәнгатьчә прозаның бер өлкәсе буларак, шулай ук камиллек, аерым кисәкләренең үзара ярашкан һәм композициясе уйланган, бер бөтен булуын да сорый. Бу яктан караганда, Ш. Рәкыйпов повестьларының бөтен җире дә килгән, шома дип булмый. Еш кына ул геройлары тормышының фактик ягы белән артык мавыгып китә һәм әсәрендәге төп образларның характерларына бернинди яңа нәрсә өстәми торган эпизодлар, исем-фамилиясе генә әйтелгән, һичничек күңелдә калмый торган чырайсыз персонажлар күренә башлый. Чынлыкта шулай булган бит дигән сылтау гына авторга акланырлык нигез була алмый, чөнки чын тормыштагы эпизод белән сәнгать әсәрендәге эпизодның әһәмияте, мәгънә куәсе һәрвакытта да бер үк дәрәҗәдә булмый. Язучы меңләгән хәл-күренешләрдән иң кирәкле, иң хасларын гына үзенең ижат максатыннан чыгып сайлап ала. Шулай итеп, повестьтагы автор сайлап алган эпизод эчтәлеклерәк, мәгънәсе дә тирәнрәк була, чөнки ул инде очраклы нәрсә түгел. Көндәлек тормышта без йөзләгән-меңләгән сүз сөйлибез. Язучы шуларның берничәсен генә, мәгълүмат бирүдән тыш, персонажларның халәтен ача, аны образ буларак характерлый һәм еш кына эчкәрерәк яткан икенчел мәгънәне бирә торганнарын гына сайлап ала. Әнә шулай иң кирәкле сүз, күренеш, хәлләрне генә нечкәләп сайлап ала белү Ш. Рәкыйпов повестьларында еш кына җитеп бетми әле.

Шулай да, кайбер аерым кимчелекләрә булуга карамастан, Ш. Рәкыйпов повестьлары — яшьләр өчен языла торган әдәбиятыбызда кызыклы һәм үзенчәлекле бер күренеш. Бу әсәрләр яшьләр күңеленә батырлык романтикасы сала, зур үрнәк булырлык тормыш мисалларында патриотлык тойгысы тәрбияли, Ватанга турылыклы булырга өйрәтә.

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.

БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Н. ИСӘНБӘТ. Балалар дөньясы.
Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел

Нәкый ага Исәнбәт балалар авыз иҗатын җыю, фәнни өйрәнү, аны төрләргә, жанрларга бүлү һәм тәртипкә салу буенча да ифрат зур эш башкарган хөрмәтле кешебез. Әле 1967 елда гына аның балалар арасында таралган җырлы-сүзле уеннарны, төрле такмакларны һәм санамышларны эченә алган «Нәниләр шатлана» исемле җыентыгы дөнья күргән иде. Узган ел ахырында ул балалар фольклорына багышланган тагын бер китап чыгарды. Күпмедер күләмдә «Нәниләр шатлана» китабын кабатлаган, шул ук вакытта аның дәвамы төсендәрәк төзелгән әлеге җыентык «Балалар дөньясы» дип атала. Һәм аңа бишек җырлары, такмак-такмазалар, тел шомарткычлар, әйтешләр, сайравычлар, алдавыч әкиятләр, яшүсмерләр яратып җырлый торган көйле җырлар тупланган.

Билгеле булганча, балалар фольклоры халык авыз иҗатының бик тә үзенчәлекле һәм бай бер өлкәсе санала. Жанр һәм характерлары ягыннан берсе-икенчесеннән нык аерылган кебек, балалар авыз иҗатына караган әсәрләр үзләренең бурыч-максатлары һәм күләмнәре белән дә гаять төрле-төрле. Баланың яшенә, үсеш һәм аң дәрәҗәсенә карап, аларны тагын да вәгъдәк махсус төркемнәргә бүлгәләргә мөмкин. Н. Исәнбәт дөрес язганча, бишектәге бәбигә үч төбендә яки тез өстендә сикертү, сигез яшьлегенә урамда авызлык кабып, ат булып кешнәп чабу кызык тоелса, унсигездәгесенә имезлек тә, авызлык та кирәкми... Шуларның һәммәсен истә тотып, галим үзе туплаган материалны аерым бүлекләргә бүлеп урнаштырган.

Беренче бүлек «Бишек яны» дип атала. Исеменнән үк күренгәчә, бу бүлеккә нәниләргә генә караган һәм бала тәрбияләүдә киң урын тоткан бишек җырлары, баланы юату, үчтеки сикертү, чәбекәй иттерү, бнетү, аны мунча кертү, юындыру, киендерү белән бәйле җыр-такмаклар туплап бирелгән. Теле ачылып, тәпи йөрү башлауга, бала тирә-юньдәге табигать, кош-кортлар белән бәйләнешкә керә, аның зур дөньяны танып-белү процессы башлана. «Бала һәм табигать дөньясы» дип исемләнгән икенче бүлеккә баланың төрле кош-кортлар, җәнлекләр арасында яшәвен, аларга төрлечә эндәшүен, аларны аерырга өйрәнә башлавын гәүдәләндергән әсәрләр кертелгән. Төрле әкәмәт эшләр турындагы кечкенә генә әкият-хикәяләрне фән телендә такмазалар дип йөртәләр. Такмазалар — балалар фольклорының иң үзенчәлекле һәм аеруча киң таралган бер төре. Кемнәр турында гына, нинди хәлләр турында гына сөйләнми аларда!.. Китапның «Такмазалар» дигән бүлегендә аларның барлык төрләре белән дә танышырга мөмкин. Балалар арасында киң таралган тел шомарткычларны, шулай ук төрле әйтеш һәм сатираларны төзүче аерым-аерым бүлекләр итеп урнаштырган. Соңгы сигезенче бүлектә яшүсмерләр яратып җырлый торган көйле җырларның кайбер үрнәкләре бирелгән. Алар арасында без, халык җырлары, җырлы-сүзле уеннар белән бергә, шагыйрь һәм композиторларыбызның халыклашып киткән җырларын да очратабыз.

Нәкый аганың башка җыентыклары кебек үк, «Балалар дөньясы» да фәнни аппаратының байлыгы белән аерылып тора. Иң элек, һәр бүлек саен диярлек балалар авыз иҗатында очрый торган аерым жанрларга махсус аңлатмалар бирелеп барылган. Китап ахырында исә «Балалар авыз иҗаты турында» исемле зур фәнни мәкалә урнаштырылган. Автор аңа «бу китапка кергән материаллар буенча» язылды дигән искәрмә бирсә дә, асылда ул күп тапкыр киңрәк һәм зуррак мәсьәләләрне ачыкларга булыша. Н. Исәнбәт анда балалар фольклорына билгеләмә бирә, балалар тормышында халык әдәбиятының тоткан урынын һәм балалар фольклорын өйрәнүнең әһәмиятен ачыклый, татар балалар фольклорын җыю һәм өйрәнү мәсьәләләрен кузгата, әдәби әсәр булу ягыннан балалар авыз иҗатының кайбер үзенчәлекләренә һәм башка мәсьәләләргә туктала.

...Җыйнап кына әйткәндә, Нәкый ага Исәнбәт нәни дусларыбызны һәм барлык укучыларны тагын бер зур бүләк белән шатландырган.

Х. ХАЛИКОВ. Шук бабай. Шигырьләр.
Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кызыклы китаплар бездә аз чыга. Бу, барыннан да элек, нәниләребез өчен язучы әдипләребезнең бармак белән генә санарлык дәрәҗәдә аз булулары, иҗатларын аларга багышлаганнарының да бөтен көчкә җигелеп эшләмәүләре белән аңлатыла. Мәсәлән, шуңа күрә дә әдәбиятыбызда, шул җөмләдән поэзиябездә беренче адымнарын ясаучы яшь каләмнәрнең кечкенәләргә атап язган уңышлы әсәрләрен аерым җыентыклар итеп бастырып чыгаруга Татарстан китап нәшрияты зур игътибар бирә. Моннан ике ел элек нәни дусларыбыз яшь

шагыйрь Хәкимҗан Халиковның «Йолдызлар ничәү» дигән китабы белән танышканнар иде. Узган ел ахырында аның «Шук бабай» исемле яңа җыентыгы басылып чыкты. Җыентыкка кергән шагыйрьләрдә Хәкимҗанның кече яшьтәге балаларның тормышларын, аларның эчке дөньяларын, психологиясен яхшы белеп эш итүе күзгә ташлана. Чоландагы сөт чүлмәген кыл урталай ярган Суык бабай, сыкылы юлдан ыңгырашып барган чанасын, әллә аңа авыр микән дип, кызганган Миләүшә, өйдә озак авырып ятсам, тышта миңа уйнарга уен калмас бит инде дип борчылучы малай образлары сурәтләнгән «Шук бабай», «Елак чана» һәм «Кайгы» шигырьләрен кечкенәләр, һичшиксез, яратып кабул итәчәкләр. Чаңгылары өр-яңа булуга карамастан, тау шуганда адым саен егылучы малай турындагы «Чаңгы шуганда» шигыре дә аларның күңеленә хуш киләчәк:

Үзе минем абый кадәр,
Ни булган бу малайга,
Чаңгылары да өр-яңа,
Гел егыла алай да.

Аптырагач, чаңгыларын
Ул салып үк ташлады:
— Әти, болар егалар бит,
Алып кайтыйк башканы.

Хәкимҗан Халиков шигырьләренә конкретлылык, балаларның игътибарын үзенә җәлеп иткән аерым вакыйга һәм күренешләрне күз алдына китереп бастыра алырлык поэтик детальләр аша гәүдәләндерү хас. «Тапкыр сыерчык», «Каргалар», «Таллар», «Кояшлы яңгыр», «Тәнге урманда», «Очты-очты», «Бии белмәгән ая» шигырьләре моңа ачык мисал булып тора. Яшь шагыйрьнең кечкенә геройлары үзләрен аз сөйләшүчән, ләкин тапкыр сүзле булуларын белән яраттыралар. Бу уңайдан җыентыктагы «Шаккаттылар» һәм «Әзер җавап» шигырьләрен күрсәтеп үтәсе килә. «Шаккаттылар» шигырендә сүз елгага төшеп киткән туп турында бара. Малайлар, аны алырга суга син кер дә мин кер, дип шаулашалар. «Әй, куркаклар!» — дип елгага шигырьдә беренче заттан сөйләүче малай үзе сикереп төшә. Шигырь аның шаян рухта әйтелгән сүзләре белән тәмамлана:

Тупны алып чыккачтын,
Шаккаттылар барысы.
Су төбенә күл җитсә,
Йөзәм лә мин анысы.

«Әзер җавап» шигырендәге шаян кыз Рузидә дә әлеге үткен телле малайдан калышмый. Әнисенең:

— Тизрәк үсәр, помидорга
Су сибеп кер, Рузидә,—

дигән сүзенә каршы ул:

— Мин су сипмичә дә үсәм,
Үсәр өлге үзе дә,—

дип җавап кайтара.

Балаларда ата-анага, табигатькә, кошкортларга карата мәхәббәт тәрбияли торган шигырьләргә дә җыентыкта киң урын бирелгән. Рәссам Илдар Әхмәдиев китаптагы һәр шигырьнең эчтәлегенә туры китереп, аны аңларга ярдәм итәрдәй матур-матур рәсемнәр ясаган. Җыеп кына әйткәндә, яшь шагыйрьнең бу китабы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ихтыяҗларын күпмедер микдарьдә канәгатьләндерерлек шигырь һәм рәсемнәрне эченә алган. Мондый китаплар киләчәктә күбрәк язылсын һәм зуррак тираж белән бастырылып чыгарылсын иде.

А. ГАЛКИН. Дуслар. Хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел

Александр Галкин урта буын чуваш язучыларының сәләтле бер вәкиле санала. Матбугат битләрендә аның беренче әсәрләре моннан унбиш еллар элек күренә башлаган иде. Шуннан бирле узган вакыт эчендә ул дистәдән артык китап чыгарып өлгерде.

Киң катлау укучыларга А. Галкин күбрәк бүгенге тормышның актуаль мәсьәләләренә багышланган шигырь һәм мәсәлләр иҗат итүче шагыйрь буларак билгеле. Ләкин ул әдәбиятның башка жанр һәм тармакларында да шактый нәтиҗәле эшләп килә: очерклар, хикәяләр яза, балалар әдәбияты өлкәсендә эшли. Узган ел Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Дуслар» исемле китапка аның нәкъ менә шул өлкәдәге эшчәнлеген чагылдырган әсәрләре — балалар тормышыннан алып язылган хикәяләре тупланган.

Җыентыкка авторның сигез хикәясе урнаштырылган. Аерым-аерым укып караганда, болай аларның сигезе сигез төрлерәк тәэсир калдыра. «Яман чир», «Карабүрек» шикелле ифрат җыйнак эшләнгәннәре, зур эмоциональ тәэсир көченә ия булганнары бар. «Бакчадагы лагерьда» яки «Көтелмәгән шатлык» сыман таркаурак чыкканнары, сүлпәнрәк язылганнары очрый. Ләкин А. Галкин хикәяләренә, зур күләмле әсәр укыган кебек, баштан ахырга кадәр тоташ, рәттән укырга кирәк: аларның чын кыйммәте шул чагында гына ачылып җитә. Мондый хәлне А. Галкин хикәяләрендә бер үк геройлар һәм бер үк тормыш күренешләре алыну белән генә аңлатып бетереп булмый. Хикмәт тагын шунда: язучының барлык хикәяләре диярлек бер-берсен тулыландырып һәм ачыклап киләләр. Бер урында аңлашылып җитмәгән нәрсәләр икенче төштә ачылып китә, бер хикәядә төсмерләнеп кенә калган персонажлар икенчесендә тагын да тулырак һәм тормышчанрак төстә гәүдәләнәләр. «Арифметика хикмәтләре» һәм кайбер башка хикәяләр буенча авторның әсәрдән-әсәргә күчеп йөргән геройларыннан Пашаны без, мәсәлән, һәрьяктан килгән әйбәт укучы дип күз алдына китерә идек. Баксаң, ул малайга мин-минлек, ипташләрен санга сукмау кебек начар гадәтләр дә хас икән. Паша характерындагы бу якларны без «Чәчәк» исемле хикәяне укыгач беләбез. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, «Көтелмәгән шатлык» хикәясе, ничектер, төссезрәк язылган. Әмма шушы йомшак хикәядә сөйләнгән вакыйгаларның да алга таба бер кирәге чыга. «Көтелмәгән шатлык» хикәясендәге полковник бүләк иткән кесә фонарен биреп, Михаил Карабүрекне

үлемнән коткарып кала («Карабүрек» исемле хикәя)... Шул рәвешчә, җыентыктагы хикәяләр бер-берсен үстереп, көчәйтеп киләләр.

Александр Галкин балалар психологиясен, аларның холык-гадәтләрен әйбәт белә. Балаларның шау-шулы тормышын, тулы канлы, тормышчан образларын җанлы итеп күз алдына бастыра ала. Аңдый эпизодларны язучының теләсә кайсы хикәясендә очратырга була.

Хикәяләрне чуваш теленнән Гали Хәйретдинов тәрҗемә иткән. Дөресен әйтергә кирәк, тәрҗемәче үз эшенә җаваплы караган. Аерым кытыршы сүзләрне, балалар өчен авыррак булган кайбер тәгъбирләрне исәпләмәгәндә, тәрҗемә уңай тәэсир калдыра. Хикәяләр татарча әйбәт яңгырый, җиңел һәм яратып укыла.

Күңелле сәхнә. 19 нчы китап. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел

«Күңелле сәхнә»нең чираттагы 19 нчы китабы әдипләребезнең Владимир Ильич Ленинга багышланган әсәрләре белән ачыла. Алар арасында без И. Юзеевның «Курайчы егет» исемле балладасын, С. Хәкимнең «Беренче тау» һәм «Без Казаннан, Иделдән», М. Садриның «Туры юлым — Ленин», Х. Камаловның «Ленин онытмады», Г. Рәхимнең «Октябрь», К. Мостафинның «Унҗиденче елның матросларын» исемле шигырьләрен һәм В. Д. Бонч-Бруевич, Е. Мар, А. Кононов, С. Алексеевларның Ильич турындагы истәлекләрен, хикәяләрен очратабыз. Ул әсәрләрнең һәммәсе хезмәт ияләренең сөекле юлбашчысына карата тирән ихтирам һәм эчкерсез мәхәббәт хисләре белән сугарылган.

Күләм ягыннан чыгып караганда, җыентыктагы иң зур урынны сәхнә әсәрләре алып тора. Драматурглар иҗатына багышланган икенче бүлекка бер скетч, өч комедия урнаштырылган. Арада, күтәргән мәсьәләләренең тормышчанлыгы, образларының сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, ситуацияләренең кызыклы булуы белән, Ә. Мирзаһитовның «Кәндәгы елан», һәм Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары» исемле комедияләре аерылып тора.

Колхозчыларның культура ихтыяҗларына, ничектер, искитмичәрәк, салкынрак карарга өйрәнгән председательдән яшьләр үч алырга, аны кызык итәргә булалар. Һәм итәләр дә. Күпме генә карышып йөрмәсен, ахыр килеп, ул барыбер яшьләр сораганнарның бөтенесен эшләргә: больница белән ясле салдырырга да, клубка ремонт ясатырга да һәм ферма кызларының барлык үтенечләрен канәгатьләндерергә дә мәҗбүр була. Бик гомумиләштереп, бер сүз белән әйткәндә, «Кәндәгы елан» комедиясе әнә шул хакта.

Туфан Миңнуллинның «Нигез ташлары» комедиясе мораль мәсьәләләренә багышланган. Көннәрнең берендә карчыгы белән ялгызы гына яшәп яткан Гарифулла карт тота да: «Тизрәк кайтыгыз, үлем түшәгендә ятам» дип, малайларына ашыгыч телеграмма суга. Бер заман илнең төрле почмакларыннан, хатыннарын, балаларын ияртеп, картның малайлары кайтып төшә. Кайтсалар, әтиләре тап-таза, җир җимертеп эшләп йөри... Ахырдан ачыклана: ул аларны бөтенләй башка ният белән чакырткан икән. Гарифулла карт фикеренчә, малайлар — аның нигез ташлары, ә нигез ташларын гел карап торырга, алар естенә үскән мүкләрне кыргалап торырга кирәк. Башкача әйткәндә, үзе исән чакта малайларның һәммәсен тагын бер күреп, сөйләшеп каласы килгән аның. Дөрес яшиләрме алар? Мүкләнеп бетмәгәнме аның нигез ташлары?.. Сораша-төпченә торгач белә: болай ярыйсы гына яшиләр икән. Тик малайларның мүкләнә башлаган урыннары да ачыла. Олы улы Хәниф артык канәгать һәм пошмас кешегә әйләнә бара, министр урынбасары булып эшләүче икенче улы борын күтәрә, һавалана башлаган. Шулай да таякның иң юан башы склад мөдире Хәлил җилкәсенә төшә... Үзенең бөтен пафосы, яңгырашы белән әсәр мещанлык мораленә, вак җанлы кешеләргә каршы юнәлтелгән.

«Күңелле сәхнә»нең яңа санында хикәяләргә дә шактый киң урын бирелгән. Китапның өченче бүлегендә ун авторның юмористик һәм сатирик характердагы унбишләп хикәясе басылган. Сыйфатлары төрлесенеке төрлечә. Шактый тапталган темаларга язылганнары, елмайтмый да, көлдермәсә дә торганнары очрый. Матурлары, рәхәтләнеп укырдайлары бар. К. Рәхимнең «Замана каргалары», Р. Фәезовның «Катгый сөйләшү», М. Мәһдиевнең «Сабакташ», Ф. Яруллинның «Авыл мунчасы» исемле хикәяләре арада уңайрак тәэсир калдыра.

Җыентык поэзия әсәрләре белән ябыла. Ә. Исхак, Г. Афзал, Н. Дәүли, З. Нури, Ш. Галиев, Ф. Шәфигуллин, Г. Насыйров һәм башка шагыйрьләрнең соңгы дүртенче бүлектә басылган юмористик шигырьләре укучылар күңелена хуш килер дип ышанәсы килә. Кыскасы, «Күңелле сәхнә»нең бу яңа саны материалларга шактый бай һәм кызыклы чыккан.

Рассказы 1969 года. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел

Татарстан китап нәшрияты татар әдәбияты үрнәкләрен рус укучылары арасында пропагандалау буенча зур эш башкара. Алдыбыздагы китап — шуның бер мисалы. Исеменнән үк күренгәнчә, аңа прозаикларыбызның 1969 елда иҗат иткән хикәяләре тупланган.

Җыентыктагы хикәяләрнең күбесе татар укучыларына электән таныш. Г. Башировның «Кыл өстендә» (русча — «Старшенькая») дигән хикәясе, мәсәлән, «Азат хатын» журналында, ә Ф. Хөснинең «Үземне югалттым» исемле хикәясе «Казан утлары»нда басылган иде. Х. Сарьянның «Пакуҗ», С. Себировның «Хәтәр сәфәр» (русча — «Без единого выстрела»), Г. Ахуновның «Фатих улы», М. Рафиковның «Сиңа ничә яшь?»,

Л. Хәмидуллинның «Кыш үткән юл буйлап» (русча — «Незабываемым проселком»), М. Хәбибуллинның «Яраткач, ташламыйлар» кебек хикәяләрен дә укучылар беләләр булыр. Хәзер генә саналган хикәяләрнең кайберләре татар телендәге газета-журнал битләрендә, икенчеләре авторларның җыентыкларында басылып чыкты. Аннан соң, ул хикәяләр тәнкыйтьчеләрнең дә игътибар үзәгендә булды. Аларның әһәмияте, уңышлы һәм кимчелекле яклары турында шактый язылды. Шуңа күрә аларга махсус тукталып, аңлатып торуның әллә ни кирәге юк сыман. Игътибарны күбрәк татар укучыларына бик үк таныш булмаган авторларга, алар каләме белән иҗат ителгән әсәрләргә юнәлтәсе килә.

Илдар Низамов — нәкъ шундый авторларның берсе. Аның Казанга күчеп килүенә күп булса 3—4 ел вакыт узды. Шушы аз гына вакыт эчендә ул үзен актив рәвештә иҗат итүче уңган һәм сәләтле хикәяче итеп танытып өлгерде: газета-журналлар битендә дистәгә якын парча һәм хикәя бастырды, ике җыентык чыгарды. Илдарның без тикшерә торган җыентыкка кергән «Ерактагы бәхет» (русча — «Счастье без встреч») исемле хикәясе дә әйбәт тәэсир калдыра. Күләме белән артык зур булмаган хикәядән чын тормыш сулышы бөркеп тора, анда гади һәм әйбәт кешеләр бар, шуларның бик тә мәгънәле, гыйбрәтле язмышы бар. Шуңа да хикәя ышандыра, күңелне әсир итә.

Билгеле булганча, Татарстанда рус язучыларының зур төркеме отряды эшли. Җыентыкта алар иҗатына да киң урын бирелгән. «Известия» газетасының үз хәбәрчесе Виктор Байдерин сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга багышланган хикәяләрдән махсус җыентык чыгарган кеше. Аның «Музыкаль бүләк» исемле җыйнак һәм матур хикәясе дә Ульяновлар гаиләсе турында. Михаил Скороходовның «Йөз поляр километр» исемле хикәясе безне дәһшәтле Ватан сугышы чорына алып китә. Хикәядә без кырыс төньяк табигате, кыю йөрәкле кешеләр, аларның батыр эшләре белән танышабыз. «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе Марсель Зарипов, Казанга килгәнче, нефтьчеләр арасында яшәде. Аның «Ятлар» («Чужие») хикәясе республикабызның йөзен үзгәрткән нефть промышленносте эшчеләре тормышыннан алып язылган. Хикәядән авторның нефтьчеләрнең авыр хезмәтен, аларны борчый һәм дулкынландыра торган мәсьәләләрне ярыйсы ук яхшы белүе күренә. Бигрәк тә әсәрдәге төп образлардан Баныкин әйбәт эшләнгән.

Ниһаять, тәрҗемәчеләр хезмәте турында берничә сүз. Хикәяләрне русчага тәрҗемә итүгә унлап тәрҗемәче катнашкан. Нигездә аларның һәрберсе үз эшенә җавап белән караган. Тәрҗемәләрнең сыйфатына артык тел-теш тидерерлек түгел. И. Гизатуллин, М. Зарецкий, М. Рафиков һәм И. Якименко тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләр исә аеруча уңай тәэсир калдыра.

В. Климентовский

«СӘЛӘТСЕЗ» СТУДЕНТ

Тормышлары Казан белән бәйләнешле атаклы рус әдипләренең берсе һәм безгә иң билгелесе, әлбәттә, Лев Толстой.

Лев Николаевичның Казанга килүе очраклы хәл генә булмый. Толстойлар нәселе күптән инде Казан белән якыннан бәйләнеш тоткан һәм кайберләре хәтта шунда яшәгәннәр дә. Толстой бабасының атасы Андрей Иванович Толстой ук әле 1754—1759 елларда безнең Казанда башта студент-майор булып, аннары Свияжскида хәрби начальник булып хезмәт итә. Лев Николаевичның бабасы Илья Андреевич шулай ук яшьлек елларын Казанда үткәрә һәм 1815—1820 елларда хәтта Казанның губернаторы булып та тора. Язучының атасы Николай Ильич та берничә мәртәбә Казанга килеп, озак-озак торгалап китә. Николай Ильичның апасы Пелагея Ильинична исә гусар полковнигы һәм Казан алпавыты В. И. Юшковка кияүгә чыга һәм бөтенләй Казан кешесенә әверелеп китә.

Ә Лев Николаевич Толстойның Казанга килү сәбәбе менә болай. Левага ике яшь чагында (1830 елда) аның әнисе, унбер яшьтә чагында (1839 елда) атасе вафат булалар. Шулай итеп, Николай Ильичның дүрт малае һәм бер кызы бөтенләй ятим кала. Пелагея Ильинична 1841 елда аларның бишесен дә Ясная Полянадан Казанга алып килә. Леваның абыйларын өчесен дә Казан университетына, апасы Марияне хатын-кызлар институтына укырга урнаштыра, ә унөч яшьлек Леваны университетка хәзерләү өчен укытучы яллый.

Инде хәзер Лев Николаевич Толстойның Казанда яшәгән елларындагы тормышы белән якыннанрак танышып китик.

Леваны университетка хәзерләргә дип ялланган очраклы укытучылар үз вазифаларын үтәмиләр, малайга тиешле белем бирә алмыйлар. Шуның аркасында Лева университетка керү имтиханын тапшыра алмый. Аңа тарих һәм статистика фәннәреннән «икеле» куялар һәм ул, яңадан имтихан тапшырып карарга рөхсәт сорап, 1844 елның 3 августында прошение бирә. Аңа рөхсәт ителәр һәм ул 1844 елның 3 октябрендә философия факультетының көнчыгыш телләре бүлегенә беренче курска укырга алына.

Нигә көнчыгыш телләре бүлегенә керә соң ул, дигән сорау туарга мөмкин. Лев Николаевичның биографы П. И. Бирюковның әйтүенә караганда, ул елларда Казанда университетның көнчыгыш телләре бүлеге бик алдынгы бүлекләрдән санала, аның даны бөтен Европага таралган була. Шуның өстенә Лева үзе дә башка фәннәргә караганда

философияне яратарак төшә һәм апасы Пелагея Ильинична да аның шул бүлеккә керүен тели, чөнки соңыннан Леваны Төркиягә дипломат итеп җибәрү турында хыялланалар. Ләкин Лева боларның берсе белән дә кызыксынмый, тота да мәсьәләне үзенчә хәл итә: башта университетның көнчыгыш бүлегеннән юридик факультетка күчә, аннары университетны бөтенләй ташлап китә.

Нигә шулай итүнең сәбәпләрен яхшырак аңлау өчен, Лев Николаевичның Казанга килгәнче һәм Казанга килгәч нинди шартларда яшәгәнлеген күздән кичерергә кирәк.

Шунысы бәхәссез, Казанга килгән чагында Лев Николаевич бик сәләтле, тәрбияле һәм үз яшьтәшләреннән күбрәк укыган булуы белән аерылып тора. Әдипнең үз сүзләренә караганда, унбер яшендә инде ул француз язучысы һәм философы Жан Жак Руссо әсәрләренең барлык унике томын да укып чыккан, ә аның рәсемен тәре урынына күкрәгенә тагып йөрергә әзер булган. Руссо тикле Руссоны аңларлык һәм чын күңеленнән яратырлык булган бу унбер-унике яшьлек малай нигә соң имтиханнарын башта тапшыра алмыйча аптырый. Хикмәт нәрсәдә соң монда! Кем гаепле! Лева үземе, әллә бүтәннәрме!

Казан тарихчысы Н. Загоскинның язуына караганда, Казанда яшәгән вакытларда Толстойлар торган йортның хуҗалары Юшковлар үзләре болай яхшы кешеләр рәтендә исәпләнгәннәр, ультра-аристократ принципларын алга сөргәннәр һәм иң затлы югары даирә кешеләре белән аралашып яшәгәннәр. Ләкин аларның шулай чамадан тыш аристократ булулары яшүсмер Левага файда түгел, киресенчә, зыян китергән. Һәм менә ничек итеп. Пелагея Ильиничнаның идеалы — халык арасында «Николай Палкин» дип яман аты чыккан патша Николай I була. Үзеннән үзе аңлашылса кирәк, Пелагея Леваны да Николайга мөкиббән китәреп тәрбияләргә омтыла. Байлар үзенә аерым катлау, ярлылар үзенә аерым, түбән дәрәҗәле халык икәнлеген яшьтән үк белеп-күреп үссен өчен, Пелагея Казанга килеп төшкән көннәрдә үк Левага крепостной яшүсмерләрне ялчы итеп билгели. Аның белән генә чикләнмичә, хәтта бозыклыкка да өйрәтә башлый. Соңыннан бу хакта Лев Николаевич үз истәлекләрендә менә болай дип яза: «Минем белән яшәгән бик әйбәт апам, саф җан иясе, миңа һәрвакыт: сиңа иң зур теләгем шул — син ирле хатын-кызлар белән бәйләнешкә кер, ди торган иде. Аннары миңа икенче бәхет — адъютант булуымны тели, патша адъютанты булсаң, бигрәк тә яхшы булыр, ди торган иде. Аның тагын бер бик зур теләге бар: ул минем бик бай кеше кызына өйләнүемне һәм шул өйләнү нәтиҗәсендә бик күп колларга хуҗа булуымны тели торган иде».

Мондый апаның үз энесенә юньле тәрбия бирә алуы, әлбәттә, мөмкин түгел. Менә шундый аристократик тормыш шартларында яшәү һәм университетта укыта торган кайбер укытучылар белән сүзгә килешү булачак әдипнең күңелен укудан биздерә башлый. Уналты яшьлек Толстой студент мундиры киеп һәм шпага тагып ала да ваемсыз һәм тәртипсез байлар тормышына кереп чума. Лекцияләргә юньләп йөрми, барган вакытларында да яхшылап тыңламый. Хәер, тыңларлык дәрәҗәдә яхшы итеп лекция укучы укытучылары да бик аз була шул аның. Лев Николаевичның ул елларда ничегрәк укыганын һәм укуга булган мөнәсәбәтен күзаллау өчен, аның үзе күргән вакыйга нигезендә язылган «Балдан соң» исемле хикәясенә мөрәҗәгать итик: «Мин сөйләргә теләгән хәл кырыгынчы елларда булды. Мин ул чакта провинциаль университетның студенты идем. Белмим, яхшы булгандырмы ул, әллә ямандырмы, ләкин ул чакта безнең университетта бернинди түгәрәкләр, бернинди теорияләр дә юк иде. Ә без яшь кешеләр идек һәм, яшьләргә хас булганча, күңел ача һәм укый идек. Мин

бик күңелле һәм шаян, шуның өстенә бай егет идем. Минем юртак атым бар иде, мин бай кызлары белән тау шуам (ул чакта тимераяклар модада түгел иде әле), иптәшләрем белән эчеп-күңел ачып (ул чакта без шампанскидан башка нәрсә эчми идек, акчабыз юкта бөтенләй эчмибез, ләкин хәзерге шикелле аракы эчү юк иде ул чакта) йөри идем. Әмма минем иң зур рәхәтем кичәләргә һәм балларга йөрү иде. Мин яхшы танцевать итәм һәм төсем-битем дә алай ямьсез түгел иде...»

Лев Николаевичның үз сүзләре белән әйтсәк, студент елларында ул кешеләрне бары тик ике генә төркемгә — «комильфо» һәм «комильфо түгел»гә генә бүлеп караган. («Комильфо»сы — бай, затлы, аристократ кешеләр, ә «комильфо түгеле» — ярлы кара халык).

Табигый, шундый гамьсез тормыш белән яшәү булачак әдипнең укуына тискәре йогынты ясый һәм ул 1844—1845 уку елының беренче яртысы өчен имтиханнарны тапшыра алмый: аңа гарәп теле һәм тарих буенча «икеле» куялар.

Ихтимал, шушы күңелсез хәлләрдән соң Толстой җитдиләнер һәм тырышыбрак укый да башлаган булыр иде. Ләкин әлеге дә баягы, Пелагея апасы һәм аның аристократ дуслары: укуда алдынгы булу «комильфо» түгел, алдынгы булырга тырышырга кирәкми, киресенчә, бернәрсәгә дә исең китмичә, үзеңне бик иркен, бәйсез итеп, аристократларча тотарга кирәк, дип студент Леваны «юаталар». Шуңа күрә Толстой икеле алуына артык пошынмый, укуын артабан да яхшыртмый. Нәтиҗәдә аны язгы имтиханнарга бөтенләй кертмиләр. Профессорлардан Иванов һәм Фишерның студент Толстой турындагы начар характеристикаларына нигезләнеп, бүлек (хәзергечә әйтсәк, деканат) түбәндәге карарны чыгара: «Лекцияләргә бик сирәк йөргәнгә һәм тарихтан бөтенләй сәләтсез булганга, Лев Толстойны имтиханнарга кертмәскә».

Дөньяда тиңе булмаган «Сугыш һәм тынычлык» исемле тарихи роман язган Толстойның «тарихтан бөтенләй сәләтсез» булганлыгы өчен имтиханга кертелмәве өстән генә караганда шактый сәер тоела, билгеле. Ләкин җентекләбрәк карый башласаң, мәсьәләнең асылы бик тиз ачыклана һәм гаҗәпләнергә урын да калмый. Студент Леваны имтиханга керттерməүгә сәбәпче булган профессор Иванов Толстойларга кардәш тиешле (Лев Николаевичның өченче буыны апасына өйләнгән) кеше була. Алай гына да түгел, Казанга килгән шәпкә яшь Толстой хәтта беркадәр вакыт Ивановларда яшәгән дә була әле. Ләкин менә студент булып укый башлагач исә Иванов белән Леваның аралары бик нык бозылып китә. Хикмәт шунда, профессор Иванов университетта тарих буенча лекцияләр укый һәм аның лекцияләре бик буш, кызыксыз була. Ул тарихи вакыйгаларны бозып, заманга, патшага яраштырып сөйли, объектив хәлләрне бөтенләй исәпкә алмый. Ә студент Толстой исә аның менә шул гадәтен һич тә онамы. Алай гына да түгел, Ивановны яманлап, студентлар арасында да сөйләнеп йөри башлый. Шуны сизеп алган Иванов (ә ул аны бик тиз сизә, чөнки соңыннан ачыкланганча, профессор ул вакытларда яшерен полиция агенты була) Толстойга көннән-көн үчегә бара һәм, Лев Николаевич үзе әйткәнчә, аның иң зур дошманына әйләнә.

Көнчыгыш факультетында уңышсызлыкка юлыккannан соң, 1845 елның көзендә Толстой университетның юридик факультетына күчеп укый башлый. Ләкин факультетны үзгәртүгә карап кына яшь Толстой өйрәнелгән гадәтләрен тиз генә ташлый алмый. Шуның өстенә апасы һәм аның якыннары да аристократик тормышны мактап торганлыктан, Толстой һаман шулай элеккечә кәеф-сафа кылып йөри бирә. Теләсә дә, шул бозык тирәлектән ычкынып китә алмый. Бу турыда үзенең «Васыять»ендә ул менә нинди дип яза: «Иң саф теләкләремне әйтергә, рухи яктан яхшы булырга тырышкан чакларымда миңа гел мыскыл итеп һәм көлеп карыйлар, ә мин бозык дәртко бирелеп китсәм, миңе шундук мактыйлар һәм хуплыйлар иде... Ул елларны искә алганда җаннарым өшеп, котларым алынып һәм йөрәкләрем авыртып китә».

Менә шундый күңел кайтаргыч тормышта яшәү өстенә, студент елларында Толстой студентларга укытыла торган фәннәрнең дә коры даталарга гына нигезләнгән «кирәкмәс» нәрсәләр икәнлеген төшенә һәм анда «тарихи характерлардагы тирән психологик үзгәрешләрне, тарихи хәлләр нинди һәм ниләктән килеп чыкканын аңларга» тырышу омтылышы туа. Шул сорауларына җавап алырга теләп, укытучыларга мөрәҗәгать итә. Әмма үзлегеңнән фикер йөртү тыелган, дәреслекләрдә язылган һәм профессорлар сөйләгән сүзләр генә дөрес булып саналган ул заманда Толстой юридик

факультетта да үзенә әллә ни зур юаныч та, ышаныч та таба алмый. Һәм ул лекцияләргә йөрүгә бөтенләй диярлек игътибар бирми башлый.

Сүз дә юк, үзеннән бер хәреф тә өстәргә куркып, Законнар җыентыгында ничек язылган булса, шулай әйтеп яздыручы поляк профессоры Станиславский һәм немец профессорлары Винтер белән Камбеклар шикелле талантсыз укытучылар шактый булгандыр ул заманда. Ләкин шул ук елларда, шул ук университетта атаклы математик Н. И. Лобачевский ректор булган, химик Зинин, астроном Симоновлар бик актив эшләгән. Кыскасы, Толстойның ул еллардагы уңышсызлыгы аның үзеннән дә булган. Исемнәре белән дөньяга билгеле булган Бутлеров, Берви (Флеровский), Бекетов (соңыннан академик-ботаник булган кеше), Пекарский (тарихчы) һәм Благовещенский (филолог) кебек галимнәр дә ул вакытта Лев Николаевич белән бер үк чорда укыганнар һәм университеттан шактый үк зур хәзерлек белән чыкканнар.

Хәер, Лев Николаевич Толстой беренче мәртәбә җитди рәвештә фәнни эш белән үзе дә шул үк Казан университетында шөгыльләнә башлый. Анысы менә болай: университетның гражданлык хокукы кафедрасына укытучы итеп, 1845 елны чит илдә командировкада булып (укып) кайткан яшь укытучы Дмитрий Иванович Мейр билгеләнә. Алдынгы карашлы ул укытучының лекцияләрен студентлар бик яратып тыңлыйлар, чөнки Мейр лекцияләрендә дәреслекләргә генә ябышып ятмый, демократик рух белән сугарылган үз фикерләрен дә ачык итеп әйтә торган кеше була. Ул хәтта «безнең ватанның эчке тормышында үзгәрешләр булыр көннәр якынаюын» һәм «крепостнойларга карата нормаль булмаган мөнәсәбәтнең» юкка чыгарылырга тиешлеген әйтүдән дә тайчанып тормый. Алай гына да түгел, ул алдынгы карашлы разночинец студентлар түгәрәген төзи һәм аның җитәкчесе булып эшли. Толстойның югарыда исемнәре санап үтелгән курсташлары барысы да Мейр түгәрәгендә член булып торганнар. Кыскасы, Казан университеты студентларында яңалыкка, алдынгы фикергә омтылыш уятуда Мейрның өлеше шактый зур була. Чернышевский белән Добролюбов юкка гына аны «җиребезнең горурлыгы булырдай» кеше дип атамаганнар, әлбәттә.

Лев Николаевич Толстой, дөрес, Мейр түгәрәгенең члены булып тормаган, ләкин ул түгәрәк членнары белән тыгыз элемтәдә булган һәм алардан үзе өчен күп кенә яңа, кызыклы мәгълүматлар алган.

Бер тапкыр гына булса да, Толстой Мейрга имтихан да тапшырган. Лев Николаевичның имтиханда биргән җаваплары бик үк шәптән булмаса да, Мейр аның үзенчә фикер йөртергә тырышуыннан канәгать булып калган. Толстойдан имтихан алганнан соң аңа бәя биреп: «Әгәр тырышса, ихтыярын туплап эш итәргә өйрәнсә, ул менә дигән әйбәт кеше була алыр иде»,— дигән.

Имтихан алган чагында Мейр Толстойда вакыйгаларга тәнкыйтьчән анализ ясау сәләте барлыгын сизенеп алган да соңыннан аңа, Екатерина II нең «Наказ»ын француз философы Монтескьеның «Дух законов» дигән хезмәте белән чагыштырып карарга кушып, фәнни тема биргән. Толстой бу эш белән чын-чынлап мавыгып киткән һәм хезмәтенең соңында Екатеринаның «Наказ»ы, Россиягә файда китерүдән бигрәк, аның үзенә дан китерүгә генә кайтып калган дигән нәтиҗәгә килгән. Шулай итеп, безнең көннәргәчә сакланып калган һәм Казанда язылган шул беренче фәнни хезмәтендә үк инде Толстой рус тормышының төп явызлыгы деспотизм һәм коллыкка кайтып калганлыгын чамалаган. Шунысы игътибарга лаек, Лев Николаевичның университетны ташларга карар кылуына китергән сәбәпләрнең берсе дә әлеге фәнни хезмәтенә бәйле була. Бу хакта соңыннан ул үзе менә болай дип язган: «Минем университеттан китүемә ике нәрсә сәбәп булды:

1) абыем университетны бетереп китте.

2) әйтергә никадәр генә гажәп тоелса да, «Наказ» һәм «Дух законов»ны тикшерү белән шөгыльләнү миңа үзлегемнән эшләп булырлык яңа акыл хезмәте өлкәсен ачты, ә университет үзенең таләпләре белән андый эшкә ярдәм итми генә түгел, хәтта комачаулый да иде».

Шулай да Толстой университеттан китү сәбәпләренең иң зурысы болар түгел, бәлки аның халык тормышын яхшыртырга омтылган хыялларын практик рәвештә эшкә ашырырга тырышуына кайтып кала булса кирәк. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен, башта ул чордагы ил хәлләрен, аннары Толстойның «Утро помещика» исемле хикәясен хәтергә төшерү дә бик җитә.

Толстой университетка кергән елларда Россиядә крестьян хәрәкәтләре шактый активлашкан чак була. Әйтик, бары тик 1842 елда гына да крестьян хәрәкәтләрендә 120 000 дәүләт крестьяны катнаша. Аннары бөтен ил буйлап дип әйтерлек «бәрәңге бунтлары» булып үтә. Дөрес, ул бунтлар хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан бик шәфкатьсез төстә бастырыла, әмма крестьяннар да, үз чиратларында, шуңа үч итеп, әерым алпавытларның утарларын туздырып ташлыйлар.

Менә шул хәлләр ул заманның прогрессив җәмәгатьчелегенә бик нык тәэсир итә. Казанда яшәгән һәм укыган елларында Толстой да бу хәлләрдән хәбәрдар була һәм җәмгыятьтә иң мөһиме — халык, шуңа күрә халык өчен тырышырга, аның тормышын яхшыртырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Ә халыкның тормышын яхшырту өчен яхшы алпавыт булырга, крестьяннар белән әйбәт мөнәсәбәттә яшәргә кирәк дип уйлый. Дөрес, соңыннан ул бу хыялларның бүш хыял гына булуын төшенә, әмма үзенә тигән мирасны яңарак кына кулына алып университеттан китәргә җыенган чагында нәкъ менә әлеге «Утро помещика» исемле хикәясендәге яшь алпавыт Нехлюдов шикелле уйлый әле ул. Ә Нехлюдов апасына язган хатында үз фикерләрен менә болай дип аңлата: «Кадерле апам! Мин шундый карарга килдем, ул карар минем бөтен киләчәк тормышымны хәл итәргә тиеш. Мин, университеттан чыгып, үземне авыл тормышына багышларга булдым, чөнки шуның өчен яралганлыгымны сизеп торам. Алла хакы өчен дип әйтәм, миннән көлмәгез, кадерле апам. Сез, син бит әле яшь, диярсез. Бәлки мин чынлап та бала гынамындыр әле, ләкин, шулай булса да, бу миңа үз сәләтемне тоярга, яхшылык эшләргә теләргә һәм яхшылыкны яратырга комачаулык итми. Инде сезгә язганымча, мин кайтканда монда эшләр язып та аңлатып булмаслык дәрәҗәдә буталып беткән иде. Шул эшләрне тәртипкә китерергә һәм аларның серенә төшенергә тырышып, мин менә шул нәрсәне ачыкладым: бөтен явызлыкның башы мужикларның фәкыйрьлегенә кайтып кала һәм ул явызлыкны бары тик эш һәм түземлелек белән генә төзәтеп булырга мөмкин. Әгәр дә сез минем ике мужикны, Иван белән Давыдны, һәм аларның тормышларын, семья хәлләрен күрсәгез иде, ышанып әйтәм, аларның кыяфәтләре генә дә сезгә мин язып аңлатырга тырышканнан күп мәртәбә гыйбрәтле булыр һәм сез минем теләгемне дә яхшырак аңлар идегез. Алла каршында алар өчен мин җавап бирәчәк әлеге җиде йөз кеше турында кайгырту минем турыдан-туры изге бурычым түгелмени! Аларны үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан һәм үз рәхәтлекләре турында гына уйлаган дорфа старосталар һәм управляющийлар карамагына калдырып китү гөнаһ булмасмы! Һәм шушындый якын, изге һәм матур бурыч алдымда торганда нигә соң әле мин башка җирдән файдалы һәм игелекле эш эзләп йөрергә тиеш! Мин үземнең яхшы хуҗа булырга сәләтем барлыгын сизәм, ә миңа, үзем аңлаганча яхшы хуҗа булыр өчен, сез тели торган кандидатлык дипломнары да, бернинди чин да кирәк түгел...»

Менә шундый уйлар белән янып йөргән Толстой башта үзенә мирас булып калган Ясная Полянага кайтып крестьян балалары өчен мәктәп ача, аннары 1847 елның апрелендә үзен студентлыктан азат итүләрен сорап прошение бирә. Озак көттермичә генә аңа университетта укыганлыгын һәм гражданлык эшләре буенча икенче разрядлы чиновник булып эшләргә мөмкин икәнлеген күрсәткән таныклык бирәләр. Ләкин унтугыз яшьлек Толстой чиновник булу турында уйлап та карамый, ниятләре белән хушлаша да туп-туры Ясная Полянага кайтып китә.

Лев Николаевич Толстойның Казанда яшәгән һәм укыган еллары турындагы сүзебезгә йомгак итеп шуны әйтергә кирәк: патша Россиясе таләпләренә җайлаштырып төзелгән университет программасына кергән фәннәрне шул ук патшаның яшерен полициясе агентлары булган укытучыларның күңеле булырлык итеп үзләштермәсә дә, студент Толстой университетта укыган елларында киләчәк тормышы өчен кирәк булачак бик күп мәсьәләләрнең серенә төшенеп китә. Әгәр Горький: «Рус тормышы турында бөтен әдәбиятыбыз сөйләгән кадәр нәрсәне Толстой безгә бер үзе сөйләп бирде... Толстойны белмичә торып, үзеңне илемне беләм дип, үзеңне культуралы кеше дип санарга ярамый»,— дип әйткән икән, бу инде Лев Николаевичның Казан университетыннан да бик күп нәрсә алып китүе турында сөйли булса кирәк. Әгәр дә инде Казан студенты чагында үзе күргән вакыйганы Казаннан киткәннән соң илле алты ел үткәч сурәтләп язган «После бала» («Балдан соң») исемле искиткеч хикәясен дә искә алсак, Казан чоры Лев Николаевичның күңеленә бик тирән сеңеп калганлыгын аңлавы бик кыен булмас.

Роберт Батуллин

КУРАЙ УЙНЫЙ БЕР МАЛАЙ

Беренче әкият

Бер авылда яшәгән, ди, гажәп оста курайчы малай. Ул су буенда уйнаса, бакалар, балыклар, кыслалар, судан башларын чыгарып, курай уйнаганны тыңлыйлар икән. Курайчы болында уйнаса, чикерткәләр, кырмыскалар, бал кортлары — барча бөҗәкләр дә аның уйнаганын тыңларга җыелалар, ди.

Бу курайчы малайның бик кире беткән усал апасы булган. Апасы энесенең курай уйнаганын бер дә яратмый икән.

— Колагымны тондырып бетердең инде! Тукта! — дип, курайчыны көн саен орыша икән.

Бәләкәй курайчы бик рәнҗегән апасының бу кыланышларына. Шуннан ул бакчага чыгып уйный башлаган. Ләкин усал кызый аңа бакчада уйнарга да рөхсәт итмәгән. Инде соңгы чиктә Киребеткән кызый энесенең кураен утка ташлаган. Шуннан соң малай урманга качып уйнарга мәҗбүр булган. Урманда рәхәтләнеп уйный-уйный икән дә кураен имән төбенә яшереп кайтып китә икән.

Көн саен урманда курай тавышы ишетелеп тора, ди. И эзли икән, и актарына икән Киребеткән кызый — барыбер курайны таба алмый икән.

— Барыбер табармын! Табармын да утка ягармын! — дип ант иткән Киребеткән.

Көннәрдән бер көнне энесенең аланда курай уйнаганын сагалап торган бу. Сагалап торган да курай яшерелгән урынны күреп алган. Малай, кураен имән төбендәге куышка куеп, кайтырга чыккан. Ул кузгалу белән мәкерле кызый качкан җиреннән атылып чыккан да курайны чәрдәкләп ташлаган. Үзе ямьсез итеп көләргә тотынган.

Курайчы аның тавышына борылып караган. Караса, ни күзләре белән күрсен — курай өстендә апасы биеп маташа, ди. Курайчының шулкадәр ачуы килгән, хәтта сүз әйтә алмый тыны капланып торган.

— Ха-ха-ха! Теленне йоттынмы, малай актыгы! — дип, Киребеткән курай ватыклары өстендә сикергәли икән.

— Син әшәке кыз! Син миһербансыз! — дип кычкырган курайчы.— Син жырлый белмисең, шуңа күрә жырчыларны яратмыйсың. Син курай уйный белмисең, шуңа күрә курайчыларны сөймисең. Син жырсыз, моңсыз, аһәңсез бәндәсең! Син кеше түгел — син бөжәк! Гомерең буена жыр-моң ишетми интегеп, тилмереп яшәсәң иде! — дип елый-елый каргаган.

Малайның күз яшьләре курай кыйпылчыклары өстенә тамган. Кинәт аяз көнне күк күкри башлаган. Урман аланы караңгыланып киткән. Аландагы барча күбәләкләр дәррәү һавага күтәрелгәннәр. Һәм усал кыз кайры кортына әверелгән.

Курайчы аптырап калган. Елавыннан туктаган. Шунда гына ул нәрсә булганын аңлап алган. Сак белән Сок әнисенең каргышы шикелле, курайчының каргышы да апасына төшкән. Ләкин малай һич тә куанмаган. Ул апасын эзләп караган, ләкин таба алмаган. Кайры корты яфраклар арасына кереп югалган.

Икенче әкият

Курайчы малай көн саен урманга китә икән. Шулай көн саен Киребеткән апасын эзләгән курайчы. Эзләгән, ләкин таба алмаган. Шулай бер көнне курайчы малай урманга менгән дә пәкесе белән кура кисеп алып курай ясаган. Ясаган да, һәй, мин сиңа әйтим, уйнап жибәргән.

Тукран, тукылдавыннан туктап, күршесендәге Сандугачка әйткән:

— Тыңласана, күршем, нинди кош ул шулай өздереп сайрый?

Кара елан Кәлтәгә дәшкән:

— Кара әле, кордаш, нинди гүзәл жырчы килгән урманыбызга? — дигән.

Болан Пошины туктаткан:

— Белмисеңме син, мөгездәш, кем ул шулай матур итеп сайрый? — дип сораган.

Җәнлекләр дә, кошлар да курай тавышы ишетелгән якка киткәннәр. Килеп житсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, алан уртасындагы имән төбенә утырып бәләкәй генә курайчы курай тарта, ди. Кош-кортлар агач ботакларын тутырып, сыгылдырып утырганнар да курай моңын тыңлыйлар, алан тулы мең төрле төстәге матур күбәләкләр оча-оча курай көенә биләр, ди. Ул еланнар түгәрәкләп тезелгәннәр дә башларын әле бер якка, әле икенче якка боргалап-сыргалап биләр икән. Ул мәһабәт боланнар, мәгърур пошилар тезелешеп бии башлаганнар. Ул торналар очып барган җирләреннән аланга төшеп тыпырдарга тотынганнар.

Алан уртасында бәйрәм башланган. Әйтерсең лә урман уртасында балалар, җәнлекләр, кош-кортлар өчен музыкаль театр ачканнар!

Малай уйнавыннан туктаган һәм кайтырга кузгалган.

— Курайчы малай, курайчы малай, кал инде! Тагын бераз гына, бәләкәй генә уйна инде! — дип ялварганнар җәнлекләр.

— Соң бит инде, мин иртәгә тагын килермен! — дип, курайчы малай кайтып киткән. Кош-корт, җәнлек-җанварлар таралганнар. Күбәләкләр аланда кунаклап калганнар. Бары тик бу аланның иң матур, иң нәфис күбәләге генә кунакларга теләмәгән. Ул курайчы артыннан калмыйча ияреп оча икән.

— И курайчы, курайчы, сүзем тыңлап карачы! — дигән күбәләк.

Курайчы болай дигән:

— И күбәләк, күбәләк! Ни гозерең бар, сөйлә! Сүзең булсын түгәрәк.

— И егеткәй, егеткәй, алып кит мине син, әй! Зинһар, калдырма мине! Мин синең кураеңа үлеп гашыйк булдым! Мин курайсыз яши алмыйм! Ал мине үзең белән авылга!

— Чуар Канат күбәләк! Син бит алан бөжәге! Синең урының монда, синең гомерең кыска!

Шуннан соң күбәләк елый башлаган һәм тагын да ныграк ялварырга тотынган.

— Ташлап китсәң син мине, мин учакка ташланам! Ташланам, шунда янам!

Курайчы риза булган. Күбәләкне өенә алып кайтып киткән. Кайтканда ул матур итеп курай уйнаган, матур күбәләк, шатлыгыннан нишләргә белмичә, курай очына кунып, канатларын лепердәтеп биегән.

Өйгә кайткач, курайчы йокларга яткан. Күбәләк, курайдан аерылалмыйча, курай көпшәсе эченә кереп кунаклаган.

Иртән торгач, курайчы малай күбәләкне эзли, эзли,— таба алмый икән. Тәрәзәдән очып чыгып киткәндер дип уйлаган малай. Бик уфтанган, кайгырган күбәләксез калдым дип. Бик тә ямансу булган аңа. Шуннан күбәләккә багышланган моңлы гына бер көй уйнамак булып, кураен алган. Өреп карый, тик нишләптер курай сызгырмый икән. И азапланган, и интеккән курайчы. Шулай өрә торгач, курай эченнән матур күбәләкнең үле гәүдәсе килеп төшкән.

Өченче әкият

Сабан туе якынлаша! Сабан туе якынлаша! Сабан туенда җырчылар вә курайчылар ярышы булачак! Иң оста җырчы, иң оста курайчы исемен яуларга кемнәр батырчылык итә!

Игъланчы шундый хәбәр салды авылга.

Бу авылда курай уйный белмәгән малай юк икән. Шулай да бер малай булган. Ул курай уйнарга өйрәнмәгән. Абыйлар, апалар курайчыларны мактап бетерәлмиләр, ди, һай, афәрин, шәп уйныйлар, һай, жаннарым, матур көйлиләр, диләр икән. Андый чакларда теге курай уйный белми торган малай болай дип әйтә ди.

— Аның каравы, миндәгедәй матур маркалар берәүдә дә юк! Аның каравы, минем альбомымдагы күбәләкләрдәй матур күбәләкләр берегездә дә юк!

— Сабан туе якынлаша! Сабан туе! Тавышларыгызны, курайларыгызны көйләгез! — дип, тагын кычкырып узган игъланчы.

Барча курайчылар да ярышка әзерләнә башлаганнар. Һәммәсе дә, аулак урын сайлап, курай уйнарга тотынганнар.

Бәләкәй курайчы күнегүләр ясарга урман аланын сайлап алган. Ул көн саен, алардагы имән төбенә утырып, курай тарта икән. Аның уйнаганын ишетеп чикерткәләр, бал кортлары, кырмыскалар, күбәләкләр, бөжәкләр, шөпшәләр җыелганнар. Алар арасында искиткеч матур бер күбәләк очып бии икән. Курайчы малай үзе курай уйный икән, үзе шаккатып матур күбәләкне күзәтә икән. Шундый матур булган инде ул күбәләк, хәтта күбәләкләр җыя торган малайның альбомында да мондый матур күбәләк булмаган. Малай уйнавыннан туктап әйтә икән:

— Күбәләк, күбәләк, мин сиңа гашыйк булдым! Әйдә минем белән авылга!

Күбәләк аңа каршы әйтә:

— Курайчы малай, курайчы малай! Мин синең белән авылга кайта алмыйм! Минем гомерем шушы аланда узарга тиеш!

Шуннан соң малай елый-елый ялвара күбәләккә:

— Әйдә инде, и гүзәл күбәләккәй... Безнең өй җылы, якты...

— Аланда да якты, җылы! — ди күбәләк.

— Мин сиңа бик күп чәчәк сатып алырмын. Сатып алырмын да бүләк итәрмен!

— Аландагы чәчәкләр матуррак, сафрак! — ди күбәләк.

— Мин сине кадерләп кенә тотармын! — ди малай.

— Сезнең өйдә ут бар! Күп күбәләкләр шул утта канатларын көйдерделәр инде! — ди күбәләк.

— Юк! — ди малай. — Безнең мичебез юк! Без өйне пар белән җылытабыз!

— Алайса, сездә кайнар куык бардыр!

— Юк, Безнең өйдә неон лампасы!

Ләкин күбәләк риза булмаган. Очып киткән.

Курайчы малай моңлы итеп курай уйный башлаган. Шундый моңлы итеп, матур итеп уйнаган, матур күбәләк түзә алмаган, кире очып килгән дә курай очына кунган.

— Мин риза! — дигән күбәләк.

Шулай итеп, курайчы аландагы иң матур күбәләкне өенә алып кайтып киткән. Бу хәбәрне ишетеп, бик күп курайчылар җыелганнар. Күргән бере аһ итә икән.

— Ай-һай, матур күбәләк! Искиткеч канатлары! Бик матур буяулары! — диешкәннәр курайчылар.

Һәммәсе дә шаккатканнар, сокланганнар, һәммәсе дә бәләкәй курайчыны тәбрикләгәннәр. Маркалар, бөҗәкләр җыючы малай гына бер сүз дә әйтәмәгән. Барысы да таралгач, ул болай дигән:

— Син бу күбәләкне миңа бир! Мин сиңа иң яхшы маркамны, шуның өстенә ун гади күбәләк бирермен!

Курайчы риза булмаган.

— Мин аны алмашырга дип аланнан алып кайтмадым! — дигән дә әрләп чыгарган.

Шуннан теге ямьсез малай хәйлә кора башлаган. Курайчы югында килеп, күбәләкне котыртырга тотынган:

— И күбәләк, берүзеңә ямансу, минем альбомда күбәләкләр бик тә күп, әйдә безгә! — ди икән.

— Миңа курайчы өендә дә рәхәт! — дигән күбәләк.

— Минем өйдә дә сыбызгы бар ла ул, әйдә, сызгыртып күрсәтермен! Очып чык тәрәзәдән!

Күбәләк риза булмаган.

Шуннан күбәләк җыючы малай тиз генә кайтып курай алып килгән һәм тырыша-тырыша курай уйнаган. Ләкин күбәләк аның уйнавын ишеткәч, рәхәтләнеп көлгән генә:

— Син уйнамыйсың, син сызгырасың гына, барыбер син минем курайчымны уздыра алмыйсың! Колакларымны рәнҗетмә!

Теге малай ачуыннан кураен сындырып ташлаган да кайтып киткән.

— Барыбер ул күбәләк минеке булыр! — дип мыгырдана икән үзе.

Ул, магнитофон алып килеп, бәләкәй курайчының уйнаганын сагалап торган да магнитофон тасмасына язып алган. Курайчы өйдә юкта магнитофонны агачлар арасына көйләп, әйләндерепме әйләндерә икән.

— Һай, матур уйный, мөгаен, бу минем курайчымдыр! — дип, матур күбәләк тәрәзәдән бакчага очып чыккан. Шуны гына көтеп торучы юньсез малай җәтмәсе белән күбәләкне тотып та алган. Тотып алган да өенә алып кайтып киткән.

Күбәләген югалту кайгысыннан бәләкәй курайчы бик нык хәсрәтләнгән, моңайган. Өзелеп-өзелеп уйнаган малай. Курай тавышын ишетеп, матур күбәләк тә өзгәләнә, бәргәләнә икән. Ишеккә барса, ишек бикле, тәрәзәгә очып килсә, тәрәзә ябык.

— Беркая да китә алмассың! — дигән юньсез малай.— Мин бар тишек-тошыкларны томалап бетердем!

Күбәләк түшәмгә очып менгән, лампа тирәли бөтерелә-бөтерелә очып йөргән дә кинәт мич авызына кереп киткән... ләкин мич ягылмаган булган. Күбәләк моржадан чыгып очкан һәм курайчы малай өенә кире кайткан. Ләкин ул моржадан чыкканда корымга буялып, пычранып беткән булган шул. Бәләкәй курайчы аны танымаган.

— Син минем күбәләгем түгел! Ул кара түгел иде! — дигән малай.

— Мин дә кара түгел! — дигән күбәләк.

— Мин үземнең күбәләгемне көтәм! — дигән дә малай ишекне бикләп куйган. Күбәләк тәрәзәгә очып килгән, малай тәрәзәне дә ябып куйган.

Берүзе калган күбәләк. Кич житкән, караңгы төшкән. Яңгыр ява башлаган. Яңгыр күбәләк канатларындагы корымны юып төшергән. Күбәләк тагын да чибәрләнгән, тагын да гүзәлләнгән.

Таң аткач, курайчы малай тәрәзә ачарга дип килсә, рамга кунган гүзәл күбәләкне күреп кычкырып жибәргән:

— Күбәләгем, кайттыңмы?

— Юк,— дигән күбәләк.— Мин синеке түгел!

Гүзәл күбәләк шулай дигән дә урманга очып киткән.

Дүртенче әкият

Шуннан соң курайчы аланга бөтенләй бармас була.

Озак вакытлар үтә. Әнисе әйтә курайчыга:

— Бар аланга! Ал кураең, уйна, тарат моңың! Бәлки апаңны табарсың!

— Юк, әнкәем,— ди курайчы малай,— мин кабат аланга бармыйм. Кабат мин курай уйнамам. Аланда курай уйнаган көнне мин гел авылга сагыш кына алып кайтам. Бик озак гомерләр ул шулай ялгыз, курайсыз гына яшн бирә.

Ләкин тумыштан курайчы булып туган кеше моңсыз яшн аламыни соң?! Бәләкәй малай да түзми, тагын аланга китә, тагын курай ясый, тагын тирә-якны шаккатырып курай уйный башлый. Аның моңын ишетеп, Тукран Сандугачка дәшә:

— Тынласана, күршем, нинди кош ул шулай өздереп сайрый?

Кара елан Кәлтәгә әйткән:

— Кара әле, кордаш, нинди гүзәл жырчы килгән урманыбызга?

Болан Пошыны туктаткан:

— Белмисеңме син, мөгездәш, кем ул шулай матур итеп моңлана?

Аланга барып баксалар, бер бәләкәй генә малай имән төбенә утырган да курай тарта икән. Тагын аланда бәйрәм башланган. Биегәннәр боланнар, биегәннәр еланнар, биегәннәр торналар, күбәләкләр. Күбәләкләр генә түгел, гомере буе селкенеп карамаган Аю-Әппәс тә ут өертеп биеп киткән, үзе болай дип такмаклый икән:

— Их-ма, их-ма, жәнлекләр!
Их-ма, их-ма, бөжәкләр!
Рәхәт икән биюе!
Их-ма, их-ма диюе!
Шатланыйк әле, дуслар!
Курай уйнаучы булса,
Балсыз да яшәп була!

Аю биегәнне күреп, Бурсык-Томсык та такмак әйтергә тотынган:

— Дуфыл-дуфыл дуфалый!
Аю-Әппәс путалый!
Путасында тәпәне,
Тәпәнендә типие...
Дуфыл-дуфыл тупалый...
Тупыл-тупыл тупалый...

— Әйдә бие, Пуфалый! — дип, Бурсык Керпе-Пуфалыйны уртага чакырган.

Бурсык дәшкәнне ишетеп, Керпе-Пуфалый түгәрәк буйлап типтерергә тотынган:

Әмпеф-әмпеф, әфәли!
Төлке мине тәпәли!
Килеп кара, Төлкисә!
Энәм күзеңне тишәр!
Әмпеф-әмпеф, әфәли!
Минем туным энәли!

Башланган җырлашу, биешү. Һәммәсе дә уенга катнашкан. Малай уйнап бетергән дә, тагын берәр күбәләк иярмәсен дип, артына борылырга да куркып, йөгерә башлаган. Бөтен күбәләкләр дә аның артыннан калмый очып киткәннәр.

— Иярмәгез! — дип кычкырган курайчы.

— Син озак килми тордың, без синнән башка яши алмыйбыз! — дигәннәр күбәләкләр.

Малай куаклар арасына кереп качкан. Әллә нинди чытырманлыкларда йөргән. Күбәләкләрне юлдан яздырырга тырышкан. Төн җиткәч кенә, күбәләкләр йокларга яткач кына, курайчы авылга кайтып киткән.

Менә сабан туе көне җиткән. Иртән иртүк игъланчы барча курайчыларны да уяткан:

— Мәйданга! Мәйданга! Җырчылар вә курайчылар ярышы башлана!

Курайчы малай сикереп торган да ярышка әзерләнә башлаган. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, аның курае сызгырмый икән. Өреп карый — барыбер уйнамый. Эчендәге ярысы купкандыр, чистартырга кирәк дип, егет кызган без белән курай көпшәсен чистартырга тотынган. Бер заманны курай тишекләреннән төтен ургый башлаган. Төтен эчендә бер шәүлә күренгән. Тора-бара ул шәүлә гүзәл кызга әверелгән. Кызның матурлыгын күреп, курайчы телсез калган.

— Кем син? — дип сораган курайчы төтен таралгач.— Пәри кызымы? Сихерчеме?

— Мин пәри дә, сихерче дә түгел! — дигән кыз, аның тавышы гажәп матур, моңлы булып чыңлаган.— Мин синең апаң! Җәберләгәнем өчен, син мине каргаган идең.

Курайчы малай шаккаткан. Киребеткән кызый шулкадәр үзгәргән, бөтенләй танымаслык булып матурайган. Апасы курайчы малайны кочаклап алган. Кочаклаган да үз башыннан кичкән хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

— Синең каргышын өстемә төшкән көннән бирле мин бөжәк булып яшәдем. Кошлар мине чукымасын, мине тотып ашамасыннар дип, шуыша-шуыша, үрмәли-үрмәли, кача-поса яшәргә мәҗбүр булдым. Кеше булган чакларымны искә төшереп ачынып-ачынып елый торган идем. Син алаңга килеп курай уйный башладың. Син шулкадәр матур уйныйсың икән! Шул чакны мин кеше булуның гажәп бер кыйммәтен тойдым. Син көн саен килеп курай уйныйсың, мин көн саен сине сокланып тыңлыйм. Курай моңын тыңлый-тыңлый миңа канатлар үсеп чыкты. Мин күбәләккә әйләндем. Башка күбәләкләр белән синең янда бөтерелдем, уйнадым, биедем. Шуннан соң, сиңа ияреп, авылга, кешеләр арасына кайтасым килде. Ләкин син соңгы вакытларда бик тә кайгылы, кәефсез, бер күбәләкне дә яртмисең. Кичә син йөргәндә сиздерми генә мин кураең көпшәсенә кереп яттым.

Кыз шатлыгыннан елый-елый сөйләгән. Энесе аның күз яшьләрен куллары белән сөрткән.

— Әгәр дә син курай эчендә янып үлгән булсаң?

— Моңсыз, аһәнсез, җырсыз яшәгәнче үлем мең өлеш артык! Мең рәхмәт сиңа! Син мине кеше иттең!

Малай кураен алып уйнап җибәргән. Гүзәл кыз чиста, матур, нәфис тавыш белән аңа кушылган.

Күбәләк-кыз шулкадәр матур җырлаган, малай шулкадәр оста уйнаган. Ярышта алар беренче урынга чыкканнар.

Зәки Нури

Коры куык

Трибунага менеп басты да әйтте:
— Эшнең, дуслар, кирәк мина кыены!
Чөнки эш ул — уку кебек. Ә уку —
Энә белән казу кебек коены.

Җыелыштан соң берәү мактый бу затны:
— Бар икән бит шундый батыр ир әле!
Кыен булса әгәр кыен эш табу,
Дустым, мина кое казып бир әле!

Китмә, Кыш бабай

Кыш бабай, китмә әле,
Безне хур итмә әле.
Безнен уйлаган да юк
Яз килер дип тә әле.

Яз нын безгә килүе
Күп нәрсәгә кагылыр:
Былтыр басуда калган
Машиналар табылыр.

Кышкы ремонтсыз калып,
Тракторлар еларлар...
Безнең башка сугарга
Кояш йодрык йомарлар...

Кыш бабай, китмә әле,
Безне хур итмә әле.
Син дә, яз, бик ашыкма,
Тиз килеп житмә әле!

Характеристика

Бер заводның директорын кинәт
Күчерәләр бүтән бер заводка.
Шунда килгәч күрә берәүне ул
Һәм аптырап кала беравыкка:
Күр син аны. Нинди очрашу бу!
Тагын мина килеп элэккән...
Искә төшә үзе язган кәгазь:
«...Өлеш ала килде бүләктән.
Җыелышларда чыгыш ясый иде.
Күндәм иде... Хәмер капмады...»
Искә төште үзе язганнары,
Күңеленнән кат-кат ятлады.

Һәм шунда ул тагын уйга калды...
Тумый калмас фикер, туар ул:
Инде моннан шул ук исерек башны
Нинди кәгазь язып куар ул?

Ялгыш юл

Кара төндә колхоз болыныннан
Печән урлап кайта бер абзый.
Чынын гына әйтсәк, хезмәт көнен
Аз эшләүче таза-көр абзый.

Туры килә шулай: председатель
Аны үзе тотып ала бит,
Ялгыш юлга, иптәш, баскансың, дип,
Элеп алып селкеп сала бит.

Абзый танмый:— Әйе, ялгыш юл шул,
Уйламыйча юләр булганмын...
Эләкмичә бәлки калыр идем,
Киткән булсам бүтән юлдан мин?!

Үземне күрдем төштә

Шундый сәер бер хәл булды:
Үземне күрдем төштә.
Бер дә сонгармыйча килеп
Утырам, имеш, эштә.

Махмырдан башым авыртмый,
Зарлану юк кәефтән.
Сонгы савыт коньягымны
Алып атам сәефтән.

Чакыртам хезмәткәрләрне
Һәм елмаеп сөйләшәм,—
Имеш, алар мине түгел,
Мин аларны көйләшәм.

Килүчеләр рәхим итсен —
Кабинетны бикләмим.
Жыелышта хәтта тәнкыйтьне
Кысмыйм, имеш, чикләмим.

Кем бу? дип көзгегә карыйм,
Баш — минеке. Димәк, мин.
Үз-үземә ышанмыйча
Сикереп торам кинәт мин.

...Покларга ягудан куркам,
Күз алдымда һаман төш.
Ятсам күз йомасым килми,
Кермәсен дип яман төш.

Җепсез йомгак

Кайбер рецензияләргә пародия

Төрле кеше төрлечә
Караш әйтте китапка.
Мин исә йомгак фикер
Әйтмәк булам бу хакта.

Повесть түгел, роман бу!
Чөнки күләм: өч йөз бит.
Бик көчле булмаса да,
Әйтмәс идем көчсез дип.

Кимчелекләр нәрсәдә?
Алар күпме, азмы соң?
Әйдә күздән кичерик
Персонажлар язмышын.

Гайшә кызыл карашлы,
Фәрит кара эчлерәк —
Психологизмыннан
Алогизмы көчлерәк.

Гайшә купшы киемле,
Ә Фәритнең — модасыз.

Гайшә кодагый булгач,
Фәрит нигә кодасыз?

Гайшә төнгә су белән
Чайкап ята тамагын.
Ә Фәритнең көндез дә
Бар белгәне самогон.

Фәрит тәнкыйтьтән курка,
Ә Гайшә куркак түгел.
Димәк, бердәмлек җитми.
Карашлар уртак түгел.

Ситуация шундый —
Ни ялган бу, ни хак бу.
Кыскасы, укымасаң
Үкенмәслек китап бу.

Шундый совет семьясын
Кем үрнәк итәр икән?..
Китап ун мең тиражлы...
Сатылып бетәр микән?

Аяктан екты

Фельетон

Ана дуңгыз унбиш бала тапты.
Инде хәзер кичме-көндезме
Бөтен ферма шул ананы карый,
Үрнәк санап шушы дуңгызны.

Тактасына «Рекордчыбыз!» диеп
Шул ук көнне язып куелды.
Абзарына ун тагарак белән
Унлап төрле азык куелды.

Алларыннан ризык өзелмәсен,
Витаминнар булсын мул! диләр —
Колхозның ул чөнки бердәнбере,
Байрагыбыз безнең шул! диләр.

Шелтә ала мөдир — көн дә әгәр
Асларына үлән салмаса.
Тастымаллар белән күтәрәләр
Күп ашагач тора алмаса.

Торды исә — фельдшер килә чабып:
Өзлегерсең, тизрәк ята күр!
Газетлардан килеп китте инде
Ким дигәндә йөзләп фотокор.

Бүлмәсендә аның дежур тора:
Чебен кунса — чебен ку, дежур.
Пычранамы, пычранмыймы дунгыз,
Син сабынлап аны ю, дежур.

Клуб әйтә: бала имезгәндә
Кубыз яки курай уйныйкмы?
Монтер сорый: көйләп йоклатырга
Микрофон да, мәйтәм, куймыйкмы?

Әйтерсең лә жирнең кендеге ул,
Шуны гына якын күрәләр.
Ә бүтәннәр ничек житте шулай
Үзләренчә яши бирәләр.

Уйлар уртак:— Бергә якын килик!
Тагын ничек, тагын кай яктан?

...«Үрнәк дунгыз» тиздән кысыр калып
Бөтенесен екты аяктан.

Бу колхозны мин бик яхшы беләм,
Ә башлыгы аның — Нургали.
Бу — үтелгән этап түгел әле,
Мондый хәлләр әле булгалый.

Камил Мостафин

ЭПИГРАММАЛАР

●

Ренат Харисовка

Башкаларга өстән генә карый-карый,
Язасың да, сызасың да, үсәсең дә.
Болытка да үрелеп була икән, жаный,
Басып торсаң Дәрдемәндләр жилкәсенә.

●

Равил Фәйзуллинга

Дан — авыр йөк. «Мәрмәр» ташы — олы, ай-һай,
Аягына төшерә күрмә аны, малай!

ПАРОДИЯЛӘР

Утлы шигырь

«Урамга чәчрәдем
шырпы кабыннан...»
Р. Мингалимов.
«Кирәк идең».

Кем шәһәрдә туган,
Кем — авылда,
Һәм тугач та дөрләп кабынган.
Соңгысы мин булам,
Ышанығыз —
Мин бит чыктым шырпы кабыннан!

Фотогеничный ишәк

«Ишәк тыныч. Бакырмый да,
Кузгалмый да... тора.
Фотогеничный төс аңарда...
...Бик акыллы, борынгы мал ишәк,
Көлеп искә алма ишәкне!»

Рәдиф Гатауллин.
«Ишәккә бер... мактау сүзе».

Ишәккә сез сүз әйтмәгез,—
Зиһене таралган чагы.
Ишәккә кул күтәрмәгез,—
Йоны каралган чагы.

Фотогеничный ишәкнең
Рәсемнәре — өстәлдә.
Мин Хәйям поэзиясенә
Шигырь телим өстәргә!

Ишәк бик акыллы хайван,
Аннан көлеп йөрсәк тә.
Шулай да, ник яздым икән
Мактау сүзе ишәккә?!

ПЬЕСАЛАРГА КОНКУРС

Үзешчән халык театрлары һәм драма коллективлары өчен югары сыйфатлы сәхнә әсәрләре булдыру максаты белән, шушы елның февраль аенда бер пәрдәлек пьесаларга бөтенсоюз конкурсы игълан ителде.

СССР Культура министрлыгы һәм СССР язучылар союзы тарафыннан оештырылган бу конкурска теләгән барлык драматурглар һәм үзешчән авторлар катнаша ала.

Конкурска монарчы матбугатта басылмаган һәм беркайда да куелмаган оригиналь әсәрләр кабул ителә.

СССР халыклары телләрендә ижат ителгән пьесалар, рус теленә сүзгә-сүз тәрҗемә ителеп, авторларның тору урыннары буенча союздаш республикаларның Культура министрлыкларына жибәрелергә тиеш.

Хәзерге заманның актуаль мәсьәләләренә багышланган иң яхшы пьесаларга түбәндәге премияләр бирелачәк:

бер беренче премия — 1000 сум;
ике икенче премия — 700 әр сум;
өч өченче премия — 500 әр сум.

Монардан тыш, уңай бәя алган сәхнә әсәрләре 300 сум күләмендәге кызыксындыру премияләре белән бүләкләнәчәк.

ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНЫҢ АЧЫК ЖЫЕЛЫШЫ

28 январьда язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында ачык партия жыелышы булды. Татарстан АССР Министрлар Советының телевидение һәм радио комитеты хезмәткәрләре, китап нәшрияты, газета-журнал редакцияләре һәм китап сәүдәсе вәкилләре катнашында узган бу зур жыелыш матур әдәбиятны пропагандалау мәсьәләләренә багышланган иде.

Башта Татарстан язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы председателе М. Шәймөхәммәтов жыелышта катнашучыларны бюроның юбилей елында башкарган эшләре белән таныштырды. Аннары фикер алышулар башланып китте. Фикер алышуларда үннан артык кеше катнашты (А. Гыйниятуллина, Г. Бакиров, З. Нури, Г. Ахунов, С. Хәсәнов, Р. Ишморатова, М. Рафиков, М. Мазунов, Р. Мингалимов, Казан телестудиясенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясенең баш редакторы Ә. Сафиуллина, Таткниготорг директоры урынбасары Н. Хәмиди, радионың әдәби-драматик тапшырулар редакциясенең Р. Ширияздановһ. б.). Алар әдәбиятны пропагандалау белән бәйле күп кенә мөһим мәсьәләләргә тукталдылар, бу эшне тагын да яхшырту юнәлешендә конкрет чаралар һәм тәкъдимнәр әйттеләр.

ИЖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучылар союзы каршындагы проза секциясенең январь ахырларында уздырылган утырышы Рәфкать Кәрамиев ижатын тикшерүгә багышланган иде. Яшь прозаикның хикәя-повестьлары буенча фикер алышуларда Г. Әпсәләмов, Г. Минский, Л. Ихсанова, С. Сабиров, Ш. Рәкыйпов, Г. Мөхәммәтшин, Б. Камалов, С. Хәсәнов, Р. Батуллиннар катнашты. Алар Р. Кәрамиев әсәрләрендәге уңай һәм кимчелекле якларга тукталдылар, авторга әсәрләрен тагын да камилләштерү юнәлешендә файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

28 январьда Язучылар союзы каршындагы драматурглар секциясенең отчет-сайлау жыелышы уздырылды. Анда секциянең бер еллык эше турында Риза Ишморат доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуларда А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Х. Гобәйдуллин һәм башкалар катнашты.

Утырыш секция бюросының яңа составын сайлады (Р. Ишморат, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев). Аяз Гыйләҗев драматурглар секциясенең председателе итеп билгеләнде.

ЯҢАЛЫКЛАР КИЧӘСЕ

ВЛКСМ өлкә комитеты каршындагы ижади яшьләр берләшмәсенең чираттагы кичәсе шушы елның 15 февралендә уздырылды. Бу көнне Актерлар йортына килүчеләр яшь жырчылар һәм яшь артистлар белән очраштылар, шигырьләр тыңладылар, әдәбият-сәнгать дөньясындагы яңалыклар белән таныштылар.

Кичәне шагыйрьләр ачып жибәрде. Яшь шагыйрьләрдән Ә. Рәшитов, Т. Камалиев, Ш. Маннапов, Р. Әхмәтжанов, Ф. Сафин, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин һәм М. Галиев үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар. Филармониянең яшь жырчылары К. Хәйретдинова һәм Р. Ибраһимова башкарган жырларны, шулай ук Н. К. Крупская исемендәге Ленинград дәүләт культура институтының Казан филиалы студентлары башкарган этюдларны тамашачылар яратып каршы алды. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары «Сүнгән йолдызлар» һәм «Әбүгалисина» спек-

такльләреннән аерым өзекләр күрсәттеләр. Кичә Куйбышев исемендәге химия заводы клубының «Саз» ансамбле чыгышы белән тәмамланды.

Ахырдан В. И. Ленинның 100, Татарстанның 50 еллык юбилейлары уңае белән оештырылган республика смотрында җиңеп чыккан артистларга ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм өлкә комитетының Мактау грамоталары тапшырылды.

БЕР ШИГЫРЬНЕҢ ТАРИХЫ

Әдәби әсәрләрне төрле язмыш көтә. Бер ишеләре басылып чыгалар да онытылалар. Икенчеләре исә баштан ук укучылар күңелен биләп ала, елдан-ел киңрәк тарала, зуррак популярлык казана бара. Яшь шагыйрь Гәрәй Рәхимнең «Әниләр зары» исемле мәгълүм шигыре шундый бәхетле язмышка очрар, күрәсең.

Авторның бу шигыре беренче мәртәбә 1965 елда «Татарстан яшьләре» газетасында басылган иде. Аннан Г. Рәхим аны үзенең «Вәгъдә» исемле җыентыгына кертә.

1969 елда Г. Рәхимне Мәскәүгә яшь язучыларның бөтенсоюз киңәшмәсенә чакыралар. Ул күренекле шагыйрь һәм прозаик Владимир Солоухин җитәкләгән группага туры килә. Семинар җитәкчесе «Әниләр зары»на һәм авторның башка шигырьләренә югары бәя бирә. Киңәшмә барган көннәрдә әлеге шигырь, Александров тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, «Литературная Россия» газетасында басылып чыга. Тагын бер елдан, республикабыз үзенең ярты гасырлык юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә, тәрҗемәче Владимир Цыбин «Әниләр зары»н «Литературная газета» битләрендә чыгара.

1970 елда Г. Рәхим Горький шәһәренә — тугандаш республикаларның яшь шагыйрьләре фестиваленә бара. Барса, биредә аны тагын бер шатлыклы хәбәр көткән икән: Горький композиторы Михаил Василицкий «Әниләр зары»на матур көй язган. Соңыннан «Вздохи матерей» исемле ул көй, үзәк телевидение аша, киң илебезнең бөтен почмакларына яңгырый.

Мәгълүм булганча, башкалабыз Мәскәүдә инглиз, немец, поляк телләрендә чыга торган «Советская литература» исемле журнал бар. Шул журналның узган елгы бер санында Гәрәй Рәхимнең портреты һәм «Әниләр зары» исемле әлеге шигыре урнаштырылган. Шагыйрь М. Львов үзенең кереш мәкаләсендә укучыларны татар шагыйре Гәрәй Рәхим белән дә таныштырып үтә.

МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

13 февральдә Ташкент шәһәренең Мәгариф йортында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, атаклы шагыйребез Муса Җәлилнең тууына 65 ел тулуга багышланган кичә булып узды. М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән Исхак Зәбиров чыкты.

Тантаналы кичәдә шагыйрьнең сугышчан көрәштәше, «Высотстрой» трестының коммунистик хезмәт бригадасы бригадиры Г. Фәхретдинов катнашты һәм герой шагыйрь турында истәлекләр сөйләде. Ахырдан Ю. Ахунбабаев исемендәге культура сарае үзешчәннәре зур концерт бирде.

РОМАН ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Нурихан Фәттахның «Казан утлары» журналында басылган «Әтил суы ака торур» исемле тарихи романы әдәбият сөючеләр арасында зур кызыксыну уятты. Шуны искә алып, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе әлеге роман буенча фикер алышу уздырды. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында узган бу сөйләшүдә өлкән әдипләребездән Н. Исәнбәт һәм Ш. Маннур, скульптор Б. Урманче, филология фәннәре кандидатлары Ш. Абилов, Ф. Урманчеев, Ф. Мусин, тарих фәннәре кандидатлары С. Алишев һәм Р. Фәхретдиновлар роман турындагы фикерләре белән уртаклаштылар. Кичәдә автор үзе дә чыгыш ясады. Ул әсәрнең язылу тарихына тукталды, фикер алышуда катнашучыларның һәм укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

ҮЗӘК НӘШРИЯТЛАРДА

Мәскәүдәге үзәк нәшриятлар 1971 елда да татар язучыларының байтак әсәрләрен рус теленда чыгарырга әзерләнәләр.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Молодая гвардия» нәшрияты планына, мәсәлән, урта буын прозаикларыбыздан Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» исемле романы кертелгән. Нәшрият бу романны 100 000 данә тираж белән чыгарырга уйлый.

* * *

«Новый мир» журналының 1971 елгы 1 санында Ренат Суфиевның (әдәби псевдонимы Роман Солнцев) «По ту и по эту сторону» исемле повесте басылып чыкты.

Повестьта безнең Татарстан туфрагында барган вакыйгалар турында сөйләнә. Геройларның да күпчелеге — татар кешеләре.

ГАШЕК ЭЗЕННӘН

Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы укытучысы С. Антонов инде байтак еллар күренекле чех язучысы Ярослав Гашекның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү белән шөгыльләнә. Күптән түгел ул Татарстан дәүләт архивында Гашекның Бөгелмәдәге эшчәнлегенә бәйләнешле яңа документлар тапты. Алар арасында язучының үз кулы белән тутырылган анкета кәгазе, хәрби комендант ярдәмчесе Гашекның ярлы крестьяннарга ярдәм күрсәтү, байларның милекләрен конфискацияләү турындагы боерыклары бар.

Татарстан дәүләт архивыннан табылган бу яңа документлар хакында «Правда» газетасында да (1971 ел, 16 февраль) язылды.

ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тамашачыларга күп кенә яңа спектакльләр күрсәтте. Шуларның кайберләре белән журнал укучыларны да таныштырып узабыз.

Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» әсәре буенча эшләнгән спектакль халыкка январь ахырларында күрсәтелә башлады. Аны сәхнәгә театрның баш режиссеры Марсель Сәлимжанов куйган, декорацияләрен Татарстанның халык художнигы Мәэмүн Сутюшев эшләгән. Әсәрдәге төп рольләрне театрның яшь артистлары башкара.

Тамашачылар яңа спектакльне гаять җылы каршылады.

* * *

Март башларында сәхнәгә Туфан Миңнуллинның «Ир-егетләр» исемле пьесасы чыгарылды.

Бу пьесаны да Академия театры сәхнәсенә Марсель Сәлимжанов куйды.

* * *

Драматург Аяз Гыйләжевнең «Энҗерменгер» исемле пьесасы бүгенге көнге яшьләр, алар арасындагы саф мәхәббәт хисләре турында. Әсәрне сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт куйды.

ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Татарстан китап нәшрияты матур әдәбият әсәрләрен укучылар арасында пропагандалау буенча зур эш башкара. Нәшрият хезмәткәрләре еш кына колхозларда, промышленность предприятиеләрендә, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында булалар, язучылар белән берлектә, конференцияләр, әдәби кичәләр уздыралар. Күптән түгел шундый кичәләрнең берсе Биектау районының Каменка авылы янындагы госпитальдә булып узды. Госпитальдәге дәвалануучылар һәм медицина хезмәткәрләре алдында язучы Ш. Рәкыйпов, шагыйрьләрдән Р. Гатауллин, Г. Рәхим, Р. Вәлиева һәм М. Зарецкийлар чыгыш ясады. Алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, якын көннәрдә нәшрияттә басылып чыгачак китаплар турында сөйләделәр.

В. И. КУДЕЛЬКИНГА 60 ЯШЬ

Февраль урталарында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Виктор Иванович Куделькинга 60 яшь тулды. Шул уңай белән Казан шәһәренең Рәссамнар йортында авторның шәхси күргәзмәсе ачылды һәм юбилей кичәсе үткәрелде.

Сынлы сәнгатебезне үстерүдәге зур хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, РСФСР Сәнгать фондының Татарстан бүлеге рәсамы В. И. Куделькинга Татарстанның халык художнигы дигән мактаулы исем бирелде.

ЖИҢҮЧЕЛӘРГӘ БҮЛӘКЛӘР

Татарстан журналистлар союзы, республиканың ДОСААФ комитеты белән берлектә, телевидение һәм радио буенча хәрби-патриотик теманы яктыртуга конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел шул конкурска йомгак ясалды.

Журналистлардан Д. Шәрәфетдинов, М. Рафиков, М. Миншин, Н. Гиндуллин, Н. Булатов һәм И. Сирматовларга, хәрби темаларга багышланган кызыклы тапшырулары өчен, акчалата премияләр бирелде.

Район газеталары арасында барган ярышта «Дружба» (Октябрь районы), «Коммунизм таңы» (Минзәлә районы) һәм «Зеленодольская правда» газеталары жиңеп чыкты. Аларның һәр кайсы өченче дәрәҗә премия белән бүләкләнде.

ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР СЕМИНАРЫ

Февраль башында Татарстан журналистлар союзы идарәсе район газеталары тәрҗемәчеләре өчен ун көнлек семинар уздырды. Аны үткәрүдә Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы, педагогия институтының тарих-филология факультеты, «Татарстан коммунисты» журналы, «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» газеталары, Татарстан китап нәшрияты катнашты.

Семинарда катнашучылар рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүнең төп принциплары турында лекцияләр циклы тыңладылар, республика газета-журналларында, шулай ук Татарстан китап нәшриятында практика үттеләр.

ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт шәһәренең Техника йортында зур әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде. Аларның берсе халкыбызның сөекле композиторы С. Сәйдәшевкә, икенчесе шагыйрь Һ. Такташка багышланган иде. Кичәләрнең тантаналы өлешендә партиянең Әлмәт шәһәр комитеты вәкилләре, язучылар һәм шагыйрьләр, театр коллективы членнары чыгыш ясады, соңыннан Әлмәт шәһәренең үзешчән сәнгать коллективлары, нефтьчеләрнең районара симфоник оркестры, музыка училищесы укучылары концерты булды. Һәр ике кичә халык ихтирамын казанырлык югары дәрәҗәдә үтте.

* * *

10 январьда Әлмәт язучыларыннан Р. Фәйзуллин, С. Сөләйманова, С. Кальметов иптәшләр ВЛКСМның Баулы райкомы чакыруы буенча район комсомол активы белән очраштылар. Әдипләр авыл һәм нефть идарәләренең комсомол оешмалары секретарьләре алдында чыгыш ясадылар, үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

Бүлекнең ел башында үткән утырышларыннан берсе ижат мәсьәләләре турында сөйләшүгә багышланган иде. РСФСР язучылар союзы идарәсе пленумы һәм яңа елда бүлек алдында торган бурычлар турында Р. Фәйзуллин сөйләде. Авыл хуҗалыгы турында актив язучылар өчен СССР язучылар союзы оештырган бер айлык курста булып кайткан Р. Төхфәтуллин Мәскәүдә уку дәверендә туган тәэсирләре белән уртаклашты.

Шул ук утырышта яшь язучы Ф. Гыйльметдиновның хикәяләре дә тикшерелде. Язучылар яшь авторның хикәяләренә нигездә уңай бәя бирделәр.

* * *

Бүлек каршында оештырылган әдәбият түгәрәгенең эше торган саен жанлана бара. Кайбер утырышларда яшь авторларның саны берничә дистәгә житә. Соңгы утырыш «Идел» альманахы өчен әсәрләр сайлауга багышланды. Чөнки «Идел» альманахы редколлегиясе киләсе саннарның берсен тулысы белән нефть районнарында яшәүче яшь авторларга багышларга уйлый.

* * *

Лениногорск әдәбият берләшмәсе шәһәрнең Калинин исемендәге Культура сараенда «Без киләбез жыр белән» дигән темага зур әдәби-музыкаль кичә уздырды.

Кичәне берләшмәнең житәкчесе Р. Вәлиуллин ачты. Бер-бер артлы чыгыш ясаган язучылар һәм шагыйрьләрдән Ш. Бикчурин, А. Хәсәнов, Ж. Рәхимов, Р. Байтимиров, Ш. Таһирова, Ф. Нуруллин, Әлмәттән кунак булып килгән С. Кальметов, музыка училищесы укытучылары Ф. Мөсәллимова, Л. Шиһапова, Ф. Йосыпов һ. б. юбилейлар елындагы ижатлары турында отчет ясадылар, яңа романнардан өзекләр, яңа хикәяләр, шигырьләр укыдылар, яңа жырлар башкардылар.

Шундый ук кичә районның «Дружба» колхозында да уздырылды.

* * *

Әлмәт бүлегенең чираттагы утырышы районның «Знамя труда» газетасы редакторы В. И. Лариннын ижатын тикшерүгә багышланган иде. Авторның 20 дән артык хикәясе укып тикшерелде. Шулар арасыннан «Тимерче», «Гудок», «Поезд фронтка ашыга иде», «Воронок» хикәяләре уңай бәя алды. Әсәрләрен камилләштерү юнәлешендә авторга күп кенә киңәшләр бирелде.

ЧАЛЛЫ ӘДӘБИ-ИЖАТ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

Чаллы әдәби-ижат берләшмәсе членнары автозавод төзүче яшьләр белән әледән-әле очрашулар уздыралар. Шундый очрашуларның берсе «Камгэсэнергострой»ның 6/12 тулай торагында үтте. Шигырь сөючеләр алдында яшь шагыйрьләр М. Әгъләмов, Р. Вәлиев, М. Газизов, Ш. Маннапов иптәшләр чыгыш ясады.

* * *

Кама автогигантын төзүчеләр өчен яңа ел тагын бер шатлык алып килде. «Камгэсэнергострой» төзелеш идарәсе каршындагы газетаның татарчасы да чыга башлады. Ул «Кама таннары» дип атала. Газета битләрендә, удар төзелеш процессын яктырткан мәкаләләр белән бергә, Чаллы әдәби-ижат берләшмәсе членнарының яңа хикәя-шигырьләре, әдәби парчалары басылып килә.

* * *

Чаллы халык театры быелгы сезонда «Шәмсекамәр» һәм «Рәйхан» исемле әсәрләр буенча эшләнгән спектакльләр күрсәтте. Жирле артистларның ижади хезмәтен караучылар саны арта бара.

Автозавод һәм яңа шәһәр төзергә килгән яшьләр арасыннан үзешчән артист булып театр коллективына кушылып китүчеләр дә шактый инде.

* * *

Чаллыда Татарстан язучылары союзы членнары Рәшит Гәрәй, Рәстәм Мингалимов иптәшләр булып китте. Аларны шәһәрнең Мулланур Вахитов исемендәге мәктәп укучылары чакырган иде. Шагыйрьләр Һ. Такташның 70 еллык бәйрәмендә катнаштылар, авыл эшчәннәре һәм төзүчеләр белән очраштылар.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ҖЫРЛАРГА ҺӘМ ХОР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ӘСӘРЛӘРГӘ КОНКУРС

РСФСР Культура министрлыгы, Бөтенроссия хор җәмгыяте, РСФСР композиторлар союзы һәм РСФСР язучылар союзы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә багышланган иң яхшы җырларга һәм хор өчен язылган әсәрләргә конкурс игълан иттеләр.

Конкурста халык хорлары, академик хор коллективлары һәм вокаль ансамбльләр башкару өчен язылган җырлар кабул ителә.

Конкурста РСФСРның барлык композиторлары һәм шагыйрьләре катнаша ала.

Конкурска беркайда да басылмаган һәм уйналмаган яңа көйләр генә кабул ителә. Ә җыр текстларының яңаларын да, инде басылып чыкканнарын да файдаланырга мөмкин. Авторлар көйләрнең текстлаштырылган клавирларын ике данә итеп җибәрергә тиешләр. Җыр текстлары шулай ук ике данә һәм машинкада бастырылып җибәрелергә тиеш. Әгәр әсәр хор һәм оркестр белән башкару өчен язылган булса, бер данә партитура да таләп ителә.

Барлык әсәрләр дә аерым конвертка салынган девиз белән җибәрелергә тиеш. Девизда авторларның исем һәм фамилияләре, эш урыннары, адреслары күрсәтелү таләп ителә. Конкурска дигән материалларны ТАССР хор җәмгыяте идарәсенә (Казан, Бауман урамы, 60 йорт) җибәрергә кирәк.

Конкурска әсәрләр кабул итүнең соңгы срогы — 1971 елның 30 мае.

Конкурс ике тур белән үткәрелә: беренче тур Казанда, икенче тур Мәскәүдә уздырылачак. Конкурс йомгаклары «Советская Россия» һәм «Советская культура» газеталарында игълан ителәчәк.

Конкурста җиңеп чыккан иптәшләргә түбәндәге премияләр биреләчәк:

а) **җырлар өчен:**
беренче премия — 500 сум,
икенче премия (ике данә) — 350 шәр сум,
өченче премия (өч данә) — 250 шәр сум.

б) **халык хорлары өчен язылган әсәрләргә:**
беренче премия — 500 сум,
икенче премия (ике данә) — 350 шәр сум,
өченче премия (өч данә) — 250 шәр сум.

в) **академик хорлар өчен язылган әсәрләргә:**
беренче премия — 500 сум,
икенче премия (ике данә) — 350 шәр сум,
өченче премия (өч данә) — 250 шәр сум.

г) **кече вокаль ансамбльләр өчен язылган әсәрләргә:**
беренче премия — 500 сум,
икенче премия (ике данә) — 350 шәр сум,
өченче премия (өч данә) — 250 шәр сум.

Дүртенче һәм бишенче урыннарны алган әсәрләр диплом белән бүләкләнәчәк.

Бүләкләнгән әсәрләрнең барысын да дәүләт заказы буенча Культура министрлыгы сатып ала һәм алар башкару өчен тәкъдим ителәчәк.

Беренче тур жюрие тарафыннан тәкъдим ителмәгән әсәрләр икенче турга кабул ителми.

Конкурска килгән әсәрләр рецензияләнми һәм авторларына кире кайтарылмый.

Хөрмәтле иптәш!

Шушы елның икенче ярты сы өчен «Казан утлары» журналына язылу дәвам итә. Алдагы айларда безнең журналны системалы рәвештә алып, укып барасың килсә, аңа вакытында язылып куярга онытма!

«Казан утлары»на Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Аның өчен журналның газета-журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән теркәлгән икәнлеген әйтергә кирәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210